Милли яшәешебезнең бер чагылышы булган Сабантуй бәйрәмен уздыру төбәк халкын берләштерүче көч булып тора: ат чабышлары, татарча көрәш, капчык сугыш, чүлмәк вату һәм бәйрәм программасын татар телендә алып бару безнең дә күңелләрне күтәреп җибәрде.

Бәрәңге урамнарында (шулай ук башка татар авылларында да) замана яңалыклары күзгә нык бәрелеп тора, яңача, милли декоратив-архитектура стилендәге йортлар фәкать бу төбәкнең үзенчәлекләре нигезендә төзелгән, алар Бәрәңге ягына гына хас. Яңа төзелешләре белән Бәрәңге татарның Пенза өлкәсендәге данлы Урта Әләзән авылын да хәтерләтә. Урам-кибетләрнең татар исемнәре белән аталуы авылның милли йөзен сыйфатлый.

Бәрәңге татарның милли ризыкларыннан казылыкны яхшы әзерләүче осталары белән дә мәшһүр.

Төбәк халкы һәртөрле эшләргә осталык күрсәтү белән бергә, үз ягының тарихи үткәнен дә истә тотып яши. Экспедиция барышында без аерым кешеләр кулларында сакланган, XVIII–XIX гасырларда Бәрәңге төбәгендә күчерелгән дистәләрчә кулъязма китаплар, документлар да тупладык. Алар әле ныклап өйрәнүне таләп итә.

## Халык тарихы зиратлардан башлана

Ташбилге истәлекләре татар халкының XIII гасыр ахырыннан башлап XXI гасырга кергәндә дә сакланып килә торган олы бер мәдәни-этнографик күренеш буларак яшәп килә.

Татар ташбилгеләре татарлар яшәгән зур киңлекләрдә мәгълүм. Варшава шәһәреннән алып Красноярск крае һәм Иркутск өлкәсенә кадәр сузылган арада анықланган, сакланган татар зиратлары һәм алардагы ташбилгеләр турында матбугатта чыккан хәбәрләр бар. Шулардан берсе – Бәрәңге төбәге татар зиратлары турында күзәтү 1990 нчы елларда Татарстан матбугатында басылган иде инде.

Экспедиция барышында 8 татар авылындагы 9 зиратны өйрәндек. Алардагы безнең өчен кызыклы саналган 63 ташның тексты сайлап алынды. Ташларның күбесенең 2, 3, 4 нче якларында да гарәби язулы текстлар бар. Мондый төр истәлекләрнең саны 37 булды.

Барысы 63 таштан 100 текст өйрәнелеп, кыр дәфтәренә күчереп алынды. Фәнни хезмәткәр Салават Галимов аларны фотога төшереп барды.

Ташлардагы текстларның күпчелеге, алда әйтелгәнчә, гарәп графикасында язылган. Бик сирәк кенә кирилл хәрефләре белән язылган ташбилгеләр дә очрап, күчереп алынды (аларны борынгы фамилия яки шигъри текст буларак исәпкә алдык). Ташларда күп кенә санда Коръән аятьләре бар.

Ташбилгеләрнең ян-якларында (ике кырыенда) еш кына гарәпчә һәм, сирәгрәк очракта, традицион канатлы юллар языла:

Күрермен дөнйаны вәйран бары,
Һәмишә бакый ирмәс йук карары!

Ташлардагы язмалар гарәпнең сөлес һәм тәгъликъ ысулларында эшләнгәннәр. Язмаларның күпчелеге уеп һәм, сирәгрәк очракта күпертеп, башкарылганнар.

Тимпаннарда башламалар төрле рәвештә башлана:

ارئ الدنيا حربا بعتبارئ
خرانا فلا يبقئ مدما بالقرار[ي]

Татарчага тәрҗемәсе:

Күрермен дөнйаны вәйран барый
Һәмишә бакый ирмәс йук карарый (1912 ел).

«Килүб кабримә зийарәт идән инсан...» (1914 ел).

قال النبئ تعالئ كل نفس ذائقة الموت

Пәйгамбәремез әйтте: һәрбер җан иясе үлем ширбәтен татыр (1887 ел).

الحكم الله تعالئ الكبير

Бөек Алланың иң югары хөкеменә (1890 ел).

انا الله و انا اليه راجعون

Һәркем Аллаһ каршына кайтучы (1921 ел).

Ташбилгеләрнең өске өлешләре ярым түгәрәк рәвешендә, сирәк кенә очракта, бюстсыман итеп, түгәрәк чикләнгән урында тар гына иңсәләр калдырылып эшләнгән.

Йөзлекләрдә язу юллары турыпочмаклы кысалар эчендә башкарылганнар. Ике язу юлы арасындагы интервал 2 см киңлектәге сызылган яки күпертеп эшләнгән юлларны тәшкил итә. Тимпаннарда

башламнар стильләштереп, түгәрәкләрнең эчке кысалары рәвешендә эшләнгәннәр. Ташбилгенең түбәсендә үк 6–7 см диаметрлы кечкенә яки 2–3 см тирәнлектә зуррак су җыелу чокырлары ясалган. Бу – бик борынгы мифологик традицияләрнең саклану билгесе.

Календарь күрсәткечләре һиҗри һәм руми еллар белән янәшә куелып бирелә, сирәк кенә мөселман кояш елы айлары исемнәре очрый (мәсәлән: сәвер, хәмәл).

Ташбилгеләр таштан ясалган дүртпочмаклы нигезгә беркетелгәннәр һәм вертикаль хәлдә торалар. Ташларның эпитафик текстлары аны эшләүче осталарның үзенчәлекләрен, зәвыкларын чагылдыра. Шул үзенчәлекләргә карап, Бәрәңге поселогындагы зират ташбилгеләре XIX гасырның соңгы чиреге һәм XX гасырның 30 нчы елларына кадәр бер нәселгә караган Әхмәд бине Хафизетдин (1877–1924), Зәйнелгабидин бине Мөхәммәд исемле осталар тарафыннан эшләнгәнлекләре раслана. Кайбер ташларда аларның тамгалары да сакланган.

Ташбилгеләр өчен материал бер таш карьерыннан алынганнар. Аларның эшкәртү осталыгын Бәрәңге төбәгенә Арча ягындагы Ташкичү авылыннан күчкән Насретдин һәм Борһанетдин нәселләре алып килгән, чөнки бу төбәкләрдәге иң борынгы тарихлы ташбилгеләр 1851, 1865, 1866 елларда гына куелган, аннан да алдагы тарихлы истәлекләр күренми. Гарәп язулы ташбилгеләр Бәрәңгедә 1921–1929 елларда да куелалар, иң соңгысы – 1939 елда 70 яшендә вафат булган Хафизҗан Зарифҗан углына куелганы булса кирәк.

Бу уңайдан бер искәрмә ясау мөһим: 1930 һәм 1960 елларда бик күп ташбилгеләрне ватканнар. Шактый күп зират ташларын җимереп, 1960 елларда Бәрәңгенең хәзерге зират капкасының эчке ягына ике әрдәнә итеп өйгәннәр.

1940–1970 еллар арасында ташбилгеләр куелмаганга охшый. Шуннан соңгы дәвердә аларга кириллицада саран гына текстлар язып (исем-фамилия, туган-үлгән еллар, ...дән бүләк) кую башлана. XX гасыр ахырыннан монда да мөселман йолаларына каршы килеп, ташбилгеләргә портретлар эшләтеп кую гамәлгә керә башлый.

Ташбилгеләрне тасвирлаганда, галимнәрне аларның зурлык үлчәмнәре дә кызыксындыра. Монда, барлык ядкярләрнең дә мәгълүматын санап китсәң, озынга китәр, дип, аларның Куянавыл зиратында 1856–1930 еллар арасында эшләнгәннәре хакында гына мәгълүмат китерелә.

| | |
|---|---|
| 1887 ел | 18×38×113 см |
| 1895 ел | 18×30×112 см |
| 1901 ел | 11×31×80 см |
| 1903 ел | 9×35×131 см |
| 1903 ел | 11×32×80 см |
| 1904 ел | 15×30×94 см |
| 1906 ел | 11×31,5×100 см |
| 1906 ел | 11×31×95 см |
| 1914 ел | 9×32×85 см |
| 1916 ел | 10×29×82,5 см |

30 еллык дәвердә ташбилгеләрнең калынлыгы 18 см дан 10 см га кала бара, борынгылары калынрак.

Киңлек ягыннан да ташбилге 7–8 см га тарая. Биеклектә дә 113 тән 82,5 см га калып кыскару күренә.

Димәк, барлык күрсәткечләр дә ташбилгеләрнең кечерәюгә юнәлеш тоткан үзгәрешләрен күрсәтәләр.

Ташбилгеләр хәзер махсус остаханәләрдә эшләнеп, еш кына тимпан урынына ай-йолдыз символлары, сирәк кенә очракта, «Бисмиллаһир-р-рахман әр-рәхим» дигән җөмлә дә күренә. Зиратларны матур чардуганнар бизәп, юлларны тыгызлап торалар.

Бәрәңге төбәге ташбилгеләре арасында бик кыйммәтле мәгълүматлы язмалар саклаганнары да бар. Мәсәлән, Портянур зиратында 1865 елда «хәмәлнең (мартның) 22 сендә 63 яшендә вафат булган мулла Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдьяр әл-Мәмдәли әл-Газани»ның ташбилгесендә аның борынгы шәҗәрәсе бирелә. Анда нәселнең Расмөхәммәд бабасы аркылы Казан ханлыгы бәге Чура Нарыковка барып тоташканлыгы ачыла. Чура Нарыков нәселләре барысы да күренекле суфый ишаннар булганлыгы таштагы шәҗәрә тексты белән раслана. Расмөхәммәд бабаның безгә мәгълүм шәҗәрә текстларында нәселнең бу тармагы юк иде әле.

Икенче бер кыйммәтле мәгълүмат: XVIII гасыр башында Арча ягындагы Курса авылында яшәгән атаклы Мортаза бине Котлыгышның мәдрәсәсендә укып чыккан мәгърифәтче Рәфыйк бине Таиб нәселеннән килгән Борһанетдин белән аның бертуганы – Насретдин нәселенең каберташлары табылу. Бу нәселнең күренекле вәкиле Хафизетдин исә Шиһабетдин Мәрҗани даирәсеннән булган, аның белән хатлар язышып аралашкан зат. Аларның кульязма хәлендә калган күп кенә хезмәтләре булуы, саклануы хакында

Әхмәд бине Хафизетдиннең 1909 елда язып бетергән «Тарихе Бәрәңгеви» әсәрендә хәбәр ителә.

Өченче ташбилге Олы Мәңгәр авылыннан чыккан Куянавыл мулласы Бикчәнтәй углы Фәтхуллага куелган. Ул Куянавылда имам булып, 1887 елда 73 яшендә вафат булган. Олы Мәңгәрдәге шәҗәрә китабында аңа кадәр бабаларының шәҗәрәсе 5–6 буынгача күрсәтелә. Алар арасында Кормаш исемлесе дә бар. Фәтхулла нәселе Кормашев фамилиясен йөрткән. Бу нәселдән Муса Җәлил белән бергә антифашистик көрәштә актив катнашкан каһарман, 1944 елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә беренче булып гильотинода башы кистерелгән Гайнан Нури улы Кормаш чыккан.

**Портянур зиратындагы ташбилгеләр.** Каберлек хәзер авылның урта бер җирендәрәк калган, аны агачлык баскан, ләкин бик куе түгел. Зиратның әйләнәсе киртәләп алынган. Аның урам ягындагы буена җилкапка ясалган. Фани дөнья белән бакыйлыкны аеручы һәм тоташтыручы сызык шушы җилкапкага туры килә.

Ташбилгеләрнең өске, түбә ягына гарәп һәм хәзер инде, еш кына, кирилл алфавитында «Бисмилла әр-рәхман әр-рәхим» кәлимәсе языла. Ләкин бу изге сүзләр кайчакта ташка хата белән төшерелгән. Өске якка, шулай ук абсолют күпчелектә, ярымай символын да төшергәннәр.

Исемнәр бирелешендә татар телендәге яңгырашны дөрес чагылдыру омтылышы бар. Язмалар, рам-кысалар, ай символлары плитәгә уеп төшерелеп, эзләр буенча кара, алтын төсләр белән бизәлү күзгә ташлана.

Текстларда – *улы, углы, кызы, туды, вафат* сүзләре, *хәерле теләк* сүзләре татар телендә бирелә:

Габдрахманова
Гөлсем
Галимьян кызы
24.01.1926 – 19.11.2008

Ситдиков Мөбәрәк
Ситдикъ улы Туды
24.09.1920
Вафат
булды
24.04.2006

Яратабыз
онытмыйбыз
сагынабыз.

Безгә 1991 елда Портянур авылы зиратын тиз генә карап чыгарга туры килгән иде. Шул вакытта без анда Мөхәмммәткәрим Мөхәммәтшәриф улының кабер ташында (1917 елның 15 апрелендә 63 яшендә вафат) XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән атаклы татар суфый шагыйре Һибәтулла Салиховның (1794–1867) «Тәндә җаным» исемле атаклы шигыреннән:

«Тәндә җаным ничә көннәр
Миһман икәндер, белмәдем
Көлли нәфсен заякателдер, белмәдем», –

дигән өзегенә тап булып, аны күчереп алган идек.

Ул вакыттан бирле 20 ел вакыт узган инде, безгә ул ташны кабат күрергә туры килмәде.

Инде Портянур зиратындагы тагын да борынгырак ташъязмаларга игътибар итик.

Көлли нәфсен даикате әл-мәвәте.
Тарих һиҗрия 1281 сәнә маһи зөлкагъдә
нең 5 ндә, тарих румия 1865 сәнә
хәмәл 22 сендә дүшәнбе кич мулла Мөхәммәд-



гали бине мулла Мөхәммәдьяр бине
Мөршид Камил
мулла Хәмид бине мулла Ислам
бине шәйех Ка-
мил вә сахибе Кәрамәт мулла Нурмөхәммәд
бине
Мөршид Камил Ишмөхәммәд баба
бине Мөршид
Камил Расмөхәммәд баба Мәмдәли
Газани
Портянур кариясендә 33 ел имам
улуб
63 яшендә дар бакайа рихләт кыйлды.



Бихөкем Ходай
Дәфен кылынды
1330 нчы йылда
28 нче рәҗәбдә
1913 нче йылда
2 нче июльдә
56 яшендә
Рәхмәте Аллаһе
Тәгалә.



Әл-хөкем Алла әл-Гали әл-Кәбир
сахибәтә һазә әл-кабер зәүҗәтә
мулла Мөхәммәдгали
Бибилатифа бинте мулла Сәгъдетдин
бине мулла Габдерәшид бине Чиркас
бине Җирҗис әл-Болгари әл-Чир-
мешәни [гашт] фи кария-и Портянур
34 сәнә-и . . . . . . . . . дар
. . . . . . . сәнә-и 1283 маһи җөмади
әл ахыри, миладия 1866 сәнә
беренче үктәбердә шинбә көн
мулла мөхәммәдгали.



Әл-хөкем Аллаһ әл-гали әл-кәбир
һиҗри 1308
сәнә сәфәр 6 да милади 1890 сәнә
синтәбер 9
нда, йәкшәнбе көн Мәхүбкамал
бинте дамелла Габделбәдыйг
бине шәйех
Кәбир дамелла Бикмулла бине
Габдерр
әззак Портянурда 23 ел
остазбикә улуб 41–44 ел [чагында?]
. . . . . . . . җан шәриф-
ләрен бакайа интикаль әйләди
талибел-сират.



Ушбу
каберстанда
Әхмәдулла ата-
сы Һадиҗан

Нигъмәтҗан углы
Җәгаль Аллаһ
каберә мөнәвәрә бинур
Һадиҗан Нигъмәтҗан улы вафат
1914 ел, 8 июньдә.

**Бәрәңге авылындагы ташбилгеләр**



Галәмәтдан морадымыз догадыр
бу көн миңа икән
йарин сиңадыр, уйан
буйан бакыб дога көтәр-
мез. Әгәр табылса
сүенешеб китәрмез.
. . . . . . . . . . . . . .



Иннә лилләһи вә иннә иләйһи
раҗигун вә фи
әс-сәнаи әл-каберия миннә
әл-һиҗрә-и ән-нәби галәйһи
әс-сәлам Мөхәммәдфатих
Мөхәммәдйар дар
бакая интикаль кылды.



Вә миннә әл-һиҗрия-и ән-нәбии
бәгъдә фи сәнә 1321 нче
дә рамазан шәрифнең 17
нче йәүмендә Кабил салават
әл-гасыр ушбу
мөгаләк дар дөньядин
фәна вә бивафадин да-
р ганә вә бакая р-
ихләт әйләди.
рәхимһа рәхмәти
вә сәгатә.

Алда китереләчәк «Тарихе Бәрәңгеви» исемле китап язучы, зур укымышлы, кабер ташлары кисеп язучы хаттат, Бәрәңгенең дүртенче мәхәлләсенең беренче имамы Әхмәд бине

Хафизетдин каберенә куелган. Ташны эшләүче – аның нәселеннән Зәйнелгабидин Мөхәммәд улы исемле кеше. Бу останың Әхмәд хәзрәт күмелгән зиратта һәм Бәрәңге поселогының хәзер күмелә торган зиратында имзалы ташбилгеләре сакланган. Зәйнелгабидиннең язмышы 1930 елларда югала.

*Дүрткырлы ташның беренче ягында:*

Бәрәңге
4 нче мәхәлләдә беренче
имамы, дамелла
мөдәррис Әхмәд
ибне әш-шәйехел-мөдәррис дамелла
Хафизетдин бине Насрый
вәляди вә Казанда мулла Габделгалләм
бине Салих вә Бохарада дамелла
Сабир-Сиддыйк әс-Сәрдәви
вә дамелла Мөхәммәд-Гауваз ибне
мулла Ибраһим әл-Хәҗәнди
вә гайре әхәде голүмә
бәгъдендә кайту берлә имам-
хатиб вә мөдәррис улды

*Ташның икенче ягында:*

19 сәнә
иҗтиһад илә
укыту вә муафыйк шәрегъ
вәгазь әйтү вә мөтәгаддид
рисаляләр язу илән
иштигъмаль итди
ахыр гомерендә инсани
Зөлкарнайингә
[йаңы үдәнә җәгальнәң]
хәлифә-и фи әр-рази
илх (сүзлектә бар) әйтә кәримә сүн
укыды.

*Ташның өченче ягында:*

1924 нче
руми сәнә
1342 нче
Һиҗрийә

нуйәбер 20 дә
рабигыль – әла-
хры 15 ндә
пәнҗешәмбе
җан тәслим
җомга көн
вафат кыйлды.

*Дүртенче ягында:*

йазгучы Зәйнелгаб.
кяфи билмәви горрәи вә ифтихар
күнә мәнүб . . . Бохара.

**Куянавылдагы ташбилге**



Калә Аллаһ Тәгаля-и, көлли нәфсен
даикате әлмәвәте, руми 1887
сәнә, июль 22 сендә, һижри 1304
сәнә зөлкагъдә 13 ндә
галим, гамил, хаҗел-хәрамин мулла
Фәтхулла бине Бикчәнтәй Куян
кариясендә 50 сәнә имам улуб
73 яшендә, чәһәршәнбә көн
дар бакайа рихләт әйләди
талиб Аллаһ сирраһ җәгалә
Әл-җәннәтә васыйла.





Килүб кабремә
зиарат иткән инсан
Кыйлың бер «Фатиха»
рухыма ихсан.
Мең яшәсәң дә
Җиһанда бер заман,
ушбу каршында –
кабердән юк
аман.

*Габделхәй Фазулла углы Кормашев ташбилгесе. 1914 ел, 17 июльдә 63 яшендә вафат.*

Галимҗан Габденнасыйр
углы Туганайыф каберенә куелган.

*Ташбилгенең кырыенда:*

Безә Коръән укуб багышлайасыз
Гомер тиз үтәрүн сагышлайасыз,
дигән сүзләр язылган.

Биредә ташбилгеләрдәге язуларның бер өлеше генә китерелде. Аларны хронология буенча тәртипкә тезеп, анализлап карыйк.

Бәрәңге төбәгендә ташбилгеләр кую традициясе 1865 елдан башлана. Бу еллардагы күп татар авылларында кабер өсләренә ташбилгеләр яздырып кую традициясе яңарып китә.

Эш шунда ки, Русиядә XIX йөз уртасыннан соң гомуми икътисади җанлану сизелә. Халык кулына азмы-күпме акча керә, игенче артык продуктларын ярминкәләргә илтеп сата башлый. Татарлар сәүдә өчен Көнбатыш Себер, Казакъстан, Урта Азия якларына барып, сәүдә эшләрен җанландыралар.

Ташбилгеләргә килгәндә, алар өчен шактый акча тотылган. Бер гади генә каллиграфик таш язу бер арба сугылмаган солы көлтәсенә бәрабәр хакка торган.

Бу уңайдан түбәндәге таблица шактый гыйбрәтле.

Бәрәңге төбәге
материаллары буенча татар ташбилгеләренең үлчәмнәре
(еллар буенча хронология тәртибендә бирелә)

| | | |
|---|---|---|
| 1. Портянур | 1865 | 28×39×135 см |
| 2. Нур | 1866 | 23×37×127 см |
| 3. Бәрәңге | 1874 | 15×37×127 см |
| 5. Куянавыл | 1887 | 18×38×113 см |
| 6. Портянур | 1890 | 18×36×92 см |
| 7. Портянур | 1890 | 18×36×92 см |
| 8. Куянавыл | 1895 | 18×30×112 см |
| 9. Портянур | 1896 | 6,5×26×62 см |
| 10. Бәрәңге | 1899 | 17×35×30+X см |
| 12. Куянавыл | 1901 | 11×32×80 см |
| 13. Куянавыл | 1901 | 11×31×80 см |

| | | |
|---|---|---|
| 14. Куянавыл | 1903 | 9×35×131 см |
| 15. Куянавыл | 1904 | 15×30×94 см |
| 16. Бәрәңге | 1905 | 14×35×114 см |
| 17. Бәрәңге | 1906 | 15×36×52 см |
| 18. Куянавыл | 1906 | 11×31,5×100 см |
| 19. Куянавыл | 1906 | 11×31×95 см |
| 20. Мазарбашы | 1906 | 8×29×80 см |
| 21. Мазарбашы | 1907 | 9×30×85 см |
| 23. Бәрәңге | 1910 | 18×35×57 см (ватык) |
| 24. Бәрәңге | 1910 | 11×31×63 см (ватык) |
| 25. Портянур | 1910 | 9,5×32×80 см |
| 26. Портянур | 1911 | 12×31,5×96 см |
| 28. Портянур | 1912 | 12×30×95 см |
| 29. Куянавыл | 1912 | 10×29×82,5 см |
| 30. Куянавыл | 1914 | 9×32×85 см |
| 31. Куянавыл | 1915 | 10×31×105 см |
| 32. Бәрәңге | 1915 | 9×31×54 см |
| 33. Бәрәңге | 1916 | 16×34×45 см |
| 34. Бәрәңге | 1918 | 16×35×70 см |
| 35. Бәрәңге | 1918 | 18×30×76 см |
| 36. Бәрәңге | 1924 | 11×30×78 см |
| 37. Бәрәңге | 1925 | 12×30×80 см |
| 38. Бәрәңге | 1926 | 10×35,5×90 см |
| 39. Бәрәңге | 1928 | 12×35×117 см |
| 40. Мазарбашы | 1930 | 8,5×31×76 см |

1950 елларда татар эпиграфика сәнгатенең Бәрәңге төбәгендә үсеп килгән тарихы туктала. Торгынлык елларында ислам мәдәниятенең ачкычы булган гарәп язуының ташбилгеләрдә югалып торуы күзәтелә. Аларда инде мәрхүмнәр өчен дога ихтыяҗы хакында сүзләр табып булмый, иман кәлимәләре юк диярлек. Ташбилгеләр йөзлегендә ай-йолдыз символлары да сирәк күренешкә әйләнә. Алар урынына җан өшеткеч зур кара портретлар карап торалар. Инде мөселман цивилизациясе өчен ят коммунистик атамалар кыскартмалары мәрхүмнәрнең мөселманлык белән галәкәләре дә өзелү чигендә икәнлегенә танык булып хезмәт итәләр. Элекке мәдәниятнең шагыйрәнә фәлсәфи өлгеләренә алмашка югалту хәсрәте, таушалган сүз тезмәләре, «соңгы бүләк»ләр

бер дә күңелгә ятмый. Әлбәттә, бу чор ташбилгеләрендә дә аерылу ачысын күз яшьләре тамчыларына әйләндерә алган нәфис осталык өлгеләре аз түгел. Әмма, тулаем алганда, бу – инде 700 ел чамасы Идел–Урал буйларында хөкем сөргән борынгы татар-мөселман кабер өсте мәдәниятенең рухи хәерчелек шартларында сүнүгә таба баруы. Шөкер, 30–35 елларга сузылган торгынлык дәвереннән соң, милли йола-гадәтләребезне торгызу омтылышы яңадан күтәрелеп китте. Ул бүген дә дәвам итә.

Нинди иҗтимагый күренешләрне чагылдыра соң Бәрәңге төбәгендә 1865–1950 елларда куелган ташбилгеләр?

Беренче чиратта, алар Бәрәңге төбәге халкының бердәм татар милли культурасы кысаларында яшәгәнлеген һәм аны бу халәттән аерып карау мөмкин түгеллеген раслыйлар. Икенчедән, Бәрәңге халкының Татарстан, Казан белән рухи, мәдәни, икътисади берлеге үсүе, нинди генә ясалма каршылыклар тудырылса да, табигый рәвештә дәвам итүен дәлиллиләр.

Бәрәңге төбәгендәге татар халкы ташбилгеләре сәнгатенең үсеше, үзгәрешләре башка өлкәләрдәге милләттәшләребез сәнгате белән беррәттән бара, ул шуның белән кызыклы да.

*Ташбилгеләрдәге язмаларның кыскача сүзлекчәсе*

айәтә – аятьләрен
аман – котылу
әхәде – бер
бакыб – карап
бәгъдә – соңыннан
бивафа – вафасыз
бинте – кызы
бихөкем – хөкемсез
васыйл – ирешүче
вәляди – баласы
галәмәтдан – билгедән
гамил – тудыручы, хаким
голумә – гыйлем алу соңында
горрәи – календарь көне
дамелла – югары белем иясе
дар бакай – теге дөньяга (мәңгелеккә)
дар фәнадан – бу дөньядан
дәфен кылынды – кабергә күмелде

Җәгальнең – Аллаһның
Җәгалә – Аллаһ
җөмади әл-ахыры – һиҗри елның алтынчы ае исеме
зәүҗәтә – хатыны
зөлкагъдә – һиҗри елның унберенче ае исеме
иҗтиһад – тырышлык
илх – һәм башкалар
Иннә лилләһи вә иннә Иләйһи раҗигун – Аллаһ тарафыннан яратылганбыз һәм аның катына кайтабыз
интикаль кылды – күчте
ифтихар – горурлану
ихсан – ярдәм
иштигъмаль итде – эчендә булды
йәүшендә – көнендә, вакытында
кабил – киләчәк
калә Аллаһ – Аллаһ әйтте
кария – авыл
кәбир – бөек
көлли нәфсен даикате әл-мәвәте – һәр җан иясе үлем ачысын татыр
маһи – календарь ай исеме
мәнсүб – мөнәсәбәтле
миладия – руми, Гайсә пәйгамбәр туганнан санала башлаган ел санау системасы
мөгаләк – бәйләнешле
мөнәвәрә – нурлы
мөршид камил – тулы акыл иясе
мөтәгаддид рисаляләр – күпсанлы хезмәтләр
муафыйк – туры килгән
рамазан шәриф – һиҗри елның тугызынчы ае исеме
рәҗәб – һиҗри елның җиденче ае исеме
рихләт әйләде – күчте, үлде
румия – христиан елы хисабы белән
сахибәтә – хуҗасы
талиб – шәкерт
«Фатиха» – сүрә исеме
фи сәнә – елда
хаҗел-хәрамин – хаҗ кыйлып кайтучы
хәмәл – гарәби кояш елының беренче ае, март
һазә – бу, шушы

## Шәҗәрәләрнең тамыры тирән

*Рәфыйк бине Таиб нәселе шәҗәрәсе.* Бәрәңге төбәгендә традицион татар мәдәниятен, мәгърифәтен саклап килгән зыялылар – тарихчылар, шагыйрьләр, дин галимнәре, табиблар, укытучылар, таш кисеп язучылар арасында көчле һәм талантлы бер төркемне Рәфыйк бине Таиб нәселе тәшкил итә.

Нәселнең әлегә мәгълүм булган бабасы Рәфыйк бине Таиб XVII йөзнең икенче яртысында олы мәгърифәтче Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети оештырган атаклы мәдрәсәдә белем алган.

Мортаза бине Котлыгыш XV гасырда ук Казан ханлыгында мәгълүм булган һәм дәүләт каршындагы хезмәтләре өчен Казан ханнары кулларынннан ярлыклар алган атаклы Манаш тархан нәселенең XVII гасырның икенче яртысында яшәгән бер вәкиле була[1].

Мортаза бине Котлыгыш мәдрәсәсеннән XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында бер төркем талантлы татар укымышлылары чыккан. Алар арасында татар мәдрәсәләре өчен дәреслекләр язып, укытып йөргән һәм үзе шагыйрь дә булган Мансур Борындыкый, Габдессәлам бине Хәсән, Мортаза бине Гали, дин эшлеклесе һәм шагыйрь Габдессәлам бине Урай, Әлмөхәммәд бине Сүкәй һ.б.ның булуы мәгълүм.

Рәфыйк бине Таиб үзе Курсапочмакта яшәсә дә, аның нәселеннән Габдессәламнең 1782–1821 елларда хәзерге Татарстан Республикасының Арча төбәгендәге Ташкичү авылында имам булып торганлыгы мәгълүм. Ләкин Габдессәламнең аңа хәтле кайда яшәгәнлеге билгеле түгел.

Габдессәламнең улы Насретдин башта Ташкичүдә атасы мәдрәсәсендә укып, соңыннан белемен Оренбург янындагы Сәгыйд бистәсендә Габдерахман әл-Кирмани (1744–1827) мәдрәсәсендә күтәрә. Аннан кайткач, Бәрәңге янындагы Яңавылга имам булып килә. Соңыннан Яңавылдан Бәрәңгегә күчерелеп, 1825–1868 елларда (43 ел) бу якларда имам булып хезмәт итә.

Нәселнең шәҗәрәсе ул заманнарда ук төзелә башлаган булса кирәк, чөнки Насретдиннән башлап, аның һәр баласы (мәрхүм бул-

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Ибраһим хан ярлыгы һәм Манаш тархан шәҗәрәсе // Средневековые тюрко-татарские государства. – Выпуск I. – Казань, 2009. – С. 16–21.

ганнары да) турында мәгълүмат туплана барган. Ләкин Насретдиннең ата-бабалары дәверендә шәҗәрәләре язылмаган булган. Чөнки Рәфыйк бине Таиб Курсави белән Габдессәлам араларында да нәсел тарихына сораулар куярлык урыннар бар. Нәселнең барлык тарихын җыйнап, тулы бер тәфсилле шәҗәрә китабын Әхмәт бине Хафизетдин төзегән. Ул үзенең «Тарихе Бәрәңгеви» исемле зур хезмәтен язганда, үзләрендә саклаңган мәгълүмат чыганакларын тулы файдаланган.

Ләкин Әхмәт бине Хафизетдиннән соң нәсел шәҗәрәләрен таблицага салып күчерүчеләр, материалны нинди эзлеклелектә бирү кирәклеге турында хәбәрдар булмыйча, укыр, аңлар өчен шактый кыен таблица төзегәннәр. Ул таблицада буыннар бәйләнеше системасы төзүчеләрнең үзләре өчен генә аңлаешлы булып, атасын да, баласын да бер йомгак рәвешендә аермыйча күрсәтәләр.

Бу таблицадагы шәҗәрәне 1966 елда Бәрәңге якларында булганда филология фәннәре докторы, фольклорчы Хәмит Ярми күчереп алган булган. Ул әлеге күчермәдән соң 1973 елның 29 мартында яңадан да шуңа охшаш бер күчермә ясаган һәм шундый искәрмә биргән: «Үземдәге төп нөсхәдән күчердем. 29 март, 1973 ел. Х. Ярми» дип гарәп графикасында язып куйган. Моннан аңлашылганча, Х.Ярми Бәрәңгедәге шәҗәрәнең төп нөсхәсен алып киткән булса кирәк. Бәрәңге авылында яшәүче Мәхмүд Борһанов үзләренә Хәмит Ярминең килгәнен хәтерләп, әтисендә саклаучы борынгы шәҗәрәдә нәселнең Казан ханлыгы дәвереннән үк килгән бабаларының тәртипләп язылганы бар иде, ул сәхифәне кемдер алып, кире кайтармады, дип сөйләде. Әлбәттә, алай булуы да бар, тик ул очракта Хәмит Ярми алган күчермәдә дә ниндидер бер логик яктан ялганып җитмәгән урыннар булыр иде.

Әхмәт бине Хафизетдин төзегән шәҗәрә инде 1930 еллардан соң бер дә тулыландырылмаганга охшый. Бу эшне фәкать Бәрәңге халкы арасында үсеп, һәр гаиләне белгән берәр затның иҗтиһады белән башлап җибәрү кирәк, һәм аны берничә вариантта төзеп тулыландырырга мөмкин. Әгәр бу эш шушы елларда башкарылмаса, шәҗәрә тар дәрәҗәдә калып, аерым кешенең нәсел тарихына гына әйләнеп китүе мөмкин. Бәлки моны Бәрәңге урта мәктәбендә укучы татар балалары ярдәмендә эшләү уңышлы булыр.

Бәрәңге авылының зиратлары, андагы ташлар сакланганда, нәсел шәҗәрәләрен төзүгә ярдәмче чыганаклар бар иде. Ләкин иске

зиратларны җимереп, аның ташларыннан кабер ташлары ватыклары тавы ясагач, ул бик авыр эшкә әйләнде.

Ә шулай да бөтен татар дөньясы үзенең нәсел шәҗәрәләре белән кызыксынганда, Бәрәңге татарлары да бу яңалыкка кушылырлар, дигән өмет бар.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Таиб | 1 |
| | *II буын* | |
| 2. | Ислам | 2 |
| 3. | Рәфыйк Курсави (Курсапочмак авылында яшәгән) | 2 |
| | *III буын* | |
| 4. | Гөлгыйзар | 3 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Габделгазиз | 5 |
| | *V буын* | |
| 6. | Габдерахман | |
| | *VI буын* | |
| 7. | Габдессәлам (1782–1821 елларда Ташкичүдә имам вә мөдәррис булып торган, шунда үлгән) | 6 |
| | *VII буын* | |
| 8. | Насретдин (1796 елда туып, 1868 елның 2 сентябрендә вафат. Бәрәңге янындагы Яңавылга имам булып килә, соңыннан 40 ел имам булып Бәрәңгедә яшәгән) | 7 |
| 9. | Сираҗетдин (Ташкичүдә туган, 1797–1862 елларда яшәгән, декабрь) | 7 |
| 10. | Фәхретдин (1791–1850 елларда яшәгән, декабрь) | 7 |
| 11. | Мәргубә | 7 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *VIII буын* | |
| 12. | Хафизетдин (1827–1917) | 8 |
| 13. | Борһанетдин (1829–1901, Хәсән Акчуриннар нәселеннән кыз алып, Гурьевкада (Зөябашы) яшәгән) | 8 |
| 14. | Җәлалетдин (1837–1902) | 8 |
| 15. | Бәдриҗиһан | 8 |
| 16. | Минһаҗетдин | 9 |
| 17. | Шаһигәрдан | 9 |
| 18. | Сафа | 9 |
| 19. | Хәбибҗамал | 10 |
| 20. | Шәмсетдин | 10 |
| 21. | Фәтхерәшид | 10 |
| 22. | Шамил | 10 |
| 23. | Шукбаййан | 10 |
| 24. | Асия | 10 |
| 25. | Айа Суфия | 10 |
| | *IX буын* | |
| 26. | Җәгъфәр Алтайар (Кашгарда 1856 елда туган) | 12 |
| 27. | Әхмәд (1877, 7 сентябрь – 1924, 1 октябрь, Бәрәңгедә «Тарихе Бәрәңгеви» исемле тарихи кулъязма авторы) | 12 |
| 28. | Солтан Мөхәммәд Фатих | |
| 29. | Гаязетдин | 12 |
| 30. | Мөхәммәд | 12 |
| 31. | Мөхәммәд-Юшагы | 12 |
| 32. | Мөхәммәд-Фидан | 12 |
| 33. | Зөлкарнайин | 12 |
| 34. | Мөхфиларай | 12 |
| 35. | Сәлахетдин | 12 |
| 36. | Шәмсемөхәммәд | 14 |
| 37. | Сәйедәхмәд | 14 |
| 38. | Солтан | 14 |
| 39. | Борһанетдин (1879–1965, Куянавылда имам, укытучы булган) | 16 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 40. | Мансур | 16 |
| 41. | Насретдин | 16 |
| 42. | Шогайыб | 16 |
| 43. | Ибраһим | 16 |
| 44. | Мөхәммәд | 16 |
| 45. | Зәкәрийә | 16 |
| 46. | Мөхәммәд-Хатиб | 16 |
| 47. | Мәгъруф | 16 |
| 48. | Габделкави | 16 |
| 49. | Мисбахетдин | 16 |
| | *X буын* | |
| 50. | Асийә | 26 |
| 51. | Мәрийәм | 26 |
| 52. | Марийә (?–1917) | 27 |
| 53. | Әхмәд-Мидхәд | 27 |
| 54. | Мәхмүд (1911–1913) | 27 |
| 55. | Аллаһдад (?–1916) | 27 |
| 56. | Мөхәммәд-Хатиб | 28 |
| 57. | Габдерахман | 28 |
| 58. | Әхмәд-Шоҗагы | 28 |
| 59. | Мәрийәм | 28 |
| 60. | Әл-җинан Раузаи | 28 |
| 61. | Нәзаһәт-Заман | 28 |
| 62. | Сәйәдәт-Бану | 28 |
| 63. | Гәүһәр-Гөлшан | 28 |
| 64. | Гөлчирә | 28 |
| 65. | Былбылназ | 28 |
| 66. | Габделгазиз | 28 |
| 67. | Хәйракелнәфүс | 29 |
| 68. | Габделхак | 29 |
| 69. | Нурмөхәммәд | 29 |
| 70. | Мөхәммәд-Нәҗиб | 29 |
| 71. | Габделбари | 29 |
| 72. | Кәрез-Мәгъфүр | 29 |
| 73. | Тәлгать-Сорур | 29 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 74. | Шәмсенаһар | 29 |
| 75. | Мансур (шагыйрь, 1917–1943) | 29 |
| 76. | Рәсих (1919 елда туган) | 29 |
| 77. | Мәгъруф (шагыйрь, 1923–1998) | 29 |
| 78. | Зәйнелгарәб | 30 |
| 79. | Тафаһел-Җинан | 30 |
| 80. | Юханд | 30 |
| 81. | Нилүфәр | 30 |
| 82. | Гөлдагна | 30 |
| 83. | Баг Ирәмгөл | 30 |
| 84. | Зәйнелгабидин (ташлар кисеп язучы) | 30 |
| 85. | Хәлилрахман | 32 |
| 86. | Хәйрелдари | 32 |
| 87. | Габдерәүф | 32 |
| 88. | Хави | 32 |
| 89. | Нурелһади | 32 |
| 90. | Бәдрелдәрҗи | 32 |
| 91. | Шәмсезәхи | 32 |
| 92. | Мөхәммәд-Әнвәр | 33 |
| 93. | Зөлкафил | 33 |
| 94. | Марзийа | 33 |
| 95. | Дөлфәйез | 33 |
| 96. | Мөхәммәд | 33 |
| 97. | Әлйасигъ | 33 |
| 98. | Мирзаҗан | 33 |
| 99. | Әкрам-Нәҗат | 33 |
| 100. | Гөлчәһрә | 34 |
| 101. | Мәрийәм | 34 |
| 102. | Габделхак | 34 |
| 103. | Нургали | 34 |
| 104. | Габдулла | 34 |
| | *XI буын* | |
| 106. | Мәгъсүм | 39 |
| 107. | Хәмбәл Габдрахман улы Гыйззәтуллин (хәрби врач, медицина фәннәре кандидаты) | 73 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 107. | Рәсих (1952 елда Бәрәңгедә туган) | 92 |
| | *XII буын* | |
| 108. | Мәхмүд (1955) | 105 |
| 109. | Шамил (профессор, 1961 елда Мәскәүдә туган) | 106 |
| 110. | Рауза | 106 |
| 111. | Рамил (Бәрәңгедә туган) | 107 |
| 112. | Раил (Бәрәңгедә туган) | 107 |
| | *XIII буын* | |
| 113. | Җәмил (Бәрәңгедә туган) | 110 |

*Гайнан Кормашның нәсел шәҗәрәсе*нә дә аерым тукталу урынлы булыр. Бәрәңге төбәге авылларында очраган татар нәсел шәҗәрәләренең шактый өлеше Казан арты авыллары кешеләре белән кардәшлекне күрсәтә. Менә шуларның берсе Куянавылдан чыккан атаклы батырыбыз Гайнан Кормаш нәселенә карый. Куянавылда экспедициядә йөргәндә, Гайнан Кормаш бабаларының Мәңгәрдән килгән булулары турында ишеткән идек, ләкин кайсы бабасы килүен төгәл әйтүче булмады.

Ризаэддин бине Фәхретдиннең «Асәр» китабының III, IV томнарында (492 бит) Бәрәңге районы Куянавылдагы Гайнан Кормаш нәселенә кагылышлы мондый мәгълүмат теркәлгән: «Әл-хаҗи мулла Фәтхулла бине Бикчәнтәй бине Кармыш бине Карманай бине Бикәш әл-Куяни 1304 ел (һиҗри), 14 зөлкагъдә, 1887 ел (милади), 23 июль вафат», – диелгән.

Куян авылындагы зиратта Фәтхулла хәзрәтнең кабер ташы да сакланган. Ташта аның Куянавылда 50 ел имам булып торуы, 73 яшьтә үлгәнлеге теркәлгән.

Куянавыл зиратында Гайнан Кормашның туганнарының таш куелган каберләре булуы ачыкланды. Мәсәлән, Габделхәй Фазулла улы Кормашев исемнәр җәһәтеннән караганда, Фәтхулла бине Бикчәнтәйнең кардәше булган дип уйларга нигез бар.

Куянавылда имам булган, 1964 елда 85 яшендә үлгән Борһанетдин Минһаҗетдиннең хатыны Зәйнәп – Әхмәтгариф Кормашевның кызы булып чыга. Борһанетдин 1879 елда туган булса, хатынының аннан беркадәр яшьрәк булуы ачыклана сыман.

Куянавылда сөйләнгән хәбәрләрдән Кормашевлар нәселенең Олы Мәңгәр авылыннан килгәне мәгълүм. Олы Мәңгәрнең сакланып калган шәҗәрә китабында бу сүзләрнең дөреслеген раслый торган дәлилләргә тап булдык. Яңа Мәңгәрдән Олы Мәңгәргә күчеп килгән Таңай-Таңатыр баба нәселе Кормашевларның ерак бабасы була. Ул бабаның шәҗәрә тексты түбәндәгечә:

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Таңай | |
| | *II буын* | |
| 2. | Кармыш | 1 |
| 3. | Борнай | 1 |
| | *III буын* | |
| 4. | Биккол | 2 |
| 5. | Сәгыйд | 2 |
| 6. | Габделмән | 3 |
| 7. | Монасыйб | 3 |
| 8. | Габдессәлам | 3 |
| | *IV буын* | |
| 9. | Бикчәнтәй | 4 |
| 10. | Сәйфулла | 5 |
| 11. | Сабит | 5 |
| 12. | Габделлатиф | 6 |
| 13. | Габделвахид | 6 |
| 14. | Габделвәли | 8 |
| 15. | Габденнасыйр ишан | 8 |
| 16. | Габдессаттар | 8 |
| | *V буын* | |
| 17. | Ике улгы булган, берсе – солдатка, берсе Себергә киткән | 9 |
| 18. | Минкә | 10 |
| 19. | Фәйзулла | 10 |
| 20. | Халид | 11 |
| 21. | Хәмид | 11 |
| 22. | Садыйк | 15 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 23. | Галиәсгар нази... | 16 |
| | *VI буын* | |
| 24. | Төхфәтулла | 18 |
| 25. | Әхмәдулла | 18 |
| 26. | Әхмәдулла | 19 |
| 27. | Хәлиулла (Актазда) | 20 |
| 28. | Сафиулла | 21 |
| 29. | Маһирә (Әтнәдә) | 21 |
| | *VII буын* | |
| 30. | Камилә / Маһирә (Иске Мәңгәрдә) | 24 |
| 31. | Хәбибулла | 25 |
| 32. | Хәлилулла | 25 |
| 33. | Ибраһим | 25 |
| 34. | Галиулла | 27 |
| 35. | Гыйлаҗетдин | 29 |
| 36. | Сираҗетдин | 29 |

Әлеге шәҗәрәдә фамилиягә нигез булган Кармыш баба Таңайның улы – II буын. IV буында Кармыш улы Биккол – Бикчәнтәй бабаның атасы. Бикчәнтәй бабаның нәселе Олы Мәңгәрдә калмаган, аның балалары хакында «Ике углы булган, берсе – солдатка, берсе Себергә киткән»дигән искәрмә язылган. Бикчәнтәй үзе Олы Мәңгәрдә калган булса кирәк.

Куян авылы шәҗәрә материаллары буенча Бикчәнтәйнең ике улы да укып, Куянавылда имамлыкка калган булып чыга. Аларның берсе – Фәтхулла (1814–1887), икенчесе Фазулла Кормашев икәнлеге аңлашыла. Фазулланың улы Габделхәй 1851–1914 елларда яшәгән. Шуннан Фазулланың Фәтхулла энесе икәнлеге ачыклана.

Ризаэддин Фәхретдин материалында Бикчәнтәйнең атасы Кармыш (Кормаш фамилиясе шуннан алынган), бабалары Карманай һәм Бикәш искә алына. Бу бабалардан Карманай баба бине Иштуган бине Иштүк, Чар (ягъни Йошкар Ола) ягыннан килеп, Олы Мәңгәрдә мәрхүм Туйкә баба хатыны Гөлбостан әбигә йортка кергән, дип языла. Ихтимал, Чар ягыннан килгән Карманай баба Кормаш бабаның якын туганы булгандыр.

Муса Җәлилнең көрәштәше Гайнан Нури улы Кормаш сугыш алды елларында Казакъстанда яшәгән. Ихтимал, алар 1930 елларда «мулла нәселләре» дип эзәрлекләнгәнгә, ул якларга барып чыкканнардыр. Әлегә Гайнан Кормаш бабаларының ерак чылбырын белсәк тә, аларның Гайнанга ата-баба буларак бәйләү ягыннан өзеклек күрәбез. Киләчәктә Бәрәңге ягы белән кызыксынган, аны тикшереп өйрәнүгә алынган галим бу чылбырны ялгап җибәрер, дигән өмет бар. Ә хәзергә шәҗәрә чылбыры түбәндәгечә кала: I буын Таңай, аның улы Кармыш, аның улы Биккол, аның улы Бикчәнтәй. Бикчәнтәйнең ике улы – Фәтхулла белән Фазулла. Болар нәселеннән әлегә Фазулла улы Габделхәй генә мәгълүм. Ә алардан таралган буыннарны әле ачыклыйсы бар.

**Кулъязмаларда теркәлгән тарих**

Татар кулъязма китаплары арасында үз вакытында басылмыйча калган күп әсәрләр инде югалып, кайберләренең исемнәре генә мәгълүм. Ә менә могҗиза белән генә сакланып калган *Әхмәт бине Хафизетдиннең «Тарихе Бәрәңгеви»* әсәренең үз кулы белән язылган нөсхәсе мәдәниятебез тарихы өчен уникаль бер чыганак булып тора.

«Тарихе Бәрәңгеви» әсәрен автор 1911 елда бастырырга омтылып карый, ләкин аны чыгаруны өстенә алган наширләр табылмый. Бу китап белән таныш булган Ризаэддин бине Фәхретдиннең 1911 елның 30 августында Оренбург шәһәреннән авторга язган хатыннан аңлашылганча, Әхмәт бине Хафизетдин моны нәшер иттерүгә үзе дә артык тырышлык куймаганга охшый. Ризаэддин хәзрәт бу 223 битлек китапны бастырып чыгаруның хакы 211 сумга төшәчәген ачыклап хәбәр язган була.

«Тарихе Бәрәңгеви» әсәренең эчтәлеге белән танышып чыккач, авторга бу кадәр генә акча табу зур кыенлык тәшкил итмәгәнлеге күренә.

Әхмәт бине Хафизетдиннең «Тарихе Бәрәңгеви» әсәре кулъязмасының башындагы буш битендә күренекле тарихчы Шәһәр Шәрәфнең (1914 елның 13 маенда) һәм нашир Гыйльметдин Шәрәфнең (шул ук елның 28 маенда) бу хезмәт белән танышулары һәм аңа карата булган кайбер язма фикерләре сакланып калган.

Ризаэддин бине Фәхретдин хатларыннан күренгәнчә, ул Әхмәт бине Хафизетдиннең китабын бик югары бәяли: «Бәрәңге тарихы» гаять гүзәл бер шәйдер, күрер өчен һәм дә истифар кыйлыр өчен *(файдалану өчен)* зия дә морак итдем *(тирәнтен уйландым)*».

Шулай да әлеге галимнәр бу хезмәттә «хосусыйлык» билгеләре күреп, аның кыйммәтен аңлап бетермәгәннәр. Эш шунда ки, анда телгә алынган Борһанетдин, Хафизетдин, Әхмәт хәзрәтләр һәркайсы үзенә күрә газаплы һәм авыр белем алу мәктәпләрен үтәләр. Аларның белем алу учаклары Кышкар, Казан, Бохара, Өргәнеч, Гөлҗа, Кашгар, Яркенд, Сәмәрканд, Ташкент, Алма-Ата, Җидепулат, Кызылҗар (Петропавловск) һәм башка җирләрнең эреле-ваклы мәдрәсәләрнең ихаталарында була. Бу юллар аларга кадәр Мортаза Симети, Юныс Иванай, Рәфыйк Курсави, Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани кебек атаклы фикер ияләребез тарафыннан XVII–XIX йөзләрдә шактый тапталган була инде. Хәтта Бохарага укырга килгән татар шәкертләре туктала торган «Нугай сарай» дигән кунак йорты кебек урын барлыгы да мәгълүм. Монда 1552 елда Казанны басып алучылардан качып килгән татарларның үз почмаклары формалашкан. Казан ханлыгының соңгы елларында дипломат, дин эшлеклесе, шагыйрь буларак мәгълүм Касыйм шәех Бохара якларында үзенең олы тетрәнүләр белән тулы җанына беркадәр дәва тапкан. Үзенең татар икәнлеген онытмаган Суфи Аллаһияр XVIII йөздә көчләп чукындыру сәясәте астында интеккән милләттәшләренә хакыйкать юлын күрсәткән «Сөбател-гаҗизин» исемле әсәрен юллый. Һәр фикер энҗеләре белән тулы бу поэма татарга менә 300 ел буена иманын сакларга өйрәтә.

Әлбәттә, XX йөз башларында татарның инде үзенең көчле милли мәгариф системасы формалашып җитә. Татарларның төп өлеше үзләренең атаклы милли уку йортларында – «Касыймия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия», Кышкар, Бакчасарай, Стәрлебаш, Буа, Чыршылы, Чистай, Буби, Бәйрәкә, Сатыш кебек уку йортларында белем алалар. Шул ук вакытта Бохара, Әл-Әзһар, Истанбул, Сарбонна, Льеж, Берлин, Петербург, Киев һ.б. шәһәрләргә барып, андагы уку йортларына кереп, Төрәк, гарәп, француз, фламанд, алман, урыс телләрендә белем алучылар саны да арта бара.

Бу дәверләрдә шулай читкә китеп, зур мохтаҗлыклар күреп, белем алган татар укымышлылары күп була. Ләкин аларның берсе дә Әхмәт бине Хафизетдин кебек татар шәкертләренең нинди авыр шартларда, зур тырышлыклар куеп белем алуларын тасвирлаган документаль дәрәҗәдәге әсәр язып калдырмаганнар.

XX йөз башы – татарның Аурупа мәдәниятенә йөз тота башлаган чор, шуңа күрә татар матбугатында Урта Азия уку йортларына

түбәнсетеп карау күзәтелә. Гыйльметдин Шәрәф һәм Шәһәр Шәрәф кебек укымышлылар да «Тарихе Бәрәңгеви» китабына үз көннәре күзлегеннән чыгып кына бәя биргәннәр, Әхмәт бине Хафизетдин әсәренең кыйммәтен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганнар. Бу яктан Ризаэддин бине Фәхретдиннең тарихчы буларак хәзерлеге Шәрәфләрдән күп өлеш өстен була.

Бүгенге көн югарылыгыннан караганда, «Тарихе Бәрәңгеви» китабы – татар тарихының 1850–1917 еллары дәвере буенча бер энциклопедик хезмәт. Анда Казан арты галим-голямасы, мәдрәсәләре, җәдидчелек, кадимчелек хәрәкәте, тарихи этнография, авыл мәхәлләләре, авыл общинасында патша ялчылары ролен үтәүче старосталарның интригалары һ.б. тасвирлана.

Мәсәлән, әлегә кадәр татар әдәбиятында муллаларның мөфтияткә барып, указ алу процедуралары бер урында да тасвирланганы юк, ә ул «Бәрәңге тарихы»нда бар.

Әхмәт бине Хафизетдиннең әсәре бер үк вакытта зур, тәфсилле нәсел шәҗәрәсе дә.

Аның иң күренекле тарихи бабасы XVII гасыр ахыры – XVIII гасырның беренче чирегендә яшәгән Рәфыйк бине Таиб әл-Курсави була. Ул Курсапочмак авылында имам булып торган. Рәфыйкның туган-үлгән еллары төгәл билгеле түгел. Ләкин тарихта аның кызы Гөлгыйзар Рәфыйк кызы әт-Түнтәринең 1820 елның 20 гыйнварында үлгәнлеге Әхмәт бине Хафизетдингә мәгълүм булган. Рәфыйк бине Таиб нәселләре Рафыйков фамилиясе белән йөргәннәр. Рәфыйк улы Ислам, Ислам улы Габделгазиз, Габделгазиз улы Габдрахман, Габдрахман улы Габдессәлам. Габдессәлам 1782–1821 елларда Ташкичү авылында (ул хәзер Татарстанның Арча районына керә) имам вә мөдәррис булып торган. Ул 1821 елның 9 июлендә вафат булып, Ташкичүнең яңа зиратына күмелгән.

Габдессәламнең Насретдин исемле улы була (ул 1796 елда Ташкичү авылында туа). Насретдин башта Ташкичүдә атасының мәдрәсәсендә укый. Аннан соң Оренбург шәһәре янындагы Сәгыйд бистәсендә Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф (1744–1827) әл-Кирмани мәдрәсәсендә белем ала. Насретдин хәзрәт игенчелек эшен яраткан. Остазының җирләрен сукалап, ашлыкларын чәчепурып бирә торган булган. Сәгыйд бистәсендә укуын тәмамлагач, Насретдин Бәрәңге авылы янындагы Яңавылга имам хатип булып килә. Матур итеп Коръән уку буенча ул тирә-якта дан ала.

Шул сәбәптән, Бәрәңге халкы, «андый зур галимне кечкенә авылда тоту килешми» дип, аны Бәрәңгегә имам итеп чакыралар. Ул анда 1825–1868 елларда (кырык елдан артык) имамлык итә һәм 1868 елның 2 сентябрендә вафат була. Соңрак хәзрәтнең улы казый Борһанетдин кабер ташы тексты яза, аны Әхмәт бине Хафизетдин ташка төшереп, кабер өстенә утырткан. Әхмәт хәзрәт, гомумән, кабер ташлары кисеп эшләү белән танылган була.

Насретдин хәзрәт – төрле һөнәрләр остасы булган. Үз киемнәрен ул үзе тегеп кигән, йортын үзе салган, арба-чаналарны да үзе ясаган. Аның гарәп телендә язган ике китабы була: аларның берсе чалма чорнаганда аның койрыгын чыгарырга өйрәткән, икенчесе – Маһинәһер (?) хакындагы китап.

Насретдин хәзрәтнең Хафизетдин (1827, 3 май – 1917, 21 февраль), Борһанетдин (1829–1901), Җәлалетдин (1837–1902) исемле уллары һәм Бәдриҗиһан исемле кызы була.

Насретдиннең иң талантлы улы *Хафизетдин* 12 яшенә кадәр атасының мәдрәсәсендә белем ала. Шуннан соң Бәрәңге авылыннан төньяктарак урнашкан Мазарбашы исемле авылда галим мулла Әхмәт бине Ихсан әл-Мәмсәви хәзрәт мәдрәсәсендә сарыф (гарәп теле морфологиясе), нәхү (гарәп теле грамматикасы, синтаксис), мантыйк (логика) һәм фикъһе (мөселман хокукы) фәннәрен өйрәнә. Шәкерт, мәдрәсәдә укыганда, үзенә кирәкле дәреслекләрне үзе күчереп язарга тиеш булган. Чөнки ул укыган елларда андый дәреслекләрне матбагаларда бастырып чыгармаганнар әле. Шунда укыган вакытында Хафизетдин «Тәфсире Хөсәен вәгъзе» (2 томда) китабын җиде ай эчендә күчереп чыккан. Китабының ахырына «Кәтәбәһү Хафизетдин бине Насретдин Әл-Болгари» дип үзе турында мәгълүмат биргән (1845, 1848 еллар).

Моннан тыш ул зур күләмле «Тәфсире Әбү-Ләйес» «Тәнбиһелгафилин» исемле китапларны да күчергән булган, әмма Бәрәңгедә чыккан бер янгында алар көлгә әйләнгәннәр. Шулай да Хафизетдиннең ут казасыннан исән калган күчереп язган кулъязмаларыннан «Гавамил» (гарәп теле грамматикасы), «Исәгуҗи» (мантыйк, логика) һәм аңа язылган хашиясе, Ташкепри дигән авторның әдәп, бәхәс тәртипләренә өйрәткән китабы һ.б. мәгълүм.

Аның тарафыннан күчерелгән китаплар арасында гарәп, фарсы, төрки телләрендәге берничә томнарга җыелган китап төпләмәләре була. Алардан үзе иҗат итеп язган «Гакаид» (Иман), «Дәләил-

хәйрат» (Хәерле дәлилләр), «Диване Мәшрәб» (XVIII гасыр үзбәк шагыйренең суфичылык идеяләре белән сугарылган популяр шигырьләре җыентыгы) һ.б. әсәрләре була. Ул 17 яшьләрендә инде мәчеттә, Тәңре Тәгаллегә мәхәббәтен белдереп, догалар укый.

Хафизетдин 18 яшендә белем алырга юл тота. Бохарага барганда, Оренбург шәһәрен узып, ат һәм дөя өстендә өч айлык юлны үтә. Аның «Исагуҗи» китабының бер буш битенә «Сәнәи 1846 елда, декабрьнең әүвәлендә мин, Хафизетдин Насретдин улы, Бохараи шәрифкә килеп кердем» дигән мәгълүматы бар. «Тарихе Бәрәңгеви» авторы Хафизетдиннең үз авызыннан ишетүенчә, ул Бохарага Мәчкәрә мәдрәсәсеннән, анда бер кыш Габдулла Мәчкәрәви хәзрәт дәресләрен тыңлагач китә.

Бохарада «Мәдрәсә-и гарибия»дә бер укучы-талиб хөҗрәсе (бүлмәсе) ала. Мәдрәсәдә бер ел укыгач, бүлмәсен сатып, «Мәдрәсә-и Хайабан»дан бер хөҗрә алып урнаша. Анда дусларыннан Гыйзетдин Минзәләви белән аралашып яши. Атасының остазы Габделмөэмин хуҗа бине Үзбәк хуҗа әл-Әфшәбәхинең (һиҗри 1283 елда вафат) олуг улы Миргалим хуҗага кордаш буларак, аның белән бергә «Шәрхе гакаид Тафтазани» китабын өйрәнеп чыга. Мирзаҗан бине Шәмсетдин әл-Бәлхи (1278 һиҗри елда вафат) «Гакаид гыйздийә шәрех дивани» вә «Шәрех тәлхисе» һ.б. китапларны укыта. Хафизетдин Бохарада шулай ук Шиһабетдин Мәрҗанидән «Тәһзиб әл-мантыйк»ның (логика фәне) бер өлешен һәм башка китапларны укып дәрес ала.

Хафизетдиннең Шиһабетдин Мәрҗани белән бәйләнеше соңгысының, 1848 елда Бохарадан Казанга кайтып, атаклы имам хатиб һәм мөдәррис булуыннан соң да дәвам иткән. Әхмәт бине Хафизетдиннең әтисе архивында Ш.Мәрҗанинең фарсы телендә язылган хатлары да сакланган булган. Ул хатлар «Тарихе Бәрәңгеви» кульязма китабының 153а – 156б битләрендә күчереп бирелгәннәр. Аларны татар теленә тәрҗемә итеп, матбугатка беренче мәртәбә филология фәннәре кандидаты Сәлим Гыйлаҗетдинов чыгарды[1].

Казанда Ш. Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу вакыйгасын татар укымышлылары зурлап билгеләп үтәргә әзерләнгәндә тарихчының шәхси архивы белән танышалар. Ш. Мәрҗанинең архивында 1861–1881 елларда Хафизетдин бине Насретдин әл-Бәрәңгеви

[1] *Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. – Казань: Фикер, 2002. – Б. 236–238.

язган хатларга да юлыгалар. Бу хәл юбилей комиссиясе әгъзаларын кызыксындыра һәм алар арасыннан Шәһәр Шәрәф һиҗри белән 1331 ел җөмади әл-ахры аенда (милади 1913 елның май ае) Хафизетдин Бәрәңгевигә хат язып җибәргән. Шәһәр Шәрәф Ш. Мәрҗани архивында Хафизетдиннең күп хатлары булуын, алар белән танышкач, бөек галимне якын фикердәшләре рәтеннән санап, аның белән танышырга, аннан мәгълүматлар алырга теләвен аңлата.

Ш. Мәрҗанигә багышлап чыгарылган җыентыкта Хафизетдин бине Насретдиннең кыскача тәрҗемәи хәле галимнең иң затлы шәкертләре арасында өченче рәттә бирелгән (Мәрҗани. – Казан: Мәгариф. – Б. 113–133).

Әлбәттә, Шәһәр Шәрәф хат язган елларда Хафизетдин исән була әле, ләкин безгә аның җавап язуы мәгълүм түгел. Улы Әхмәт Бәрәңгеви язган китаптагы сәхифәләргә караганда, аның бу дәвердә 60 ел элек булган хәлләрне хәтерләп язарлык дәрте булмаганга охшый.

Хафизетдинның шәхси китапханәсендә Ш. Мәрҗанинең «Мостәфадел-әхбар» һ.б. тарихи китаплары булуы турында хәбәрләр калган.

Хафизетдин Бәрәңгеви Урта Азиягә 18 яшендә килеп, аның күп шәһәрләрендә (Җизьяк, Бохара, Сәмәрканд, Хаҗәнд, Кашгар, Хуканд, Хотан һ.б.) була. Суфыйчылык карашларын үзләштереп, нәкышбәндиләр тәрикасын тота. Бохарада ишан пир Шаһ Яхъядан иҗазәтнамә ала. Ул Урта Азия якларында яшәгән елларда андагы Бохара һәм башка шәһәр әмирләре күп сугышлар алып барганнар, йөзләгән укымышлыларны үтергәннәр, күп китапларны яндырганнар. 1861 елда Хафизетдин белән энесе Борһанетдин, укуларын тәмамлап, Бохарадан туган якларына кайтырга чыгалар. Башта алар Сәмәркандка, аннан Ташкентка, аннан Төркестан шәһәренә киләләр. Төркестаннан, авылдашлары Сиражетдин Бәрәңгеви белән берлектә, Кызылҗар (Петропавловск) шәһәренә китәләр.

Кызылҗарда Хафизетдинне, бер мәхәлләгә имам итеп кую нияте белән, өйләндерәләр. Ләкин Бәрәңгедә 1865 елда атасының ир туганы мулла Җәләлетдин үлү сәбәпле, чакыру килеп, ул авылына кайтып китә.

1865 елда, Хафизетдин Бәрәңгедә имза җыйнап, указ алыр өчен Уфага барып, имтихан бирә. Гомерен имам булып, мөселман мәдәнияте буенча күпсанлы хезмәтләр язып уздыра. Хафизетдин хәзрәт 1871 елның 13 октябрендә хаҗ сәфәренә чыгып китә. Бәрәңгедән

Казанга, аннан Түбән Новгородка, аннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Одессага, Одессадан Римга, аннан Искәндәрия каласына, аннан Мисырга барып җитә һәм, ниһаять, Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә булып кайта. 1917 елның 21 февралендә үлә. Аның үлеменә сәбәп – 1916 елда улы, тәрбиячесе Мөхәммәднең армиягә алынуы була.

Әхмәт хәзрәт үзенең **«Тарихе Бәрәңгеви»** китабында атасының киемнәрен, төсен-битен тасвирлап яза. Анда Хафизетдин хәзрәтнең каралтылары, бакчалары, йортының эчке тәртипләре, ашау-эчү, кунак җыю мәҗлесләре, аш төрләре дә тасвирлана. Кулъязмада Хафизетдин хәзрәтнең йорт хужалыгы урнашу тәртибен тасвирлаган сәхифә белән танышып үтик:

«Ишек алды бик олы бер аралык, ындырны бакчада ясамак касде (*теләге*) илә агачлар утыртылмыш һәм урта бер йиринә тирән бер күл казытып, яз кергән су җәй буена кадәр бетмәс... Йорты кара-каршы ике озын өй улып, берендә кәндисе (*үзе*) вә берендә җөдәмез (*барчамыз*) торып «Әби улы» дия йөридер идек. Өй алды ике ишекле, бере кунакларга махсус, аның мокабилендә (*кара-каршы*), дәхи олуг бер ишек бакчага чыгар иде. Бундан чыккач бер кечек бакча, буны фәкыйрь мин ясамыш идем. Вәләдемез (*атабыз, тудыручыбыз*) монда чыгып, китап моталяга идәр иде, гяһ (*кайчакта*) чәй эчәр идек. Ашханә дәхи артда, бунның юлысы белән тоташ такта белән ясалмыш юл бәдрәфкә варыр иде.

Хәммам (*мунча*) ике бүлмәле: бере киенмәк өчен махсус иде. Хәммам кермәкне бик сүәр иде. Хәтта һәр көн улса да күплек итмәс иде. Кергәндә вә чыкканда мотлак (*ничек кенә булмасын*) җилдән сакланып, төренеп, кереп чыкдыгы соңра тирән бүрекне вә калын кәзәкине тирләгәннәре басылганчы, ягъни ятканчы салмас. Как, йә лимон белән фамильный чәй эчәр, бер шәй дә (*нәрсә дә*) ашамас иде.

Өенең хариҗи (*тышкы ягындагы эшләре*) – тышкары чыгып, йорт тәфтиш итүе (*тикшерүе*) юк, анбар вә азбарларга кереп йөрмәде. Кибәнне кәндисе (*үзе*) бик маһарәт (*осталык*) белән куяр икән. Берадәрләремез үедеке соң, буны дәхи тәрк итмештер (*бу эшен ташлады*). Хайван асрамакта мазаклы (*мәшәкатьле*) дәгел зарурәи сыгырдан гайре хайван улмамыш. Хәтта мәет өчен килгән тавыкларны күрше Бибигаишә нам хатынга биреп, ул йомыркасы илә файдаланып, кирәк вакытта алдырып бугазлатырлар икән. Каз вә үрдәк кебиләр ишек алдыйн нәҗесләр дия тәрбия кылмамышдыр (*асрамады*).

Тәгам вә йимәк (*ризык ашау гадәтләре*): кунак сүүчән вә ләзлик (*тәмле тамак*). Һәр базар көнне, дүшәмбе ханәсе тулы муллалар улыр, мулла Фәтхулла бине Бикчәнтәй әл-Хәргүши вә Баһаветдин әл-Купали, ахунд Нурмөхәммәт бине Мөхәммәтгали әл-Пуртанури һичбер базар калмай керерләр һә шамга (*кичкә*) кадәр кунак булырлар иде. Мәҗлесләрдә кунакларыны дәрәҗәләренә муафикъ сурәтдә ихтирам идәр, бәгъзыларга гына каршыламак өчүн торыр, озатмак өчүн чыгар иде. Мәҗлесе исә гыйльми бер җәмгыйййәт улып, җәридә (*газета*) хәбәрләрен дыңлар вә сөйләр иде. Әмма гайбәт вә низагъ кеби гөнаһлардан мәҗлес пак, вә һич кемнең гаурәтине (*хатынын*) итлагыны (*аеруны*) таләб кылмас иде. Кирәк кайда улсын заруриятсез йа хурмала (*хурлау*) йагыйна улан бер кәлимә (*сүз*) сөйләмәс. Голәмә-и мәҗлесендә һәр кайда садыр нишин (*рәислек итүче*) улыр иде. Бай вә ярлы һәр кемнең мәҗлесинә варыр. Кешенең ханәсенә (*йортына*) вә мәҗлесендә улан кемсәйә күтәрелеп бакмас иде. Безнең бу тарафда бундан егерме сәнә (*ел*) мөкаддәм (*элек*) күберәк карья (*авыл*) муллалары һәр елда мәүлед ашы ясап хәтем кылдырырлар, тушы мәҗлескә кадәр кем, бер вакыт Олуг Кыр карьясының имамы Әхмәт бине Сиражетдин мәүлед мәҗлесе ясап, әтрафтан муллаларны дәгъвәт итмеш (*чакырган*).

Вәләдемездән мәкаддәм Кетнә карьясенең мулла Садыйк вә углы Йосыф вә Путчәрә имамы Сабирҗан бине Сәгыйд килеп, дөньяви бер гарыз (*үтенеч*) өчүн вәләдемез белән низаг идаргә иттифак кылмышлар (*берләштеләр*). Батырлык вә мәһабәт алынмасын өчен дия, бер шешә хәмер эчкәннәр. Вәләдемез белән мулла Фатих абзый мәҗлескә кереп, берничә дәкыйка (*минут*) утырдыкдан соң, низаг кыла башлаганнар. Исерекләр белән сүз көрәштеремәк файдасыз улдыгындан вәләдемез мәҗлеседән чыгып кайтып китмешдер. Бундан соң мәҗлесләр һәм бетте. Тәгам йимәге гыйльме тыйб (*медицина*) кагыйдәсенчә гамәл идәр. Чәй эчүдә һәр йотуда тәлинкәсене йирә куяр. Агызында тәгам вар икән чәй алмас иде. Сүдиге ашы: икмәк, сөт вә шикәр һәм ит улыр иде. Мәгәр пешерелеп сатыла торган тәгамне вә буяулы хәлвәләрне йимәс, мәҗлесдә нәфрәтләнерлек сүзләр сөйләтмәс вә эшләр кылдырмас иде. Дәхи салкын су һичбер вакыт эчмәс иде.

Җәй көннәрендә озак сәфәрләргә йөрер вә кәндисе һәр йылда кунак чакырып, миһмандари кылыр вә әтраф муллаларын дәгъват итәр иде. Фәкыйрь бән, шәкерт улдыгым соңра Оры мулла Сәмигулла мәхдүмне чакыра башлады».

Әхмәт Бәрәңгеви әтисе Хафизетдиннең китап яратуын да язып калдырган: «Китапка акча кызганмады, нинди китап булса да алды», – дип хәбәр итә. Яратып һәм кат-кат укый торган китапларыннан суфичылыкка кагылышлы әсәрләр була. Шулардан «Тәгърибел-рәшәхат» (гарәпләштерелгән Рәшәхат китабы), имам Раббаниның мәснәви һәм хатларын («Мәктүбәт») һәм моның нәселеннән Әхмәт-Сәгыйд бине Әбүсәгыйднең «Изһар рабига» һ.б.ны санап китәргә була. Аның даими үз янында тоткан китаплары: гыйльме нәхүдән «Мәгани әл-ләбиб», «Китабел-бериз», «Сәйрелсәхабә». Фарсы телендәге китаплардан – «Лөгате фарсия» һ.б.

Хафизетдин хәзрәт күп язган, күчергән, иҗат иткән. Аның язып утыру халәте кулъязма китап күчерүчеләрнең хезмәтен күз алдына китерергә ярдәм итә. Аның язу процессы түбәндәгечә тасвирлана:

«Йазар исә кәгазьне өстәлгә куймай, бәлки бохарилар кабиләндән кәгазьне тезе өстенә куеп камыш каләм белән, йә тимер каләм белән язар, харикылгадә» (*гадәттән тыш*) тиз язар вә кагәзь исраф итмәкдән бик сакланып, бер сатырга (*юлга*) гадә-и сатырның сүзине сыгдырыр исә һәм рәсем хат гарибә (күрелмәгән) вә гүзәл вә һәр лафыз (*сүз*) нокта гадәтенчә тезелеп торыр иде.

Аның хатирә дәфтәре идүб тотдыкы йегерме сәхифәлек, гаять нечкә тимер каләм белән язылмыш, гомер буена тотдыгы шу кечкенә дәфтәре бер харыйкадыр (*гадәттән тыштыр*). Күрдеге төшләре һәм алыш-бирешләре, вә гайре (*башка*) шәйләрне (*нәрсәләрне*) анда язмышдыр. Ушандак эчендә гарызи бер виршук, тулыда ике бармак кадәр кәгазь улыб, бер башы мәхәлләдә вөҗүдләрне (*туган кешеләрне*) вә икенче башы мәйетләрне язар өчен иде. Балаларга исем вирдегендә мәҗлескә дәфтәр алып вармаз, бәлки шул баланың исменә муафикъ «Коръән» укыр иде. Нитәк көннәрнең берендә Сәфәрхан бине Нигъмәтулла нам бер кешенең баласына исем вирер өчен мәҗлескә вардык. Атасы боерганча, Сабирҗан, – дия исем бирде, бәгъдә (*соңыннан*) «Коръән»дән аять кәримәне укыды.

Бундан бер-ике ай үткәч, бер көн митрикә дәфтәрен язарга утырды. Мәгәр мәзбур (*искә алынган*) баланы, ни исемдә кушдыгыны хәтердән чыгармыш икән. Бездән: «Ул баланы ничек куймыш идем? – дия сорады. Без һәм белмәдек. Бераз уйлап торды да – «Ии… дип укыдым ич, Сабирҗан имеш», диде. Никах укулары вә язулары да шу рәвешдә иде.

Бу урында канде каләмнәреннән садир (*чыккан*) улан бер чук (*күп*) асәр мәнкуләсенең (*кучерелгән*) исемнәрен санамак улдым, бунлардыр: Бохарага китүгә мөкаддәм (*элек*) төрки вә фарси мөтәгъдәр күп китаплар язды, ләкин һәммәсене шәкерде Сәгъдулла әл-Әгерҗи хәлфәгә бәхеш (*бүләк*) итмеш. Бу көн аның дарында мәхфуздыр (*кулында саклanадыр*).

1. «Гавамил», мәга (*белән*) шәрхә гарәби, һәмәшендә фарси тәркибе (*кушымтасы*) белән. (Бу грамматика китабы, гарәпчә искәрмәләр һәм фарсыча кушымталар белән – *М.Ә.*).

2. «Исәгуҗи» (*логика*), мәга хашиятенә (*искәрмәләре*) Мөхетдин вә Ташкепри.

3. «Тәфсир Хөсәен», әлвәгъзе ике җилд (*том*), калын ак кәгазьдә язылмыш.

4. «Ризан әс-сыбйан» назым белән, лөгате гарәбия бәййан иделмеш…

5. «Кимийа-и әз-зәһәб» («Химиягә бару»).

6. «Шәрхе мохтәсар әл-вәкая» (Шәригатьне кыскача аңлату).

7. «Әл-тәҗрид мәга шәрех әл-җәдид әл-дивани...»

8. «Фараиз әл-гакаид…»

9. «Көһестани әл-фикыһ Кайдани вә гайрә».

10. «Һәйакел әнвар…»

11. «Кыйссасел-хөкем ля бине Гарәби».

12. «Әт-тәрикаи әл-мисле әл-мәрхәбә…»

13. «Тәзһибел-мантыйк…»

14. «Тәзһибел-калям әл-Тафтазани». Буны Минһаҗетдин бине Нәҗметдин әл-Иске Авылыйдан гарийәтә алып, 1321 сәнәдә үз йортында сәфәр 3 ндә йазып фәкыйрьгә Бохарага йибәрмеш иде.

15. «Әл-ваих әл-Җами, әсрар әл-кыйсме 28 фасыл», «Җәгърафия фарси», «Рисалә-и фи гыйльми әт-тәксир», «Расалә-и фи әр-рәмел вә гайрә» вә «Сийәллә әт-Туси», «Рисалә-и фи әсрар исамаи әл-Хөсни, Мәгани фи ысул әл-фикыһ әл-Хабази, әл-Хаҗенди, әл-хәнәфи», «Никат Бидәл рисалә-и фи әл-Куафи вә гыйлем әл-фәрасәт», «Рисалә-и әл-тәсхихел-Коръән әл-Әхмәдгали Сәһанйури» вә гайреләр бер мөкавәдә фәкать бер илле калдырып, вак язган Кашгар шәһәрендә.

16. «Мәктүбәт әл-имам әр-Рәббани. Олуг кулда мөҗәлләдер, буның нөсхәсене бер йарым ай вәгъдә белән мулла Нурмөхәммәд ахунд әл-Пуртануридан гарийәтә (*бурычка*) алмыш. Вәгъдә тулудан бер һәфтә (*атна*) элек язып тәмам итде вә кырык чакрым йирә би-

реп мокавә кылдырды. Бәгъдә ахунд бер базар керүендә ике нөсхә виреп ни дияргә белмәй, хәйран улды. Ушбу китапның ахрыйна бу рәвештә тәхрир итмешдер».

Моннан тыш Әхмәт Бәрәңгеви этисе Хафизетдин хәзрәтнең башка язган әсәрләренең исемлеген китерә:

«1. «Шакайык әл-Ногман фи гыйшыйа әл-Газан». Ушбу китапны аксаре Лийалдә Гыйшь-йаның вөҗүбе хакында ахунд Фәтхулла бине Хөсәен әл Орувигә ривая сурәтендә Бохара шәһәрендә язмышдыр. Гыйбарәсе фәсих вә балигъ улмак белән мөшкелдер…

2. «Әл-горувә-и әл-вәсика-и әл-нәфәсәт ләһә» – гарәби фикыһ гыйльмендә һидайә рәвешендә икенче таснифы уларак сәнәдә… китабел-тәһарәтдән яза башлып, бәгъзе шөгыльләр сәбәпле баб әл-җәмәгатькә тукталмышдыр. Берзаман бәлки тәккәмел идүчи дә улыр…

3. «Шикәстә-и тәракаккыя», өченче таэлифдер. 1274 сәнәдә Кашгар шәһәрендә (*1857–1858 елларда*) истикамәт (*яшәү*) итдеке вакыт шәһәрнең әгъләм вә муллаларының угылларына вә гайре шәкердләргә дәрес әйтеп шөгыльләндегедә «Холяса-и хисап» («Саф арифметика») улкучы талибәнең үтенмәкләре белән холясане Кашгар лисаненә тәрҗемә әйләде».

4 нчесе – «Ән-нәҗих әз-зәних фи әл-хисаб әш-шалех», гарәп телендә язылган хисап гыйльменнән мөстәкыйль бер китап. Тапкырлау гамәленә өйрәтүче 38 битлек әсәр.

5 нчесе – «Зәвәлбәһҗәи фи әл-хажә-и» китабы: фикһ, шәригать, мантыйк (логика), Коръән проблемалары.

6. «Тәнкихел-камус» («Никахлау сүзлеге»). Бу китапны милади 1857/58 елларда Кашгар шәһәрендә Казый Хәмиднең йортында тоткын булып торган вакытында язган. Урта кулда, кәгазь битендә буш урын калдырмыйча, нечкә каләм белән язылган. Имзасы «язучы Хафизетдин бине Насретдин әл-Болгари» дип күрсәтелгән.

7. «Милүкия-и табигиять» фарсы телендәге китап, Кашгар шәһәрендә язылган. Төрле карашлар һәм һөнәрләр белән эшләүгә кулланма.

8 – бу тәртип саны, ялгыш булса кирәк, бөтенләй төшеп калган.

9. «Мәҗмугаи мөшхат» – (Хафизетдиннең) шигырьләр тупламы.

10 нчысы – «Рийаз әл-җәннәтә ләлмиләтә» медицина буенча фарсы телендә язылган китап. Аны медицина өлкәсенә караган абруйлы китаплардан күчереп язган. Бәрәңге авылында төгәлләнгән. Ике зур томнан гыйбарәт булып, беренчесендә һәр төрле дәвалар вә үләннәрнең файдаларын һәм зарарлары күрсәтелгән.

Икенче томда кешеләрдәге төрле авыруларны дәвалау әмәлләрен, авыру сәбәпләрен ачып бирә.

Хафизетдин хәзрәт үзенең медицина буенча үзләштергән белемнәре белән йөзләгән кешеләрне дәвалаган (мәсәлән, Пермь ягындагы Удик дигән авылдан кантун Мирза Нигъмәтҗан Адудов, Чистайдан Закир ишан Камалов, Сембердән Тимербулат Акчурин һ.б.). Аның дәвасыннан баласыз хатыннар да, хәтта өметсез авыру булганнар да шифа тапканнар. Аның табиб буларак даны Пермь, Чистай, Сембер якларына кадәр җәелә.

Әхмәт бине Хафизетдин үзенең бу хезмәтендә этисенең «Шихем ханзал» дигән дәва белән сихәтләнүен яза. Бу дару медицинада «Шихем Ханзал» (Ханзал – II Колоквинт) исеме белән мәгълүм икән. Әлеге дару XI гасыр башы табибы Әбүгалисинаның «Тыйб» китабында да бар. Димәк, Хафизетдин хәзрәт бик борынгы галимнәрнең хезмәтләре белән дә таныш булган.

11. «Икъваил әр-рәсүл салиуллаһе…» Хәдис китаплары («Мөшкәтел-мөсабих» һ.б.) буенча 1324 һиҗридә язылган (милади 1906–1907).

12 – китап исеме күрсәтелмәгән.

13. «Икъвал рәсүл с.г.м». Төрле җыентыклардан тупланган кече кулда язылган китаплар.

14. «Рисалә-и фи әл-хаҗ» – хаҗилар өчен язылган, төрле китаплардан тупланган мәгълүматлар.

15. «Әр-рисаля-фи сәнгафа-и әр-риҗаи». Хәдис китапларындагы риваятьләре ышанычсыз булган сәхифәләрне туплаган китап. Утыз сәхифәлек бер әсәр.

16. «Китабәтел-нәсәб» – гарәп тарихчысы Ибне Халдун (? – 1406) һ.б. урта гасыр галимнәренең хезмәтләреннән файдаланып төзелгән җыентык. Һиҗри ел исәбе буенча 1297, милади буенча 1879/80 елларда эшләнгән.

17. «Тәфсил… әл-әфгаль» – гарәп грамматикасы буенча язылган филологик хезмәт.

18. «Әр-раббубийәте, әл-кәшфийәтә, әл-хәбүдийәтә, әл-халисә». Зур-зур ике томлык гарәби гыйбарәләр, «суфийа тәррикате»нә аңлату өчен кыйммәтле әсәр дип бәяләнә. Хезмәт һиҗри буенча 1300 елда, милади буенча 1882/83 елга туры килә.

19. «Җафар җамигъ», («Өстенлекне исбатлауга сәләтле, ярдәм итүче»), 1883 елда тәмамланган фәлсәфи әсәр.

20. Хафизетдин хәзрәт 1307 һиҗридә, 1889/90 миладида бик нык авырып китә, хәтта яшәвеннән өмет өзә. Шуннан соң ул: «Әгәр бу чиремнән котылсам, шәригать серләре хакында китап язар идем», – дип нәзер әйтә һәм бер атнадан терелеп, бер ай эчендә шәригать эшләре хакында бер китап язып бетерә.

21. «Риддайел-гатизал» – Коръәнне өйрәнү фәне буенча булган атаклы бәхәсләрне эченә алган теоретик хезмәтләр. Ул һиҗри исәп буенча 1312, милади буенча 1894/95 елларда язылган.

22. «Рисалә-и әл-истихкак» – «гыйльме фараиз» (математика) милек бүлү турындагы фән (һиҗри 1303, милади белән 1385/86 елларда язылган).

23. «Кәнүз әл-гыйшьйа» исемле гарәб китабының кыскартып эшләнгән варианты, шәригать хөкемнәре.

24. «Рисалә-и һиҗа» – гарәби гыйбадәт турында хезмәт.

25. «Исма-и риҗал әл-хадия әс-сихах». Хәдисләр белән шөгыльләнүчеләргә төбәп язылган. Ике бөтен Коръән зурлыгындагы китап. (Һиҗри буенча 1325, милади буенча 1907/1908 елларда язып төгәлләгән. Аны бастырып чыгаруга алынучы табылмаган.

26. «Иказ әл-мөслимин», алты бүлектән торган бер әсәр, һиҗри белән 1315, милади белән 1897/98 елларда тәмамланган).

27. «Рисалә-и мигъраҗ» – пәйгамбәрнең күккә ашуы, анда күргәннәре хакындагы хезмәт.

28. «Тәфсир аяте Йаэҗүҗ-Маэҗүҗ». Коръәннең 18 нче сүрәсендәге 90 нче аятенә карата язылган тәфсир. Әсәрнең бер данәсен күчереп, Бохарада укучы улы Әхмәткә дә җибәргән булган.

29. «Рисалә-и фиән-нәҗем әл-мәзәнеб». Һиҗри буенча 1329, милади буенча 1911 елда күктә койрыклы Галлей йолдызы күренү мөнәсәбәте белән язылган әсәр.

Хафизетдиннең улы Әхмәт тарафыннан табылган китаплар шушылар. Әсәрләре файдалы булсалар да, аларны бастырып чыгаручы табылмаган.

Хафизетдиннең, моннан тыш, үзе анализ ясаган китапларының читенә язган искәрмәләре дә кызыклы булса кирәк. Әхмәт Бәрәңгеви үзенең китабында этисенең гарәп телендәге васыятьнамә текстын һәм аның татар әдәби теленә тәрҗемәсен дә күчереп үтә.

Хафизетдин хәзрәт гомерендә дүрт мәртәбә никахка кергән.

Беренчесе, 1855/1856 елда Кашгар өлкәсенә сәяхәте вакытында була. Анда ул Корбанмөхәммәт һәм Фатыйма исемле кешеләрнең

Хәмидә исемле кызына өйләнә. Ул монда үзенең белеме белән таныла. Кашгар казые аның киңәшләренә колак сала. Хафизетдин Кашгарда укытучы булып та эшли. Аның «Шәрхе мулла», «Кыйраәт», «Шәмсия» «Сәлламел Голүм», «Шәрхе вәкая», «Шәрхе гакаид» (Тафтазани), «Холясаи әл-җәнаб» (Җәгъмәни), «Тәлхис», «Хикмәт» кебек ислам дине нигезе буенча язылган китаплардан дәресләр биргәне мәгълүм.

Моннан тыш, ул, Хотан шәһәрендә торганда, угыл ханыма – Сөләйманның яшь кенә кызына өйләнеп тора. Аның бу өйләнүе җирле йолаларны үтәү заруриятеннән генә булганга ошый.

Хафизетдиннең никахлы беренче хатыны Хәмидә бер ир бала китерә. Аңа Җәгъфәр Алтаяр дигән исем кушалар. Хәмидә соңыннан әлеге улы тәрбиясендә 1903 елда Кашгарда вафат була. Җәгъфәр Алтаяр, үзенә 40 яшьләр чамасында, Хафизетдин хәзрәтнең адресын һәм исәнлеген белеп, хат язышып, Бәрәңгегә килеп чыга. Кырык елдан соң ата һәм бала бер-берсе белән бик тәэсирле очрашу кичерәләр. Хафизетдиннең ярдәме белән Җәгъфәр Алтаяр, Кашгарга кайтып, кибет ачып, сәүдә эшенә керешә.

Хафизетдин өченче мәртәбә Кызылҗарда 1861 елда өйләнә. Анда ул Габделбари ахун Яушевның наибе, мөәзин Гомәр бине Хәмид әл-Кавалиның кызы Маһикамалга (ул 1918 елның 18 июнендә үлгән) никахлана. Балалары – Мөхәммәт-Фидаи Зәйнел-Гарәб, Гаязетдин, Мөхәммәт, Солтан Мөхәммәт Фатих, Мөхәммәд, Юшагы, Әхмәт, Зөлкарнәйин һ.б.

Дүртенче хатыны Фатыйма – дамелла Сибгатулла әл-Оруви кызы. Фатыйма беренче мәртәбә мулла Жәлалетдин бине Насретдингә кияүгә бирелгән була. Мулла Җәлалетдин үлгәч, аны Хафизетдинга бирәләр, Бәрәңгедә яшәп үлә.

Хафизетдин хәзрәт үз дәверендә татар дөньясында үзенең гыйлеме һәм дөньяга карашлары белән шактый танылган шәхес була. Аны Казанда да, Бохарада да, бөтен Казан артында да яхшы белгәннәр.

Кызганыч ки, аның гыйльми хезмәтләренең басылмавы ислам дөньясында исеме таралуга зур киртә булган. Соңыннан, үзе үлгәч тә, Русиядә мөселман диненә карата уздырылган коммунистик террор галим мирасына киң дөньяга чыгу юлын бикләп куя, һәм бүгенге көндә дә бу галимнең хезмәтләре басылып таралуга юл ачылганы юк әле.

Инде Әхмәт бине Хафизетдингә Ризаэддин бине Фәхретдин язган хатларга да күз салып узыйк.





Әхмәт бине Хафизетдиннең «Бәрәңге авылы тарихы« (1912–1913)









Әхмәт бине Хафизетдин күчергән китаплар.
Расих Зөлкәрнәевтән алынды. Бәрәңге

Метрика дәфтәрләре (1924, 1926). Куянавыл









Эш кәгазьләре. XX гасыр башы. Куянавыл



Шәкерт шәһадәтнамәсе. XX гасыр башы. Куянавыл



Ризаэддин бине Фәхретдиннең Әхмәт бине Хафизетдингә хаты (1919 ел, 1 май). Расих Зөлкәрнәевтән алынды. Бәрәңге

Мәгълүм булганча, Ризаэддин бине Фәхретдиннең мәшһүр «Асәр»е, Ибне Таймия, Ибне Рөшд, Ибне Гарәби турындагы тарихи-энциклопедик хезмәтләре татар укымышлыларын битараф калдырмаган. Алар арасында Ислам мәдәнияте, фәлсәфәсе, татар укымышлыларының мираслары белән кызыксынучылар аз булмаган.

Миңа, беренче буларак, Ризаэддин бине Фәхретдиннең С.Петербургка, урыс тюркологы Самойловичка җибәргән «Асәр»гә нигез булган беренче кул чыганаклары белән танышырга туры килгән иде. Алар арасында галим адресына җибәрелгән күпме татар укымышлыларының язмышлары, хезмәтләре турында мәгълүматларны күреп, исем китте. Билгеле, алар арасында Әхмәт бине Хафизетдиннең хатлары да булгандыр, тик ул вакытта (1973–1974 еллар) аларга игътибар ителмәгән.

Соңыннан, археографик экспедицияләр барышында Ризаэддин хәзрәтләренә хатлар язган кешеләрне яки аларның гаиләләрен күрергә туры килде. Алар белән аралашулар әлегәчә билгесез булган язма тарихи чыганаклар белән танышуларга юл ачты. Мәсәлән, заманында Ризаэддин хәзрәтләре Фәхретдин Хадими (1888–1976), Галиулла Заһидуллин (1874–1947), Әхмәт бине Хафизетдин Бәрәңгеви (1877–1924) кебек тарихи әсәрләр язучылар белән танышып, аларга хатлар язган булган.

Шулай итеп, безнең алда – Әхмәт бине Хафизетдингә язылган дүрт хат тексты.

«Бисмиллаһ әр-рахмән әр-рахим

Мөхтәрәм Әхмәд әфәнде!

Әссәламугаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтиһү!

4 нче март тарихлы мәктүбегез тәслим улынды. Фәкать таэссефкә аңа кадәр «Ибне Гарәби»[1] табгысы тәмам улмыш иде. Хафизетдин хәзрәт исмене дәреҗ итмәк насыйп улмады. Хафиз хәзрәт языларга тиешле бер кемсә имеш. Бунын Ибне Гарәби әсәрләре илә бу мөрәттәбә иштигалендә хәбәрем юк иде. Имди мәктүбеңезни «Асәр»дә язылачак Хафизетдин хәзрәт тәрҗемәсинә куйдым. Кирәк вакытта шунда дәреҗ кыйлыныр. Хафизетдин хәзрәткә кадәр бән бәлки, иртихал кыйлырмын. Шуйлә исә дә, тәрҗемәсине бер кадәр тәртип итсәм хилафдәм ай мөнасыйб заммәл илә үз урныйна куярлар.

[1] Мөхетдин Әбү-Габдулла Мөхәммәд бине Гали әл-Хәтими әт-Таги бине әл Гарәби (1163–1240). Ризаэддин бине Фәхретдин, аның мирасын өйрәнеп, 1912 елда Оренбургта «Ибне Гарәби» исемле хезмәтен бастыра.

Һәр ки бу хосусда үземнең бер кадәр соңга калыб хат язуым өчүн, һәм дә сезнең мәктүбегез гадәт тышында уларак кичегүб килүе өчүн таэссеф кыйлдым. Ләкин, әл-хәйер фима сәнигъ Аллаһ лә фима ирадә әл-габед[1].

Ризаэддин бине Фәхретдин.
Сәнә 1330, 22 җөмади әл-әүвәл. Оренбург.»
(1911 елның апрель аена туры килә).

*Сүзлекчә*

Тәслим улынды – тапшырылды.
Таэссефкә – үкенечкә.
Табгысы – басмасы.
Дәреҗ итмәк – бастырмак.
Мөрәттәбә – төзелгән.
Иштигалендә – шөгыльләнүендә.
Тәрҗемәсинә – биографиясенә.
Иртихал – үлеп китсәм.
Хилафдәм – каршы килеп.
Мөнасыйб – яраклы.
Заммәл илә – өтерләре белән.

«Мөхтәрәм мелла Әхмәд әфәнде!

3 нче август тарихында язмыш мәктүбеңезне Фатих әфәнде[2] безгә тәслим итде. Бу мәктүб исә шуңа җабаб улачакдыр. «Асәр»нең 3 нче җилды бер юлы басылыр өчен хәзерләнүб, йарин матбагага вирергә дия ният иделүб торылдыгы кичәдә тентү улыб, хөкүмәт тарафыннан забыт кылынды.

Мөсәүвәдәсе улмадыгы сәбәбле һәнүз басарга мөмкин улмадыгы халдә калды.

Өмидемездер ки хөкүмәт буны сәламәт халендә кайтаруб вирер, шундан соң инша Аллаһ табгы улыныр.

Борһан хәзрәт[3] тәрҗемәсене 3 нче җилде варуб йитәрме, йаки 4 нче җилдкә калырмы, ачык мәгълүм дәгел иде. Шуйлә исә дә үзем белдекем кадәр Борһан хәзрәт тәрҗемәсине язмыш идем. Әгәр дә мәктүбләрин гарийәт йуллай ирсаль итсәңез, күчрүб алуб үзеңезгә

[1] *Аллаһ иҗатына хәерле теләктә булыгыз!* – мәгънәсендә.

[2] Фатих әфәнде – язучы Фатих Кәрими булса кирәк.

[3] Борһан хәзрәт – Хафизетдиннең энесе. Борһанетдин бине Насретдин әл-Бәрәңгеви (1829–1901) Зөябашы авылыннан мәхәллә имамы һәм мөдәррисе, Хорамша Акчурин кызы Диләбрузга өйләнгән. Галим имам булган. Берара Уфада мөфтияттә казый булып та торган.

кайтарыр идек. Мәрҗани вә башка мәшһүр затлар мәктүбләрин бәрабәр күндерер улсаңыз, дәхи гүзәл улыр.

«Тарихе Бәрәңгеви» гайәт гүзәл бер шәйдер, күрер өчен һәм дә истифадә кыйлур өчен зийа дә морак итдем. Фәкать хосусый улдыйгындан үзине генә бастыручы табылуы шөбһәлидер. Гали әлитлак Орынбурда бастыручы улмаз. Казанда табылса гаҗәб дәгел. Шуйлә исә дә гүзәл бер эш эшләмешсез. Бәлки бер вакыт әрбабы чыкуб бастырырлар да.

Бәни Насер кабиләсенә 3 йөз нөсхә сатмакны өмид итмешсез. Шунлар фидакарьлек кыйлыб да буның өчүн 3 йөз сум акча итсәләр, шуның илә бастырмак да ачыг улмаз иде.

1200 нөсхә бастырсаңыз, шул өч йөз сум тәмам йитсә кирәк. Шуны бер хисаб кыйлсаңыз зарар улмаз. Вәссәлам.

Ризаэддин бине Фәхретдин.
30 нчы август, 1911 сәнә. Оренбург.»

*Искәрмә:*

Артына зәңгәр карандаш белән «Типографиядән белешдем. 200 битлек китаб. 211 сумнан артык төшмәс. Бәлки бик күп ким төшәр, дип әйтделәр.

Әгәр дә нөсхәсене йибәрсәңез ни бәһагә төшәчәген ачык бәййан кыйлырмыз», дигән сүзләр язылып, «Р.Ф.» имзасы куелган.

*Сүзлекчә*

Йарин – киләчәктә.
Забыт – кулга алынды, конфискация ясалды.
Мөсәүвәдәсе – караламасы.
Гарийәт – биреп торсагыз.
Ирсаль итсәңез – җибәрсәгез.
Истифадә – файдалану.
Зийа дә – күп, артык.
Морак итдем – көттем.
Гали эл-итлак – олы коткаручы.
Әрбабы – Ходаның теләге.
Бәни Насер кабиләсенә – Хафизетдин бине Насретдин туганнарына һәм балаларына.

«Бисмилла

Бөрадәр мөхтәрәм Әхмәд әфәнде!

Әссәламугаләйкүм вә рәхмәтә Аллаһу вә бәрәкәтиһү!

Ушбу сәнә, кичәсенә 21 нче сентябрь, 2 нче гыйнвар тарихлы мәктүбләреңез тәслим улынды. Һәрберин хозур кылыб иллә укыб

чыктым, вә истифадә кыйлдым. Әманәт мәктүбләреңез[1] тәслим улынмыш имеш.

Хафизетдин хәзрәтләрин «Ихъйа» вә «Әл-фотухат әл-милкиә» кеби әсәрләр илә мәшгульдер дия зан итмәкемдә идем. «Агай» моталягасы илә мәшгуль улмакындан тәгаҗҗеб кыйлдым. Бу шәй, бу илә шәйләр илә вакытында иштигаль итмәдикнең нәтиҗәсе улса кирәк.

Һәр хәлдә сәламәтлек илә гыйлем өстендә тормакы гүзәл бер шәйдер. Бездән сәлам әйтүб догасыны үтенсәңез иде. Маша раидә вәляды мәҗиденезе Мәрҗани хәзрәтләрендән мөхаррәф дийә ишетдем. Буңа сәбәб ни улмышдыр, гаҗәб?

Борһан хәзрәт тәрҗемәсе[2] васыйл улмады. Бунын өчүн җөда мөтаэссеф улдым. Шәмсетдин суфый әсәрләре язылмыш бер мәҗмугъны Орск өйәзендән Тимач имамы (шимди исмене оныттым) йибәрмеш иде. Бән бундан анчак бәгъзе шәйләри генә интихаб итдем. Җөмләсене йазсам, бер җөзъә «Асәр» кадәр улачак иде. «Әл-рисаләи әл-германия-и» һәм шунда йазма әсәр иде. Орск вә Верхурал өязләрендә күб булса кирәк.

Йаздыкыңыз «Әл-фикһ әл-Кәбир» хәбәрин ишетдикем улса да, нөсхәсине күрдикем йукдыр. Йукса, кулымызда улан «Асыл әт-тәүхид» дийә башланмыш вә Гали әл-Гари шәрех йазмыш Әбү-Хәнифә таэлифе улмаса кирәк.

«Килмийа-и сәгадәт» шимди үземдә вар. Орск шәһәренең имам Галиуллa әфәнде көтебханәмә һәдийә итди. «Имам Газали» рисаләсини йаздыгым вакыт аны күрмәмеш вә матбугъ улуб улмадыйгыйндан хәбәрдар улмамыш идем.

«Ләис фи әл имкян шәрхе» кимийәнең кангый сәхифәседер? Берәр мәктүбегездә бәййан итсәңез, бәни кәгазь актарудан котылдырырга сәбәб улыр идеңез. Бән лязем дәрәҗәдә фарси белмәз исәм дә, Аллаһ могавәнәт итсә максудый аңласам кирәк. Ләис фи әл-имкян сүзинә соң вакыт шәрех йазучылардан бери – Мөхәммәдгали әл-Утари иде. Бу кемсә фарсый лисаныйны билмәз иде. Шуның өчүн «Кимийа-и ра-иса» карамамыш улур.

---

[1] Әманәт мәктүпләреңез... – сүз Әхмәд бине Хафизетдиннең Ризаэддин бине Фәхретдин сорап язган хатына, җавап итеп, Ш. Мәрҗани хатларын җибәрү хакында бара булса кирәк.

[2] Бу урында Әхмәд Бәрәңгевинең карандаш белән язылган искәрмәсе бар: «Буны үктәбер 2 сендә язмыш идем. Әхмәд».

Хәзрәтнең бәди вә хавас сәламәт идикинә шадландык. Кашки заман мәсагыйд ула иде. Йанына варуб мәгасыйрьләре хакында мәгълүмат йазуб алур идем. Бән Мәрҗани тәрҗемәсине гайәт озун йаздым. Бунда бик күб адәмләрдән сүзләр ривайәт итдем. Вә Борһан хәзрәт, дамелла Галимҗан, Зәйнулла хәзрәт, ахунд Рахманколый вә гайреләр. Бу җөмләдән Хафизетдин хәзрәтдән һәм сүз ривайәт кыйлуб йазар идем. Бундан башка хәзрәтнең Габделхәбир әл-Мөслими (Кызылҗар), Нәҗиб мәхдүм (Казан), Гаяс мәхдүм, Хәбибулла ишан (Сабаҗай) хосусларында (?) күб мәгълүмати улачагы мәзнун. Иштә бунлар хакында йазуб алур идем. Нәҗиб мәхдүм дидекемдә хәтеремә төшде: бер тәкъсим тәрикә хакында (Мамыдышмы, Малмыжмы йаки Өрҗем өйәзендәме олуг бер урман вә милек дәгъвәсе иде). Ногман ахунд Ирмашев тарафыннан тәртиб иделмеш бер шәҗәрә вар иде. Шул шәҗәрәдә Байморад хәзрәтләре вә аның углы Нәҗиб мәхдүм варлыгы хатеремдә. Олуг бер гаиләдән гыйбарәт улан шул шәҗәрә ботаклары фаригълары Русиянең һәрбер мәһшүр шәһәрләринә таралмыш идеке дә мәгълүм иде. Субрания мәзкүр эшне бер сөаль өчүн Ногман ахундга кирү кайтардыгыйнда мәзкүр шәҗәрә субраниягә кайтмады. Иван Пуст исемле йәрминкәгә вардыйгында ахунд Уфага керде. Күрдикемдә «Ул шәҗәрәи үземез тәртиб итмеш идек. Субрания өчүн лазуме улмадыгыйн билдикемездән билгакес алуб калдым», – дийә сөйләде. Әл-кыйсса, шул шәҗәрә үзе, йаки мөсавидәсе Ногман ахунд фаригъләрендә сәламәт улса кирәк. Шуны алуб гыйна, йаки күчрүб (дөрестләб) безгә күндерә алмазсызмы? Аны рәдә йаздыйгым бик күб адәмләрнең мәзкүр шәҗәрәгә мәнсуб улачакларыйн зан итмәкдәйем. Шуның өчүн аның әһәмияте бәнем кашымда олугдыр.

«Бәрәңге тарихы» һәнүз басылырга башламадымы? Бән буны күбдән көтеб торам, бер нөсхәсене йибәрә күреңез!

Бөрбаш имамы Мөхәммәди хәзрәт һәм Мәрҗанидән (соң вакыт) мөнәҗәрәф улмыш дийә ишетдекем вар. Бу хәбәр дөрестмидер, сезгә мәгълүмме? Дәрест улса, бунының сәбәбе нидер? (Буны Ишмөхәммәдтән ишетдекем өчүн инабәтем камил дәгел.)

Хафизетдин хәзрәт Хөсәин мулла Фәизханины күрүб биләдерме? Аның хакында ничек сүзләр ишетдеке бар? Хөсәин мулла Мәрҗанинең иң самими мохлисләрендән вә сердәшләрендәндер. Бунының мәктүбәтене җәмигъ идүб бер рисалә кылмак касдендә йөрим.

Хәзрәт Ибне Гарәби әсәрләрин мотәләга кыйламы, кыйлса кангый әсәрләрен моталәгә кыйладыр? Гомумән, Ибне Гарәби хакында фикре ничүкдер? Мөхибләрендәнме, йаки мөбагазәләрендәнме? Әгәр дә ушбу соң фокарә хакында әһәмиятле мәгълүматыңыз улса билмөһадәт йазуыңызи риҗа идәм. Чөнки бәнем «Ибне Гарәби» исемле рисаләм табыгъ иделенәдер. Сездән бер мәктүб килүб йитешсә, шунда дәреҗ идәрем. «Русия исламлары кашында Ибне Гарәби» дийә бер баб куйдым, шунда Гали ишан, Габделхәбир әл-Мөслими, Мәрҗани, дамелла Галимҗан хәзрәтләренең Ибне Гарәби хакында улан фикерләрин кайд итдем. Хафиз хәзрәтнең хосусый бер фикере улса, аны һәм әлбәттә йазарым, ләкин җаваб тиз килмәк лазем.

Ризаэддин бине Фәхретдин
12 февраль, 1912 сәнә
Оренбург.»

*Сүзлекчә*

Зан итмәкемдә – уйлаганым.
Моталягасы илә – укуы белән.
Тәгаҗҗеб кыйлдым – гаҗәпләндем.
Иштигаль – шөгыльләнү.
Мөхәррәф – бозылган, үзгәртелгән.
Васыйл – ирешүче.
Җөда – бик тә.
Шимди – инде.
Анчак – ул вакытта.
Бәгъзе – кайбер.
Интихаб итдем – сайлап алдым.
Җөмләсене – барсын да.
Матбуг – басылган.
Кангый – кайсы.
Лязем – тиеш.
Могавәнәт – ярдәм итү.
Мәсагыйд – дәрәҗә.
Мәгасыйрьләре – замандашлары.
Мәзнун – уйланган.
Тәкъсим – бүлү.
Тәрикә – үлгән кешедән калган мал.
Фаригълары – нәсел тамырлары.
Мәзкүр – искә алынган.
Лазуме – кирәге.
Билгакес – киресенчә.
Мөсавидәсе – күчермәсе.

Мөнәҗәрәф улмыш – ызгышлар булу.
Инабәт – ышану.
Камил дәгел – шикле.
Мохлисләрендән – ихласлы дусларыннан.
Җәмигъ идүб – туплап.
Мөталәга – тикшерү, өйрәнү.
Кангый – нинди.
Мөхибләрендәнме – яратканнарыннанмы.
Мөбагазәләрендәнме – дошманнарыннанмы.
Билмөһадәт – күрсәтеп.
Рижа идам – үтенәм.
Кайд итдем – теркәдем.
Ишмөхәммәдтән – Ишми ишан Түнтәридән.

*Искәрмә:*

Бу хатның баш өлешендә Әхмәд бине Хафизетдин карандаш белән болай язып куйган: «8 данә мәктүбләр белән йибәрмеш хаты буладыр. Әхмәд».

«Мөхтәрәм бөрадәр Әхмәд әфәнде!
Әссәламугаләйкүм вә рәхмәтуллаһү вә бәрәкәтиһү
5 нче зөлкагдәдә

Йибәргән мәктүбеңезне алдым. Теге имамнан бушаганнан соң «Тарихе Бәрәңгеви»ны заказнуй итүб йибәрүеңезни үтенәм. Хафизетдин хәзрәт әхвалини үзем күчерермен һәм сезнең әсәреңездән алынганлыгыйны бәййан кыйлырмын.

Беркадәр мәктүбләрнең безнең тарафымыздан кирү кайтканлыгыны бәййан бийурасыз. Бу вакыйганы бөтенләй белмим, оныткан-мын ахры. Бу хакда ике төрле фикергә килдем.

Беренче, ихтималга күрә ул мәктүбләр заказнуй ителүб йибәрелгәндер дә, пависткасы безгә табшырылмагандыр, почтаханәдә йаткандыр да, баруб алмаган сәбәбле, кайтаруб йибәрелгәнләрдер.

Икенче фикер, (безнең үз тарафымыздан кайтарылганлыгы мәгълүм булса) бушагандан соң кайтарган булурмын. «Үзеңдә калса да йарый» – диб, йазылмаган мәктүбләрне, иске йазуларны әманәт хисаблаб мин һәрвакыт сахибләринә кайтарам.

Һәр ни бу хәбәр өчүн бик борчулдым. Әгәр дә әүвәлге ихтимал булган булса, зинһар шул мәктүбләрне «Тарихе Бәрәңгеви» берлә берлектә йибәрә күреңез.

«Асәр»нең калган җөзьәләрин мәрхүм Мөхәммәд-Хәсән әфәнде Акчурин[1] басдырырга хәзерләнгән иде. Шушы фаҗигаләр чыгу сәбәбле кәгазь вә эшчегә кытлык булуб, эш йулда калды.

Дамелла Мөхәммәдгауваз Рәхмәтулланың тәрҗемәсине иншаи Аллаһ «Асәр»гә дәреҗ кыйлурмын. Үзеңез йазган кадәр «Тәрҗемаи халь» кафи һәм вафи. Мин үзем аны йахшы белмим дә.

Әбүлгазыйның «Шәҗәрә-и Төрәк» нам асәре әһәмийәтле, ләкин аның Петербургта басылган нөсхәсе мәкъбүлрәк. Бездәге нөсхә ... битдә басылган. Догачыйңыз Ризаэддин бине Фәхретдин.

1917 сәнә, 8 синтәбер.

(P.S.) «Вакыт» идарәсе исминә йибәрелгән заказнуй мәктүбләр павистка буйынча почтаханәдән барылыб алынадыр (кантурда махсус кеше бар). Әмма үз фатирымызга йазылганларны китерүб бирәләр. Шуның өчен сез «Тарихе Бәрәңгеви»не үземезнең фатирымыз исменә йазыңыз.»

*Сүзлекчә*

Бәййан кыйлырмын – күрсәтермен.
Сахибләренә – ияләренә.
Дамелла Мөхәммәд – Гауваз?
Кафи – тиешле, кирәк кадәр.
Вафи – сүзендә торучы.
Мәкъбүл – күрелгән.

## Шагыйрьләр төбәге

Бәрәңге төбәгендә әлегә исеме мәгълүм булган беренче шагыйрь XIX йөзнең тәүге чирегендә яшәгән. Аның турында беренче мәгълүмат Шиһабетдин Мәрҗанинең тарихи хезмәтендә сакланып калган[2].

Ул мулла Мөхәммәдшәриф ахун бине Габдеррәшид бине Йосыф бине Кадер бине Бикмөхәммәд бине Тәтеш әл-Каргалый исеме белән мәгълүм. Аның этисе Оренбург Каргалысыннан булып, 1774 елда Казан шәһәрендә вафат булган. Ә вафатына кадәр, 1767 елның 26 маенда патшабикә Екатерина II Казанга килеп кит-

---

[1] Акчурин Мөхәммәд-Хәсән (1866–1916, 23 июнь), меценат – аның вафат булуы «Асәр»нең калган өлешләрен чыгарып бетерү ниятен өзгән.

[2] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар. II том. – Казан, 1900. – 22 б.

кәннән соң, ул монда таштан мәчет салдыруда зур тырышлык күрсәткән һәм анда беренче имам булып торган. Бу мәгълүматлардан күренгәнчә, аның улы 1774 елда, ягъни әтисе үлгәнче Казанда яшәгән булып чыга. Мулла Мөхәммәдшәрифнең туган елы мәгълүм түгел, шунлыктан аның 1774 елга кадәр үк мәдрәсәдә укыганмы, әллә инде эшли башлаганмы икәне хакында фикер әйтеп булмый. Ләкин аның, Портянурда имам һәм Бәрәңге ягында беренче ахун булып торганыннан чыгып, яхшы гына дини мәгълүмат алганлыгы бәхәссез. Мөхәммәдшәриф Портянурда 1832 елда вафат булган.

Шиһабетдин Мәрҗани Мөхәммәдшәрифнең шагыйрь булуын, аның үз кулы белән язылган «Оры аккан бәет», «Кәҗә бәете», «Чәй бәете», «Кече хатын» кебек шигъри, халык арасында таралган әсәрләре барлыгын яза. Боларның барысы да диярлек, кульязма хәлендә киң таралган булып, археографик экспедицияләр вакытында табылалар.

Шагыйрьнең әсәрләре, кулдан-кулга күчерелеп йөреп, күп укылганнар, ягъни ул әсәрләре XX йөзгә хәтле халык тарафыннан укылган шагыйрь булган. Укучылар, күчерүчеләр аның сүзләрен еш кына үзгәрткәннәр, текстны кыскартканнар һәм, шулай ук, күчергәндә, хаталар җибәреп, шигырьләрнең ритм-рифма техникасына да зыян китергәннәр.

Шагыйрьнең иң озын әсәре 1819 елда Түбән Оры авылын су басу фаҗигасенә багышланган «Аккан Оры бәете» булса кирәк. Аның кыскартылган бер варианты безнең тарафтан 2001 елда табылды. Ул җыентык 1840 елларда төзелгән шигъри әсәрләрдән тора. Анда Оры агу тарихыннан тыш «Чәй бәете», «Кәҗә бәете», «Зөлхәбирә бәете» һ.б. бар. Кульязманы күчерүче бик оста каллиграф булмаган, текстны хаталар белән күчергән. Ләкин аларны төзәтеп укырга мөмкин. Кульязма тузган катыргы тышлы, форматы 11х18 см лы булып, 43 биттән гыйбарәт. Җыентыктагы әсәрләрнең, нигездә, XIX гасырның беренче чирегендә тупланган булуына карап, андагы авторының исеме күрсәтелмәгән тагын берничә әсәрнең Мөхәммәдшәриф тарафыннан язылу ихтималы бар («Зөлхәбирә бәете», «Җиде кыз бәете» һ.б. ).

Без шулардан бүгенге укучыларыбызга 1818 елда, нindидер көчле яңгыр яву сәбәпле, Оры авылында булган фаҗигагә багышланган «Оры бәете»н (хәзерге Татарстан Республикасы, Арча төбәге, Түбән Оры авылы) тулы килеш тәкъдим итәбез. Әсәр моңарчы бик кыска вариантта гына билгеле иде.

## ОРЫ БӘЙЕТЕ

*«Илаhи бәйет будыр»*

Казан дигән илләрдә,
Оры дигән илләрдә
Алты аршын су булгай,
Уйсуврак йирләрдә.

Габидулла сачен алдырган,
Түбәтәйен калдырган.
Алла эшнә җара[1] йук,
Суда җанын алдырган.

Казлар очар йыракга,
Куәт бирсүн канатка.
Габид берлән Ибраhим,
Калды Коллар[2] зийратда.

Шул Колларга барыңыз,
Кабрен сораб белеңез.
Хәлал йиган малларыңны
Хәйер итеб бирүңез.

Әткәй чәчкән тарыны,
Әнкәй баруб урсана!
Габид берлән Ибраhимның
Хәлен баруб сорсана.

Әй, хәлалем, Сахибҗәмал,
Васыйәтем шул сиңа:
Йәтимләрне ташлар булсаң,
Бәхиллегем йук сиңа.

Әй, хәлалем, Сахибҗәмал,
Күзем туйа күрмәдүм.
Ак беләгең йастык итүб,
Йатакда йатыб үлмәдүм.

Әй, хәлалем, Миhербан,
Җаным, сине сүвдем мин.
Мин үйдән чыкган чакда
Кеше үйендә калдың син.

Габид әле йәтимлә кеше
Агублар китте су берлән.
Йәнә башын тыгыб барыб,
Зикер әйтер тел берлән.

Мөхәммәд байның чарлагы
Агуб киткән Колларга.
Эҗендәге маллары
Очраган йаман бурларга.

Мөхәммәд барган Колларга,
Чарлак эчен карарга.
Барып йиткәч, исе киткән
Агып барган малларга.

Мөхәммәд байның йортлары
Уйсу йиргә салганнар.
Әле дә шөкер Ходайга,
Үзләре исән калганнар.

Мөхәммәд байның чарлагы,
Бар да мамык маллары.
Су эчендә җан бирде,
Мөшкел икән хәлләре.

Әй, әнкәем, Гөлзифа,
Ак сөтеңне хәлал ит!
Хезмәтеңне итә алмадым,
Бәңа күңлүң бәхил ит.

Мулла чатны йитебдер
Ике угълум күрсәми.
Бу хәлләрне күргәнче,
Аз аң ари үлсәми.

Әй, элмәлек, элмәлек,
Элмәлеккә кершәдүк.
Бу хәлләрне күргәнче,
Үләремезне белмәдүк.

---

[1] Җара – чара.

[2] Коллар – хәзерге Арча районы, Кызыл Яр авылы.

Әй, хәлалем, Сахибҗәмал,
Дөнья кывыб йөрембез.
Дөнья артындин йөри тогач,
Ахирәткә йитембез.

Суларда дулкын агладыр,
Шәех агыб барадыр,
Агай, мине алсанай, диб,
Тилмереб йыглаб барадыр.

Әстерханның кырлары,
Йәмле микән җуллары.
Җан алубән, җан бирмәкнең
Мөшкел икән хәлләре.

Өйлә килде, йәстү әйтеб,
Икендейә җату улмадым.

Әй, балалар, җылама, зәгыйфь,
Васыйәтем әйтелгән.
Йәтимләрне ташлар булмыйк,
Мөхиб Аллаһ йук сиңа.

Казлар очар йыракга,
Куәт бирсен канатга.
Хәсән берлә Муса абзый
Калай Симипулатта.

Сулар көчле агадыр,
Габид агыб барадыр,
Агайлар, бәни алсана, диб,
Тилмереб йыглаб барадыр.

Шәхми чәчен алдырган,
Түбәтәйен калдырган.
Аллаһ эшинә һич чара йук,
Суда җанын алдырган.

Габиделхалик әйтүбтер,
Әй, угланнарым, киттек, диб,
Дөнйа артыннан йөри торгач,
Ахирәткә йитдек, диб.

Әй, элмәлек, элмәлек,
Элмәлеккә кермәдек.
Гыйззәтә җанум  чыкмай тизи,
Кем үләрен белмәдек.

Мөхәммәд байлар бай әйткән,
Бар да мамык маллары.
Су эчендә җан бирүе,
Мөшкел икән хәлләре.

Мөхәммәд байның чарлагы
Агыб киткән Колларга.
Оры шәһри халкының
Йортын салган уйсуга.

Әле дә шөкер Аллага,
Үзләре исән калганлар.

Ул әйткәйсен дәлилә
Мин Орга бирә алыймма,
Байдин үзүм акча алуб,
Берсенә бүрүк алыймма?

Барсана, углым, барсана,
Сүгән бүркең алурсың.
Анда сиңа әҗәл килсә,
Безне күрмәй калурсың.

Әвә эткәй син үзүң
Нидин әйттең бу сүзең!
Суда агыб килгән чакта
Алалмадум бән күзүм.

Әй, әнкәйем, Гөлзифа,
Ак сөтеңне хәлал ит,
Кызганмый җийган малыңны
Үзем өчен хәйер ит.

Мөхәммәд байның чарлагында
Агыб килә ун кеше.
Ун кешенең рыскалында
Вә алмаган бер төшесе.

Йоны йулга тузгандыр,
Арасындайын өзгәндер.

Оры шәһәре байларын,
Бар да мамык малларын.
Аны күргән ирәнләрүнең
Тик чыкмаган җанлары.

Олуг җомга көн ирде,
Хакдин афәт ирешде.
Бозлар агыб, сулар агыб
Һәлак булды маллары.

Байлары мәсҗеддә ирде,
Атлары тышта ирде.
Атлар агуб китә вә бу
Кешеләр чагырушды.

Раст икенде вакытта
Атлар ага башлады.
Гарәсәт ахшам вакытында
Сулар агыб ташдылар.

Сали Садыйк улыннан
Ивләр ага башлады.
......................... вакытда
Күб кешеләр үлдиләр.

Су буйында Мусалар,
Судан түбән Мөхәммәд бай
Өйләр акканны күрүб,
Йыглашдыйлар, җөмлә, һай.

Мөхәммәд байның йортлары
Агыб китте җөмләсе.
Эчендәге ирәнләрнең
Шаһид булды барчасы.

Җөмлә үлгән кешеләр
Агыб барган Колларга.
Иртә торыб, авыл халкы
Һәм чыкдыйлар эзләргә.

Үлгән кешенең барчасы
Йегерме биш улдыйлар.
Бер Алланың тәкъдире илә
Җөмлә шаһид булдылар.

Ашыт суы буйында
Бары үлеб йатдылар.

Халык җыйлыб, судлар килеб,
Күммәгә бойордылар.
Үлекләрне һәм күмдиләр,
Сорарлаб да йаздыйлар.

Хәддиндин бойорсын, диб,
Падишаһа салдыйлар.
Мөхәммәд байның зарары
Кырык биш мең булубдыр.
Муса байның зарарлары
Йөз кырык мең булубдыр.

Габделхалик мулланың
Ивләре һич калмады.
Шул мулланың хатыны
Үлек булыб табылмады.

Ул мулланың алабән
Тазларга илтеп күмдиләр.
Ишан, һәмма муллалар
Тилмереб агыб китдиләр.

Үзләре исән калганнар,
Хакка шөкер кыйлыбдыр.

Талибләрдән бер талиб
Агыб китде су берлән.
Аны күрүб, тагы бер талиб
Зикер әйтер тел берлән.

Талибләрнең зарурларын
Һичберәүсе белмәде.
Күб «Коръән»ләр агыбдыр,
Күп китаплар агыбдыр.

Аны күрүб, һәрбер талиб
Зари горьян улубдыр.
Талибләр күб йыглады,
Остазлары һәм йыглады.

Бер Аллага дога кыйлыб,
Һәммәси хәйран улдый.
Догаларыйн кыйлурлар,
Иҗабәтен кыйлсалар.

Хуб кыйлыб хозурында
Зарилыклар кыйлурлар.
Намазларыйн кыйлурлар,
Догаларыйн кыйлурлар.

Оры шәһрин су алдый,
Унсигезенче йыл ирди.
Маллары агыб китде,
Үзләре хәйран калды.

Бу фаҗиганең төгәл булган вакытын әдәбият тарихында белмиләр иде. Әлеге бәеттә бу хакта төгәл хәбәр китерелә. Элеккерәк елларда Арча якларында Оры авылының суга агуы хакында картларда аз-маз мәгълүмат бар иде. Хәзер инде бөтенләй белмиләр. Бу авыл белән Портянур арасы 40 чакрым чамасында. Түбән Оры авылы Татарстан белән Мари Эл чигендә урнашкан.

## КӘҖӘ БӘЕТЕ

*(Кулъязмада «Кәзә бәйете» дип язылган)*

Һәр кәҗәнең ике исме булыр, имеш:
Бере – мирза, бере каза булыр, имеш.
Ул кәҗәне ярлы кеше асрар, имеш,
Сыер урынына сөтен савып эчәр имди.

Игътибар юк ул кәҗәнең гакылына,
Инабәт юк ул кәҗәнең сакалына.
Кая барсаң, шунда аны гайбәт кылгыл,
Язык булмас, бәлки савап булыр имди.

Ул кәҗәнең караклыгы иртә белән,
Җиңеп булмый аны асла киртә белән,
Үгет алмый колагына киртү белән,
Кеше күрсә, кире чигенеп сикерер имди.

Ул кәҗәнең аерылыдыр тояклары,
Бакча эчендә гизәр аның аяклары,
Калмас аннан кәбестә, суган кыяклары,
Һәркайсының башын кыркып йөрер имди.

Йөрер үзе киртәнең буе белән,
Ашлыкка ашлыкка керүнең уе белән.
Ялгыз йөрмәс, ул йөрер туе белән,
Чүмәләне үрә торып ашар имди.

И яраннар, ул кәҗәне асрамагыз,
Асрасагыз, ачык тишек калдырмагыз.
Ат алдыннан солыгызны калдырмагыз,
Солы күрсә, җанын фида кылыр имди.

Бәгъзесе ятыр аның печәнлектә,
Бәгъзесе ятыр аның начальникта,
Караклыкны үгрәнер кечеклектә,
Акча биреп, иясе түләп алыр имди.

Ул кәҗәнең тәкәсе мөрәвәтле,
Үзе чиркин сыйфатлы, кабих затлы.
Суйсаң, аның тиресе бик кыйммәтле,
Читек тексәң, биш елга чыдар имди.

Дәхи мирза, диерләр тәкәсенә,
Мәһабәтле басып торыр һәммәсе дә,
Түрәмен, дир, куй-сарыкның барчасына,
Аларны кырдан башлап кайтыр имди.

Бәрәңге төбәге белән бәйле тагын бер кызыклы мәгълүматны теркәп калдырасы килә. Ул – Таһир белән Зөһрәнең легендар мәхәббәте тарихына багышланган атаклы «Бабахан дастаны» исемле әсәр белән бәйле. Әлеге әсәрнең авторы Сайяди икәнлеге күрсәтелгән. Сайяди бу мәхәббәт турындагы сюжетны борынгы татар дәүләтендә Баба хан идарә иткән дәвердәге вакыйганы тасвирлап язган булган. Татар әдәбияты тарихында «Бабахан дастаны»ның иң тулы нөсхәсе итеп Куянавылда 1818 елда Бибиганбәр Йосыф кызы тарафыннан күчерелгәне санала. Хәзергә хәтле татар әдәбиятчылары бу әсәрнең күчерелү урынын билгеләгәндә уңайсыз хәлгә калалар иде. Кайдагы Куян авылы булыр икән бу, дигән сорау туа иде. Ник дигәндә, Татарстанның Актаныш районында һ.б. төбәкләрдә дә Куян авыллары бар бит. Бу сорауның җавабын без 2011 елда, Мари Республикасының Бәрәңге төбәгенә оештырылган археографик экспедиция вакытында, Куянавылның әүвәлге мәрхүм имамы Борһанетдиннән калган кулъязмалар арасындагы бер язмадан табып аныкладык.

Ул язмадан аңлашылганча, Бибиганбәр Йосыф кызы 1800 еллар чамасында Куянавылда туган, 1817 елда Шәфигулла исемле Куянавыл егетенә кияүгә чыккан һәм аның 1818 елда Мотыйгулла исемле улы туган. Шулай итеп, борынгы татар дастанының күчерелү тарихына бер кызыклы һәм әһәмиятле деталь өстәлде.

# ТӨБӘК ТАРИХЫННАН ЯКТЫ СӘХИФӘ

*Рәшит Галләм*

Табигать шартларына бәйле рәвештә, кешеләр элек-электән яшәү өчен уңайлы урын сайлап алырга тырышканнар. Бу уңайдан Мари Элның Идел, Чулман кебек олы елгалардан читтәрәк, Илләт елгасының югары агымындагы урманлы җирләрдә урнашкан хәзерге Бәрәңге районы җирләре иң уңайлылардан саналмаган. Археологлар билгеләвенчә, бу якларда беренче кешеләр б.э. кадәр V–IV меңьеллыкларда яши башлаган.

Билгеле булганча, милли аңның бер чагылышы һәм гәүдәләнеше буларак, төбәк, авыл тарихлары ил, халык тарихларын калыплаштыруда, аларны конкрет җирлеккә беркетеп, тарихи материал белән баетуда әһәмиятле урын алып торалар. Тамчылардан күл, елгалардан диңгез хасил булгандай, авыл, төбәк тарихларыннан олуг дәүләтләр, милләтләр тарихы оеша.

Шунысы игътибарга лаек – татарлардан туган як тарихын өйрәнү-язу эшенең аеруча җанлану дәверләре, аларда үзаң үсүгә бәйле милли күтәрелеш, алгарыш чорлары белән тәңгәл туры килә. Бу табигый да. Чөнки күрсәтелгән процесслар милли тарихка булган ихтыяҗны (шул исәптән авыл, төбәк тарихларына булган сорауны да) бермә-бер арттыра. Шуңа нисбәтле, татарларда туган як – авыллар, төбәкләр тарихын өйрәнү-язу эшендә өч җанлану, алгарыш чорын билгеләп үтәргә була: 1) XIX йөз ахыры – XX гасыр башы (1917 ел инкыйлабына кадәр); 2) 1920 еллар – 1930 еллар башы; 3) 1980 нче еллар ахырыннан алып, хәзергәчә (иң яңа чор). Игътибар итсәк, авыл, төбәк тарихларыннан башланган күпчелек кульязма, басма хезмәтләр нәкъ менә шушы чорларга карый. Кагыйдә буларак, боларның авторлары – үз чорларының укымышлы,

мәгърифәтле кешеләре (патша Россиясе шартларында күбрәк дин әһелләре, мәдрәсә мөгаллимнәре, башка мөхтәбәр затлар, соңрак – мәктәп укытучылары, хезмәт ветераннары, галимнәр һ.б.).

XIX йөз ахырында – XX гасыр башында күзәтелгән милли алгарыш шартларында туган төбәкнең үткәнен, табигатен, гореф-гадәтләрен, бәйрәм йолаларын, һөнәр-кәсепләрен, сөйләм телен чагылдырган кулъязма, басма хезмәтләр татарларда туган якны өйрәнү эшен гамәлгә куеп, аны гыйльми кимәлгә күтәрү өчен ныклы нигез булдырдылар. XX йөз башында иҗат ителгән шундый әсәрләрнең классик үрнәге булып, мәсәлән, Әхмәт бине Хафизетдин бине Насретдин әл-Бәрәңгевинең кулъязма «Бәрәңге тарихы» тора. 1912–1913 елларда язылган бу тарихи хезмәттә хәзерге вакытта күрше Мари Эл Республикасының Бәрәңге муниципаль районы үзәге булган Бәрәңге авылының XX йөз башынача үткәне бәян ителә.

Мәгълүм булганча, Мари Элның Республикабызның Арча, Әтнә районнарына орынып торган көнчыгыш бер төбәгендә – хәзерге Морки, Бәрәңге, Мари-Төрәк муниципаль районнары җирлегендә татарлар бүген дә күпләп яши. Бу – алар элек-электән төпләнеп яшәгән Казан арты, Арча, Әтнә яклары белән тыгыз тарихи бәйләнештәге төбәк. Шуңа да монда эреле-ваклы татар авыллары шактый күп. Бәрәңге шуларның иң зурларыннан. 1931 елда район үзәге итеп тәгаенләнгәнчегә кадәр ул саф татар авылы булып йөргән. Хәзер исә анда сигез меңчамасы кеше яшәп, шуның алты меңләбен татарлар, калганын, нигездә, мари халкы вәкилләре тәшкил итә. Тирә-якта Портянур, Мазарбашы (Алашайка), Иске-авыл (Таштоял), Яңавыл (Ирнур), Олыкыр (Поле Кугунур), Куянавыл кебек күп кенә башка татар авыллары да урнашкан. Гомумән алганда, хәзерге вакытта Бәрәңге муниципаль районы җирлегендә яшәүче унсигез меңләп халыкның 48 % ы чамасын татарлар, 43 % ын марилар, 9 % ка якынын башка милләт вәкилләре (нигездә руслар) тәшкил итә. Шулай итеп, Бәрәңге төбәген чын мәгънәсендә тарихи бер татар төбәге, Казан артының табигый дәвамы итеп карарга була. Әле дә булса бәрәңгелеләр халкыбызның элек-электән килгән күркәм гореф-гадәтләренә, йолаларына тугры калып яшиләр.

Төрле фаразлар булса да, Бәрәңге авылы атамасының килеп чыгышы әлегә ахыргача ачыкланмаган. Әмма аның бакчада игелүче бәрәңгегә бәйле булмавы хак. Безнең тарафтан авылның XVII йөз ахырына караган ясаклы хуҗалыкларны язу-теркәү,

XVIII йөз башында тутырылган, җан башын исәпкә алучы ландрат кенәгәләрендә «Янгильдин починок» яисә «Починок Янгильдин» (ягъни, «Янкилде» яки «Җанкилде пүчинкәсе») дигән икенче бер исем астында теркәлүе дә ачыкланды.

Хәзерге Бәрәңге районының үзәге булган Бәрәңге авылының тарихы «Бәрәңге тарихы»нда шактый тәфсилле итеп бәян ителгән. (Бу кулъязма истәлек турында алдагы мәкаләдә шактый мәгълүмат бирелгән иде инде. Әмма без аны тулыландыру максаты белән сүзне дәвам итәргә булдык.) Әлеге хезмәтнең авторы Әхмәт бине Хафизетдин әл-Бәрәңгеви (1866–1931) авылның «асаба», ягъни нәселдән күчмә муллаларыннан булып, аның бабасы Насретдин дә (1796–1865), әтисе Хафизетдин дә (1825–1917), агасы (әтисенең энесе) Борһанетдин дә (1829–1901) төрле елларда Бәрәңгедә имамлык иткәннәр. Алар барысы да үз чорларының укымышлы, мәгърифәтле кешеләре, дини, тарихи характердагы, шулай ук медицина өлкәсендәге шактый күп кулъязма хезмәтләрнең авторлары (аларның кайберләре «Бәрәңге тарихында»да тасвирлана).

«Тарих» авторының әтисе дамелла Хафизетдин, мәсәлән, Бохарадагы «Мәдрәсәи Гарибиядә» (русча «медресе Мир-Араб») укыганда булачак күренекле тарихчы-галим Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре (1818–1889) белән дуслашып, аның иң якын мөридләреннән, теләктәш-фикердәшләреннән берсенә әйләнә. Соңыннан алар хат алышып та торалар. «Хөрмәтле туганым Хафизетдин!» яисә «Хөрмәтле вә кадерле туганым Хафиз!», дип мөрәҗәгать итә аңарга Ш. Мәрҗани үзенең мәктүбләрендә, аларны дустына, фикердәшенә «хөрмәтле туганым дамелла Хафизетдингә», «хөрмәтле туганым, фазыл дустым дамелла Хафизетдингә», дип юллый. Ул хатларның беришләрен имам Хафизетдиннең улы Әхмәт бине Хафизетдин үзенең «Бәрәңге тарихы»на да урнаштыра.

Моннан тыш «Тарих» авторының тарих, тел белемнәренә караган башка кулъязма хезмәтләре булуы да мәгълүм. Автор үзенә «әл-Бәрәңгеви» тәхәллүсен ала. XIX гасырда – XX йөз башында мәгърифәтле татарларда туган җиргә нисбәтле мондый тәхәллүсләр киң таралыш алган була.

Хәзерге вакытта «Бәрәңге тарихы»ның автор 1918 елда гарәп шрифтында иске татар язуы (иске имля) белән үзе күчереп язган бер нөсхәсе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

20,5×13,5 см форматтагы 195 битле бу кулъязма басма бизәкле катыргы тышлык белән тышланган. Аның бите 14×8 см үлчәмдәге унсигезәр юлдан торган, тексты зәңгәрсу кәгазьгә кара, матур, каллиграфик язу белән төшерелеп, һәр биттә кара, сары һәм кызыл сызыклар белән кысаланган.

Белүебезчә, бу «тарих»ның тагын бер кулъязма нөсхәсе Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәсендә, аның кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

1990 еллар башында, Бәрәңге районы хакимияте мөрәҗәгате буенча (ул чорда район хакимияте башлыгы Э.С. Сибгатуллин иде), күренекле галим, тел белгече Рифкать Әхмәтьянов «Бәрәңге тарихы»ның ТӘһСИ мирасханәсендәге нөсхәсен, аның үзенең искәртүенчә, эчтәлеккә зыян китермәүче кайбер кыскартулар белән, текстта очраучы иске төркичә, фарсыча һәм гарәпчә язылган урыннарны хәзерге татар теленә тәрҗемә кылып, кулъязманы эчтәлеккә нисбәтле «Кереш сүз», текстологик искәрмәләр, тасвирламалар белән тулыландырап, кирилл язуына күчереп чыга. Басма хәрефләр белән җыелган 232 битле бу күчермә текст хәзерге вакытта, эш башкаручының үзеннән кала, берничә данәдә Казанда (шул исәптән бу юллар авторында да) һәм Бәрәңгедә саклана.

XIX йөздә – XX гасыр башында иҗат ителгән җирле тарихлар төзелеш принциплары, аларның чыганак нигезләре, тарихи материалны бирү ысуллары буенча бер-берсеннән әллә ни аерылмыйлар. Гадәттә, аларда авылның табигате, аңа нигез салучылар, аларның токымнары, авылның, аның атамасының килеп чыгышына бәйле тарихи риваятьләр, мәгърифәт, мәчет, мәктәп-мәдрәсәләр тарихы, төбәкнең атаклы кешеләре, дин әһелләре, шуларга нисбәтле шәҗәрәләр үзәк урынны алып тора. «Бәрәңге тарихы» да шундыйрак тәртиптә эшләнгән. Шулай да ул башка күп җирле тарихлардан берникадәр үзгә. Беренчедән, хезмәт «Бәрәңге тарихы» дип аталса да, анда авылның тарихын оешканнан алып, XX йөз башынача хронологик эзлеклелектә бәйнә-бәйнә тезеп бәян итү омтылышы күренми. Мәгълүм дәрәҗәдә ул эчтәлек, мәгънә ягыннан берберсе белән әллә ни бәйлелектә булмаган аерым-аерым мөстәкыйль сюжетлардан торучы тарихи хикәятләр, чыганаклар җыелмасын хәтерләтә. Авторның игътибар үзәгендә – аның үз нәселе, шуңа бәйле Бәрәңге һәм аның тирә-ягындагы башка авыл муллалары,

аларның нәсел шәҗәрәләре, тәрҗемәи хәлләре. Кулъязма өстендә эшләгәндә ул, иң элек, гаилә архивына, шәхси китапханәсенә, шулай ук халык хәтеренә, аның бай күңел сандыгына мөрәҗәгать итә. «Бәрәңге тарихы»ның тагын бер характерлы үзенчәлеге – гаиләдә төрле елларда төрле кешеләр тарафыннан язылып, төрле кешеләргә юлланган бай мәктүбәт тупланмасыннан, васыятьнамәләрдән киң файдаланып, әлеге хат, васыятьнамә текстларының байтагын кулъязма эчендә китерү. Бу хатлар, васыятьнамәләр, чынлыкта, үз чорының елъязмасы буларак кабул ителәләр. Шулай итеп, «Бәрәңге тарихы»н, бер яктан, авыл яисә нәсел тарихы дип тә, икенче яктан, XIX – XX йөз башы мөселман дин әһелләре мохитен чагылдыручы елъязма, Ризаэддин Фәхретдиннең «Асәр»е рухындагы тарихи белешмәлек, чыганак дип тә характерлап була.

Тарих Бәрәңгенең географик урынын, табигатен, хуҗалык тормышын тасвирлау, аның оешуына бәйле тарихи хәбәрләрне бәян итү белән ачыклана. «Бәрәңге, – дип яза автор, – Казан шәһәреннән 110 чакрым шималендә (төньяк) Уржумга табигъ (Уржум тарафындагы) дүрт мәчетле бер карьядер (авылдыр) ки, Русия лисанында һәм аз гына тәхриф (хәреф хатасы) белән «Параньги» тәгъбир. Ошбу карья мәзкүр өяз дәхилендә булган унбер карьяләрнең иң олысы булганлыктан, ерак җирләрдә дә барлык бу карьяләрне бергә «Бәрәңге ягы», диләр. Вә «Илләт урманы» дигән кәҗүнни урманга (казна урманына) якынлыгы өчен «Урман арты», дип тә атыйлар».

«Бәрәңге карьясе иңкел вә тигез, гүзәл урында урнашкан, – ди ул, аның табигатен тасвирлап, – карьянең урталыгыннан ага торган ике зур елга булып, авылдан чыгарак, алар бергә кушылалар». Шуннан тагын ул: «Моннан йөз генә ел элек (ягъни XVIII йөз ахырларында – XIX йөз башларында) Бәрәңге бик кечкенә, имеш... Хәзердә Апур, Урмай дидекләре җирләр һәм Яхенлек елгасы балыклы су булып, аннан югары хәбиб-шәригъләр исә гел вак-вак куаклык булган», дип тә искәртә.

«Әгәр дә бер кемсә бабаларыбызның каләмнәреннән түгелгән язуларның кадерен белсә, күз тутыясы кебек саклар», – ди автор, ул кулъязма истәлекләрне бәяләп.

Авылның оешуына бәйле риваять буенча, «Иң элек Бәрәңгедә мәҗүсләр булып, Бураш вә Чураш исемендәге ике мөселман килеп, боларны кумышлар». «Тарих» авторына мәгълүм булганча, Бәрәңге халкы берничә кабиләдән (ырудан) таралып, болар арасында

Тугнай һәм Рәхимкол нәсәпләре аеруча атаклы икән. Шуннан аерылып, Бәнү, Әбәдле кебек бүтән ырулар пәйда булган. Аларның кай тарафтан килеп урнашулары билгесез. «Фәкать Кәчеләр бабасы Ишморат (мулла Ишморат бине Дәмин бине Давыт) Каргалыдан (Ырымбурның Сәет бистәсеннән) һәм Чураш Кәчемнән (Касыйм якларыннан) килгәнлеген риваять итәләр», – ди автор. Һәм сүзен: «Кыскасы, ошбу кабилә-ыру, нәсел-нәсепләрнең Бәрәңге җиренә килеп урнашуларына берничә йөз еллар бардыр. Димәк ки, шушы күп кабилә инде береккән. Бәрәңге авылы бүген кырык йөз (дүрт мең) кешедән артык. Кыскасы, бер шәһәр кебек», дип йомгаклый. Шунда ук шул ырулардан кайберләренең нәсел шәҗәрәләрен дә китерә.

Авылның хуҗалык тормышын тасвирлап, «Бәрәңге басуы башка әтраф (як) басулары кебек өчкә тәкъсим ителгән, – дип яза автор, – берсендә арыш, икенчесендә солы яисә арпа, йә карабодай игелә. Өченче басу бер ел ял итә. Туфрагы кара, уңдырышлы – ашлык яхшы уңа. Шул сәбәпле халкы, гомумән, игенче: җир эшкәртеп терек-лек итә һәм имам вә мәзинләрне дә шуның гошере белән тәрбия вә тәшвиш кыла».

Бәрәңгедә һәр атна дүшәмбе көн бер мәртәбә базар булып, кыш фасылында, елга бер мәртәбә, «Май базары» дип аталган атаклы базар җыела торган була, анда ерак җирләрдән сәүдәгәрләр һәм кунаклар килә икән. Ул базарда төп товарлар исәбендә ашлык, тере һәм кызыл мал йөри. Халкы да шулар белән эш итә һәм шул нигездә зур гына сәүдәгәрләр дә бар икән. «Тарих» авторы соңгыларын шелтәләп тә ала: «Бурычсыз байлар – ташпулатлы сәүдәгәрләр зәкят, хаҗ кебек шәригать кушканнарны үтәргә бик яратмыйлар һәм вәгазьләрне кабул итмиләр. Ләкин сабан туйлары һәм җыеннар вакытында фәкыйрь-мохтаҗ халыкка чүлмәк-чүлмәк бал (сыра) чыгаралар».

Читтән килеп торучылар арасында берничә мөселман һәм күп кенә руслар да булып, кайберләре хәтта йөз еллап торалар икән. «Ләкин алар мөселманнардан иҗарәгә (арендага) җир алып торалар».

«Моннан 40 еллап элек (ягъни 1870 еллар тирәсендә) Лажы дигән карьяне үткәч, – дип хәбәр итә автор, – Бәрәңге җире һәм мөлке булган урында тегермән бар иде. Хәзер инде Лажыга караган кечкенә тегермәнгә барып йөриләр. Ләкин бу соңгысы авыл халкын канәгатьләндерми. Моны әлеге элекке тегермәннең тегермәнчесе

булып торган Андрей исемле рус канал казып шул авылга кертте. Элек каналы тар гына булса да, хәзер аны шактый киңәйткәннәр. Лажы һәм Бәрәңге халкы күбрәк файдалана торган тегермән шул. Болардан башка, тирәдә өч җил тегермәне салынып, боларның берсе икенче авылга күчерелеп, берсе туктатылып, икенчесе берәр потпот ярым арыш күләмендә генә арыш тартып ята».

Авылның эчкән суына тукталып, «Бәрәңге халкы, башлыча, кое суы эчә, – дип яза ул. – Һәркемнең үз ихатасында коесы булып, аннан тыш атаклы өч чишмәләре бар. Бу чишмәләрнең бигрәк тә Таш чишмә дип аталганы суының бик татлы һәм шифалы булуы белән атаклы. Бу чишмәләрдән күбрәк 4 нче мәхәллә файдалана, чөнки алар авылның тышында булгач, бүтән мәхәлләләрдән ераграк».

Бәрәңгене хәвеф-хәтәр, бәла-казалар да читләтеп узмый. «Тарих»тан мәгълүм булганча, мәсәлән, 1872 елның 14 маенда һәм 1906 елның 3 маенда авылда зур янгыннар булып уза. Соңгысы карьянең базар урамындагы Әкет дигән кемсәнең урынында торучы «Кипкән Бәсир» кушаматлы бер русның кибетеннән чыгып, ярты сәгать эчендә өч мәхәллә янып, зыян гаять күп була. «Һавада такталар очып йөрде, – дип яза бу көчле янгынның шаһиты булган Әхмәт бине Хафизетдин. – Иртән ризыклы кешеләр кичкә ач-ялангач калдылар. Берәр көн басуда тордык. Соңыннан берәр айдан хәлле кешеләр йорт төзеп керделәр. Бу вакытта беренче мәчет һәр дүртенче мәчет салырга дип әзерләнгән бура һәм такталар янды». Хәер, нәтиҗәдә аңарчы киртәләре дә булмаган бәгъзе адәмнәр соңыннан үзләренә биек капка-коймалы яңа төзек, матур йортлар салып керәләр.

«Тарих»та бәян ителгәнчә, Бәрәңгенең Урта мәчет дип йөртелгән Беренче мәхәллә мәчетен алда тасвирланган янгын казасыннан соң, 1907 елда, үзе Мамыш авылыннан булган Габделхәбир бине Фәтхулла исемле бер кеше бина кыла. Бу мәчет бик матур булып, авылның урта бер җирендә, Чарсу (Зур базар) мәйданында урнашкан була. Башка урындарак булган, аннан әүвәлге мәчет сигез ел гына тора. XIX гасыр урталарында булса кирәк, мәдрәсә бинасын Казан байларыннан Мортаза Әсхәбов атлы бер кеше торгыза.

Әмма, әйтелгәнчә, «Тарих» үзәгендә авылның үткәненә, анда дин, мәгариф тарихына нисбәтле авторның нәселдән күчмә дин әһелләреннән булган мәгърифәтле үз нәселе, Бәрәңге һәм аның

тирә-ягының башка күренекле дин эшлеклеләре, заманының атаклы, мәгълүм шәхесләре тора.

Авторның бабасы Насретдин (Насыйретдин дип тә язылa) Бәрәңгегә һиҗри ел исәбе белән 1240 елда (милади белән 1824 елда) килеп, имамлык итә башлый. Ул – Казан өязе, Мәмсә волосте, Ташкичү авылының (хәзер Арча районында) указлы иман-мөдәррисе Габдессәлам (Габделислам дип тә бирелә) бине Габдерахман әл-Нурсиви хаҗи вә имам Рәфыйк әл-Туктари кызы Гөлфизар (яисә Гөлгазар, 1820 елда вафат) улы.

Мелла Әхмәт бине Хафизетдин Габдессәлам (Габделислам) бабасы турында: «Бабабыз мулла Габделислам хәзрәт 1194 елда (һиҗри, милади белән 1778 елда) имам-мөдәррис һәм мөхтәсиб булып, озын гомер кичереп, 1236 елда (милади белән 1820 елда) шәүвәлнең җидесендә вафат булды. Кабере Ташкичүнең Яңа зиратында», – дип яза. Чыгышы белән Арча төбәгенең Курса почмагыннан булып, Бәрәскәдә (хәзер Әтнә районы) заманының күренекле дин әһелләреннән мелла Габдерахман әл-Кирмәнидән гыйлем алган, «Ташкичүнең таш мәчетендә имам һәм хатыйб булып, мәдрәсә тотып дәрес әйткән».

Бу шәхес байтак кына хезмәтләр авторы да. Мәсәлән, аның Малмыж өязендәге (Вятка губернасы) Урбар (Арбор) мәдрәсәсендә укыганда ук язылып, һиҗри 1191 елда (милади 1775 елда) тәмамлаган «Мирсәет Шәриф» дигән китабы мәгълүм. Күренекле дин эшлеклесе буларак, ул Шиһабетдин Мәрҗаниның «Мөстафадел...»ендә, аннан алып Ризаэддин Фәхретдиннең «Асәр»ендә дә шәрехләнә.

Бу нәселнең «Асәр»дә урын алган күренекле вәкилләреннән тагын берсе – югарыда тасвирланган имам Габдессәламнең (Габделисламның) бабасының бабасы Рәфыйк бине Таиб әл-Курсави («Бәрәңге тарихы»нда ул «Рәфыйк бин-Мәкәй...» дип тә бирелә) мәшһүр Габденнасыйр Курсави хәзрәтнең якын мөридләреннән берсе, 1720 нче еллар уртасында яшәгән, Саба төбәгенең ике Симет авылы арасында җирләнгән күренекле имам Мортаза хафиз бине Котлыгыш әс-Симетинең шәкерте булып, Арча төбәгендәге искә алынган Курса почмагында имамлык һәм мөдәррислек итә. Мәртәбәле остаз буларак, күп кенә дин әһелләренә гыйлем сеңдереп «кыска төннәрдә Болгар халкына ястү намазы уку кирәклеге хакында бер рисаләсе бар икән».

«Бәрәңге тарихы»нда авторның бабасы Насретдиннең тулы шәҗәрәи шәрифләре «хаҗи әл-мөхтәсибин Насретдин бин-хаҗи әл-мөхтәсиб Габдессәлам ибн әл-галәм Габдерахман ибн әл-голүм Габделгазиз бин-Ислам бин-Рафыйк бин-Мәкәй бин-Мәмтәй бин-Җәмкәй бин-Вәмит бин-Котлыбүкәч бин-Яңгурчы бин-Арыслан бин-Солтанай бин-Әхмәт бин-Урмат» дип бирелә. Күрүебезчә, бу шәҗәрә борынгы чорларга, урта гасыр төрки-татар дәүләтләре дәверенә үк барып тоташа. Әхмәт бине Хафизетдин язуынча, ошбу әйтелгән нәсел чылбырын аңа әтисе, «мулла Хафизетдин үзенең тыйб (медицина) китабының хәтимәсендә (азагында) язып калдырган. Аны ул кайбер хатлардан, язулардан табып төзегән».

Булачак имам Насретдин 1796 елда Ташкичү авылында туып, башта әтисе Габдессәлам мәдрәсәсендә, аннары чыгышы белән Ханкирмәндәге (Касыймдагы) Яубаш авылыннан булып, әтисенең дә остазларыннан саналган гыйлем иясе Габдерахман әл-Кирмәни (1827 елда вафат) хозурында тырышып укый. «Хәтта җәйге каникулда да, өйгә кайтмыйча, гыйлем белән мәшгуль булган кебек, буш вакытында остазының җирләрен үгезләр белән сукалап, ашлык чәчкән вә башка хезмәтләрен дә кылган, – дип яза аның турында оныгы Әхмәт бине Хафизетдин. – Гыйльме кыйраәттә (Коръән укуда) мәшһүр дәмелла әл-Багдадидан кыйраәт күнекмәләрен алган. Шуңа күрә кыйраәте дөрес һәм мәкаме шәп иде». Ул башта Бәрәңге төбәгендәге Яңавылда (Ирнурда), аннан Бәрәңгенең үзендә 45 еллап имамлык иткәннән соң, 1865 елның икенче сентябрендә вафат булып, авыл зиратында җирләнә.

«Тарих» авторы дөньялыкта Мәккәгә барып, ике кат хаҗ кылуга ирешкән хаҗи бабасын характерлап: «Бабабыз мулла Насретдин галим, тәкъва, хуш күңелле, сабыр вә эш сөючән зат иде, – ди, – арба-чаналарны үзе ясый иде. Гаиләгә кирәк киемнәрне дә үзе тегеп, өйгә тегүче кертмәде ... Бүтән кайбер надан муллалар шикелле гаммәдән (ил-көннән) файда күрүне генә уйламыйча, гыйлем тарату, Коръәнне аңлату белән дә шөгыльләнә иде ... Чалма чалу һәм көндезге эш киеме турында гарәпчә ике рисаләсе дә бар. Үз халкы өчен тырышучы, аларга дин вә тәрәкыйне өйрәтүче иде».

Башка дин әһелләреннән аермалы буларак, бәгъзе имам һәркөн иртә белән сыерларын көтүгә үзе куып, хайваннарны карап һәм бигрәк тә атларга мөгамәләсе игътибарлы булып, хатларында да

шулар турында күп яза торган булган. «Бабабызның гыйбарәтне кабатлау мәсьәләләре белән нәзари (теоретик) шөгыльләнүләреннән күпләр файдаланган. Безгә дә шундый хезмәтләр язарга язсын», – дип җөпли аның турында автор.

Әхмәт бине Хафизетдиннең әбисе (имам Насретдиннең хәләл җефете) Хәбибҗамал исә Бәрәңге тарафында беренче мәшһүр абыстай булып, зур иҗтиһат белән кыз балалар укыта. Замана гадәтенчә, араларында гарәп вә фарсы китапларын укучылар да бар икән. «Дәү әниебез бар гыйлеме белән гамил (гадел, гакыйл, камил) булып, ятим вә ятимәләрне, мескен вә фәкыйрьләрне сөяр, аларга матди вә рухи ярдәм итәр, даимән гыйбадәт вә зекер белән шөгыльләнер һәм хатыннарга вәгазь сөйләр иде, – дип яза аның турында оныгы. – ... Зур абруйга ия һәм тагын үзенең хуҗалык-аналык вазифаларын да бик әйбәт башкара иде.»

Имам Насретдиннең һәм аның хәләл җефете Хәбибҗамал абыстайның Хафизетдин («Тарих» авторының әтисе), Борһанетдин, Җамалетдин, Бәдриҗиһан исемле балалары була. «Тарих»та искәртелгәнчә, «болар һәммәсе бер карыннан булып, чыгышлары-ватаннары җәһәтеннән Бәрәңге кешеләредер. Болардан башка тагы Җәләлетдин вә Шәмсеҗиһан исемле балалары булып, әүвәлгесе 1834 елның вә соңгысы 1835 елның метрикә дәфтәрендә язулы». Шулардан аеруча «Тарих» авторының әтисе Хафизетдин белән агасы (әтисенең энесе) Борһанетдин күренекле гыйлем ияләре, дин эшлеклеләре булып танылалар.

Аерым алганда, 1245 һиҗри елда (1829 милади елда) Бәрәңге карьясендә туып, 1318 һиҗри елда (1902 милади елда) вафат булган Борһанетдин (Борһанетдин бин-Насретдин әл-Болгари) имам «Яшьлеге чәчәк атканда грамматика вә синтаксис һәм фикъһе (юриспруденция) фәннәрен Бәрәңгенең төньягында, аннары алты чакрым ераклыктагы Мазарбашы авылында мулла Әхмәди ибн-Әхсән әл-Мәмсәүи (Мәмсәви) хозурында өйрәнеп, шунда биш ел чамасы яши».

1849–1860 еллар тирәсендә, абыйсы Хафизетдин белән берлектә, белемен Бохарада арттыра (автор язуынча, «ничә еллар гыйлемен арттырып Бохара галимнәре арасында йөрде»). Әмма «тәрикатьне үзләштерсә дә, мулла булырга теләмәде. Аның төп шөгыле, башлыча, дәрес бирү булды», – ди агасы турында Әхмәт бине Хафизетдин. Бу чорда Бохара мосафирлары, хосусан

Русиядән килгән таләбәләр (шәкертләр) яраткан имамнарның берсенә мөрид булырга тиеш булып, имеш, Бохара халкының ышанганнары шул икән: «...Сары булу – русның катнашлыгыннан. Русиядә мөселман юк, алар тик «губер» (губернатор) өчен генә Бохарага килеп гарәп һәм фарсы философиясен өйрәнеп китәләр. Чөнки «губер» булу өчен гарәпчә һәм фарсыча белү шарт». Шул исәпле дә, Русия шәкертләре артыннан бохаралылар һәрвакыт «кяфер» кебек сүзләр белән озатып калалар икән. Моны раслау өчен «Тарих» авторы агасы Борһанетдин хатларының берсеннән өзек тә китереп үтә.

Бохарадан кайтышлый Борһанетдин, абыйсы Хафизетдин белән бергә, берникадәр вакыт Кызыл Ярда (хәзерге Петропавловск шәһәре) тукталышыннан соң, имам хатип, мөдәррис белән ахун дәрәҗәләрен алып, озак еллар Сембер губернасының Зөябашы авылында үзе ачкан мәдрәсәдә мөгаллимлек итү белән шөгыльләнә. Хәтта 1890 елларда, җәмгыяте-шәргыягә әгъза буларак, үтенеч буенча, Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Уфадагы диния нәзарәтендә казый вазыйфасын да башкара. Ул имамлык вә мөдәррислек иткән Зөябашы авылын күздә тотып, «Шәһәр кебек җиргә имам булып, мәдрәсә ачып, дәрес бирде, икенчедән ахунлыкка иреште һәм диния нәзарәтендә казыйлык итте», – дип яза аның турында «Тарих» авторы, – гыйлемдә-фәндә дә, башкалардан үрнәк алуда да бер атаклы кеше».

«Коръән-хафиз булып, ураза-сәхәрләрдә Коръән чыга торган иде, – ди аның турында «Бәрәңге тарихы» авторы, – кыяфәтекарашы мәһабәт, күркәм ак чырайлы, элек кара, аннары түгәрәк ак сакаллы, урта буйлы, борыны бераз зуррак иде. Сакалы агаргач ул тәмам безнең дәү әтигә (имам Насретдингә) охшады. Аның белән әңгәмә кору күңелле, табигате тыныч, сүзендә туры вә тугры иде». Ул ике елның берендә Бәрәңгегә кунакка кайтып йөри икән. «Бу сәфәре вакытында берничә китабы һәм берничә төрле авырулардан дарулары язылып салынган тартмасы була иде, – дип искә ала Әхмәт бине Хафизетдин. – Кием, әсбап, йорт җиһазларыннан бигрәк, китабы күп, даимән укып йөрер иде. Үзеннән соң акчасы, әйберләре һәм бигрәк тә китаплары күп калды».

Мөхтәрәм Борһан хәзрәтнең басма, кульязма хезмәтләре күп булып, автор аларның кайберләрен тасвирлап та уза. Аерым алганда, аның төрки-татар телендә «Касыйдәи банәт» («Хатын-

кызга мактау») китабы Казанда Кәримовлар матбагасында нәшер ителә. Гарәп телендә язылган икенче бер китабы «Фарызлар турында сөйләшү», дип атала. Кадерле һәм кыйммәтле гаилә ядкаре буларак, Бохарада чакта нәсех язуы белән ике төстә кыйммәтле ефәккә язылган «Җәлимгыль-рәмүз» дигән кульъязмасы имам Хафизетдин хәзрәтләре китапханәсендә дә сакланган була. «Язуы күркәм, укырга бик уңайлы, ялтырап тора, – ди аны үз хозурында күргән автор. – Бу эшкә аның бик зур хезмәт, көч салганы күренә». Ул кульъязманың ахырында гарәпчә: «Монда Казаннан килгән Борһанетдин бин-Насретдин әл-Болгари үз халкы вә диненең даны өчен язды» мәгънәсендәге сүзләр язылган була.

## БӘРӘҢГЕ РАЙОНЫ ГИМНЫ

## ГИМН ПАРАНЬГИНСКОГО РАЙОНА

*Авторы Тәбрис ФӘЙЗРАХМАНОВ*

Илләт-су башланган урманнар,
Ир, Нәлә буйлары, тугайлар,
Сабантуй гөрләгән мәйданнар –
Зур бүләк, якташлар, туганнар!

*Кушымта:*
Бердәмлек, тигезлек төбәге,
Халыклар дуслыгы терәге.
Чәчәк ат, ирекле бул мәңге,
Кадерле, гүзәл жир – Бәрәңге!

Иделгә ашкына суларың,
Дөньяга танылган улларың.
Киң юллар, мул уңыш — байлыгың,
Иң тәмле икмәкле районым.

*Кушымта.*

Таң ата, уяна туган як,
Яңгырый иртәңге моң – азан.
Бу жирне яраткан изге зат,
Мең шөкер сиңа! Дан сиңа! Дан!

*Кушымта.*

*Автор Татьяна ОЧЕЕВА*

Обнимая деревни, поля,
Протекают Илеть и Ноля.
Край родной, в этих дивных местах
Развернул Сабантуй торжества.

*Припев*:
Братской дружбой единой сильна
Ты для славы великой дана.
Будь всех краше, богаче, мила,
Параньгинская наша земля!

Сыновей, дочерей имена
Помнит с гордостью, знает страна.
С чудным вкусом ржаные хлеба –
Угощаешь соседей любя.

*Припев.*

Над землей встала зорька светла,
Ждут нас свершенья, дела.
Всем, кому мать-земля так мила,
Благодарность, почет и хвала.

*Припев.*

## ПАРАНЬГА РАЙОНЫН ГИМНЖЕ

Чодыра дене ялым эртен,
Ший Элнет шыргыкта йывыртен.
Сабантуй ден Пеледыш пайрем
Шергылтеш, калыкнам чумырен.

*Припев*:

Ик еш семын келшен илена,
Ойго ден куаннам пайлена.
Куш, чаплане, шӱмбел мландына,
Чон шепка – Параньга кундемна!

*Авторжо Татьяна ОЧЕЕВА*

Шочмо Эл чын шочшетым пала,
Рвезе тукым шарналын ила.
Перкем налше киндетым акла,
Родо-влакшым эн порын сийла.

*Припев.*

Эр кынелын, пашаш каена,
Тыршымаш ден лӱмет нӧлтена.
Кӧ вер-шӧржым сакла, йӧрата –
Шочмо мланде тудлан таушта.

*Припев.*

# ҺӘР АТАМАНЫҢ ҮЗ ТАРИХЫ

*Фирдәвес Гарипова*

*«И туган, изге җирем...»*
Габдулла Тукай

Мари Эл Республикасының татар авылларына мин 1993 елда сәфәр кылган идем. Бәрәңге районының кайбер татар авылларында өлкән яшьтәге бабайлар, әбиләр белән әңгәмәләр кордым.

Бу Республикада яшәүче татарлар яхшы гына көн итеп ята. Авыллары, йортлары төзек, матур. Татар, кайда гына яшәсә дә, тырыш һәм эшчән булып кала. Ул якларга барып чыгуымның максаты – халыкның холкын, гореф-гадәтләрен, йола-кануннарын, урнашу-оешу тарихларын белү, тирә-юньдәге географик берәмлекләрне барлау, каләм очына алу, халык телендә сакланган барлык төр географик атамаларны тоташтан (фронталь рәвештә) кәгазьгә теркәү иде.

Бәрәңге районының Портянур өлкәннәре үз авыллары турында болай сөйләгән иде:

– Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан соң, буйсындырылган халыкны көчләп чукындыру сәясәте башлана. Халык, чукындырудан качып, төрле урыннарга китеп җирләшә. Портянур авылы халкы да марилар арасына Казан якларыннан килеп урнашкан...

Портянур күршесендәге Ирнур (халык телендә Яңавыл), Бәрәңге (район үзәге), Куянавыл, Лажы, Мазарбашы (Алашайка), Искеавыл дигән авылларда да татарлар яши.

Портянур белән Яңавыл арасында Тапшер елгасы ага. Күрше районда Тапшер исемле авыл бар. Бу елга шул авыл тарафыннан

агып килә. Шунысы игътибарга лаек: бу елганы авылның бер башында – Сәлахетдин елгасы, икенче башында – Балтыр елгасы, ә бер өлешендә Ситдыйк елгасы дип атыйлар. Бу елгадан 200–300 метрлар читтәрәк ясалма күл җәйрәп ята иде. Аңа суны Тапшер елгасыннан суыртканнар. Тора-бара бу күлне Ибрай күле дип йөртә башлаганнар. Ни өчен дисәң, күлне булдыруда күрше авылның җирле үзидарәсе рәисе Ибрай исемле кеше зур көч куйган.

Шактый элек авылда зур һәм бай китапханә була, ләкин янгын чыгып, андагы күпсанлы китаплар, авыл тарихы буенча кыйммәтле мәгълүматлар һ.б. юкка чыга.

Авылда, нигездә, татарлар яши. Хәтта килен булып төшкән мари кызлары да инде татарлашып беткән дияргә ярый.

Авылдан чама белән бер чакрым ераклыкта зур урманнар бар. Халык аларны «Басу арты урманы», «Пүчинкә урманы» дип йөртә. Пүчинкә урманы янында элегрәк «Пүчинкә» дип йөртелгән авыл да булган. Хәзер ул беткән. Пүчинкәнең кайбер гаиләләре хәзер Портянур авылында яши. Пүчинкә зираты әле дә матур итеп тотып алынган, агачлары күкрәп үсеп утыра.

Портянур зираты авылның нәкъ уртасында. Авыл халкы ел саен зиратны чистарта һәм тәртипкә китерә. Каберләр өстенә чәчәкләр, агачлар утыртылган, ташлар куелган, чардуганнары буялган.

Авыл зур һәм аның табигате бик матур. Авыл янындагы чишмә һәм сазлыклар табигатькә ямь биреп тора. Елга-инеш ярларында агачлар үсә. Авыл уртасыннан ерым уза. Аның як-ягына куаклар, агачлар утыртканнар. Яз көннәрендә бу ерым, кар суы белән тулып, ташып ага икән. Өй каршыларында агачлар, чәчәкләр үстерелә. 1995 елда таштан мәчет салып куйганнар. Ул бөтен авылга иман нуры бөркеп тора.

Авылда унберьеллык мәктәп эшли. Бирегә күрше Яңавылдан да укучылар килә. Клуб, китапханә һәм балалар бакчасы бар.

Бу төбәктә өлкән буынга игътибар елдан-ел арта. Бәйрәмнәрдә, өлкәннәргә хөрмәт йөзеннән, чәй мәҗлесләре оештырыла.

Мин килгәндә (1993), бу хуҗалыкның рәисе шул авылныкы иде. Халык өчен ул бихисап игелекле гамәлләр кылган. Мәчет, яңа зур мәктәп бинасы салдыру белән бергә, ул юлларга асфальт түшәткән. Тагын бер кибет ачтырган һәм һәр йортка телефон керттергән.

Мари Эл Республикасы районнарында яши торган татарларның кунакчыл, кече күңелле икәнлекләрен, ата-бабалардан калган

гореф-гадәтләрне күз карасы кебек саклап, татарларга гына хас көнкүреш таләпләренә буйсынып яшәүләрен күреп кайттым.

Мари Эл Республикасында көн итүче милләттәшләребез, үз тырышлыклары аркасында, мул тормыш, киләчәккә якты өмет белән яшиләр.

Бу яклардагы һәр авыл, халык көнкүрешенең тарихына әверелгән һәр урын гомумтатар ономастика системасы белән бербөтенне тәшкил итә. Аларның барлыкка килү принциплары һәм хасиятләре бик охшаш. Шунысын да күрсәтергә кирәк, татарларның килеш-килбәте, кайсы халык арасында көн итүләренә карап, гәүдә ягыннан, ничектер, шушы төбәктә яшәүче халыкка охшый башлый. Бу күренеш мари арасында яши торган милләттәшләребездә дә күзәтелә.

Тагын шунысы игътибарга лаек, ут күршеләребез Мари Элның бер төбәгендә, аерым алганда, Бәрәңге авылында көн итеп яткан газиз кардәшләребез зиратында (кабер ташында) Чирмешән исематамасы ныгып калган.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң (1552), чукындыру сәясәте килеп чыгу нәтиҗәсендә, бу җирләрдәге урман арасына хәзерге Татарстанның Дөбъяз, Әтнә, Арча тирәләреннән урман арасына күчеп килеп утырган татарлар үзләре белән бу исем-атаманы да алып килгәннәр.

Бабаларыбыз кулланган Балыматы, Юрматы, Шонгаты, Урмат, Кыят һ.б. атамалар кергән система-ояга *-ат* компонентына тәмамланган сармат кавем-кабиләләре дә керә. Мари илендә көн итә торган милләттәшләребез дә шушы ареалга керәләр, димәк, алар да сармат бабаларыбызның варис-оныклары.

Фәндә Чирмешән атамасының *сармат* этнонимы белән бер икәнлеген раслаган дәлилле фикерләр бар. Иң беренче булып, галим П.Д. Шестаков (XIX гасыр) *сармат* сүзе белән *сярмысның* аһәңдәшлегенә, охшаш яңгырашына игътибар итә. Төрки телләрдә һәм, шул исәптән, иске татар телендә дә киң әйтелешле «а» авазының «и»гә һәм «и»нең «е» авазына күчеше законлы күренеш. (*Сабир→Сибир→Себер; Сармат → Сирмеш → Чирмеш; Сярмыш → Чирмеш* – фонетик вариантлар. Борынгы төрки һәм иске татар телендә с~ч~ш~т авазлары күчешәләр: *чишмә~сишмә~тишмә~шишмә; сай~чай~шай~тай; чишен~тишен~шишен~сишен һ.б.*)

Мари галиме Ф.И. Гордеев Чирмешән атамасы, халыкларның бөек күчеше вакытында хәзерге Башкортстан җирләреннән Урта Идел буйларына кысып чыгарылган соңгырак чор сарматларга бәйләнешле, сармат этнонимына нисбәтле, ягъни Сармат кавем-кабиләләре дип уйлый. Елга ярына килеп утырган сарматларның су чыганагын үз исемнәре, этнонимнары белән атау гаҗәп түгел. Үзләре төзегән торак пунктларны да аларның *Сярмешән~Чирмешән* дип атаулары табигый күренеш.

Бу турыда, ягъни Чирмешән атамасының сармат кабиләләренә мөнәсәбәтле булуын 1989 елда ук инде «Ватаным Татарстан» газетасында да язып чыккан идем (27 август саны). Бу фикер археологлар тикшеренүләре белән дәлилләнә. 1988 елның җәендә Уфа археологлары Оренбургтан 100 чакрымга көнбатыштарак урнашкан Филипповка авылы янындагы сармат курганнарыннан өч йөзгә якын бик матур итеп эшләнгән әйберләр тапканнар. Табылдыклар арасында иң күбесе – болан, сайгак, кабан, бүре, юлбарыс, балык, ташбака, фантастик кошлар һәм башка җәнлек, кош сурәтләре. Татар халкының тарихы борынгы һәм гаҗәп катлаулы бит ул.

Чирмешән атамасының сармат бабаларыбызга барып тоташуын М.И.Әхмәтҗанов та тикшеренүләре белән дәлилләде.

Чирмешән елгалары һәм аларның кушылдыклары ярларына урнашкан авыллар янында һәм халыкта татар халкы тарихы белән бәйле күп истәлекләр сакланып калган. Бу авыллар янында борынгы гасырларга мөнәсәбәтле шәһәрлек һәм авыллар хәрабәләре, кабер ташлары һәм язма истәлекләр табылган. Сармат бабаларыбыз шагыйрьләребез иҗатында да урын алган. Татар халык шагыйре Гамил Афзал мондый юллар язган:

Сарманда сарматлар торгандыр,
Сарматлар самовар куйгандыр,
Сакаллы сарматлар сабырсыз,
Сакмарда су кергән булгандыр.

Тәңредән мәрхәмәт көткәнсез,
Тирмәдә кизәкләр яндырып,
Дулкындай, килгәнсез, киткәнсез,
Далада таш сыннар калдырып.

Сарматлар, скифлар, кайда сез,
Чыгыгыз чал тарих каршына!
– Уралдан Дунайга чаклы без,
Далада кылганнар астында...

Җил исә, таң ата елмаеп,
Чәчәкләр яраткан балага,
Балбаллар утыра моңаеп,
Кылганнар чайкала далада.

Татарстан җирендә чирмешән сүзе белән байтак кына атамалар бар. Зур Чирмешән һәм Кече Чирмешән икесе дә әби-бабаларыбыз

гомер иткән газиз туфрагыбыз аша агалар. Зур Чирмешән – Куйбышев сусаклагычына коя. Кече Чирмешән – Зур Чирмешән елгасы кушылдыгы. Зур Чирмешән елгасы ярында Чирмешән районы үзәге булган Чирмешән авылы урнашкан. Д.А. Корсаков тарафыннан бастырып чыгарылган җыентыкта (1908) хәзерге Чистай районында, Кече Чирмешән елгасы ярында Татар Чирмешәне авылы күрсәтелгән һәм ул Майна, Кече Чирмешән дип тә аталган.

Казан артының Балык бистәсе районында да Чирмешән авылы бар. Рәсми атамасы Шетнев–Чирмешән (халык аны «Шетнев» дип түгел, «Шетнәү» дип йөртә) авылы бар. Әшнәк суы буендагы бу авыл Казан ханлыгы чорында ук булган.

Авылдан бер чакрым чамасы ераклыкта «Чирмешән куаклыгы» дип йөртелә торган кечкенә генә куаклык бар.

Тау ягындагы Апас районында Чирмешән елгасы ага, ул Бола суына кушыла. Чирмешән елгасы ярына Чирмешән авылы урнашкан. Д.А. Корсаков хезмәтендә (1908) бу авыл «Икенче Чирмешән» дип бирелгән. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Чирмешәннән ике чакрым ераклыкта урнашкан Багыш авылы элек Өченче Чирмешән исемендә йөргән.

Апас районында Чирмешән үзәге (үзәк – «елга») Бола елгасының – уң, Чирмешән суы Боланың сул кушылдыклары. Бу районда Чирмешән компоненты белән ясалган вак географик атамалар – микротопонимнар (Чирмешән чаты (кыр), Чирмешән чишмәсе, Чирмешән буе, Чирмешән болыны, Чирмешән куаклыгы һ.б.) теркәлде.

Н.Ф.Калинин Тәтештән 15 чакрым түбәндәрәк Чирмешән елгасы булуы турында яза.

Чирмешән атамасы белән топонимнар һәм гидронимнар Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә очрый. Кармасан һәм Чирмәсән – Урал төбәгендәге гидронимнар. Башкортстанның Бәләбәй һәм Благовар районнарында Чирмәсән атамасы алган кичү 1773–1775 еллардагы Пугачев хәрәкәтенә бәйле документларда очрый. Элекке Пермь губернасының Верхотур өязендә Чирмешән елгасы һәм аның ярында Чирмешән авылы искә алына. Саратов өлкәсенең Хвалын шәһәреннән 6–7 чакрым ераклыкта староверларның (православие динен искечә тотучылар) үзәге, аскет монахлар торган Чирмешән исемендәге атаклы монастырь булган. Шул ук Хвалын шәһәре янында Чирмешән исемендә ике күл, бер санаторий һәм ике ял йорты беркетелеп калган. Элекке Ставрополь өязенең

Хрящевка исемен йөрткән торак пункттан 25 чакрымда өстәрәк ага торган Чирмешән елгасы ярында Чирмешән (Никольское) авылы урнашкан. Бу урыннан Чирмешән елгасында пароход һәм суднолар йөреше башланган. Самара өлкәсендәге Шонталы районы җирләреннән агып үткән Чирмешән елгасы бассейнында Чирмешән бистәсе (поселогы) теркәлгән. Самара шәһәренең бер урамы «Чирмешән» исемен йөртә. Димитров шәһәрендә бер футбол командасына «Чирмешән» исеме бирелгән. Чиләбе өлкәсенең Югары Уфалы районында шәһәр тибындагы Чирмешән бистәсе бар икән. Чирмешән атамасы Кырымда, элекке Дон гаскәри казаклары өлкәсендә, Төньяк Кавказда, гагаузларда, Ока елгасы бассейнында һ.б. урыннарда очрый. Приморье краеның Дальнегорск районында да Чирмешән бистәсе теркәлгән. Чирмешән атамасын Алтайда, Югары Иртеш бассейнында да берәр елга йөртә.

Йомгаклап әйткәндә, авыл өлкәннәре белән сөйләшү түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә: югарыда тупланган мәгълүматларны күздән кичергәч, бабаларыбыз – сармат кавем-кабиләләренең төрле җирләргә сибелеп көн иткәннәре ачыклана. Инде югарыда әйтелгәнчә, Мари илендә көн итүче татарлар телендә кулланыла торган географик берәмлек атамалары гомумтатар топонимик системасының бер канатын тәшкил итәләр. Моны алардагы элек-электән сакланып килгән гореф-гадәтләр дә раслый. Әйтик, халык буыннан-буынга күчеп килгән дини бәйрәмнәрне хөрмәт итә, аларны канунга туры китереп үткәрә. Сабан туйлары, каз өмәләре да халык игътибарыннан читтә калмый. Балаларга исем куштырулар, мәрхүмнәрне, йоласына туры китереп, соңгы юлга озатулар бу төбәктә көн күрә торган татар халкына хас гадәтләрдән санала.

Татар халкы мари кавемнәре белән дә дустанә яши, алар берберсен хөрмәтләп көн итә. Бу гамәл – үзе бер зур казаныш.

Халык үзләрен чолгап алган географик мохитне һәм атамаларны әйбәт белә. Бу аспект та игътибарга лаек. Ул тел һәм халык тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Болар барысы да төрки, аерым алганда, татар кавем-кабиләләренең, татар халкының төрле урыннарга сибелеп яшәсәләр дә чыгыш тамырлары уртак икәнлеген күрсәтә торган шөбһәсез дәлилләр.

## ҮЗ ЯМЕ, ҮЗ ТӘМЕ БАР

*Дария Рамазанова*

Бәрәңге сөйләше хәзерге Мари Элда Бәрәңге (Параньга), Мари-Төрәк районнарында таралган.

Мари Элда таралган бу төркем төрле чыганакларда (тарихта һ.б. басмаларда) зур күпчелеге Бәрәңге районында яшәгәнгә булса кирәк, бәрәңге татарлары дип йөртеләләр. Район үзәге Бәрәңге үзе дә зур татар авылы булып санала.

Сөйләш вәкилләренең бабалары бик борынгы заманнардан бирле биредә яшәгән булулары ихтимал. Тарихчылар, Кама елгасының төньягында болгарларның аерым төркемнәре дә, монгол яуларына кадәр үк, фин-угор халыклары белән аралашып яшәгәннәр, дип күрсәтәләр. Тарих һәм археология буенча тикшеренүләрдә бу турыда нигезле фикерләр әйтелгән.

Монгол яуларыннан соң, Алтын Урда чорында болгарларның төньякка таба күчүе активлаша. Археологик өйрәнүләр дә Казансу һәм Мишә бассейннарында бу чорларда болгарларның бик тыгыз урнашкан булуын раслый.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, андагы халыкның Нократ елгасы буйларына, төньякка таба Илләт, Ашыт, Бәрәңге елгалары бассейннарына да күпләп күчкәнлеге мәгълүм. Бу чорлардагы күченүләрнең төп сәбәбе – көчләп чукындырудан качу булган, дип фаразлана.

Соңгырак чорда төзелгән административ бүленешләр бәрәңге сөйләше вәкилләренең казан арты татарларыннан теге яки бу дәрәҗәдә аерымланып яшәвенә китергән. Бу исә сөйләштә күчеп килгән чорга хас күренешләрнең тотрыклырак сакланып калуына сәбәп булган (мәсәлән, -*мага/-мәгә* формасы һ.б.). Шул ук вакытта сөйләштә

яңа билгеләр дә формалашырга мөмкин. Мәсәлән, *н* янында *г* авазы әйтелү күренешенең активлыгы җирле яңа шартлар белән бәйләнеп, сакланып килә торган үзенчәлекләрнең берсе булуы ихтимал.

**Фонетик үзенчәлекләр**

Сузыклар. Бәрәңге сөйләшендә сузык авазларның ясалышы һәм әйтелеше әдәби телдәгечә. Биредә [а] авазының әйтелеше турында гына кайбер моментларны билгеләп үтәргә кирәк.

Билгеле булганча, фәндә бәрәңге сөйләшенең формалашуында дөбьяз сөйләше белән уртак компонентлар да катнашкан булуы мөмкин дигән фикер яши. Әмма ләкин [а] авазының дөбьяз сөйләшенә хас ачык, иренләшү төсмере булмаган варианты бәрәңге сөйләшендә, нигездә, күзәтелми. Шулай да өлкәннәр телендә аерым очракларда, аеруча тирән тел арты [к], [ғ] авазларыннан соң, ачык [а] авазының әйтелү очраклары теркәлгән.

Сузыклар өлкәсендәге калган үзенчәлекләр төрле фонетик күренешләргә кайтып кала.

Авазлар тәңгәллегенең түбәндәге очраклары бар.

Билгеле бер төркем сүзләрдә [и] авазы әдәби телдәге [е] авазы урынына әйтелә. Мәсәлән: *билә* – әд. белән, *тирмән* – тегермән, *иңгер-миңгер* – эңгер-меңгер, *инә* – энә, *ире* – эре, *җирләү* – *җегерләү* – эрләү һ.б.

Кайбер сүзләрдә әдәби [и] авазына [ә] сузыгы тәңгәл килә: *әнәй* – әни, *әтәй* – әти, *бәк* – әд. бик, *имеш-мәмеш* – имеш-мимеш, *кәтмән* – китмән, *кәтмәлләү* – китмәнләү. Бу күренеш алынма сүзләрне үзләштерүдә дә чагылыш тапкан: *йәнwәлит* – инвалид.

Киресенчә, әдәби [и] сузыгы [ә] авазы урынына әйтелергә мөмкин: *әзрик* – әзрәк, *сике* – сәке, *җийәү* – җәйәү.

Кайбер сүзләрдә [ә] авазы урынына [е] сузыгын әйтү күзәтелә: *әммесе* – һәммәсе, *дийерлек* – дийәрлек.

[е (э)] ~ [и]: *кермеч / керпеч* – кирпеч.

Бу тәңгәллекләрне галимнәр борынгы төрки телләргә хас тарихи [ә] ~ [и] күчеше белән бәйли.

Татар теленең барлык сөйләшләрендә дә табыла торган *ә ~ е, и ~ е, е ~ ә, ә ~ и* һ.б. шундый күренешләр *и* авазы күчешенең төрле этап-ларын чагылдыралар (12).

[у], [ү] ~ [о], [ө] тәңгәллеген чагылдырган очраклар да теркәлде: *йүгерү* – әд. йөгерү, *мүгез* – мөгез, *бүгү* – бөгү, *сун* – соң, *үнәрле* –

һөнәрле, *туķмач* – токмач, *боғол / буғыл* – кибән, *бүwелеп / бүгелеп* – бөгелеп һ.б.

Кайбер сүзләрдә [у] авазына киң әйтелешле [а] сузыгы тәңгәл килә: *алабата* – әд. алабута, *ķысķач* – кыскыч, *йасмаķ* – ясмык.

Түбәндәге очракларда [ы], [е (э)], [и] ~ [у], [ү] тәңгәллеге күзәтелә: *шышы* – шушы, *тыбырча* – тубырча, *бығай* – бугай, *сабан тийы* – сабан туе, *мийбау / мийын бау* – диал. *муен бавы* – муенса.

Бәрәңге сөйләшендә әдәби телдәге [ы], [е (э)] тар әйтелешле сузыкларны киңәйтү күренеше бар. Бу үзенчәлек *-мы/-ме* сорау кисәкчәсендә, кайбер сүзләрдә чагылыш таба: *исәммә* – исәнме, *беләмә* – беләме, *барама* – барамы, *уķыйма* – укыймы, *ķысķач* – кыскыч, *шар йалангач* – шыр ялангач, *ашаға* – ашыга һ.б.

Киресенчә, киң әйтелешле [а], [ә] авазлары урынына тар әйтелешле [ы], [е (э)] сузыкларын әйтү күренеше, нигездә, фигыльләрдә күзәтелә: *чығырым* – чыгармын, *йазыр* – язар, *барғынчы / барғанчы* – барганчы, *чағыр* – чагар, *йафа чикенче* – чиккәнче, *атырға* – атарга.

Аерым сүзләрне иренләштерү күзәтелә: *мөн* – мең, *ķош* – кыш һ.б.

Әдәби телдән аермалы буларак, арткы рәт сузыклары белән әйтелә торган сүзләр алгы рәт сузыклары белән әйтелә: *әзрик* – әд. азрак / әзрәк, *әчкеч* – ачкыч, *әч* – ач (фигыль), *әчек* – ачык, *төрбә* – труба, *бөрчә* – борча, *Өрҗөм* – Уржум (өяз исеме) һ.б. Күрше дөбьяз сөйләшендә моның мисаллары күбрәк табыла.

Сөйләштә тагын *казаки / кәзәки, тәбәнәк / табанаķ* кебек сингармоник парларны да билгеләп үтәргә кирәк.

Алгы һәм арткы рәт сузыкларын алмаштыруның мисаллары борынгы төрки телдә үк теркәлгән.

Ике сүз арасында төрле күтәрелешле сузыклар туры килсә, киң әйтелешле аваз тарая һәм бөтенләй әйтелмәскә дә мөмкин: *булыйкән* (була икән), *аķчышли* (акча эшли), *нәстийе* (нәстә иде), *көзлөкт ийе* (көзлөктә ийе), *бирегуйлыйлар* (бирергә уйлыйлар), *үзеношаған* (үзенә ошаған), *балыйы* (бала ийе), *тағыдикенче* (тагын да икенче), *нәрсечен* (нәрсә өчен) *ķайдурнашырға* (кайда урнашырга) һ.б.

Рус теленнән кергән сүзләрдә татар теле өчен ят булган сузыклар татар теленең үз авазлары белән алмаштырылалар. Моның белән бәйле рәвештә түбәндәге күчешләрне күрсәтеп китәргә мөмкин:

1. Рус алынмаларындагы басымлы һәм басымсыз [а] сузыгы урынына еш кына [ә] сузыгы әйтелә: *кәбестә* – капуста, *әртис* – артист, *әрмийә* – армия, *кәртечкә* – карточка, *әдерис* – адрес, *сәтин* – сатин, *кәтлит* – котлета, *әптик* – аптека һ.б.;

2. Рус телендәге басымлы [о] сузыгын, татар теленең күпчелек сөйләшләрендәге кебек үк, [у] сузыгы алмаштыра: *пушты* – почта, *лимун* – лимон, *багун* – вагон, *тупыл* – тополь, *ыраскут* – расход, *тучнысы* – точносы, *гурыт* – город, *дастуйын* – достоин, *сутый* – сотый, *асубинны* – особенно, *суйа* – соя (борчагы);

3. Сүз башындагы басымсыз [о] авазы урынына, нигездә, [а] сузыгы әйтелә: *ахута* – охота, *кантур* – контора, *патнус* – поднос, *качтун* – костюм, *самаwыр* – самовар, *караuник* – коровник, *собранҗә* – собрание, *таwарабит* – товаровед һ.б.

Киресенчә, алынмалардагы [у] авазына сөйләштә [о] тәңгәл килү очраклары бар: *сохари* – сухари, *сослон* – суслон һ.б.

4. Кайбер алынма сүзләрдә сүз башындагы басымсыз [о] авазы [ә] авазына күчә, мондый күренеш составында нечкә [и], [е] авазлары булган сүзләрдә күзәтелә: *кәрҗин* – корзина, *кәжни* – каждый, *кәнсәләр* – канцелярия, *кәрәчин* – керосин, *әфисәр* – офицер, *кәнсирт* – концерт, *сәвит* – совет, *калакун – колокол* – кыңгырау, *кәләңкүр* – коленкор һ.б.

Рус һәм рус теле аша кергән башка алынмалардагы басымлы [е] авазы [и] авазы белән алмашына: *силсәwит* – сельсовет, *билит* – билет, *нифет* – нефть, *иликтерик* – электрик, *зимләмир* – землемер, *губирна* – губерна, кәмбирт – конверт һ.б.

Мисаллардан аңлашылганча, әлеге күренеш ябык иҗекләрдә күзәтелә.

С у з ы к  а в а з л а р  т ө ш ү күренеше бәрәңге сөйләшендә чагыштырмача сирәк очрый. Мәсәлән: *җой / койо* – кое; *зату* – озату.

С и н г а р м о н и з м  к ү р е н е ш л ә р е. Бәрәңге сөйләшендә дә татар әдәби теленә һәм күпчелек сөйләшләргә хас ирен гармониясе эзлеклелеген саклый: ирен-ирен [о], [ө] сузыклары, беренче иҗектә килгәндә, үзләреннән соң килгән иренсез [ы], [е (э)] авазларны иренләштерәләр. Иренләштерү икенче, өченче иҗеккә кадәр дәвам итә, ачык иҗектә, бигрәк тә ул соңгы иҗек булса, иренләшү төсмере бермә-бер кими, юкка чыга.

Мондый иренләшү күренешен ассызыклап үтү урынлы булыр, чөнки, билгеле булганча, бәрәңге сөйләше белән тарихи-генетик

һәм географик яктан бәйле булган дөбьяз сөйләше [о], [ө] ирен-ирен авазларын иренсезләштерү белән характерлана. Шулай итеп, иренләшү гармониясенең үзенчәлекләре белән бәрәңге сөйләше дөбьяз сөйләшеннән аерыла.

Сүз эчендә сузыкларның калынлыкта һәм нечкәлектә ярашуы, ягъни аңкау гармониясе, үзенең эзлеклелеген саклый, һәм ярашмау, әдәби телдәге кебек, бары кушма (*өчпочмак, чәчкап* һ.б.) һәм алынма (*китап, галим* һ.б.) сүзләрдә генә күзәтелә. Шул ук вакытта, сөйләштә *төрбә* (труба), *тәбанак̧ қына* (тәбәнәк кенә) кебек очраклар да мәгълүм.

С у з ы к л а р  ө с т ә л ү. Рус теленнән кергән сүзләрдә сүз башында [ы], [е (э)] авазлары өстәү янәшә ике тартык аваз булганда күзәтелә: *ышнур* – шнур, *ышкап* – шкаф, *ыстакан* – стакан, *ыстанса* – станция, *ыскылат* – склад, *ырайун* – район, *ышкул* – школа һ.б.; *эскерт* – скирд, *эстина* – стена, *эскәтер* – скатерть, *эскәмийә* – скамья, *эшләпә* – шляпа, *эсбижий* – свежий һ.б.

Сүз башында өч тартык туры килгәндә сүз өстәлмә авазга [ы яки е (э)] башлана һәм икенче иҗек ясый торган өстәлмә аваз ачык иҗек оештыра: *ызбыруй* (ыз + бы + руй) – сбруя, *ыспырафкы* (ыс + пы + раф + кы) – справка, *эстерәпке* – эс + те + рәп + ке – стряпка һ.б.

Кайбер алынмаларда протезаны метатеза алыштырырга мөмкин: *эрвизур* – ревизор, *эрвизийә* – ревизия, *пыржина* – пружина.

Гарәп-фарсы алынмаларында да сүз башында аваз өстәү (протеза) күзәтелә, тик мондый күренеш, күпчелек очракта, алынмалар татар теленә хас булмаган авазларга (мәсәлән, *р, ш* һәм шулай ук *ч*) башланганда барлыкка килә: *ыризык* – ризык, *ыриза* – риза, *эрәхмәт* – рәхмәт, *эрәхәт* – рәхәт, *эшәл* – шәл, *эшәм* – шәм, *эчәй* – чәй, *эшешә* – шешә һ.б. Шулай ук: *өтөрмән* – төрмә.

**Дифтонглар**. Бәрәңге сөйләшендә дифтонгларның кулланылышы әдәби телдәгечә. Бары тик *-өй* дифтонгын *-ий* дип әйтү очраклары гына күзәтелә: *сийәк* – әд. сөйәк, график сөяк; *кийәнтә* – әд. көйәнтә, график көянтә; *ийрәтү* – өйрәтү һ.б. *-өй* дифтонгын болай иренсезләштерү урта диалектның казан арты сөйләшләрендә, (дөбьяз, мамадыш, минзәлә һ.б.да) таралган.

Шулай итеп, бәрәңге сөйләше сузыклар системасы белән әдәби телгә бик якын тора. Сөйләштә табыла торган диалекталь күренешләрнең бер төркеме бәрәңге сөйләшенең формалашуында зур роль уйнаган казан арты (дөбьяз, мамадыш, балтач) сөйләшләре белән уртак.

**Тартык авазлар.** Аларның әйтелеше ягыннан бәрәңге сөйләше әдәби телдән аерылмый. Сөйләшкә хас диалекталь үзенчәлекләр төрле аваз тәңгәллекләрендә һәм башка фонетик күренешләрдә чагыла.

Билгеле булганча, татар теленең диалектларын билгели торган төп дифференциаль үзенчәлекләрнең берсен сүз башында [ж] һәм [й] тартыклары тәңгәллеге тәшкил итә. Көнбатыш (мишәр), тубыл-иртеш, бараба һәм том диалектларына күрсәтелгән позициядә *й*-ләштерү хас.

Бәрәңге сөйләшендә [ж] һәм [й] авазлары икесе дә кулланыла дип әйтергә мөмкин. Беренчедән, [ж] авазы, әдәби телдәге кебек үк, өрелмәле тартык аваз һәм, шулай итеп, әлеге сөйләш дөбьяз сөйләшеннән аерылып тора. Билгеле булганча, дөбьяз сөйләшендә [ж] тартыгы аффрикат [дж] итеп әйтелә. Шундый ук аффрикат [дж] авазы тагын касыйм, нократ, норлат сөйләшенең Чувашия белән чиктәш авыллары сөйләшләрендә кулланыла. Тел очы өрелмәле [ж] тартыгын һәм [й] сонантының янәшә кулланылуы ягыннан бәрәңге сөйләше пермь, красноуфим, мамадыш сөйләшләре белән зур уртак-лык күрсәтә. Күргәнебезчә, бу сөйләшләр татар теленең төп нигез сөйләшләреннән аерым, башка телләр чолганышында формалашканнар.

[ж] авазы бәрәңге сөйләшендә сүз уртасында да кулланыла: *дөнжҫа* (әд. – дөнйа, график – дөнья), *Мәржҫәм* (Мәрйәм, язуда – Мәрьям), аржақ (арйак, язуда – аръяк), *бержҫулы* (берйулы, язуда – берьюлы), *алжҫу* (алйу) һ.б. Шушындый ук күренеш казан арты һәм тау ягы сөйләшләре төркемнәрендә дә, минзәлә, пермь сөйләшләрендә дә күзәтелә. Ул көнбатыш (мишәр) диалектның мордва-каратай сөйләшенә дә хас.

[ж] һәм [й] авазларын параллель куллану, сүз яки иҗек башында гына түгел, ике сузык уртасында да күзәтелә: *гәйәп / гәжҫәп* – гаҗәп, *шәйәрә // шәжҫәрә* һ.б.

Ике сузык уртасындагы [җ] авазына, дөбьяз сөйләшендәге кебек үк, еш кына [ж] тартыгы тәңгәлләшә: *бажа* – әд. баҗа, *хужа* – хуҗа, *хужалық* – хуҗалык, *ижат* – иҗат һ.б. Мондый күренеш татар теленең урта диалектына караган златоуст, тепекәй, сафакүл сөйләшләрендә билгеле, башкорт телендә исә ул әдәби норма булып кабул ителгән.

[н] ~ [ң] тәңгәллеге бәрәңге сөйләшенең әһәмиятле үзенчәлекләреннән берсе. Тел очы [н] авазы бер төркем исемнәрдә сүз азагын-

да, исемнәр һәм алмашлыкларның иялек килеш кушымчаларында даими рәвештә әдәби [ң] авазын алмаштыра: *тан* – таң, *күлмәкнен* – күлмәкнең, *баласынын* – баласының; *безнен* – безнең, *үземнен* – үземнең, *монон* – моның, *сезнен* – сезнең; шулай ук: *китерәсен* – китерәсең, *барасын* – барасың, *менгәнсен* – менгәнсең һ.б.

Татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек үк, бәрәңге сөйләшендә дә башка борынгы күренешләр сакланып киләләр. Мәсәлән, шундыйлардан [п] ~ [ф] тәңгәллеген күрсәтергә мөмкин. Бу күренешнең килеп чыгышы ике төрле сәбәпкә бәйле.

Бер төркем сүзләрдә борынгы п (– б) авазы сакланган: *тупрақ* – әд. туфрак, *керпек* – керфек, *йапрақ* – йафрак, *язуда* – яфрак, *қалпақ* – калфак һ.б.

[п] ~ [ф] тәңгәллегенең икенче өлеше татар теленә, шулай ук барлык төрки телләргә дә [ф] авазының ят аваз булуыннан килеп чыга. Шуңа күрә дә, алынма сүзләр составында татар теленә кергән бу аваз урынына сөйләшләрдә ясалу урыны белән аңа якын торган [п] тартыгы әйтелә: *Нәпис* – Нәфисә, *Сәйпи* – Сәйфи, *Патыйх* – Фатыйх, пирмә – ферма, *пурма* – форма, *тип* – тиф һ.б.

Бәрәңге сөйләшендә үзенчәлекле тәңгәллекләрдән тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

[к] ~ [х]. Түбәндәге сүзләрдә борынгы [қ] саклана: *қатын* – хатын, *қан* – хан. Гарәп-фарсы телләреннән кергән кеше исемнәрендә күзәтелә: *Қәнипә* – Хәнифә, *Қәтмулла* – Хәтмулла һ.б.

Аерым очракларда, киресенчә, саңгырау [қ] авазының спирантлашуы да очрый: *wахыт* – вакыт, *хауп* – кабып, *хәдәре / қәдәре* – кадәр һ.б.

[м] ~ [п]: *кермеч / керпеч* – әд. кирпеч.

[н] ~ [л]: *налпы / нампы* – лампа; *тастыман / тастылман* – тастымал. Бу мисалларда [н] һәм [л] сонорлары тәңгәллеге генә түгел, бәлки әлеге авазларның охшашлануы / охшашсызлануы күренешләре дә чагыла. Шуны ассызыклап күрсәтергә кирәк, *лампа, тастымал* сүзләрендәге мондый тәңгәллекләр татар теленең башка сөйләшләрендә теркәлмәгән, димәк алар бәрәңге сөйләшенең үзенчәлекле билгесен тәшкил итәләр.

Бәрәңге сөйләшенә хас үзенчәлекле күренешләрнең берсе [ч] ~ [ш] тәңгәллеге. Бу тәңгәллек ике күренештә чагылыш таба. Әдәби телдәге тел очы [ч] тартык авазы урынына [ш] авазы әйтелү: *ушырып* – очырып, *шығып* – чыгып, *шебеш* – чебеш,

*шикләwек* – чикләвек, *пешекше* – пешекче, *Гөлширә* – Гөлчирә, *шишмә* – чишмә, *шыршы* – чыршы (соңгыларында урта диалект сөйләшләренә хас кире ассимиляция күренеше дә булырга мөмкин), һәм, киресенчә, кайбер сүзләрдә [ш] авазы урынына [ч] тартыгы әйтелә: *чырпы* – әд.шырпы, *чеш* – шеш, *чөшлө* – шөшле.

Башка сөйләшләрдә [ч] белән әйтелә торган бер төркем диалекталь сүзләр дә бәрәңге сөйләшендә [ш] белән әйтеләләр: шәбен (тархан, стәрлетамак сөйләшләрендә: *чәбен*) – күбә (бер күтәрәм, бер сәнәклек – печән турында), *шуйыт* – 1) ак әнис үсемлеге орлыгы (тмин); әнис орлыгы; Чагыштыр: мамадыш, тархан сөйләшләрендә *чуйырт* – әнис, *шынҗыр* – чылбыр; балтач, нократ, мамадыш, касыйм, кузнецк сөйләшләрендә *җынҗыр* – шул ук мәгънәдә. *Бәпшек* – агачның яки солының яшь үсентесе. *Бәпшек сүзе бәпчек күшә* сүзтезмәсендә балтач сөйләшендә, *бәпчек күшә* вариантында мамадыш, дөбьяз сөйләшләрендә күзәтелә, балтырганны белдерә. [ш] ~ [ч] тәңгәллегенең башка очракларда да чагылуына мисаллар теркәлгән: *Сорамыйчы шығып* (чыгып) *та китеп булмый*.

Шулай итеп, бәрәңге сөйләшендә [ш] ~ [ч] тәңгәллеге шактый актив күзәтелә һәм мондый фонетик күренеш тикшерә торган сөйләшнең үзенчәлекле билгеләренең берсен тәшкил итә.

Билгеле булганча, [ч] ~ [ш] тәңгәллеге гомумтөрки характердагы фонетик күренеш, мәсәлән, татар телендәге [ч] авазы урынына башкорт телендә [с], нугай, казакъ телләрендә [ш] авазлары туры килә. Әйтеп үткәнебезчә, дөбьяз якларындагы сөйләшкә нугайларның йогынтысы зур була, Казан ханлыгы чорында нугайлар, ханнар белән килеп, биредә, аеруча Казан артының хәзерге Дөбьяз тирәләрендә яшәгәннәр һәм аларның, Казан ханлыгы җимерелгәч тә, шунда яшәүләре билгеле.

Бәрәңге сөйләшендә исә тел ситуациясе башкарак булган. Бу сөйләш вәкилләре икенче административ үзәккә буйсынган хәлдә, башка телләр чолганышында, төп татар халкыннан аерымланып яшиләр. Фәндә билгеле булганча, мондый очракта алар үзләре белән килгән сөйләү үзенчәлекләрен ныграк саклыйлар. Шуңа күрә дә, хәзерге яшәү урыннарында алар, берьяктан, үзләре белән бер чорларда килгән мамадыш һәм норлат сөйләше вәкилләре белән аралашып, татар әдәби теле йогынтысы астында, үзләренчә бер мөстәкыйль сөйләш булып формалашалар. Икенче яктан, сөйләшнең кайбер үзенчәлекләре көчәеп китәргә мөмкин.

Тикшерә торган сөйләшкә хас тәңгәллекләрнең берсе интервокаль позициядә тел очы йомык [д] тартыгы урынына тел очы өрелмәле [з] авазы әйтелү: *қазақ* – кадак, *изән* – идән, *назан* – надан, *йозорық* – йодрық, *бозай* – бодай, *қазау* – кадау, *Изел* – Идел, *Мәзинә* – Мәдинә, *Бәзерттин* – Бәдертдин һ.б.

Мондый күренеш татар теленең күп кенә сөйләшләрендә таралган: казан арты төркеменнән мамадыш, дөбьяз, балтач сөйләшләрендә, минзәлә, бөре, нократ, пермь, красноуфим, тепекәй [d] ~ [д]; Тау ягында кама тамагы, норлат сөйләшләрендә дә бар.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек, бәрәңге сөйләшендә дә тамырдагы ирен-ирен [п] тартыгы [б] авазы аша иренирен өрелмәле [w] авазына күчә: йап- > йабып > *йаwып* – ябып, чап- > чабып > *чаwып* – чабып, қап- > кабып > *қаwып* – кабып, тап- > табып > *таwып* – табып һ.б. Мондый очракларда [ы] авазы төшеп калырга да мөмкин: *чауп* – чабып, *йауп* – ябып, *тауб* алдым – табып алдым һ.б.

Бәрәңге сөйләшендә аерым-аерым сүзләрдә түбәндәге тәңгәллекләр күзәтелә. [м] ~ [н] һәм [к] ~ (м >) [п]: *кампаси* – монпансье, [л] ~ [р]: *күлек* – күрек, *бәлқут* – бәрхет, [ч] ~ [с]: *фич* – весь, *пачач* – почес, *чичта* – чиста; [ч] ~ [з]: *гәрнич* (з > с > ч) – карниз; [с] ~ [ч]: *ис* / *ич* – ич, *әчкес* – ачкыч, *ақса* – акча; [н] ~ [к]: *иңече* – икенче; [м] ~ [в]: *нирмы* – нерв; [р] ~ [н]: *үткер* – үткен; [к] ~ [т]: *карантас* – тарантас; [з] ~ [ж]: *зеп* – зерләп; [d] ~ [з]: *хәdер* – хәзер, *тап-таdа* – тап-таза; [п] ~ [б]: *әрпет* – эрбет; [д] ~ [г]: *диктар* – гектар.

Рус алынмаларындагы үзенчәлекле тартык авазларның түбәндәге тәңгәллекләре бар.

Ирен-теш [в] авазы урынына, күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек үк, ирен-ирен [б] яки [w] авазы әйтелә: *багун* – вагон, *зийәблинҗә* – заявление, *бырач* – врач, *силсәwит* – сельсовет, *йәнwәлит* – инвалид һ.б.

Сүз яки иҗек азагындагы позициядә ирен-теш [в] авазына иренирен [п] саңгырау тартыгы тәңгәл килә: *сәпсим* – совсем, *гүпчи* – вовсе һ.б.

Авазларның охшашлануы (ассимиляция). Бәрәңге сөйләшендә тулы прогрессив ассимиляциянең түбәндәге очраклары күзәтелә.

1. Бер төркем сүзләрдә [ч] авазыннан соң килгән [с] авазы тулысынча охшашлана: *чичта* – чиста, *чичла* – число, *чичтыра* – чистыра – систыра һ.б.

2. Түбәндәге сүзләрдә [с], [ч] тартык авазлары [ш] авазына тулысынча охшашлана: *Шәмшийә* – Шәмсия, *шийләшә* – сөйләшә, *шуғыш* – сугыш, *шишәмбе* – сишәмбе, *шәршәмбе* – чәршәмбе һ.б.

Регрессив охшашлану. Сүз азагындагы [н] авазы кушымчадагы (*-ла(н)/-лә(н); -лық/-лек; -лар/-ләр; -лы/-ле; -лай/-ләй* һ.б.) [л] авазына тулысынча охшашлана: *чыллап* – чынлап, *қайыллар* – каеннар, *урмаллар* – урманнар, *сизгәлләр* – сизгәннәр, *үстергәлләр* – үстергәннәр, *урылларға* – урыннарга, *төтөлләре* – төтеннәре.

Шуны аерым ассызыклап үтәргә кирәк, бәрәңге сөйләшендә бу күренеш, дөбьяз сөйләше белән чагыштырганда, сирәгрәк күзәтелә.

Мондый хәл бәрәңге сөйләшенең формалашу тарихы белән аңлатыла. Чөнки бәрәңге татарлары формалашуда, дөбьяз сөйләше вәкилләре белән беррәттән, мамадыш, норлат сөйләшләре дә актив катнашканнар. [л] ~ [н] күренешенең яңа җирләрдә пассивлаша төшүенә әдәби телнең йогынтысы да зур роль уйный.

Тикшерә торган күренеш, дөбьяз һәм бәрәңге сөйләшләреннән кала, башка сөйләшләрдә әлегә теркәлмәгән.

Төрки телләр күләмендә карасак та, әлеге үзенчәлекнең гаять сирәк очравын күрәбез: ул бары нугай телендә генә билгеләнгән. Мондый хәл исә дөбьяз сөйләшенә әлеге күренешне Казан ханлыгы чорында нугайлар алып килгән булуын фараз итәргә мөмкинлек бирә. Чөнки нугай гаскәрләренең гаиләләре Казаннан ерак булмаган җирләргә урнаштырылган була.

Шулай итеп, Казан ханлыгы чорындагы тарихи вакыйгалар дөбьяз сөйләшенең мөстәкыйль сөйләш булып формалашуына китергән. Бәрәңге сөйләше формалашуда дөбьяз сөйләше вәкилләренең катнашулары турында тарихчылар, археологлар һәм телчеләр уртак фикердә торалар, моны бәрәңге сөйләшенә хас диалекталь күренешләр дә раслый.

Тулы регрессив ассимиляциянең тагын түбәндәге очракларын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек үк, юклык кушымчасыннан алда килгән тел очы [н] сонанты кушымчадагы [м] авазына охшашлана: *ышамма* – ышанма, *кийеммә* – киенмә һ.б. Мондый күренеш ирен-ирен [м] сонантына башланган башка кушымчалар яки сорау кисәкчәләре алдында да күзәтелә: *уйаңғамма* –

уянганмы, *чығарғамма* – чыгарганмы; *күреммн* – күренми, *туғаммын* – туганмын һ.б. Бу күренеш ике сүз арасындада була: *ум бала* – ун бала, *төм буйы* – төн буе; *исәм бул* – исән булл, *қойоңғам* бар – коенган бар, *очратқам бар* – очраткан(ым) бар; *ишеткәм бар* – ишеткән бар һ.б.

[н] сонанты [ғ / г] тартык авазларыннан алда килгәндә, өлешчә кире охшашлануга дучар була: *урмаңға* – урманга, *идәңгә* – идәнгә, *пүкәңгә* – диал. пүкән / бүкән – урындык, *имәңгә* – имәнгә һ.б.

Билгеле бер төркем сүзләрдә саңгырау [ч], [с] тел очы тартыклары, [ш] авазы алдында килеп, тулы регрессив ассимиляциягә биреләләр: *шыршы* – чыршы, *шаршау* – чаршау, *шишмә* – чишмә, *шишү* – чишү, *ширмеш* – чирмеш (марилар революциягә кадәр шулай аталып йөртелгәннәр), *шебеш* – чебеш, *шуғыш* – сугыш, *шишәмбе* – сишәмбе һ.б.

Алынма сүзләрдә дә төрле регрессив ассимиляция күренешләре күзәтелә: *пуссыз* – рус. путь + -сыз, *пампаси* – монпансье.

Тартымлы исемнәрнең чыгыш килеше кушымчалары охшашланмаска мөмкин: *арасындан* – арасыннан, *атасындан* – атасыннан, *алма ағачындан* – алма агачыннан, *аwылындан* – авылыннан, *шундан* – шуннан һ.б.

Шушында ук *андан ары* (әд. аннан соң) бәйлек сүзен дә күрсәтеп үтү урынлы булыр, анда да чыгыш килеш кушымчасы охшашланмый кала. Алга таба бу сүз үзенчәлекле фонетик үзгәрешләргә дучар була. Мәсәлән: *Андрасыннан қул белән әйләндереп суқтым. Андыра болай* (аннан соң) *йазыр ийем. Җитен талқығач, тимер шырт белә тартабыз, андыра* (аннан) *була үзәк. Андырарсыннан телӘдем* (теләсә) *нәрсә эшләрем. Андарыгысыннан бер энем бар ийе. Андарығысыннан ашлык суwырмаға җөрдөк инде, балам. Андыра ақтықтан ыриза булды инде.*

Диссимиляция (охшашсызлану) очраклары. 1. *Шушы, шушында, шушылай* сүзләрендә сүз башындагы [ш] авазы, охшашсызланып, [т] авазына алмашына: *тушы* – әд. шушы, *тушында* – шушында, *тушылай* – шушылай. Мондый күренешнең таралыш ареалы урта диалектның тагын дөбьяз, норлат сөйләшләрен дә эченә ала.

Биредә *чашу* – әд. шашу сүзен дә күрсәтеп үтәргә кирәк. Шундый ук *чашу* варианты мамадыш, балтач, дөбьяз, лаеш сөйләшләрендә дә бар.

Сүз башындагы [ш] тартык авазының үзеннән соң килгән [ш] авазына охшашсызлануы тагын *чешә* – шешә, *чешү* – шешү, *чөшлө* – шөшле сүзләрендә дә күзәтелә.

Аваз өстәлү. Ике сузык арасындагы [н] авазы йанына [ғ/г] авазы өстәлә: *күңгел* – күңел, *сеңгел* – сеңел, *моңғайу* – моңаю, *шуңға* – шуңа, *аңға* – аңа, *синға* – синә, *иңге* – иңе һ.б.ш. Мондый күренеш сүзтезмәләрдә дә күзәтелә: *иңголосо* – иң олысы, *иңгелек* – иң элек һ.б.

Шунысы характерлы, *н* авазы янына *г* өстәлү күрше мари телендә дә, аеруча тау марилары сөйләшендә дә күзәтелә. Бәрәңге сөйләшендә әлеге күренешнең, күрше дөбьяз, мамадыш һәм башка кайбер татар сөйләшләре белән чагыштырганда, активрак булуында сөйләш вәкилләре аралашып яши торган мари сөйләшләренең дә теге яки бу дәрәҗәдә роль уйнавы мөмкин.

Аерым очракларда түбәндәге тартык авазлар өстәлә: **т** (*күләткә* – күләгә, *артқылы* – аркылы), ***к*** (*тулык* – тулы); ***в*** (*вырғыту* – ыргыту), ***б*** (*кәшәмир / кәшәмбир* – кашемир), ***ғыл*** (*җаңғылыш* – ялгыш), ***ө*** (*өтөрмән* – төрмә) һ.б.

Авазлар төшү. Ике сузык арасындагы позициядә [г], [ғ] тартык авазлары, редуцияләнеп, [w], [й] сонорларына күчәргә яки бөтенләй төшеп калырга мөмкин. Мәсәлән: *тее / те* – теге, *бүwелеп* – сөйләштә: *бүгелеп* – әд. бөгелеп, *җуйалту* – йугалту, язуда: югалту һ.б.

[h] авазы татар теленә гарәп-фарсы сүзләре белән кергән ят аваз булганга күрә күпчелек сөйләшләрдә әйтелми. Сүз башындагы позициядә [h] авазы төшә: *әммесе* – һәммәсе, *үнәрсез* – һөнәрсез, *үнәрле* – һөнәрле. Сүз уртасындагы позициядә [h] авазы төшкәч, [й] яки озын сузык әйтелә: шәәршәмбе – чәршәмбе (– чәһәршәмбе), мийер – миһер – изгелек, яхшылык, йәннәмдә – җәһәннәмдә.

Аерым сүзләрдә түбәндәге тартык авазлар төшә: ***н*** (*ниди* – нинди, *муча* – мунча, *билә / белә* – белән, *чалқа* – чалкан), ***л*** (*сеңгесе* – сеңлесе, *сеңем* – сеңлем, *төчөгән* – төчлегән), ***в*** (*ағус* – август), ***д*** (*йалында* – өйалдында).

Иҗекләр төшү: ***ды*** (*қарнық* – карындык), ***ла*** (*айса* – алайса), ***е(э)л*** (*тийлек* – тийеллек – тиенлек), ***ба*** (*ласа* – ләбаса), ***ге*** (*җерләү* – *җегерләү* – эрләү), ***йи*** (*тәкмәк / тәйкмәк / тә*$^{й}$*кмәк* – тәйикмәк) .

Метатеза (авазларның яки иҗекләрнең урыннарын алмаштырып сөйләү): *сулама* – сумала, *күгәлә* – күләгә, *әйтеп бетерек-*

*сез* – әйтеп бетергесез, *нилет* – лента, *чибкән* – чикмән, *күсәртү* – күрсәтү, *чорау* – очрау һ.б.

## Морфологик үзенчәлекләр

**Исем сүз төркемнәре.** Сүзләрнең ясалышы белән бәйле үзенчәлекләр:

Алда әйтелгәнчә, сүз [л] белән башланган (*-лар/-ләр, -лык/-лек, -ла(н)/-лә(н), -лы/-ле, -лата/-ләтә*) кушымчалар алганда, аның азагындагы [н] авазы кире ассимиляциягә дучар була: *суғаллар* – суганнар, *замаллар* – заманлар, *қайыллық* – каенлык, *утыллық* – утынлык һ.б. Дөбьяз сөйләшенең төп дифференциаль билгесе булган бу үзенчәлекнең изоглоссасы бәрәңге сөйләшендә дә дәвам итә. Ләкин биредә аның кулланылышы бераз чикләнгән икәнен ассызыклап үтәргә кирәк. Монда төрле факторлар зур роль уйнаган: беренчедән, бу тирәләргә күчеп утырган казан арты татарлары сөйләшенең тәэсире көчле булган. Икенчедән, әдәби телнең йогынтысы да зур роль уйнаган. Менә шушындый шартларда бәрәңге сөйләше вәкилләренең административ-территориаль яктан берникадәр аерымланган булуы да күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган.

Бәрәңге сөйләшендә дә, башка күп кенә сөйләшләрдәге кебек, кеше исемнәрен кыскарту һәм аларга иркәләү-кечерәйтү кушымчалары (*-ый/-ий, -ыш/-еш, -ч, -кай/-кәй* һ.б.) ялгау күренеше күзәтелә: *Гәйфи* – Гайфетдин, *Әхми* – Әхмәтгали, *Сира* – Сираҗетдин, *Сафук* – Сафа, *Сәйпи* – Сәйфетдин, *Бикмүш* – Бикләметдин (?), *Мехәми* – Мөхәммәтгали.

**Исемнәр**. 1 нче һәм 2 нче зат берлек сан тартым кушымчалары алган исемнәрнең төшем килеше ике вариантта ясалырга мөмкин: *-ы/-е* (угыз тибында) һәм *-ны/-не* (әдәби телдәгечә): *Қулымы* (кулымны) *қыстым җаңгыш. Күргән төшеңе* (төшеңне) *теләсә кемгә сөйләргә кирәк түгел. Эшеме* (эшемне) *бетермичә җатмыйм мин, андарығысын иртә белән читен була ич.*

Исемнәрнең иялек килеше *-нын/-нен* варианттагы кушымча белән ясала: *Бақчанын* (бакчаның) *эше күб анын* (аның). *Аwылнын* (авылның) *тарихларын йазмағайтәләр икән. Кисут, диләр, марилarнын* (мариларның) *келәү итә торған җирләре ул.*

Тартымлы исемнәрнең төшем килешен угыз тибында формалаштыру аеруча урта диалект сөйләшләрендә билгеләнгән: мамадыш, балтач, лаеш, тау ягы сөйләшләрендә, пермь. керәшен,

златоуст, минзәлә, красноуфим (чагыштыр: шулай ук Төрәк, гагауз һ.б. кайбер телләрдә дә).

Икенче тип изафә бәйләнешендә оешкан сүзтезмәләрдә икеләтелгән тартым кушымчаларын әйтелү күзәтелә: *җир җиләгесе* – әд. җир җиләге, *күлмәк җиңгесе* – күлмәк җиңе, *ишек алдысы* – ишек алды, *ипи башысы* – ипи башы (ачыткы турында) һ.б.

Мондый күренеш татар теленең тау ягы, нократ, минзәлә, пермь, керәшен сөйләшләрендә, шулай ук златоуст, каргалы һ.б. сөйләшләрдә дә күзәтелә.

**Алмашлыклар**. Алмашлыкларның составы, төркемнәре һәм функцияләре буенча бәрәңге сөйләше әдәби телдән аерылмый. Аерымлыклар аларның фонетик яисә грамматик төрдәшләре булуга кайтып кала.

*Әнәтерә / әнәтора – әнә + тора / терә, менәтерә / менәтора – менә + тора / терә* алмашлыклары да кулланыла: *Әнәтерә шәлләр, ҡайсысын телисең. Менәтерә бу гөлләргә су сибәргә кирәк ич. Шул ҡортно* (колорадо коңгызы турында) *чүплибез менәтора.*

Әлеге алмашлыклар, нигездә, урта диалектта һәм тагын көнбатыш диалектның мордва-каратай һ.б. сөйләшләрендә таралган.

*Шушы, шушында* алмашлыклары белән беррәттән, бәрәңге сөйләшендә аларның диалекталь вариантлары да кулланыла: *Тушында* (шушында) *ғынайы ласа күзлегем. Тушы җулдан барасы.*

Мондый диалекталь төрдәшләр тагын норлат, балтач, керәшен сөйләшләрендә күзәтелә.

*Теге* күрсәтү алмашлыгының бәрәңге сөйләшендә дә *тее/ти* төрдәшләре күзәтелә: *Тее сиздермичә генә чыып* (чығып) *киткән. Тийаҡта* (теге якта) *бер мари аwылы да бар монда. Те* (теге) *кеше озаҡҡа килде микән сун? Фундамит салып бетергәч, теннән (тегеннән) чаҡырталар, ҡөр'ән ашына, дип.*

Бу үзенчәлек [г] авазының ике сузык арасындагы позициядә редукцияләнүенә бәйле рәвештә барлыкка килә, гомумтөрки характердагы закончалыклы күренеш булып тора һәм шуңа күрә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә теге яки бу дәрәҗәдә табыла, башка төрки телләрдә дә күзәтелә.

*Нәрсә* сорау алмашлыгының *ни, нәстә, нийәрсә (– нә/ни + ирсә)* вариантлары актив кулланыла: *Андарығысын җаучыға атанасы бирмәкче була йикән, ҡызның берәр зурыраҕраҡ нәстәсен* (нәрсәсен), *сөлгөмә, ашаулыҡма, биреп җибәрәләр ҡул билгесе*

*итеп. Нийәрсә кирәк, әни, дип тора улым.* Бу вариантлар татар теленең күп сөйләшләрендә күзәтелә.

*Нинди* сорау алмашлыгының *ниди* төрдәгесе дә күзәтелә, ул аеруча өлкәннәр телендә очрый. *Ниди кешеләр болар, кәнсирт қуйалар микән эллә, дип сорый, туксан ике йәш үзенә.*

Мондый үзенчәлек керәшеннәр, мамадыш, лаеш, минзәлә, бөре сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән.

Бәрәңге сөйләшендә үз билгеләү алмашлыгы үзе вариантында кулланыла: *Иген иктеләр бабайлар, әммесенен үзе игене булды. Элек гел үзе белеме белән тордо халық.*

Бу алмашлык Тау ягы татар сөйләшләрендә, пермь сөйләшендә дә билгеләнеп үтелгән, тубыл-иртеш диалектының саз ягы сөйләшендә ул *үс/үсе* вариантында кулланыла.

Алмашлыкларның килеш белән төрләнеше. Алмашлыкларның иялек килеше, әдәби телдән аермалы буларак, *-нын/-нен* кушымчасы белән формалаша: *Безнен* (безнең) *аwыл. Анын* (аның) *атламмайы барсыныкыннан қаты, тәмне була торған ыйы. Сезнен* (сезнең) *җақларда да булама сабан туйы? Монон да қорсағы бар.*

*Мин* алмашлыгы, иялек килеше белән төрләнгәндә, тамырдагы [н] авазы төшә, янәшәдәге сузыкларның күтәрелешләре төрле булганга күрә, [н] урынында [й] соноры барлыкка килә: *Мийем дә туғаллар бар анда.* Шулай ук: *Мийеке бигерәк тә әшәке җиргә туры килгән* (печән өлеше турында).

Тамырдагы [н] урынына [й] сонорын куллану саз ягы сөйләшендә актив (1, 55), Урал төбәгендәге башка сөйләшләрдә дә бар.

I зат күплек сандагы *без* алмашлыгының иялек килеше, әдәби телдәге *безнең* варианты белән беррәттән, *безен* формасында да әйтелә: *Безен* (безнең) *йақшы кешеләр күп.*

1 нче һәм 2 нче зат берлек сан алмашлыкларының юнәлеш килеше бәрәңге сөйләшендә *миңа/миңға/мийа/мийә, сиңа / сиңга / сийа / сийә вариантларында кулланыла.* Мәсәлән: *Сиңға* (сиңа) *қунақлар килгән икән. Мийа да* (миңа да) *күрергә туры килде орчоқ җегерләүләрне. Сийа* (сиңа) *қайсысын бирим, бу шәлләрнең зурырағынма? Мийә* (миңа) *күчтәнәчкә төш пешерүче кирәг ийе. Сийә (сиңа) өч сутый печән җитәрмә, дий.*

Болардан *мийа, сийа* формалары өлкәннәр телендә ешрак күзәтелә, яшьләр сөйләмендә ул чагыштырмача сирәк очрый.

*Мийа, сийа* диалекталь формалары чиктәш дөбьяз сөйләшенә хас төп билгеләрнең берсе булып тора. Аны Л. Җәләй дә ассызыклап күрсәтеп үткән. Аның сингармоник варианты (*мийә, сийә*) татар теленең Урал, Себер төбәкләрендә таралган сөйләшләргә хас.

Шундый ук формалар караим телендә, азәрбайҗан теле диалектларында да теркәлгән.

*Миңға, сиңға* вариантларында сөйләшкә хас [ғ] өстәлү күренеше чагылган. Мондый вариантлар урта диалектның тагын казан арты төркеме һәм түбән кама керәшеннәре сөйләшендә дә күзәтелә.

Күрсәтү алмашлыкларының юнәлеш килешендә борынгы кушымчалар яки аларның вариантлары кулланылу сакланып килә: *-ар/-әр, -гар/-гәр* һ.б. Мәсәлән: *Мин аңғар* (әдәби телдә аңа) *сөйләдем. Тегеңгәр* (тегеңә) *җаңга ишекләр җасаттым. Шушыңғар* (шушыңа) *хәтле белмичә йөргәнмен. Шуңғар (шуңа) тағын бер қат түшәк тә җәйәсен. Шуңғар күрә* (шуңа күрә), *шүрәле қарғаған Лажыны* (авыл исеме).

Бәрәңге сөйләшендә *анысы, монысы, кайсы, шунысы* алмашлык-ларына 3 нче зат берлек санда икеләтелгән тартым кушымчалары ялгана: *Қайсысын* (кайсын) *телисен, шунсысын* (шунысын) *аласын. Бусысы* (монысы) *бигрәк матур. Монсосы* (монысы) *җәшләй китте кийәүгә.*

Шушындый ук күренеш *бер, кайсы* сүзләрен кулланганда да саклана: *Берсесен* (берсен) *күпер аржағында очраттым. Ике малайның берсесе* (берсе) *китсә дә, берсесе қала дип торам инде. Қайсысын телисен, шунсысын аласын.*

*Бу* күрсәтү алмашлыгының, кыек килешләрдә килгәндә һәм башка грамматик күрсәткечләр алганда, еш кына, тамыр варианты саклана: *Боннан* (моннан) *да кечкенә йем әле. Бососы* (монысы) *матурраграқ дип, зәңгәрен алдым* (шәл турында).

Мондый үзенчәлек Урал тирәсендәге (пермь, минзәлә, стәрлетамак, красноуфим, сафакүл һ.б.) сөйләшләрдә күзәтелә.

**Сыйфатлар**. 1. Бәрәңге сөйләшендә сыйфатларның составы, нигездә, әдәби телдәгечә. Шулай да кайбер диалектизмнар сөйләшнең үзенчәлеген арттыралар: *икеләнчек* – икеләнүчән (чагыштыр: әдәби *кыланчық* сыйфаты белән бер калыпта); *төсбәт* – шыксыз; *ыжгырыйн / ажгырыйн* – зур гәүдәле, киң җилкәле кеше турында; *җағылмалы* – ягымлы һ.б.

2. Чагыштыру дәрәҗәсендә икеләтелгән кушымча ялганып килә: *Җақшырағрақ* (йақшырақ) *күлмәк алырсын сабан туйына. Дәүрәгрәк* (дәүрәк – әд. зуррак) *бәрәңгеләрне айырып җудым да, әрчеп тозға җарып салдым пешәргә.*

**Рәвешләр**. Бәрәңге сөйләшендә диалекталь лексик рәвешләр дә табыла: *җилеш* – көч-хәл белән, көчкә-көчкә (башка сөйләшләрдә билгеләнмәгән), *иртә беләгә* – иртәгә һ.б. Түбәндәге рәвешләр киң кулланыла: *әwәле* (элек). *Әwәле күлмәг өстөннән изү кийеп қуйарлар ийе қунаққа ашқа барғанда.* Ин ал – башта, алдан. *Ин ал берсен бағып бирдем өч йәшенә җиткәнче.* Әwәл-әwәлтеннән – элек-электән. *Әwәл-әwәлтеннән ни сорый, бич биреп барды.* Көлләрдә бер көллө – әд. көннәрдән бер көнне. *Көлләрдә бер көллө қайтты бу.* Араға бер – сирәк-мирәк, әллә нигә бер. *Араға бер күмәч килә инде* (сатуга). Иңгәwәле. *Қазаннан килгән 4 аға-эне, иңгәwәле җорт салгаллар.*

Сөйләштә исемнәрдән, сыйфатлардан рәвешләр *-лай/-ләй, -лый/-лий* кушымчасы белән ясалалар: *Бушлай эшләт. Сөтләй генә биреп җибәрдем. Хәзер ақчалай түлиләр түләwен. Йәшлий үлгәннәр анын атаналары икесе дә, тип* (тиф) *чығып. Төллә әхрән тора, көндөзлий җоқлаб ала әзрәгрәк. Әтийем йәшләй үлде.*

*Көйө* бәйлеге ярдәмендә рәвеш ясау очраклары да еш күзәтелә: *Әммә җаратам шул кәбестәне, чи көйө дә қапқалыйм.*

Сөйләштә рәвешләрнең чагыштыру дәрәҗәсенә дә икеләтелгән кушымча ялгау хас: *Тизрәгрәк* (тизрәк) *барсан, суңға қалмассын әле. Йақшырағрақ эшләсән, қайда да җаратырлар үзенне.*

Шундый ук үзенчәлек татар теленең башка сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән. Мәсәлән: пермь, ләмбрә һәм темников, саз ягы һ.б.

Вакыт рәвешләренең ясалышы белән бәйле мондый үзенчәлекләр бар:

1. Вакытны белдерә торган исемнәрдән *көнө* сүзе белән (*йаз көнө, көз көнө, қыш/қош көнө*), яисә *-ын/-ен* кушымчалары ялганып (кышын, йазын, көзен, җәйен, кичен, иртән), вакыт рәвешләре ясала. Семантик яктан алар эш яки хәлләрнең тамырда күрсәтелгән вакыт аралыгында башкарылуын белдерә. Мәсәлән: *Қошлоқло бодай* (көзге бодай), *анысын көз көнө чәчеп қалдыралар. Көз көнө киндер итәрләр* (булдырырлар) *ийе, андарығысыннан җегерләргә утырмаға җөрдөк инде, балам. Әwәл wәл диғән шәлләр булыр ийе бәк җақшы, җәй көнө бөркәнергә.*

2. Ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән *-лықта/-лектә* кушымчасы ярдәмендә вакыт рәвешләре ясала: *Көн белән төн ике рәт тигезләнә, бер йазлықта* (яз көне), *бер көзлектә* (көз көне). *Қышлықта* (кыш көне) *бардым қызыма, айдан артық тороп қайттым. Көзлектә, қызны бирергә уйласалар, қодалар төшә, бирнә кисәсен.*

*-лықта/-лектә* кушымчалары ярдәмендә вакыт рәвешләре ясау татар сөйләшләрендә шактый киң таралган күренеш. Мәсәлән, ул мамадыш, балтач, лаеш, нагайбәк, минзәлә, пермь, златоуст, каргалы, шарлык һәм богырыслан (аеруча актив) сөйләшләрендә күзәтелә, көнбатыш (мишәр) диалектында да бар.

Бәрәңге сөйләшендә дәвамлы вакыт түбәндәге чаралар белән белдерелә:

1. Әдәби телдәге кебек үк, ел фасылларын, тәүлек өлешләрен атый торган исемнәр һәм буйы, буйынча бәйлек сүзе ярдәмендә: *Қыш буйы пирмегә су ташыр ыйы, җылытып эчерәсе булғачыннан. Җәй буйы чытлым җаңғыр төшмәгән җыл булган, шуннан ачлық булган. Киленнең килене қыш буйынча су китерде.*

2. *-лый/-ли(й)* кушымчасы ярдәмендә: *Ике чиләк бәрәңге булса, қышлый* (кыш буе) *ашап чығарыма җитә. Миче килешмәде, қышлый су тама почмақлардан.*

Мондый очракта басым рәвешнең тамырына төшә.

Бу кушымча саннарга да ялганып килә һәм сан рәвеше ясый: *Икенчеләй фамилҗасын сорыйлар монон.*

3. *-ын/-ен* кушымчалы антонимик вакыт рәвешләреннән торган парлы сүзләр ярдәмендә: *Көнөн-төнөн җауды җаңғыр, печәлләр нәстәшләп бетә инде. Малны да қышын-җәйен тәрбийәләсәң генә була ул. Аwыл җирендә көзөн-йазын эрзин итек айақтан төшми.*

Рәвешләр башка төрле ярдәмлек чаралар белән дә белдерелә ала: *көнозон* – көн буена, *озон көн(нәр) буйына, төннөн төн алып* – төне буе һ.б.

**Фигыль. Затланышлы формалар.** Хикәя фигыль. Әдәби телдәге кебек үк, бәрәңге сөйләшендә дә хәзерге заман хикәя фигыльнең *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы төре кулланыла.

Беренче зат берлек санда, нигездә, тулы тарихи форма саклана: *Җал җитсә, балаларның қайтқанын көтөп торамын. Утырамын да саwамын, ашарына андарығысын бирәмен. Иртүк тороп чығам, мунча йағам, суwын китерәм. Мин ат җигәмен ич, күрмисеммә?*

II зат берлек санда архаик -*сын/-сен* варианты төп форма булып тора: *Син күп сөләшәсен. Син чийәне оста җийасын. Нәстә йазасын?*

Бу вариант татар теленең барлык сөйләшләрендә дә табыла, ләкин ул факультатив характерда гына күзәтелә. -*н* вариант исә урта диалектның касыйм, нократ сөйләшләрендә төп форма булып тора.

Билгеле булганча, зат кушымчалары зат алмашлыкларыннан килеп чыкканнар һәм әлеге сөйләшләрдә бу тарихи чыганак форма тотрыклылык саклый. Нократ сөйләшендә исә ул ассимиляциягә дә бирелми (*барасин* – барасың, *санайсин* – саныйсың һ.б.).

II зат хикәя фигыльнең күплек саны ике вариантта күзәтелә: -*сыз/-сез* һәм -*сыгыз/-сегез*. Мәсәлән: *Башта Бәрәңгегә* (район үзәге) *барасығыз* (әд. барасыз) *инде. Андарығысын җаучы әйтә, күпме қолақ сөйөнче сорыйсыз? Бүген кич чығасығызма* (чыгасызмы)*? Сез киләсегез* (киләсез) *икән, қызларым қайта дип торам*.

Бу вариантлар икесе дә кулланыла һәм алар традицион сөйләшне саклый торган өлкәннәр сөйләмендә дә, әдәби тел кануннарын яхшы белә торган яшьләр, зыялылар сөйләмендә дә кулланыла.

-*сығыз/-сегез* кушымчасының изоглоссасы татар диалект теленең шактый зур өлешен алып тора: бәрәңге, дөбьяз сөйләшеннән башланып, ул мамадыш, балтач, лаеш (ягъни казан арты сөйләшләре төркемен тулысы белән) сөйләшләрен, минзәлә, бөре, тепекәй, богырыслан, каргалы, сафакүл сөйләшләрен эченә ала.

Башка төрки телләр яктылыгында карасак, әлеге форма татар һәм башкорт телләренә уртак тарихи күренеш булып тора.

С и н т е т и к  ү т к ә н  з а м а н  х и к ә я  ф и г ы л ь. Бәрәңге сөйләше үткән заман формаларының составы ягыннан да әдәби телгә якын.

1. Билгеле (категорик) үткән заман -*ды/-де/-ты/-те* кушымчасы белән ясала: *мин бардым, килдем, қайттым, киттем, син бардын, килден, қайттын, киттен, мин бармадым, килмәдем, син бармадын, килмәден* һ.б.

Сөйләштә билгеле үткән заман формасының, *йуқ* сүзе белән килгәндә, категорик (билгеле) киләчәк заман мәгънәсен белдерү очраклары теркәлгән. Мәсәлән: *Моннан сун синен белән кешегә бардым йуқ* (барачагым юк), *сүз тылламыйсын. Адашып җөргәлләр дә, қайтқачыннан «бүл'ше ул җақ урмаңга бардым җуқ* (бармаячакмын)», *тип антлар эчте. Бүген уеңға чығам, өйдә қалдым йуқ* (калмаячакмын). *Мин күршегә генә керәм, анда озак тордым йуқ* (тормаячакмын).

Мондый күренеш казан арты сөйләшләре төркемендә дә күзәтелә, тик анда эмоциональ-экспрессив мәгънә салынган була: *Бу пычрақта бақчаға чығам дип йөрдөм йуқ* (чыгачагым юк, йөрисем юк). Шушындый караңғы төндә бәкәй эзләп йөрдөм жуқ (йөриячәгем юк), *кирәк булса үзең эзлә* һ.б.

Китерелгән материалларда, нигездә, бер үк коннотатив эчтәлек чагыла кебек. Аерымланып формалашу процессында бәрәңге сөйләшендә йә борынгырак чорга хас үзенчәлек сакланып куллануын дәвам итәргә яисә, эмоциональ-экспрессивлык гадәти, нейтраль эчтәлеккә әйләнә башлаган булырга мөмкин.

2. Нәтиҗәле (билгесез) үткән заман. Бәрәңге сөйләшендә нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәге кебек, *-ған/-гән* формалы сыйфат фигыльгә нигезләнә һәм I төр зат кушымчалары белән төрләнә: *Мин алғаммын, күргәммен, төшкәммен* һ.б. *Сез алғансыз / алгансығыз, күргәнсез / күргәнсегез, төшкәнсез / төшкәнсегез* һ.б. Мәсәлән: *Без Күwәмнән* (ав. ис.) *күчеп килгәмбез, дип сөйләр иде бабай. Безнең бабайлар Иске Таззар дигән аwылдан килгәлләр. Қыз бала әз генә қалықса, орчоқ җегерләргә утырған. Анасы шәл бәйләгән, шәл сатқан анын, шулай итеп қараб үстергән ике баланы. Мин җәшләй җәтим қалғаммын, абый кулында үстем. Син аны күрмәгәнсен, тушында ғына торған ул уйынчық. Сез җырақтан килгәнсегез икән.*

Бәрәңге сөйләшендә нәтиҗәле үткән заманның төрләнеше белән бәйле тагын бер үзенчәлек – зат кушымчалары урынына тартым кушымчаларын куллану теркәлгән. Мәсәлән: *Җаңғыш синең чиләгеңе апкереп киткәнем* (әд. киткәнмен). *Сез җырақтын, Қазаннан уқ килгәнегез икән* (килгәнсез икән). *Син тирәк чығаруны* (чигү чигүне) *күргәнең* (күргәнсең) *генә.*

А н а л и т и к ү т к ә н з а м а н х и к ә я ф и г ы л ь. Бәрәңге сөйләшендә аналитик үткән заманнарның түбәндәге формалары бар.

1. Күптән үткән заман *-ган/-гән* формалы сыйфат фигыльгә *иде* ярдәмче фигыле кушылып ясала. Мәсәлән: *Мин барып җиткәндә печәнне җийып бетергәннәр ийе. Мин унны бетергәндә сез читкә киткән ийегез инде. Үткән атнада тийатырға барғанийық Қазанға. Сез ул бабайларда булғанийығызмы?*

2. *-адырыйы* формалы тәмамланмаган үткән заман: *Даллықлы* (данлыклы) *базар була торған ийе, җийыллар буладырыйы. Чәчүгә чықмас борон сабан тийы* (туе) *буладырыйы. Бөгәлҗәле алқаны алтынчыдан аладырыйық.*

3. Кабатлаулы үткән заман формасы да әдәби телдәгечә: *Элек уйыллар әнә тушы җирдә була торғаныйы, күңгелле җирдә. Атларға утырып тезелешеп китә торғаннарыйы сабан туйға. Утауға барсақ, кәҗә сақал, қақы, ақбаш ашый торған ыйық. Үлчәп бирә торғаллар ийе безгә җирне.*

Кабатлаулы үткән заман *-ыр/-ер иде* формасы белән дә ясала, аны әдәби телдәге -а/-а торган иде формасына туры килә дип саныйлар. Ул, күбесенчә, үткәннәрне искә төшереп, хәтирә рәвешендә сөйләгәндә кулланыла: *Йәшлектәге – төшлөктә, диләр, үтә дә китә, көнө буйы эшләсәк тә кичке уйынға чығарыйық, сабан туйлары күңгелле булыр ыйы. Иңгәлек сабан туйы булыр ийе, андарығысын* (аннан соң) *чөгән атнасы* (җыен исеме). *Суқмаға чығар ыйым шабағаш белән. Безнең йақта бодай бик булмас ийе. Хәситә дип балаларға тағырлар ийе күз тимәскә дип. Туңмас ыйым да, казакилар кийеп йөгөрөп йөрөр ийем туар* (мал) *қарап.*

*Ди-* фигыленнән *-ыр/-ер иде* конструкциясе ясала: *Таштеки дирер* (әд. дияр) *ийек, ташларны тезеп-тезеп уйнар ийек. Өститәк дирер ийек, өчәр итәк салып тектерер ийек.*

Сөйләшнең үзенчәлеге шунда, диалекталь *дирер* сүзенең кыска формасы актив кулланыла. Мәсәлән: *Қандала қабығы, дирләр ийе, ансы тақта күтәреп суққан* (үзеннән бизәк чыгарып сугу турында). *Изү йапмаларынын тоташкан урнын күнчек дирләр ийе, күнчек белә имнәгәлләр күз тисә.*

Билгеле булганча, *-ыр/-ер иде* формасы урта диалектның үзенчәлекле билгеләреннән берсе булып тора, күпчелек сөйләшләрдә таралган.

Киләчәк заман хикәя фигыль. Бәрәңге сөйләшендә киләчәк заман хикәя фигыльнең ике формасы кулланыла:

1. *-ыр/-ер* кушымчалы билгесез киләчәк заман. Тамырында [р] авазы булган фигыльләрнең I зат берлек һәм күплек саннарында килгәндә, ике [р] авазының берсе кыскара: *барымын, барым, барысын, барысыз, барысығыз.* Мәсәлән: *Қайтқанда керемен* (керermен). *Җарар, җарар, хәзер барым* (барырмын). *Кич белән килерсегез, бөтенесен сөйләрем* (сөйләрмен). *Утырым, утырым* (утырырмын), *әле wақыт бар. Қайтышыңға өс-баш алып қуйарым* (куярмын), *қайтқанда мийә кересен.*

I зат берлек санның юклык формасы да кыска һәм тулы вариантларда кулланыла: *Алмамын* (әд. алмам) *буш бирсәгез дә. Барып*

*йөрмәм инде, җырақ. Туwар* (мал) *да асырамамын җаңғыз башыма, дип торам.*

Соңгы еллардагы лингвогеографик тикшеренүләр *барым, утырым* тибындагы үзенчәлекнең барлык диалектларда да табылуын күрсәтә.

*Барырым, килерем* тибындагы вариантлар аеруча угыз төркеме телләренә хас. Мәсәлән, Төрәк, азәрбайҗан, гагауз телләрендә алар әдәби норма булып торалар.

2. Билгеле киләчәк заман. *-ачак/-әчәк* кушымчалы билгеле (категорик) киләчәк заман, башка сөйләшләрдәге кебек, бәрәңге сөйләшендә дә шактый сирәк күзәтелә. Түбәндәге берничә моментны билгеләп үтик.

Бу форма, нигездә, булачагына шик-шөбһә булмаган, булачагы билгеле булган, сөйләү моментыннан соң булачак эш яки хәлләрне белдерә: *Тушы бабай шәфәққә қарап қына алырыйы да иртәгә айаз булачак дирер ийе. Қыйбладан килеп җауды җаңғыр, бәрәңгеләр үсеп китәчәк.*

Киләчәк заманның юклыгы төрле чаралар белән белдерелергә мөмкин:

а) *-ма/-мә* юклык кушымчасы белән: *Көлләр җылынмыйчы тороп, бәрәңге тишелмәйәчәк. Мим барып урнашмыйчы ул әле Қазанға килмәйәчәк.* һ.б.

б) *түгел* модаль сүзе белән: *Беләм мин аны, эшләйәчәк тә түгел, кешегә дә тапшырачақ түгел* (чөгендер җирендәге өлешен).

в) *җуқ* сүзе белән: *Булачағы йуқ бу шомортнын быйыл, анатыра ничек қорт төшкән. Баш аwыртуымның бетәчәге җуқ, нинди генә дару эчмәдем инде.*

Боерык фигыль. Аның формалашуы һәм кулланылуы һ.б. буенча бәрәңге сөйләше татар теленең нигез сөйләшләре һәм әдәби тел белән зур уртаклык күрсәтә.

Билгеле булганча, боерык фигыль сөйләүченең икенче бер затка нинди дә булса эшне башкарырга кушуын, боеруын белдерә. Кушу-боеру бары башкаларга карата гына мөмкин булганга күрә, боерык фигыльнең төрләнеш парадигмасы II һәм III затлардан гына тора: син эшлә, ул эшләсен һ.б. Мисаллар: *Оло җулға чыққачтын уңға борылығыз. Бар, син үзең қарап қайт. Балаларны өйрәтеп, җақшы киңгәшләр биреп торсын. Кеше арасында матур булсыллар дип тырыштым.*

Кушу, боеру бик катгый, яисә, киресенчә, йомшаграк булсын өчен, киңәш итү, үтенү, ялвару һәм башка төрле модаль мәгънәләрне белдерә торган төрле чаралар да кулланыла. Мәсәлән, бәрәңге сөйләшендә түбәндәге чараларны язып алырга мөмкин булды: *Чү, әкренрәк сөйлә, баланы уйатырсын. Зинаһар барып әйт инде, белмичә торалардыр. Сөтнең тамчысын җиргә төшермә, ишетсен қолағың. Ипләп кенә тота күр инде, чешкән җирен аwырттыра күрмә. Әбисенең җыллық ашына килә күрсен, бик үтенеп чакырдылар, бик көтәбез, диб әйт инде, җәме.*

Шарт фигыль. Бәрәңге сөйләше шарт фигыльнең ясалышы, грамматик категорияләре һәм семантик функцияләре буенча әдәби телдән аерылмый. Әлбәттә, бу әлеге сөйләшнең формалашуында уйнаган төп факторлар белән бәйле: сөйләш вәкилләре бабаларының төп чыгышы Казан арты районнарыннан һәм Тау ягының төньягындагы авыллардан булу; хәзерге территориягә күчеп утырганда әлеге төбәкләрдәге сөйләшләрнең инде формалашып җитү алдында торулары; матбугат, радио һәм мәктәптә татар әдәби теленең актив кулланылышы һ.б.

Мисаллар: *Wахытында чықсан, машина туры килми қалмый ул. Қарасалар, қуйан чаwып бара икән, шуннан аwыл Қуйан булып қалған. Соло онон ипигә қушсақ, күмәчтән тәмне була. Бик қаты қойашлы булса, көнгә суғарлар ийе, кибән айағына суғу, диләр.*

Теләк фигыль. Билгеле булганча, бу наклонение борынгы *-гай/-гәй* кушымчалы теләк фигыльгә барып тоташа. Аның ясалышы, кулланылышы әдәби телдәгечә. Мисаллар: *Мунча керик тә кич белән қунаққа китик без. Бәрәңгене қарыйм әле, йәш бәрәңге пешериг әле.*

Сөйләштә эчке (субъектив) теләк, теләк-ният, исәп итү һ.б. шундый мәгънәләрне белдерә торган конструкцияләр, формалар күзәтелә. Мәсәлән, әдәби телдәге кебек үк, эчке (субъектив) теләк *-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыль һәм *килә* ярдәмче фигыле белән ясала: *Җиләк ашыйсым килә. Эчәсегез килсә, базда қуwас бар. Сезнен сөйләшкәнне тыллап* (тыңлап) *утырасым килде.*

Билгеле булганча, *-асы/-әсе килә* тезмәсе урта диалектның төп билгеләреннән берсе булып тора.

Сөйләштә теләк-ният мәгънәләре тагын мондый чаралар белән белдерелә:

*-макчы/-мәкче: Өйөбезне сипләтмәкче булып торабыз. Иртәгә иртүк җиләккә китмәкчеләр ийе алар. Тушы көлләрдә* (шушы көннәрдә) *Қазанға барып қайтмақчы булып торам әле.*

Сөйләштә аның кыска формасы да очрый: *Атны тизрәк атамақ булды. Туйға қызы белән килмәг ийе.* Мондый үзенчәлек бараба диалектында актив, Урал аръягы татар сөйләшләрендә дә күзәтелә.

*-ырға + итә/-ырғайтә: Ата қазлары шундый усал, этне чуқырғайтә. Кибеттәге ышқапны алырғайткәнийем* (алмакчы булган идем), *кичә апкиткәннәр икән. Қайчан китәргәйтәсез* (китмәкче буласыз)*? Суны өйгә үк кертергәйтәләр* (кертмәкче булалар).

Татар телендә әлеге борынгы *-гай/-гәй* кушымчасы фигыльләрнең юклык формасына ялганып килә һәм түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

а) теге яки бу эшләрдән сагаюны, ихтималлыкны, шикләнүне: *Болотлар қабарды, җил дә чықты, җаңғыр җаумағайы. Җийында көтөп торасын инде, қунақлар килмәгәйе, дип. Чиләгеңге қара әле, аwып китмәгәйе.*

б) сөйләүченең теге яки бу эш-хәлләргә битарафлыгын, исе китмәвен: *Җаңғыр җауса, бу керләрең лачма була инде. Булмағайы! Койаш чығар да кибәр дә китәр. Ирең ташлап китәр, урындығыңны алып қуй. – Китмәгәйе! Ырым-шырымнарға ышаммыйм мин.*

Бәрәңге сөйләшендә эш яки хәлләрнең башкарылуына карата сөйләүченең битарафлыгын *-сани/-сәни* формасы белән белдерү бик актив. Бу күренеш казан арты сөйләшләре төркемендә дә киң таралган. Мәсәлән: *Тизрәгрәк қу инде, көтүwен соңға қала ич. – Қалсани, җырақ китмәсләр әле. Җаулығыңғы қойашқа элгәнсен, зәңгәр тиз уна бит ул. Унсани, җаулық бетмәгән. Безне ташлап башқаларны Сөйсәни, сөймәсәни.* (Халык җыры)

Бу күренеш урта диалектның гомум характердагы билгеләреннән санала.

Бәрәңге сөйләшендә тагын көчле теләкне (*-сын/-сен + ийе, -асы/-әсе + ийе*), үкенүле теләкне (*-ырға/-ергә + ийе*), итагатьле теләкне (*-ырға/-ергә + ийе*), теләк-киңәшне (*-ар/-әр ийегез*) һ.б. белдерә торган формалар күзәтелә. Мәсәлән: *Әчеп кенә қарар ыйым бу башымны, аwыртуларына түзәр хәлем қалмады. Җаңғыр җаумаса җарар ыйы, печәннәр чери инде. Җәйгә тағын бер қайтсыллар ийе қызым белән кийәwем. Безгә дә килергәйе сезгә, чәйләр эчеп, бақчаларыбызны күреп китәр ийегез. Без җибәрмәскә йе, китәсе*

*килә моның. Эх, тағын бер барасыйы, тағын бер күрәсейе Себер урманнарын.*

Бәрәңге сөйләшендә итагатьле киңәш-теләк боерык фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыленнән торган конструкциясе белән дә белдерелә: *Ал ийең күлмәген дә, ансы йәшкелт булған ийе, монсо зәңгәр булыр ийе.*

Эшнең үтәлеш дәрәҗәсен белдерә торган формалар. Әдәби телдәге һәм урта диалект сөйләшләрендәге кебек үк, бәрәңге сөйләшендә дә эшнең үтәлеш дәрәҗәсе, нигездә, *-гала/-гәлә, -қала/-кәлә, -ыштыр/-ештер, -штыр/-штер* кушымчалары ярдәмендә белдерелә. Бу формаларның кулланылышында берникадәр аермалы төсмерләр бар.

*-гала/-гәлә, -қала/-кәлә* кушымчасы эшнең кабатланып торуын, кимлеген аңлата. Мәсәлән: *Күз салғалап тор әле ашқа, малларны җаwып керәсем бар ийе. Айақ минеке дә җә тезеннән, җә шайтан ашығыннан аwыртқалап тора, әрекмән җапрағы җапқаласам хайран ару булып китә.*

-*ыштыр/-ештер, -штыр/-штер* кушымчалары эшнең сирәк башкарылуын, вакыйга яки хәлләрнең ара-тирә генә булуын белдерә. Мәсәлән: *Гәзитне уқыштыра шунда, бабайның күзе бик зәғыйфләнде инде. Өйдәге вақ-төйәк эшләрне генә қараштыра, бийеме қартайды инде бик.*

**Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив.** Аның формалашуында түбәндәге чаралар катнаша:

1. Әдәби телдәге һәм казан арты, һәм тау ягы төркемнәре сөйләшләрендәге кебек үк, сөйләштә инфинитивның *-ыр/-ер* кушымчалы сыйфат фигыльгә *-ға/-гә* юнәлеш килеше кушымчасы кушылып ясалган формасы төп чара булып тора: *Нәстәшлисен, үлгән артыннан үлеп булмый, тормыш итәргә, суқыр бийемне қарарға, балаларны кеше итәргә. Қыз балан булғачыннан тупларға да тупларға, караwат җәймәләре, мунча җәймәләре. Бүген печән җыйарға барырға.*

2. Бәрәңге сөйләше *-мағa/-мәгә* кушымчалы инфинитивның активрак кулланылышы буенча әдәби телдән һәм казан арты, тау ягы төркемнәре сөйләшләреннән бераз аерыла. Мәсәлән: *Җыйылыш уздырмаға* (уздырырга) *барам. Балаларым уқымаға* (укырга) *җөриләр күрше аwылға. Җоқламаға җатсам, уйлап җатам. Бу кызларны печән җыймаға* (җыярга) *апкилдем. Печән төшөрмәгә дип менгән.*

Мондый үзенчәлекнең активлыгы ягыннан бәрәңге сөйләше дөбьяз, норлат сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә.

Билгеле булганча, *-маға/-мәгә* формасы борынгы татар язма истәлекләрендә үк теркәлгән һәм XX гасыр башларына кадәр татар язма әдәби телендә, әдәби норма буларак, яшәештә булган. Бүгенге көндә *-маға/-мәгә* формалы инфинитив урта диалектның дифференциаль билгеләренең берсен тәшкил итә, көнбатыш (мишәр) диалектында аңа *-ырга/-ергә,* Себер ареалы татар сөйләшләрендә тубыл-иртеш, бараба, том диалектларында *-ғалы/-гәле* формалары туры килә. Ләкин урта диалект сөйләшләре *-маға/-мәгә* кушымчалы инфинитивның кулланылыш активлыгы, мәгънә функцияләре буенча шактый зур төрлелек күрсәтәләр. Урта диалектның нигез сөйләшләрендә бу форма *утырмага (бару), алмага (килү), асрамаға (бирү)* гыйбарәләре составында гына сакланып калган. Төп татар сөйләшләреннән читтәрәк, перифериядә, башка телләр яки аларның диалектлары чолганышында формалашкан сөйләшләрдә *-маға/-мәгә* формалы инфинитив активлыгын саклап калган. Мәсәлән, касыйм, бастан, нократ, пермь, минзәлә сөйләшенең әгерҗе урынчылыгында бу форманың кулланылышы шактый системалы характерда.

3. Сөйләштә инфинитив мәгънәсендә *-у/-ү* формасы да кулланылырга мөмкин: *Балаға йақшы итеп аңлату кирәк* (аңлатырга кирәк). *Эшкә соңға қалу җарамый* (калырга ярамый). *Кеше арасында үзеңге матур тоту* (тотарга) *тийеш.*

Мисаллардан аңлашылганча, *-у/-ү* формасының инфинитив ролендә килүе бигрәк тә инфинитив бәйле кулланылышта булганда күзәтелә. Бу күренеш Себер ареалы татар сөйләшләрендә дә очрый.

*-у/-ү* формасының максатны белдерә торган *-уга/-үгә* төрдәшенең инфинитивка тәңгәл килүе кайбер башка сөйләшләрдә дә күзәтелә.

4. *-асы/-әсе* формасы, татар теле урта диалектының күпчелек сөйләшләренә хас булганча, катгый тиешлекне, кирәклекне, фигыльнең нигезеннән аңлашылган эш яки хәлне башкару ихтыяҗын, зарурлыгын белдерә һәм функциясе белән инфинитивка туры килә: *Көн аралаш дижур торасы* (әд. торырга кирәк). *Бүген райуңға барасы* (барырга тиеш).

Кайбер очракларда *-асы/-әсе* формасы икеләнүне, аптырауны да аңлатырга мөмкин: *Ничек сөйләшеп карасы, сүземне тыллар* (тыңлар) *микән. Қазаңға китәсеме, унынчыға керәсеме дип җөри әле.*

Бу чара киләчәктә һичшиксез булачак эш-хәлләрне дә белдерә: *Уллары бийыл көзгә өйләнәсе* (өйләнәчәк). *Иртәгә қызым қайтасы.*

Әдәби телдәге һәм урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек, *-асы/-әсе* формасы, *бар*, *җуқ / йуқ* хәбәрлек сүзләре белән килеп, эш яки хәлне башкаруга ихтыяҗ булу / булмау кирәклек, зарурилык, тиешлек мәгънәләре дә күзәтелә: *Магазиңға барасы бар ыйы. Иртәгә көтүгә чығасы бар әле. Печән җыйасыбыз бар ыйы, шуңғар җиләккә баралмадық. Гуртта эрәхәт инде, ипи саласы җуқ, бақча қазыйсы җуқ.*

*-асы/-әсе* формасының урта диалект сөйләшләренә дә хас үзенчәлек булуы да диалект вәкилләренең этник тарихы белән бәйләнгән. Әлеге форма угыз телләренә хас күренеш. Бу турыда М. Кашгари үзенең «Диван...»ында (1097) язып калдырган (Кашгари, 34 б.; Л. Җәләй хезмәте буенча китерелә. 1947: 26 б.).

Урта диалект вәкилләренең бабалары болгарларның дәвамчылары булып торалар һәм, галимнәр (Л.Т. Мәхмүтова һ.б.)фикеренчә, болгар телендә угыз элементлары көчле булган.

Исем фигыль. Бәрәңге сөйләшендә исем фигыльнең түбәндәге формалары бар:

1. Иң актив кулланыла торган форма – әдәби телдәге *-у/-ү* кушымчалы исем фигыль. Ул борынгы *-гу* формасыннан үсеш-үзгәреш алып килеп чыккан. Әдәби телдәге кебек үк, бәрәңге сөйләшендә дә исем фигыльләр процессны предметлаштырып, эшләрнең яки хәлләрнең исемен атыйлар. *Кәнсәләрдән сийа йазу китергәлләр. Уқу аwыр эш, шуңға аны инә белән қойо қазу дигәлләр дә. Ғөмөр бетүгә бер сәбәп чыға шул. Қыз белән кийәү қайтуwына суйарым дип торам, тәкәм дәү инде.*

2. Сөйләштә исем фигыльнең *-ыш/-еш/-ш* кушымчалысы да кулланыла. Ул, күбесенчә, хәрәкәтне белдерә торган фигыльләргә ялгана. Мәсәлән: *Суң йақ йарда тийен күп, суның ағышы белән қараб әйткәннәр. Мин* (минем) *әле Қазаннан қайтыш* (кайтуым). *Китешмени* (китүегезмени) *инде сезнең? Бақчаға барыш. Кийәү белән җәш килен мунчадан чығышка тәйикмәк пешерәләр. Қызның төшөшөнә айағастына мендәр салалар.*

Шуның белән бергә, сөйләштә *-ыш/-еш/-ш* кушымчалы исем фигыль башка фигыльләрдән дә ясалырга мөмкин, мондый очракларда исем фигыльләр эшнең яки хәлләрнең барышын, процессын атыйлар. Мәсәлән: *Хәзер дөнҗа көтөшләре* (көтүләре) *қатлауланды.*

*-ыш/-еш/-ш* кушымчалы исем фигыльнең сыйфат фигыль функциясендә дә килү очраклары теркәлгән: *Туғаннары түгел, белешләре* (белгәннәре, белгән кешеләре) *булған ул аларның. Қазанда белешләребез дә, җақылларыбыз да күп безнен.*

*-ыш/-еш/-ш* формасы аеруча урта диалект сөйләшләрендә табыла, Урал төбәге (минзәлә, златоуст, нагайбәк, эчкен, красноуфим, сафакүл; стәрлетамак, каргалы, богырыслан һ.б.) сөйләшләрендә дә шактый киң таралыш алган.

Бу форманың татар телендә кулланылышы, берьяктан, нугай теленең, икенче яктан, татар язма әдәби теленең роле белән бәйле, ул борынгы төрки телдә үк билгеле булган, карлук телләренә хас архаик чараларның берсе.

3. *-мақ/-мәк* формасы исем фигыльнең архаик төре булып санала. Ул сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдереп, төрле модаль мәгънәләрдә күзәтелә.

Сөйләштә ул күбесенчә сорау алмашлыгы + *-мақ/-мәк* формасы һәм *кирәк* модаль сүзеннән торган төзелмә составында килә, аптырауны, гаҗәпләнүне, сөйләүченең башкарыла торган эшен өнәп бетермәвен һ.б.ны белдерә: *Бу бақчаны ничек қазып бетермәк кирәк!? Ничек итеп алай эшләмәк кирәк!? Берәр бәлә килеп чықса, җаңғыз башың қайа бармақ кирәк?!*

Билгеле бер төркем фигыльләр *өчен* бәйлеге белән килгәндә, максатны белдерәләр: *сынамағ өчөн генә* (сынау өчен) *әйткән ийем. Җурамақ өчөн* (юрау өчен) *төшләк салдырғаныйым, төшөмә кермәс микән дип.*

Бу типтагы тезмәләр татар теленең минзәлә, бөре, пермь, красноуфим һ.б. сөйләшләрдә дә билгеләнеп үтелгән.

*-мақ/-мәк* формасы, модаль сүзләр (*бар, җуқ / йуқ* һ.б.) белән килеп, сөйләүченең эш яки хәлләргә субъектив мөнәсәбәтен белдерә (икеләнү, шикләнү һ.б.): *Бу дөнҗада үлмәгең бар, қалмағың бар. Дөнҗа булғач қушылмақ та, айырылмақ та җәнәшә генә торалар, ди торғаныйы бийанам мәрхүм. Үлмәктән қалмақ йуқ, белеп булмый.*

Татар язма әдәби телендә XX гасыр башына кадәр актив кулланылып килгән *-мак/-мәк* формасы хәзерге көндә бигрәк тә перифериядә формалашкан сөйләшләрдә генә сакланып калган. Мәсәлән, ул минзәлә, байкыбаш, спорадик рәвештә тау ягы сөйләшләре төркемендә, камышлы сөйләшләрендә теркәлгән.

Башка төрки телләрдән *-мақ/-мәк* формасы аеруча көньяк төркемгә керә торган телләргә хас. Мәсәлән, Төрәк, Төрәкмән, шулай ук комык һәм башка телләрдә күзәтелә. Ул башкорт теле сөйләшләрендә дә бар.

Хәл фигыль. Бәрәңге сөйләшенә хас хәл фигыль формалары аның казан арты һәм тау ягы сөйләшләренә, әдәби телгә бик якын торуын күрсәтә.

1. *-а/-ә, -й* формасы: *Қарны таптый-таптый тутырабыз базға, җәй буйына җитә. Көлә-көлә сөйләр ийе әби ничек кич утырғалларын. Сез йаза-йаза қулларығыз қалмый икән.*

Сөйләштә *-а/-ә, -й* кушымчалы хәл фигыльнең мөстәкыйль кулланылу очраклары бар, ул вакытта алар максат белдерәләр һәм инфинитивка тәңгәл киләләр. Мәсәлән: *Бәрәңге чығара* (чыгарырга) *қайтқаныйы бер қызым. Җирләре җырақ булғачыннан қуна* (кунарга) *барғалыйлар. Тағын җаңғыр җаумағайы дип, өйләре белән печән җыйа* (җыярга) *киттеләр. Сабан туйға бер-ике көн қала* (калгач) *күкәй җийарға чығарлар ийе.*

Күргәнебезчә, мисаллардагы *-а/-ә, -й* формалы хәл фигыльләр әдәби телдәге *-гач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльгә яисә инфинитивка туры килә.

Билгеле булганча, *-а/-ә, -й* кушымчалы хәл фигыльләрне мөстәкыйль куллану көнбатыш (мишәр) диалектының дифференциаль билгеләреннән санала, бу күренеш, нигездә, хәрәкәтне белдерә торган фигыльләрдә күзәтелә (*йылый бара, ашыга килә* һ.б.). Соңгы елларда диалектларның һәм алардагы сөйләшләрнең үзенчәлекләре тасвирламасын төзү (Татар халык сөйләшләре, 2 китапта, 2008) *-а/-ә, -й* кушымчалы хәл фигыльнең урта диалекттагы кайбер сөйләшләрдә дә очравын күрсәтте. Шулай итеп, *-а/-ә, -й* кушымчалы хәл фигыль кулланылышы ягыннан бәрәңге сөйләше урта диалекттагы казан арты сөйләшләре төркеме, керәшен сөйләшләре, богырыслан һәм каргалы, красноуфим, нагайбәк, эчкен һәм сафакүл сөйләшләре белән аерым уртаклык күрсәтә.

*-а/-ә, -й* формалы хәл фигыль иң борынгы форма дип санала. Ул аеруча көнчыгыш төрки телләргә хас: шор, алтай, тува һ.б.; башкорт теленең кызыл, бөрҗән, күбәләк һ.б. сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән.

2. *-ып/-еп, -п* формалы хәл фигыльләрнең семантик функцияләре, кулланылыш закончалыклары буенча бәрәңге сөйләше белән

әдәби тел арасында уртаклыклар бар: *Матур итеп җитәкләшеп китеп бардылар. Қайсы көннәрне җә уқып, җә бәйләп утыра. Ташу киткәндә, җылгада бозлар шаулап аға. Печәнне өйөп, чүмәләгә қуйып, эшен бетереп қайттық.*

3. *-а/-ә, -й, -ып/-еп/-п* формалы хәл фигыльләрнең юклык формалары *-мый/-ми, -мыйчы/-миче, -мыйча/-мичә* кушымчалары белән ясала: *Сүзеңге ашықмыйча ғына сөйлә син. Қойаш байымыйча җату җуғ инде ул. Аңнамый-нитми баланы ачуланып ташлаған. Балаларны уқытмыйча булмый.*

4. *-ғач/-гәч* формалы хәл фигыль, әдәби телдәге кебек үк, бәрәңге сөйләшләрендә дә, нигездә, *-ғачыннан/-гәченнән* фонетик-морфологик вариантында кулланыла: *Җәй үткәченнән бардым Йошқарға. Безнен өй тушы тауны менгәченнән ийе.*

Сөйләштә шулай ук *-ғач/-гәч, -ғачтын/-гәчтен* вариантын куллану очраклары да теркәлгән: *Җырақ булғачтын җалға ғына қайталар ыйы. Урманға кергәч ин әwәле исәлләшергә кушадыр ыйы шул бабай. Әрмийәдән қайтқач та өйләнде ул.*

5. *-ғанчы/-гәнче* формалы хәл фигыль бәрәңге сөйләшендә дә, әдәби телдәге кебек үк, төп эштән алда булган эш-хәлнең күләм яки вакыт ягыннан чиген белдерә. Аның *-ғанчы/-гәнче, -ғынчы/ -генче, -ғанчыға/-гәнчегә + хәдәр* вариантлары күзәтелә: *Қараңғы төшкәнчегә чақлы қырдан қайтмағаннар. Әрмийәгә киткәнчегә хәдәр институтта уқыған булған. Бик тузып беткенче қарап қалдырыйм нигеземе, дип йөрим шунда.*

*-ғанчыға/-гәнчегә + хәдәр, чаклы* һ.б. урта диалектның балтач, минзәлә һәм башка сөйләшләрендә дә күзәтелә.

Урта диалектның нигез сөйләшләрендәге кебек, бәрәңге сөйләшендә дә *-ғанчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыльнең синонимик төрләре бар. Алар, нигездә, *-мас/-мәс* формасына нигезләнеп ясалалар.

*-мастан/-мәстән: Қойаш чықмастан* (чыкканчы) *торам мин. Көтү қайтмастан* (кайтканчы) *ашны булдырып қуйған.*

*-мастан/-мәстән + элек, алда* һ.б.: *Қабақларны қырау төшмәстән алда* (төшкәнче) *җыйып керергә кирәк. Шуғыш чықмастан элек читкә киткәннәр ийе җазылып.*

*-мас/-мәс* формасы һәм *борон* бәйлеге: *Мағазинға җитмәс борон* (җиткәнче) *аларның өйләре. Бәрәңгегә* (район үзәге исеме) *җитмәс борон* (җиткәнче) *уңға боролып керәсе икән ул аwылға.*

*-мастан/-мәстән* формасы мәгънә эчтәлеге белән *-ып/-еп* формасының юклыгына (*-мыйча/-мичә*) туры килергә мөмкин: *Бер көн қалмастан* (калмыйча) *эшкә йөрим.*

Бу форма шундый ук мәгънәдә көнбатыш диалектның көнбатыш зонасында, нагайбәк, Оренбург өлкәсендәге, Урал төбәге, себер ареалы татар сөйләшләрендә дә бар.

*-ышлый/-ешли* формалы хәл фигыль татар теленең барлык сөйләшләрендә дә күзәтелә, әмма ул грамматикаларда, дәреслекләрдә әдәби норма буларак каралмаган. Бу форма тематик яктан хәрәкәтне белдерә торган фигыльләрдән ясала: *бару, қайту, китү, килү, менү, төшү, керү, чыгу.* Мәсәлән: *Мәктәпкә барышлый суғылырсын әле, йәме. Су буйыннан менешли бер-ике җиләк өздөм. Керешли чиләкне ала керсән икән. Китешли дә кердем, қайтышлый да кердем, ул әби өйдә йуқ.*

Шуны ассызыклап күрсәтергә кирәк, бәрәңге сөйләшендә әлеге форманың синонимы, ягъни әдәби телдәге варианты – *-ғанда/-гәндә* формасы да актив: *Қайтқанда алырбыз дигән ийек. Қунақтан қайтқанда шуларға да кердек.*

Сыйфат фигыль. Бәрәңге сөйләшендә сыйфат фигыльнең түбәндәге формалары кулланыла.

1. *-а/-ә, -й + торган:* Мәсәлән: *Эшкә китә торған машиналар китеп беткәндер инде. Сабан ура торған җирендә үк тапқан ул малайын, шуңға күрә ыризықтан бәхете булды. Су апқайта торған чиләкләр қайа микән.*

2. *-ыр/-ер* формасы: *Утын кисәр, утыр җарыр кешеләребез җуқ бит әле. Җийында, барыр туғаның булса, қунаққа барам дип көтөп торасың. Балалардан зарланыр җире җуқ.*

3. *-ырлық/-ерлек* формасы: *Эшкә йарарлық кешеләре җуқ. Үзенүзе туйдырырлық эшли алса җарый инде. Өй җудығ әле, бар нәстә тарау-торау, утырып торырлық урын җуқ.*

Бу форманың юклыгы *түгел* сүзе белән ясала: *Пычрақ, урамны арқылы чығарлық түгел. Машина wатылды барырлық түгел.*

4. *-учы/-үче* формалы сыйфат фигыль. Бу чара кеше һәм кешегә караган исемнәрне генә ачыклап килә: *Печән җыйучы қызлар өрҗаңға тырмалар күтәреп китәрләр ийе. Җиләккә җөрүче әбиләрдә бардыр әле мәтрүшкә. Сыйырның айырылып қалғанын көтүче малайлар да күрмәде микәнни.*

5. *-асы/-әсе* формалы сыйфат фигыль. Ул урта диалектның дифференциаль билгеләреннән санала: *Барасы җирләрегездә*

*җулларығыз уң булсын. Җуwасы керләреме шунда салып қуйғанийым. Эчәсе сулары, җыйасы эризықлары киң булсын.*

6. *-улы/-үле* формасы да күзәтелә. Мәсәлән: *Эшкә йараулы* (әд. ярарлык, ярый торган) *қызы суға төшеб үлде. Ололарына ошаулы* (ошаган) *бала булмады монсысы, бер дә тик тормый.*

Бу форма әдәби телдә дә очрый, ул сыйфат мәгънәсендә килә һәм аергыч була: *түләүле уку* һ.б.

*-улы/-үле* формасы татар теленең башка сөйләшләрендә дә бар. Мәсәлән, минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгында, стәрлетамак, тепекәй, казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә ул хәбәр функциясендә генә килә: *урын җәйүле, ут йанулы,* шундый ук функциядә тубыл-иртеш, том диалектларында да билгеләнеп үтелгән. Тикшерә торган форма кыпчак телләренә хас.

**Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Бәйлекләр. Бәрәңге сөйләшендә, татар әдәби телендәге кебек үк, бәйлекләр кулланыла, аерымлыклар бары аларның фонетик үзенчәлекләре белән бәйле.

*Белән/белә: Иртә белә торасың да эшкә җүгерәсен. Қабалар белә җеп җегерләп утырадырыйық. Җәшләр гармуннар белән урам җөриләр ийе җырлап.*

*Кебек / күүк / күк: Бийеме күк килене дә, бер минут тик тормый. Аның күүк әйбәт кешене күрмәссен бүтән. Қырыққатламаны җәймә күг итеп җәйәсен башта, төйгән киндерне җағасын да қаплап чығасын бер-ике тапқыр, кискәләп-кискәләп пешерәсен.*

*Сыман / сымақ* (сирәк күзәтелә): *Паштитны бизисен әле матурлап, қамырны бау сымағ иттереп ишәсен дә читенә салып чығасын. Қуй сарық сыман бер мал инде ул.*

Сөйләштә шулай ук *қәдәр, хәдәр(е), хәтле, тиңентен, тигетен, чақлы, шикелле, күрә, бирле, сайын, өчен, табатын* һәм башка бәйлекләр дә кулланыла: *Иңгелек килгән татарлардан монда Алашай бабай булған, шуңға күрә аwыл Алашайка дип әйтелгән. Килешкәч қызнын берәр зурраграқ нәстәсен биреп җибәрәләр қул билгеситеп над'ужны булсын өчөн. Шул балдақ табылсыйы дип шул хәдәре теләдем. Тез тиңетен* (тезгә хәтле) *генә йе киленнәре, ачуwым килмәгәйе. Ғөмөр бар тигетен* (хәтле) *йәшибез әле.*

Бәрәңге сөйләшендә *табатын* бәйлеге дә теркәлгән: *Менә моннан табатын* (монда таба) *барсағыз чатқа килеп чығасығыз.*

Бәрәңге сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән берсе – *шай(ы)* бәйлеге. Ул әдәби телдәге *чаклы, хәтле* бәйлегенә туры килә, үзе

бәйләнгән сүзләрдән аңлашылган әйберне яки эш-хәлне күләм-чама ягыннан билгели: *Қабақлары монон шайы, монон шайы була анын, күтәрә дә алмыйсын. Җәйгә чыққачыннан, китергән бәкәйләре бүрек шайы ғына. Кичкә шайы җөрисегезмә?*

Бу бәйлекнең чагыштыру, чамалау мәгънә төсмере, хәбәр составында килгәндә, аеруча ачыклана төшә: *Кичәгенәк кенә қайтқаннар шай алар* (кайтканнар ахрысы). *Аларнын бабалары Қазан җағыннан килгән шай* (бугай). *Анда шыршылық шай* (ахыры).

Шулай итеп, бәрәңге сөйләшендә *шай* бәйлеге күләм-чама бәйлеге буларак һәм модаль мәгънәдә кулланыла.

Бәйлек ролендә килә торган сүзләр. Татар әдәби телендә урын-ара мәгънәсе белән бәйле бер төркем сүзләрнең тартымлашкан формалары урын-ара килешләрендә бәйлек ролендә дә киләләр – *өстәл өстенә* (өстеннән, өстендә), *агач артына* (артыннан, артында) *качты, агач башына менү* (*башыннан төшү, башында утыру*) һ.б. Бу функциядә килә торган сүзләр, сан ягыннан, нигездә, чикләнгән.

Сөйләшләрдә исә бәйлек ролендә йөри торган сүзләр, әдәби тел белән чагыштырганда, күбрәк. Мәсәлән: мордва-каратай, эчкен (*Сыw битендә утырдыңмы?*), карсун (*Улсы йөгерә йери урман битендә*), норлат (*бәлеш бите* – өсте, капкачы) һәм башка сөйләшләрдән китерелгән бу материаллар бит сүзенең бәйлек ролендә килүен күрсәтәләр (ТТЗДС: 125).

Татар диалектологиясе буенча хезмәтләрдән күренгәнчә, төрле сөйләшләрдә бәйлек ролендә төрле сүзләр килә. Мәсәлән, пермь сөйләшендә *башлап, тышында* бәйлек сүзләре билгеләнеп үтелгән, керәшен сөйләшләрендә *уңғай/ынғай* (як мәгънәсендә), *қыр, қат* һ.б. бәйлек сүзләр актив; минзәлә сөйләшендә *түбән, тапкыр, тәңгәл, ала* һ.б. бәйлек сүзләр теркәлгән, стәрлетамак сөйләшендә *түбән, ала, арысы, булла / бола* һ.б. Бәйлек ролендә йөри торган сүзләрнең бай һәм кызыклы төркеме Урал арты татар сөйләшләрендә билгеләнеп үтелгән: *қабырға, қыр, сирә, чүрә, тигәрәк / түгәрәк, қабат, тигел, эргә, бит* һ.б.

Бәрәңге сөйләшендә бәйлек ролендә *итәк* сүзе йөрү үзенчәлекле. Аның ике мәгънәсе бар:

1) як, билгеле бер урын, билгеле бер җир: *Ул итәктә* (якта) *дә татар аwыллары күп диләр. Бу итәктә* (якта) *дә байар җирләре булған, дип сөйләр иде бабай.*

2) тартымлашкан формада: *итәгенә, итәгеннән, итәгендә* – әд. буе, яны. Мәсәлән: *Тушы урман итәгеннән* (буеннан, яныннан) *чықса болот, ташу ақмыйча қалмый торған ыйы.*

*Җайында* – ягында: *Пәтиқа апа кылуп җайында тора, җырақ түгел.*

*Тишегеннән*: көн тишегеннән. Мәсәлән: *Көн тишегеннән* (әд. таң тишегеннән) *бақчада җырлый башлыйсың.*

Теркәгечләр. Бәрәңге сөйләше теркәгечләрнең составы һәм кулланылышы белән дә әдәби телгә бик якын тора.

Сөйләш өчен үзенчәлекле күренешләрнең берсе – *-дагысыннан/ -дәгесеннән* формасы. Бу катлаулы кушымча *да/дә, та/тә* теркәгече, мамадыш, минзәлә, балтач сөйләшләренә хас *-гын/-ген* форманты, тартым һәм чыгыш килеш кушымчаларыннан тора: *да-гы (сы) н-нан, дә-ге(се)н-нән.*

Шунысы характерлы, мондый катлаулы кушымча билгеле үткән заман формасына ялганып килә. Мәсәлән: *Әйттем дәгесеннән, ну аңлап бетерә алмадылар. Сине күрдем дәгесеннән сүземне оныттым* (күргәч). *Син килдең дәгесеннән, күңгелле була* (килгәч). *Эштән қайттым дағысыннан бақчаға чықтым, бәрәңгене чүп басқан* (кайткач). *Сез килгәнне күрдек тәгесеннән самаwыр қуйдым, қоймақ туғырға тотындым.*

Безнеңчә, *-дағысыннан/-дәгесеннән* формасының килеп чыгуы тагын бер күренеш белән бәйле. Эш шунда ки, *-ғач/-гәч, -қач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль бәрәңге сөйләшендә, нигездә, *-ғачыннан/ -гәченнән, -қачыннан/-кәченнән* формасында кулланыла.

Икенчедән, вакыт ягыннан эзлеклелек белдерә торган башка сүзләрдә дә *-гысыннан/-гесеннән* кушымчасы кулланылучан. Мәсәлән: *Башта өч-дүрт йорт килеңгән, андрагысын ғына Кетнаулы зурайған. Андарығысын җаучәйтә, күпме қолақ сөйөнчесе* (туйга егет ягыннан кызның ата-анасына бирелә торган акча) *соройсыз дип. Никах укыйлар дағысыннан да андарығысын җегетне алмаға китәләр.*

Өченчедән, бәрәңге сөйләшендә тартым кушымчасы өстәү күренеше дә шактый актив, -*дағысыннан* тибындагы формада да шушы күренеш чагылган булса кирәк: *да > дагы + сы + н + нан.*

*-дагысыннан, -андрагысыннан* формалары татар теленең башка сөйләшләрендә билгеләнмәгән. Алар бәрәңге сөйләшенең төп татар сөйләшләреннән аерым, башка телләр чолганышында формалашу процессында оешкан җирле форма булып тора.

Икенче яктан, бу чараны, кайчандыр бәрәңге сөйләше вәкилләренең Казан арты Мамадыш төбәгеннән алып киткән *-дагын/-дәген* теркәгеченең яңа шартларда, башка сөйләш (дөбьяз, норлат) вәкилләре белән үзара тәэсир итешү барышында туган дип карарга була.

Бәрәңге сөйләшендә билгеле үткән заман формасына *исә* теркәгече ялганып килү очраклары теркәлгән: *Барчасы да килделәр исә башлап җибәрик* (коръән укуны). *Бер бүрәнә таптисә тота да эшли бүкәнен дә* (урындыгын да).

Мондый күренеш татар әдәбияты әсәрләрендә актив булган. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә:

> Яғкуб әйдүр: «Әгәр уйлә улур ирсә,
> Йусефи қорд йэйүб һәляк қылди исә,
> Әғзасендән берәр нәснә қалды исә –
> Ул әғзани бәңа алуб кэлең имди!

*Да / дә* теркәгечен кабатлау очраклары бар: *Әл дә-дә кичке уйыңға чығу бар ич. Бер дә-дә ишек төпкә килгән кеше булмады. Аны бер дәләр дә әйтүче йуқ. Хәзер дә-дә кич утырам әле, йә бәйлим, йә тирәк чығарам* (чигү чигәм). *Бер дә эшләмәсәң, бер дә-дә йуқ.*

Мондый күренешләрнең минзәлә, кама тамагы, пермь сөйләшләрендә барлыгы билгеле. *Да / дә* теркәгеченең кабатлануы аеруча ярдәмлек сүзләр янында килгәндә күзәтелә.

К и с ә к ч ә л ә р. Кисәкчәләрнең төрләре, аларның грамматик функцияләре һәм мәгънәләре ягыннан бәрәңге сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый дияргә мөмкин.

Көчәйткеч кисәкчәләр: *ин* (әд. иң), *өр, нәкъ, дөм, ямь-, кып-, зәп-, ап-, сап-, қап-* һ.б. Бу функцияне аерым сүзләр дә башкарырга мөмкин: *Тач шундый күлмәк* (нәкъ шундый), *Бийыл әкәмәт* (бик) *күп ти қура җиләге. Диңгезсез* (чиксез, иге-чиге юк, чамасыз күп) *ди анда бийыл шикләшек. Доға белә салсан, әллә ниндәйен* (бик) *тәмле була бәлеш.*

Чикләүче кисәкчәләр: *ғына/генә, қына/кенә.* Мәсәлән: *Иртә беләң генә җүгереп йөргән кеше кичкә айақсыз қалсын әле. Икәү генә барыбыз да хәлен белеп қайтырбыз.*

Раслауны белдерә торган кисәкчәләр: *ич, ласа / ләсә, ла / лә, лабаса,* инкар итүне белдерә торган *һич, ич* сүзе һ.б. Безнең күзәтүләр бәрәңге сөйләшендә *бит* кисәкчәсенең чагыштырмача сирәгрәк, ә

аның синонимы *ич* кисәкчәсенең, киресенчә, ешрак кулланылуын күрсәтте. Мисаллар: *Әйттем ич инде, иртәрәк төш суға дип, қазлар суны қуйыртқанчы. Күрдек ләсә иренең әүлийә күк кеше икәнен. – Син барыйын ич қор'ән ашында, ишетмәден мени. Көннәр җылыныып китә алмый ич, бәрәңгеләр тишеләлмичә җаталар. Ич күрмәдем дә, әйтмәдем дә мин ул сүзне.*

*Ич* кисәкчәсенең килеп чыгышы, һичшиксез, күрше фин-угор телләре белән бәйле: мари телендә *-с (-ыс), -ш (-ыш)*, удмурт телендә *-ось*, манси телендә *-ос*, венгр телендә *is* һ.б. Галимнәр фикеренчә, алар палаталь *с'* элементына кайтып калалар һәм көчәйтә, ассызыклап күрсәтә торган чара буларак кулланылалар.

Татар телендә бу кисәкчә урта диалект сөйләшләре өчен генә характерлы. Ул аеруча казан арты сөйләшләре төркемендә, нократ (Чепца буе) сөйләшендә, ягъни татар халкының марилар һәм удмуртлар белән тыгыз контактта булган территориядә актив кулланыла һәм фин-угор телләрендәгечә көчәйтү, ассызыклау семантикасына ия.

Икеләнүне, билгесезлекне белдерә торган кисәкчәләр: *-дыр/-дер, -тыр/-тер* һ.б.: *Су қойонырға барасыздыр әле, беләм. Аңға май да салырға кирәктер, қамыр тағын да үзләнеп китә диләр ич. Бу функцияне сөйләштә тагын әллә, әле инде, түгелме, шай(ы), ахыры сүзләре дә башкара.*

Үтенүне, теләкне, кушу-боеруны белдерә торган кисәкчәләр: *-чы/-че, -сана/-сәнә: Куwып қына чығарчы шул эт баласын, өрә дә өрә. Бер килеп кит сәнә, Асийәләрнен хәлләрен дә сорашырыйым.*

Бәрәңге сөйләшендә бергәлек, тизлек мәгънәләре, әдәби телдәге кебек үк, *да/дә, та/тә* кисәкчәләре белән белдерелә: *Керде дә, ашығыч эшем бар ыйы әле, дип чығып та китте.*

Сорау кисәкчәсе, әдәби телдән аермалы буларак, киң вариантта кулланыла: *-ма/-мә*. Мәсәлән: *Әле көтү кердемә* (кердеме)? *Син белмәденмә, ипи киләмә бүген? Қазанда чиккән түбәтәйләр барма? Сез қөр'әнне уқый беләсегезмә? Уналты йәшендә укысынма wул, эшләсенмә wул?! Исәммә?*

Мондый күренеш татар диасистемасының тагын күрше дөбьяз, көнбатыш (мишәр) диалектының мордва-каратай сөйләшләрендә бар. Себер ареалы татар диалектларында (тубыл-иртеш, бараба, том) бар.

## Синтаксик үзенчәлекләр

Сөйләшләргә хас диалекталь күренешләр синтаксис өлкәсендә дә күзәтелә. Синтаксисның төп берәмлекләре – сүзтезмәләр, гади һәм кушма җөмләләр – формалашуда тел фәнен тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итә торган үзенчәлекләр дә чагылыш таба. Әдәби телгә якын булса да, бәрәңге сөйләшендә дә бу өлкәдә кайбер аерымлыклар табыла.

Компонентлары нисбәтлекле мөнәсәбәттә булган исем-исем сүзтезмәләр (мәктәп бакчасы, язу өстәле, тәрәзә пәрдәсе), әдәби телдән аермалы буларак, бу төбәктә грамматик күрсәткечсез кулланылалар: *шоморт чәчәк* – әд. шомырт чәчәге, *муча җәймә* – мунча җәймәсе, *чәчәк бақча* – чәчәк бакчасы, *қойаш җақты* – кояш яктысы, *қаз чәй* – каз чәе (үлән исеме), *қуныч сыр* – куныч сыры, *ойоқ қунычта ақчасы булған* – оек кунычында акчасы булган; *қунақ қыз* – кунак кызы, *утын пычқы* – утын пычкысы һ.б.

Тартым мәгънәсен грамматик күрсәткечсез белдерү бәйлек сүзләр ярдәмендә оешкан тулы булмаган тезмәләрдә дә күзәтелә: *Ул әби әле өйдә җуқ, қызы җаңға киткән* (кызы янына). *Тау аста* (тау астында) *аларның өйләре. Су өскә* (су өстенә) *қалқып чығалар балықлар сикерешеп.*

Шул ук вакытта бәрәңге сөйләшендә әле карап үткән күренешкә каршы тора торган үзенчәлек тә кулланыла: III зат тартым кушымчалы изафә өстәмә тартым кушымчасы алырга мөмкин. Мәсәлән: *Әүлийә қәбере Оло Қорнон* (басу исеме) *бақча башысында. Хәзер аның киндер олрлоғосы да йуқ. Ишек алдысын* (ишек алдын) *себерергә wахыт җуқ. Күлмәк җиңгесе артыққа озон булса, казан тирәсендә қомачау була* (күлмәк җиңе). *Қапқа башысын* (капка башын) *да қалай белән җапқан аларның.*

*-ныкы/-неке* кушымчалы сүзләрнең аергыч функциясендә дә килә ала. Мәсәлән: *Анықы өйө чат башында* – Аның өе почмакта (чатта). *Берwахыт аwылның мулласыныкы* (мулласының) *нәселе қорған* һ.б.

Бәрәңге сөйләшендә модаль мәгънәне – икеләнү, фараз итү мәгънәсен – *бул* ярдәмче фигыле белән белдерү очраклары теркәлгән: *Аwылнын истүрийәсен Барни ағай бераз белә булыр.*

*Бул* – фигыльнең мондый семантик функциясе урта диалектның тау ягы сөйләшләре төркемендә актив күзәтелә.

Сорау җөмләне оештыруда кайбер үзенчәлекләр. Татар теленең күпчелек сөйләшләрендәге кебек, бәрәңге сөйләшендә дә сорау интонация белән генә белдерелергә мөмкин: *Бабай сөйләде аwыл тарихларын? Аwылның теге башына барып җитә алдыгыз?*

Интонация ярдәмендә генә сорау белдерү диалогларда еш күзәтелә:

*– Бүген килдегезме?*

*– Әйе.*

*– Автобуслар җөри?*

*– Wатылмаганда.*

*Яисә:*

*– Яңавылда печәнгә төшмәгәннәр?*

*– Җук, ти әле.*

*– Алар иртәрәк төшә торганнар ийе?*

*– Җук, бәребер инде, җыл ничек килә.*

Бу типтагы күренешләр татар теленең төрле сөйләшләрендә билгеләнеп үтелгәннәр һәм алар сөйләм теле закончалыклары (мәсәлән, ситуация, сорау интонациясе һ.б.) белән бәйле.

## Лексик үзенчәлекләр

Тупланган материаллар күрсәткәнчә, бәрәңге сөйләшенең лексик-семантик системасы да әдәби телгә бик якын. Шулай да сөйләшнең сүзлек составында диалекталь сүзләр дә табыла һәм алар тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләренә карыйлар.

**Туганлык атамалары.** Билгеле булганча, бу төркем атамалар аеруча тотрыклы төркемне тәшкил итәләр. Әйтергә кирәк, аларның составы ягыннан сөйләш әдәби телдән аерылмый.

Кантуганлык атамалары: *әтийем, әнийем, қыз, малай, аппай/апай, тәтә* – апа, *сеңге(м)/сеңем* – сеңлем, *эне; бәбәй; бала, бала-чага, туғаллар* – туганнар, *туған-тумача; аға-эне; әби, бабай, бертуған абый. Олы әби* – әбисенең әнисе, *зур апайым* – иң олы апасы һ.б.

*Бағым* – иркәләп эндәшү сүзе (*Йаңғыр йаумый, бағым, йаумый*).

**Никах туганлыгы атамалары:** *җизнә, җиңгә. Бийем* – каенана, *бийата* – каената; иремнең абыйсы. *Кече қатын* – ирнең икенче хатыны; *Кайын сеңле, каенэне; балдыз; бажҗа, килендәш* һ.б.

Күргәнебезчә, бәрәңге сөйләше туганлык атамалары системасы белән казан арты төркеме сөйләшләреннән, нигездә, аерыл-

мый. Мондый факт бәрәңге татарларын этник яктан казан арты татарларының дәвамы дип карарга мөмкинлек бирә.

Халыкның тормыш-көнкүреше, башкара торган эшләре белән бәйле сүзләрдә бәрәңге сөйләше вәкилләренең нинди һөнәрләрне белүе, ничек көн итүләре чагылыш таба.

**Хуҗалык эшләре:** *туwар* – мал-туар; *җир* – җир үлчәү берәмлеге (*Җир ун тайақ иңге, 100 тайақ буйы, 20 сутый була*); *богол / бугыл* – кибән; *кәлшә* – курпы; *қуллазақ* – бүрәнә ташый торган озын арба (*Қулазақ була озон, распускыда ике передок қына*); *тирәк чыгару* – чигү.

**Йорт-җир төзелеше:** *кәбәртке* – мич арасы; *гәрнич* – карниз, *гәрнич тегү* – карниз ясау; *көнгә сугу, кибән айагына сугу* – көннәр эссе торганда, ашлыкны уру белән сугу; *кәбәртке мунчасы* – өй эчендәге мунча; *ақтанасты* – өйалды асты һ.б.

**Кием-салым исемнәренең** кайберләре әйтелешләре белән әдәби эквивалентларыннан аерылалар: *сай* – чабата ясау өчен әзерләнгән юкә телемнәре; *инеш* – инеч, *кәшәмбир* – кашемир; *итәк* – 1) итәк, 2) балайтәк, 3) өститәк (*Өститәк салып кийә торган ийек, өчәр итәк салып, итәк тотқан күлмәге әнийемнен әле дә тора әле*); *тезмә* – чәчкап, *қулбау* – мәрҗән беләзек; *сабақлы чулпы, изү* – әд. қалпақ / қалфак; *хастә* – хөситә; *гөлйаулық* – француз яулык, *күнчек* – 1) кесә; 2) изү капламаларының тоташкан урыны; *муйын баwы* – муенса, *бөгәлҗәле алқа; балдақ* – балак, куныч.

*Кәзәки / казаки, wәл* – биткә каплана торган челтәр; *җинсез кәзәки* – камзул кебек рус алынмалары сөйләшнең яңгырашына үзенчәлеклелек өстиләр.

**Аш-су:** *кәтермәч* – уалып тора торган юка, төче күмәч; *ипи тә*[й]*кмәге / таба ипие* – көлчә; *ат тойагы:* (*Бер қамыр, бер орлоқ, қатлы-қатлы була торган ыйы*); *қагу* – туглау, изү (*Солосы белә қалын тә*[й]*кмәк қақсаң да була*); *җуқа* – затлы камырдан майда пешерелгән юка гына камыр ашы; *тышлы тә*[й]*кмәк* – кыстыбый; *чалма* – катыкка үлән, суган, пешкән чөгендер яки башка нәрсә кушып ясаган ашамлык; *күкәй бәлеше* – гөбәдия.

**Җиһаз, кирәк-яраклар:** *чермә* – бишек, *бүкән* – урындык; *чүпләм сөлге* – чүпләмле сөлге, *қандала қабыгы сөлге* – үзеннән бизәк чыгарып суккан киндер сөлге, *ташыйақ* – касә, *чара* – ипине эвәләгәч салып тора торган, үрелгән табак, *тәпиле кәсә* – аяклы рюмка.

Сөйләшкә хас диалекталь сүзләр халыкның рухи мәдәнияте белән бәйле лексикада да чагыла.

**Йолалар:** *кисут* – мариларның келәү итә торган урыны; *әүлийә кабере – Оло Қор* (ав. ис.) *янында. Әүлийә қәбере Оло Қорның бакча башысында, аwыл башында зур шыршы, күкәй тондоралар шунда, утырмаға җөрү*;

**Уен исемнәре:** *таштеки* – балалар уйный торган чәчәкле фарфор ватыклары; *пота суғыш* – парын бирмәсә, каеш белән сугып җәза бирү уены; *пелин алыш; кыруг уйнау* – җырлы түгәрәк уен; *қул суғыш* – арка сугыш уены; *шырпы салыш* – йөзек салыш; *хатирә, урта қазық* – уртага берәү чыга торган, җырлы түгәрәк уен; *чуқрақ кина* – тавышсыз, телсез кино; *чоқор туп уйыны, қағыш туп уйыны* – тупны чөеп җибәрәләр дә кемгә тия, шул туп чөя.

**Төрле ышанулар, ырымнар:** *Күз тимәскә дип, әбисе артыш тагып җибәргән. Хәситә дип балаларга тағырлар ийе күз тимәскә. Шыр/шер* – зәхмәт*: Шайтан шырыннан ходай сақласын.*

**Туй йолалары:** *чығып бару* – качып чыгу, ябышып чыгу; *ир булғаным* – ирем; *қул билгесе* – колак сөенчесе; *қалын қортлау* – бирнә котлау һ.б.

**Җыен исемнәре:** *җийын* – сабантуй; *Қарайләк атнасы* (*Қарайләг атнасы Әмшәндә* (ав. ис.) *буладырыйы*). *Чөгән* (*төчлөгән*) *атнасы йаз көнө җир кибә башлағач та була*.

*Бәрәңге базары (Бәрәңге базары ул зур җийын, даллықлы).*

**Кешене тасвирлый торган лексика:** *тәүбәле-тапиқлы – тәртипле,* тыңлаучан; *мийер* – шәфкать (*Ходай мийерләреннән йаздырмасын балаларымны*); *йағылма* – ягымлы (*Кешегә йағылма кешеләр икәнсегез икән*). *Танықлы* – билгеле, абруйлы; *нәмүш* – телсез; *кире үҗәт, алған* – бик кире, *каңға* – чандыр, ябык; *қаңғыр* – аңгыра; *силферү* – җен кагылу, саташа башлау, *тәпи* – аяк, *тәпи башы* – 1) аяк башы, 2) кечкенә чолгау; *ирәбә* – төксе, коры; *шамақай* – ялганчы, алдакчы һ.б.

**Җир-су атамаларында** төрле мотивлар чагылыш тапкан. Бу якларда комач, җеп эрләү һәм башка төрле фабрикалар эшләгән. Шуннан *Фабрика таwысы* – дигән исемнәр ясалган. Аwылны *Татар Кушбайы* дигәннәр, (марича – Қошпайул. *Сира пучинкасы* (Сиражетдин – күчеп чыккан кечкенә авыл). *Күз: чишмә күзе* (*Анда булған чишмә күзе биг әйбәт*). *Мамай таwы* – Мазарбашы авылы янындагы тау исеме; *Умрат йылғасы* – Мазарбашы авылын-

дагы чишмәле елга; *Мулла йылғасы* – Мазарбашы авылында ике мәхәлләне бүлеп тора; *Көйөк күпере* – шул ук авылдагы күпер.

**Үсемлекләр дөньясы белән бәйле сүзләр.** Алардан аеруча кеше тормышында нинди дә булса роль уйнаганнары актив кулланыла: *балдырған* – әд. балтырган, *кәчтеркә* – малларга печән өчен игелә торган үсемлек; *эрпет* – эрбет (агачы һәм чикләвеге), *алабата* – алабута, *қала гөлө* – яран гөле; *қошлоқлы бодай* – көзге бодай; *йасмақ* – ясмык; *эт мәге* – белена черная; *камыш туқмак* – аир болотный, *тырантас* – бака яфрагы; *ләтчә қычытқан* – вак яфраклы тәбәнәк кычыткан, *қарга қузғалақ* – ат кузгалагы һ.б.

**Хайваннар дөньясы белән бәйле лексика:** *бәти* – бәрән, бәкәй; *қыслаңқы* – кысыр; *нөгө* – ташбаш (пескарь) (*Нөгө симез генә, қылчығы да йуқ, нийе дә йуқ*). *Зәңгелә* – эт балыгы (*Зәңгеләсе дә шундый ук йалтыраwықлы була*); *күкри бабай* – камка (божья коровка) һ.б.

Китерелгән материаллар бәрәңге сөйләшенең лексик-семантик системасының бай һәм фән өчен дә кызыклы икәнлеге турында сөйли. Диалекталь сүзләрнең зур күпчелеге дөбьяз, норлат, балтач һәм мамадыш сөйләшләрендә дә табыла. Бу факт бәрәңге сөйләше вәкилләренең әлеге төбәкләр белән этник яктан тыгыз мөнәсәбәттә формалашулары турында сөйли.

Диалекталь сүзләрнең тагын бер әһәмиятле төркемен ассызыклап үтми булмый. Бу төркемгә керә торган берәмлекләр әлегә бәрәңге сөйләшендә генә билгеләнгән һәм алар сөйләшнең үзенчәлеген тәшкил итә: *ақтанасты* – өйалды асты, *қарға қузғалағы* – ат кузгалагы, *бағым* – иркәләп эндәшү сүзе (борынгы *баг* – бакча сүзеннән булса кирәк), *җөп, бау, җир* кебек үлчәү берәмлекләре*, чермә* – бишек, *чермә җәwере* – «чермә» нәселе, *хатирә, урта қазық* кебек уен исемнәре, *эт мәге* – тилебәрән орлыгы, *нөгө* – ташбаш һ.б.

Гомумән, бәрәңге сөйләше татар теле диалектлары системасында мөстәкыйль берәмлек буларак урын алган һәм татар теле тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле сөйләш булып тора.

**Нәтиҗәләр**. Бәрәңге сөйләше – әдәби телгә аеруча якын булган сөйләшләрнең берсе. Аның үзенә генә хас грамматик үзенчәлекләр системасы бар, аларның зур күпчелеге бәрәңге сөйләшенең күрше дөбьяз, чыганак сөйләшләрдән норлат, казан арты сөйләшләре төркеме (мамадыш, балтач) белән зур уртаклыгы булуын күрсәтә. Мәсәлән, шундыйлардан *-асы/-әсе* формасының киң функциялелеге,

хәл фигыльнең юклык формасының *-мый/-ми, -мыйча/-мичә* кушымчалары белән ясалуы һ.б.

Шул ук вакытта, бәрәңге сөйләше төп татар сөйләшләреннән бераз аерымланган хәлдә, башка телләр чолганышында үсеш-үзгәреш кичерә.

Нәтиҗәдә, анда борынгы чорга хас үзенчәлекләр тотрыклылык саклыйлар. Мәсәлән, инфинитивның *-мага/-мәгә* формасы, II зат күплек санда килгән хикәя фигыльләрнең катлаулы кушымчалар белән ясалуы *(барасығыз, барғансығыз, бары(р)сығыз),* компонентлары нисбәтлек мөнәсәбәтендә булган исем-исем сүзтезмәләренең кушымчасыз, архаик формасы һ.б. шундый чаралар сөйләштә, казан арты сөйләшләреннән аермалы буларак, бүген дә активлыкларын югалтмаганнар.

Чыганак сөйләшләрдән килгән кайбер күренешләр бәрәңге сөйләше шартларында берникадәр үзенчәлекле үсеш-үзгәреш кичергәннәр. Мәсәлән, мамадыш сөйләшенә хас *-дагын/-дәген* теркәгечләре бәрәңге сөйләшендә очрамыйлар, әмма билгеле үткән заман формасы белән килеп, хәл фигыль ясаганда, әлеге формалар катлаулы фонетик-морфологик төргә *-дағысыннан/-дәгесеннән* формасына әверелгәннәр һәм мәгънә функцияләре ягыннан әдәби телдәге -*гач/-гәч* кушымчасына тәңгәл киләләр. Әлбәттә, бу процессларда сөйләшкә хас -*гачыннан/-гәченнән* формасының да тәэсире булган булырга тиеш.

Кайбер диалекталь күренешләрнең тотрыклылыгына күрше фин-угор телләре белән тыгыз контактта үсеш-үзгәреш кичерү дә ярдәм иткән булырга мөмкин. Мәсәлән, сорау кисәкчәсенең киң варианты *-ма/-мә,* килеш формаларында әдәби *ң* урынына *ңг* варианты кулланy һәм аның ике сузык арасындагы позициядә дә (*күңгел, җиңгел, сеңгел* һ.б.) күзәтелүе, *ич* раслау кисәкчәсе кебек күренешләрнең сөйләшкә генә хас үзенчәлекләр системасын формалаштыралар.

Шулай итеп, хәзерге Мари Эл Республикасы составында татар теленең шактый үзенчәлекле бер сөйләше формалашкан һәм фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре системасы белән ул татар диасистемасында мөстәкыйль урын алып тора, татар теле тарихын өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия.

Бәрәңге татарлары мәгърифәтле, бай тарихлы халык. Алар үзләренең рухи мәдәниятләрен, күркәм йолаларын сакларга, яшь буынга тапшырып барырга тырышалар. Туган телен ярата, шул

телдә матур итеп сөйләшә торган халык буларак, бездә аларга карата олы хөрмәт хисе, киләчәгебезгә ышаныч хисе уяна. Түбәндә китерелә торган текстларда да бәрәңге татарларының әнә шундый матур, аһәңле сөйләме чагылыш таба.

## Авыллар тарихыннан

«Тушында тудым, тушында үстем. Бу аwылның урнашуwы – Ибан Гырозный көчләп чуқындыра башлағач килгәннәр. Монда шулай сөйлиләр. Имештер, татарлар килгән өч-дүрт кеше: Тобоқ, Кормас (Қормаш), Ағыш. Жаңадан Чермә җәwере *(нәселе)* барлыққа килгән, чермәдә бала қалдырып киткәннәр, бишекне «чермә» дигәннәр. Ғайнан Қормаш Җәлилнең көрәштәше, аны бик күп кешеләр белә. Қормас бара-бара йомышлы татар булып киткән.

Мариларға мөрәҗәғәт иткәннәр. Бу су атала «Лаж» дип, инеш инде. Уң йақ йарда қуйан күп, суң йақ йарда тийен күп. Суның ағышы белән қараб әйткәннәр. Суңыннан, бик күп йыллар үткәч, суның теге йағына урнашқан «Тийен пүчинкәсе» дигәлләр. «Ағыш татар Қушбайы» *(авыл исеме)* дигәлләр, йәғни мари дип кимсетебрәк әйткәннәр, марича «кошпай» ул. Күренекле кеше булған қормашлар. Кандовый двор'анин түгел, ә служилый, помещикмы булған. Шушы аwылның мулласының берwахытны нәселе қорған. Шуннан Қормашның *(авыл исеме)* Бикчәнтәй морза үзенең Фатхулла дигән улын мулла йасаған. Монда ике мәхәллә булған, Қазан астыннан килеб утырғаллар. Тубиковларның қызына өйләнгән ийе. Тубиков теге Тобоқтан инде. Сира пучиңкәсе Сиражидан *(кеше исеме)* килеп чыққан, кытат пабрикасы булған, қызыл қомач чығара торған.

Мазарбашының тарихы қызық қына. Аның мәчете өч йөз йыллар элек салынған. Анда элек зийарат булған, «мазар» дип йөрткәннәр.

Таштойал урынында мари аwылы булған, Искеаwыл дигән сүз түгел микән. Алашайкыға салмақчы булғаннар, килгән зимләмир җир кисә башлаған. Қартлар қуғаннар. Қормашевлардан иң соңғысы – Ғәптелхәй морза, аннан Фазылбай морза. Аның туганы(?)ның улы Нурмөхәммәт (Ақтүбәгә китеп йәши), аның улы Ғайнан Қормаш».

*Сөйләүче: Габдуллин Барый (1912 елгы).*
*Куянавыл*

«Мазарбашы йанында Мамай таwы бар. Ғәмбәл абыстай булған, Таһир белән Зөһрәне көйгә салучы. Мазарбашында тағын Умрат йылғасы бар, чишмәле йылға. Көйек күпере бар, Мулла йылғасы ике мәхәлләне бүлеп тора, Хәй болоны, Хәй тегермәне, йыраі түгел генә Фабрик таwы, анда Сира пүчинкәсе, Сиражеттин исемле булған ул. Ул йақларның хәлен белмәгә қушалар. Мийем дә туғаллар бар, башлы-күзле булып беткәлләр.

Ничек булғанны бер дәләр дә әйтүче йуқ. Искеаwылда шул Қазан жағыннан килгән дүрт аға-эне жорт алғаллар, чирмешләрне жибәргәннәр иңгәwәле. Шүрәлеләр булған монда, шүрәлене қыйнағаллар, шуңғар күрә шүрәле қарғаған Лажыны, Искәwылны. Җиттем, дигәндә генә ут чыға да жана да китә аwыл. Шурәли қарғамаған булса, йахшы буласикән.

Килгәлләр бабайлар, урман икән, кандаwай ағачлар, өй салырға булғаллар. Чәй қайнатқаллар. Нинди исем қуйабыз? Нинди хайван чыға, шуны (куябыз). Қарасалар, қуйан чаwып бара икән. Шуннан аwыл Қуйан булып қалған.

Хәсәнша аwылындан өч кеше килгәлләр: Ағыш, Туғыш, Қормас. Үзләре йортлар салырға оста булырға тийешләр. Туғанымы, йақындашымы, Ситтық бай дигән кеше килә. Фыран-суз фабиригы әчеп йебәргән ул. Байалар, тарихта эшләре йуқ. Су артқылы ғына Тийен пүчинкәсе булған, алар чи чирмеш булғаллар».

*Сөйләүче: Хәбибуллин Зиннәт (86 яшь). Куянавыл*

«Таштойал белә икарада *(ике арада)* йул булмаған. Бер үгез чыққан бу йақ урманына. Монда да аwыл бар икән дип, татар аwылын тапқаллар.

Закл'ученныйлар булған, аларға чабата йасый башлағаллар. Олау-олау төйәп чабата аппарадырыйық, тип сөйлидер ийе этеки мәрхүм.

Бездә «мари чабатасы» дигән чабата йасыйлар, үзенә бер төрлө ул. Бездә дә жиде сайлы *(юкәле)* диләр, қырында бөтөрөлөп барама, сай, диләр шуны. Биш сайлы чабата да була.

Үнәрле бездә халық. Эшкә киткәнчегә хәтле чабата үреп китә.

Безнекеләр Ородан *(авыл исеме)* килгәлләр, Бикчәнтәй бабай, Йахйа бабай.

*Сөйләүче: Шәрифьянов Мөбарәкжҗан (1929 елгы). Искеавыл (Таштоял)*

## Тормыш-көнкүреш турында

«Бәпкәләре дә тузған өйөмнең, қазақ қағарлық түгел. Қурқасың, ишелеп төшмәгәйе, дип. Бер қолағым ишетми, шуңғар қычқырыбырақ сөйләшәм. Йаңғыз торам. Әтийем йәшләй үлде. Тушы нигеземдә үстем, тушында торам. Сеңнем, апайым бар ыйы. Миңға қәзер җитмеш җиде йәш. Шул хәтле торғаммын, торған шикелле дә түгел. Таза-сау wақытым булса, бер эшләб алыр ыйым. Минем эшләмәгән эшем қалмады. Җоқламаға йатсам, уйлап җатам. Суқмаға чығар ыйым шабағаш белән. Андырасыннан *(аннан соң)* қул белә әйләндереп суқтым. Җегерме биш пот орлоқлоқ бирдем, сигез җир *(авыл кешеләренә җирне бүлеп биргәндә тигән өлешне үлчәү берәмлеге)* уҗым бирдем. Җир ун тайақ иңге, йөз тайақ буйы, җегерме биш сутый була. Нәчәллек қушты, фамилҗаларны андыра болай йазыр ийем. Үлчәп бирә торғаллар ийе безгә җирне. Киндер чәчәбез, тастыман, җаулық кирәк ич. Җерләп үзәк җебеннән, суғып. Җитен талқығач, тимер шырт белә тартабыз, андыра була үзәк.

Әле генә дөнҗа рәхәт, балам. Ни кисәк тә бар, ни ашасақ та бар. Киндер орлоғо, киндер майы була торған ийе. Җитен орлоғоның түбе бик тәмне була, ғомбағыш түпләре ашый торған ийем. Мин сийа апкереп күрсәтерем әле суға торғаннарыбызны: көрөдән, қылычтан аласың, тыбырча белән, шүре йасыйсын, сусаға тығып, хәdер дөнҗалар эрәхәт, җанықайым. Қартайғалларны йәшәртә торған дару йуқмы, туйғынчы бер эшләб алыр ыйым.

Ачлығын да күрдек, бәбекәйем, йарый әле алабаталар үсте, төйдөк, чыпчық қузғалағы биг ашадым, қапчық белән җыйып, чауп. Қычытқан ашлары, пирчәткә кийеп җыйып, өтөли ич. Wақ қычытқан, кәрлә қычытқан дибез тағы берсен. Утауға барсақ, кәҗә сақал, қақы, ақбаш ашый торған ыйық. Балтырғанның ашы тәмне була торған ыйы, сөт тә салып җиппәрсәң.

Көлләрдән беркөллө түләүләрне туқтаттылар да җиңгел сулап қуйдық.

Урмаллар күп булған монда. Йортурын бирәләр дә, шуны чичтартып чәчкән. Нарат, чыршы, йүкә, өрәңге, усақ, қарағай үсә монда. Элек тотқаллар ақ чыршыны, хәdер тотмыйлар. Чыршы тоталар түшәмгә, ақ була, дип. Арыш җиткән wахытта қамчау *(аҗаган)* уйный йылық-йылық. Печән өсләре була ул, печәнне

боғол *(кибән)* итеп қуйасың, башта шәбелләп китәбез сәнәк белә бер күтәрерлек итеп, аннан алда әле киштәләп чығасың. Чүмәләне боғолға өйәсең, боғол үзәге йасап. Арпа, соло, бодай, арыш чәчкәлләр безнең йақта. Қошлоқло бодай *(көзге бодай),* анысын көз көнө чәчеп қалдыралар. Безнең йақта бодай бик булмас ийе. Борчақ, йасмақ чәчтеләр – соло онон ипигә қушсақ, күмәчтән тәмне була. Солосы белән қалын тәйкмәк *(җәеп, таба-да пешерелә торган камыр ашы)* қақсаң *(тугласаң)* да була. Урақ өсләрендә җаwымны йылларда көпчәкләр печәнгә уралып бетә, кетекий бәбәй әле тағын. Көлтәне сослон *(ашлык көлтәсеннән куелган чүмәлә)* итәсең, аны ташыйсың да кибән итәсең. Әwенгә киптерер ийек, миченә җағырлар ийе. Бик қаты қойашлы булса, көнгә суғарлар ийе, кибән айағына суғу диләр, муклака утыртырлар ийе дә. Чабағач, аның тәпәче була, үзенең көйө була аның суққан чақта. Тайақ, бау, тәпәч, моның хәтле озоно була, ансын «күбәк» дибез, чабағач күбәк. Башақлары китә икән, чалулап алырлар ыйы, қайынны себерке кебек итеп бәйләп алырлар ийе дә. Тегермәндә очорорлар ийе арышның башағы қалса, ул тағын да чичта булыр ийе. Тары электән булды ул, қарабодай. Бездән йырақ түгел тегермәне бар ийе, арулый да чығара тарыны. Элек гел үзенең белеме белә тордо халық, уқымаға да кермәгән.

Сарық күб асырадық. Бәрәлләсә, бәти җылдан бәрәлләде, дибез, бәрәлләмәсә қысланқы дибез. Башмақ тана киләсе йылны бозауласа, сыйыр йылына чығып бозаулады, теши, икенче бозаwында тешәү, урт тешен сала, бәтинеке дә төшә бит сарық җылына килгәндә».

*Сөйләделәр: Гайнуллин Барый (1912 елгы),*
*Рәхмәтуллин Габтелхак (1902 елгы), Йосыпова Нәфисә,*
*Мөхтәрова Гайния. Куянавыл*

«Без килендән ундық. Қайсысы бүген мендәргә басалар, иртәгә чығып төшәләр *(сүзгә киләләр)*.

Бер малайым белән килнем бақча башында. Әниләргә менеп йатыр ыйық йал итергә, ди, бишек тирбәткәндә, қуныпт төшөп китә торған ийе.

Әлли-бәлли итәр ул,
Бохарағa китәр ул.
Бохарадан қайтқачтан
Илендә хезмәт итәр ул.

Кийәwемнең йаратқан жыруwы бу. Ашыйсы аш, эчәсе су йөртә, диләр бәндәне.

Балам қалықсын,
Суwы сарықсын.
Көндөз уйнасын,
Төнлә йоқласын.
Таки күк таза булсын.
Бәхетле, тафиқлы,
Ғөмөрле-ғөзөрле булсын,

дип ташқа суwын жилкәсеннән өрәдерийем».

*Сөйләүче: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы).*
*Куянавыл*

«Қаз суйулар бик күңгелле булыр ыйы. Өмәдә тағын тула басу булыр ыйы. Басып тора торған ийе өмәдә без басқан тулалар. Тулыйықны теләде кем кисә алмас ыйы. Бер күңгелле әби бар ийе, ансы тегеләйрәкмә, ақсаған-туқсаған кебек, ту анда ту монда баса»

*Сөйләүче: Мөэминова Мәрьям (1936 елгы).*
*Мазарбашы (Алашайка)*

## Туйлар турында

«Килен белән кийәү мунчасына керсән, ақча салалар ийе.

Улларымны сезгә бирдем,
Қәдрен белеп тотығыз,

дип жырлыйлар.

Тарантаслар белән китәрләр ийе парлап-парлап, паштитлар белән, баwырсақлар, қайсы гөбәдийә тотоп шунда. Паштитлар белән, ашаулықлар белән қаплап әби-бабай никахтан сун. Қыңғыраулар шаулап торор ийе».

«Әйбәт бийемләр белән йәшәдек без, йегерме өч йыл йәшәдек, әбигә хезмәт итеп. Элек урлап қайту ич инде. Алды да қайтты. Алты малай, бер қыз үстердек. Әйберләр бар ийе, қашаға, шаршау, мендәр.

Мәмдүдә апайның киткәне исемдә, карантаслар белә. Урлап төшкәннән сун, әни қайчан әзерләп пирә әйберләрне. Унике әғъзә сау-сәләмәт булсын, ике күз, борын, баш, қул, айақ, гәүдә, әйберсе табылыр, диләр.

Кийәү бүләкләре тарата кийәү, иптәш қызларыма пудыр, ислемай.

Сийыр алыштырдылар, дип дан итеп сөйләделәр. Без алардан тана алдық, аларға мин килен булып төштөм».

*Сөйләүче: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы).*
*Куянавыл*

«Элекке wахытта йаучы килгән. Исәмме, дип кердер инде ул, ыштан балдақларын *(балакларын)* чыгарып. Элек бүләкләр бирешкәннәр қызның ата-анасы – йегетнекенә, йегет йақ қода-қодағыйлар – қызнықына. Безнең wахытта аwырраграқ йыллар ийе, бүләк алышмыйбыз, бирешешмибез, дигән шунда қайсы-берсе. Ике туйны бергә итәбез дигән кешеләр дә булған.

Қалын қортлау булған. Туйға килгән кешеләр бүләг апкиләләр.

Килен төшкәндә қыз белән йегеткә элек мамық мендәр қуйғаллар, түгәрәг ипи тотып қаптырғаллар. Бийем кешегә тийәмени, бийемнен бийатасы бар ийе әле, қырық җиде йыл бергә тордоқ. Қайынсенге бар ийе, кийәүгә бирдек. Килен-килендәшләр булып та йәшәдек».

*Сөйләүче: Һадиева Раушания Газиз кызы (1936 елгы).*
*Мазарбашы (Алашайка)*

## Туганлык атамалары

«Анна сун оло әби бар, әнеки бар. Иңголосо йегерме җиденче йылгы абыйым, зур апайым бар үзем белә бертуған. Безең әни Хәсән атлы кешегә чыққан булған. Туғалларыбыз күб ийе.

Оло бала булғач, сеңгесе, әнисе анын қулында қалған.

Қызын *(кызның)* әнисе йегет йағын йаратмаған дағысыннан ыриза булмаған. Фаҗиғалар булғалады. Мазарбашының болай булған. Апалары йөргән дә анандарысыннан «бармыйм дигән». Мин өч әнеки белән бергә тордом: әнеки, әнекинен апасы, әнекинен сеңгесе. Әнекинен апасынын қәберендә шишмә чыққан Өржөмдә *(Уржумда)*».

## Карға боткасы

«Чалғыларны суға тығалар «йаңғыр йаусын» дип, чабаталарны суға тыққаллар. Қарға ботқасы пешерәләр ийе, балалар җийып йөриләр ийе күкәйен, йармасын. Бер кеше пешереп бирәм, ди.

Бер гөл бар, йаңғыр йаwасы булса, тамчы тамыб утыра аннан».

*Сөйләүче: Габдрахманова Дания (1936 елгы).*
*Лажы*

## Җыеннар

«Даллыклы базар була торған ийе. Җийыллар буладырыйы. Қарайләг атнасы Әмшәндә. Арбалы җийын бөтөн аwылларда булды ул. Чөгән атнасы ағач қайрысы қуба башлағач. Ағачның чөгәне қата башлаған, дип сийлийләр, асубинны йүкәдә.

«Мари кисуты» дибез. Қушбай кисуты бар, кирәмәт шул инде ул. Аwыл башында зур чыршы, күкәй тондоралар шунда. Әүлийә қәбере бар, йырақ түгел, Оло қорның *(кырның)* бақча башында. Имәнсәрлек бар. Анда булған чишмә, күзе биг әйбәт. Чишмә күзе булғач, җир астыннан чыққан була ул. Аның суwын басуға алып барғаллар. Туздан йасыйлар саwыт, басуға су алып барғаллар шуның белән җылынмасынға.

Йәшлектәге төшлөктә, үтә дә китә. Көнө буйы эшләсәк тә кичке уйынға чығар ыйық, сабан туйлары күңгелле булыр ыйы. Йаңаwылда чөгән атнасы, умбиш көн алда арбалы җыйын. Кетнәдә Төрәк базары, ул зур җийын, даллықлы. Чәчүгә чықмас борон сабан туйы буладырыйы.

Иң элек сабан туйы булыр ийе, андарығысын чөгән атнасы, кийәү бүләгенә җөрөр ийек: эрпет чикләwеге, қуйан буғы перәллек, бөтөркәле кершән. Туйға төш кисәләр әле, алҗапқычлар бирәләр төш кискәнгә. Төш кискән қызлар җәйә урынны да. Атасы-анасы тигез булған қызлар җәйә инде.

Төннөң төн алып җөрөр ийек урамда.

Элек пота суғыш, ширпы салыш, пелин алу, кыруг уйнаулар бар ийе, қул суғыш уйныйдырыйық, Қаз җолоққан жирдә берәү әбилек булыб утыра, икенчесе аның җанына килеп бөкөрәйеп җата да, аның йанына берәү килеп қулына суға. Кем суққанын белмәсә, җаңғадан җатасы бар. Ас кийезе – киндер, үзебез сүстән суққан, өс журғаны – киндердән, үзбез рәхәтләнеп уйнап җөридерийек».

*Сөйләүче: Газизова Мәүлидә.*
*Куянавыл*

## Сабан туйлары турында

Утыралар атларға. Урам сайын, өй сайын керәләр. Өйдәге кешеләр бәйгене (сабан туйына бүләкне) әзерләп қуйалар.

Күкәйне җийалар алдарақ. Тақмағын да беләдерийем әле.

Киби-киби кипкән,
Сабан туйы җиткән;
Сабан туйы иртәгә,
Атың бәйлә киртәгә.

Бездә, Мазарбашыта анда чөгән атнасы буладыр ыйы. Йәш қызлар барыр ыйы, уйнап җөрөрләр ийе. Берәр атна уйын уйнап җөрөрләр ийе.

Анан алар безгә қунақ булып килерләр ийе. Шулай итеп аwыштөйөш килеп җөрерләр ийе.

Бездә сабан туйы булыр ийе. Жаңғаwыл, башта шунда Қомлық тигән таулық, су қырыйында бәк матур җирләре бар. Уйыллар була, оло қатыллар да буладыр ыйы. Йуғары урамда тее йағы басулық, ат чаwып килә торған ийе. Сабан туйдан сун кемдә ике чирек балы бар, қунағ итә. Умбиш көнгә, өч атнаға хәтле барыр ыйы».

*Сөйләүче: Сәлахетдинова Рәшидә (1927 елгы).*
*Портянур авылы*

«Җәйәүле җийын булған, ат белән қунаққа барып. Чөгән атнасы матур wахытны булған. Искаwылда, бездә – Мазарбашында, аннары Искаwылда, Таштойалда инде. Бик матур болында була ул, қапчық кийеп йөгөрөшләр, көрәш, қашыққа күкәй салып йөгөрөшләр.

Кичке уйын сабан туйға хәтле, болонноққа төшөп. Қулйаулығы салыш дип уйныйдырыйық. Йаза чықса жырлыйдырыйық.

Танкиткаларын тишек.
Кичә йөргән йегетеннен
Памилийәсе ничек?

Иртәгә сабан туй дигән көннө бәйге (сабан туена бүләк) җийалар. Гармуллар белә, атқа утырып. Тайаққа ин матур сөлгөне бәйләп қуйалар. Арбаны бизәп, кыңғыраулар тағып, ағач арба була ул. «Бәйге, бәйге», – дип қычқыралар, аwыл көйөн жырлыйлар. Күкәй җийалар ийе атчылар. Жырлыйлар:

Сибլә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә җил искәлләрдә.
Сибелә чәчем, түглә йәшем,
Исемә төшкәлләрдә».

*Сөйләүчеләр: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы),*
*Садыйкова Гайшә. Куянавыл*

«Чөгән атнасы шул сабантуй инде. Бер атнада Мазарбашында, икенчесе – Җуйанда, өчөнчесе – Бәрәңгедә.

Чөгән атнасы була менә тушы аwылларда: Җуйан, Мазарбашы, Җурай, Путчара, Таштоял. Ат чабышы булмый анда.

«Арбалы җыйын» дигәне булыр ийе тағын иген җыйғач».

*Сөйләүче: Шәрифьянова Дания (1938 елгы).*
*Искеавыл (Таштоял)*

**Аулак өйләр**

«Аулаķ өйләр буладырыйы. Уйнамаған уйын ķалмыйдырыйы, тышķа чығыш, пута *(каеш)* суғыш тисенмә.

Аулағый, аулағый,
Аулағыйлар шауламый.
Аулағыйлар шаулар ыйы,
Йегетләре уйнамый.

Бер шулай ду китереп уйнап йатадырыйыķ, җегетләр бәлешне алып чығып баралар икән.

Ай пешә ич, пешә ич,
Бер сикерсән төшә ич.
Тегеннән берсе җаwап бирә:
Ничег итсән итә ķал,
Алып чығып китә ķал.

Чығып киткәч кенә белдек бәлешне урлағаннарын.

Ķылубта урта ķазыķ уйныйдырыйыķ. Парлы-парлы булалар да ķара-ķаршы басалар. Башында берәү басып тора йаңғыз, урта ķазыķ шул инде. Арттагы бер пар икесе ике йаķķа йүгерәләр, урта ķазыķ тигәне шуларның берсен тотарға тийеш. Тота алмаса, тағын ķазыķ була.

Аулағыйда ķулйаулыķ салыш, йөзөк салыш та диләр аны, шырпы салыш, диләр.

Әзерәк кенә ķар бетә башласа, уйнарға чығадырыйыķ. Тал чыбығын бәйләп ыскакалка йасап сикерәдер ийек».

*Сөйләүчеләр: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы),*
*Садыйкова Гайшә. Куянавыл*

«Бер шулай аулагыйға җыйылдыķ. Җегетләрне кертмибез, ишекне бикләдек, әчкеч чәчүргечтә.

Бәлеш пешерәбез ич инде. Идән астына ишегалдыннан керү ийе безнен. Җегетләр шуннан кергәннәр бәлешне урламаға. Мәче Равиленең арты саны кергән мичкә, тартыбалдыķ. Элеке тормыш читен

булса да күңгелле ийе. Тәйкмәкне, җәнәсе җәшерәбез, шаршау кебек элеп...»

*Сөйләүче: Мөэминева Мәрьям (1936 елгы). Мазарбашы (Алашайка)*

**Уеннар**

«Чоқор туб уйныйдырыйық, сийыр йонон түгәрәкләп әwәлисен дә туб йасыйсын.

Қағыш туб уйныйдырыйық.

Җир кипкәченнән оло... су буйында гармуллар уйныйдырыйық, бездән олорақлар «киндер туқмақлыйбыd» дип уйныйлар ыйы.

Хәзер уйын уйнамыйлар, җитәкләшеп җырлап уйныйлар ийе, сабан туйларында да».

*Сөйләүче: Габдрахманова Дания (1936 елгы). Лажы*

«Сызығ уйнау, әл дә бетеки балалар уйнап җөриләр ич. «Сызығ уйнасан, әчлек була, ашлығ унмый, туплы уйнасан, туқлық була» диләр ийе, сызығ уйнаганны йаратмыйлар ийе.

Әwәлерәк булған ул күкәй җийып, пешереп апчыққаллар. Чәчүгә чыққанчы чәчеп җибәргәлләр пешкән күкәйләрне. Үdләренчә ғөрөф-ғәдәтләр шулай булған».

*Сөйләүче: Борһанова Сафура (1924 елгы). Бәрәңге авылы (район үзәге)*

«Қағыш туп болай була. Тупны чөйәдер ийек тә, кемгә туп тийә, тупны андары шул чөйә.

Урта қазық та уйныйдырыйық. Уртада берәү тора, артта икәү тора. Теге берәү боларның берсен тота да, берсе яңғыз кала.

Қайыш суқтыру, ансы аулағыйдайы.

Айақ тибеш. Тезелешеп утыралар. Ишек қатында тора берәү. Берәү айағын тибә. Кем типкәнне белмәсә, тағы тора ишек қатында.

Аулағ өйләр, төрлө-төрлө уйыллар уйнаб йатырыйық. Җырлап та уйнар ыйық. Қул алыш эшләү дә булыр ыйы, миңғашлибез дә аңғашлибез тушында, йарты қабырға, дип йөртәләр ийе.

Йаз көнө күч қарамаға *(ташу карарга)* төшәрләр ийе».

*Сөйләүче: Ситдикова Гөлсылу (1925 елгы). Портянур*

«Мәктәпкә төшә торған чат бар ийе. Ташу шул күпергә төшә торған ийе. Анда Порт'анур *(авыл исеме)* да төшә, ирләр дә төшә.

Шул күпердә уйналған уйыннар. Ике аwыл тоташадырыйы. Әбиләрнең әйтүwе буйынча, суға соқланмаға йарамый.

Су анасы Сылубикә,
Су атасы Сөләйман.
Миңға тимә, мине алма,
Менә сиңға ал йаулық,
Миңгә бир саулық,

тип җеп сала торған ийе. Җә берәр җирдән тартыб алып ташлый җепне. Хәзер инде су да җыйылмый».

*Сөйләүче: Галләмова Кәүсәрия (1933 елгы).*
*Яңавыл*

«Төрәкә урмаллары йәмле йе. Төрәкә урманға менәләр ийе, наратның баллы қайырысын ашыйдырыйық та уйыллар уйнап, бийеп йатадыр ыйық.

Суқыр налпы *(лампа)* йандыра-йандыра икең бергә утырасың да, «Кара!» диләр. Икең бер-береңә қарасан урамға чығып китәсен. Без бәләкәй ийек, кәбәрткеләренә *(аралыкларына)* кереп қарап торор ыйық.

Кыруг әйләнеп уйныйдырыйық.
Қашың қара уйылған.
Қашыңнын бер почмағына,
Маратым, дип қуйылған.
Әй, дустым, кил әле,
Икәү әйләниг әле.
Әйләнсәк-әйләнмәсәк тә,
Минем дустым син әле».

*Сөйләүче: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы).*
*Куянавыл*

«Аулағыйда эрәхәтләнгәннәр уйнап. Пута суғыш *(каеш сугыш)* уйнағаллар, йырлап-йырлап та утырғаллар. Шырпы салышта салып чыға да берәү, шырпы кемдә сикереп чық, ти. Андрағысы йаза бирәләр, йырлап күрсәтәме анда.

Йарты йырулар булыр ыйы, йартысын әйтәләр дә, йартысын син әйтәсен.

Кигәwелләр тешлиләр.
Эскерәбин аwылында
Тыршып-тыршыб эшлиләр».

*Сөйләүче: Һадиева Раушания (1936 елгы).*
*Мазарбашы (Алашайка)*

«Аулағый була инде, әниләргә әйтмиче аулағыйдә жөрөп килер ийек, атнасына бер генә қайтыр ыйық *(Казаннан*). Пелин алышлар уйныйдырыйық, жегет килә дә йалында *(өйалдында)* сөйләшеп алып керәдер ийе. Шырпы салыш уйнарыйық.

Болынға төшәр ийек, урта қазық уйнар ыйық парлы-парлы қара-қаршы тезелеп басыр ыйық та, башта тора инде урта қазық, ул бер пар икесе ике йаққа йүгереп киткәченнән, тотыб ала. Алмаса, тағын урта қазық була.

Хатирә уйыны бар ийе, жырлаб уйнарлар ыйы. Әч булсақ та, йалаңғач булсақ та уйнап, жырлап үткәрдек йәшлегебезне».

*Сөйләүче: Мөэминева Мәгъсүмә (1924 елгы). Мазарбашы (Алашайка)*

## Ырымнар

«Әнекиемнен баласы тормаған, тапқан да үлгән, тапқан да үлгән. Бу туған, бососона қорама күлмәк тегеп кийерткәлләр, бу торған. Бер малай исән қалып үсеп киткән.

Мин *(миң)* булғанда Миңкә, Миңлебикә исемен қушқаннар. Бәбәй чәйе әзерлиләр әнекиләр. Шул күрше «синең қызыңға Винира» қушам, диде андра анысыңға.

Ат тайлағачнан *(колынлагач)* тайға миләш ағачын асып қуйалар, артыш ағачларын, күз тимәсен, дип. Тозно бәйләп қуйасын «күз тимәсен» дип, баш түбәгә печтик кенә саласын тозно. Күз тимәсен өчөн бөтине салмадым. Берйулы ике бөти йасаттым. берсен матчаға қыстырдылар, берсен алып киттем. Малайым әрмийәдән қайтқач,икесен қушалар.

Менә мин әтинен суғышқа киткән чағын беләм. Әнеки ипинен башын кисеб алды да тешләргә қушты. Қалғанын матчаға қыстырып қуйды. Сүкәри булып бетте. Жә қайсы кеше оңға қулын тықтыралар. Тегендә (армиягә) барғачыннан, анда ул даwыл уйнатқан. Қайтышлый безгә керде, исән қайтты. Теге ипийен қайсы эткә бирә шунда.

Кеше үлгәченнән, мәйетне жуғачыннан суwын ару жиргә күмәргә қушалар.

Нигезен ойоштырғач та мулла алып қайтасын да укыйлар, ботқа ашыйлар».

*Сөйләүче: Габдрахманова Дания (1936 елгы). Лажы авылы*

«Хәйwаллар асрап, өйләр салдық. Бүлмә тақталары йасап, башына сиртмә қуйып балалар үстердек. Сиртмәдә үскән балаларыбыз бар бит. Сиртмәсе миләш булғандыр инде ул. Баланың баш астына бишеккә, мендәр астына доғалық қуйалар, тимер қайчылар – ниләр қуйалар ийе.

Бусағаға dоға қуйалар ийе.

Бизгәк тотқан, ул бик әшәке чир, тундырып, қалтыратып. Йә муллаға барып им-том итәләр. Бер әби бар ийе имнәүче. Ул әби андыра *(аннан соң)* үлде.

Арпа бар ийе, бәк чығадырыйы күзгә. Әбиләр аңға «мә күзеңгә», «мә күзеңгә» дип төртәләр бит ул. Болайттереп йеппәреп, күкиш күсәртәләр қайсы-берсе, қурқыталар, хурландыралар йәнәмәсе».

*Сөйләүче: Борһанова Сафура (1924 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

«Мин айател көрсине йегерме берне уқып, өрөп йатам, йорт ийәләрен қуwам. Тан суwы күз тигән кешегә файдалы. Қойаш чыққанчы алғаннар, шуны эчәргә дә йарый. Мунчаға сул айақ белә керәргә, ун айақ белә чығарға, диләр. Мунчадан чыққач, тоз қабарға.

Қамчау *(аҗаган)* булса, ашлық уна, диләр. Салаwат күпере суға төшсә, тағын йаңғыр була.

Күп балалы ананын табан астында да оҗмах, тиләр.

Ат ийәләренә, абзар ийәләренә, йорт ийәләренә сәдәқә бирү кирәк».

*Сөйләүче: Ситдикова Гөлсылу (1925 елгы).*
*Портянур авылы*

«Қайсыбер кешене йорт ийәсе сөйми, диләр. Ипи пешергәч йатып торыйм, дип җатқан ыйым, ди, шуның тәүмәлеге *(зурлыгы)* кеше кебек басты, ди, белгәннәремне уқыйм, ди. Йорт ийәсе йаратмаса, мулла чақырып уқыталар.

Безнең йуғароч әби бик қурыққан ийе. Қурыққач қурқулық қойдорадыр ийе. Җеннәр кермәсен дип, артыш ағачы йандыралар ийе.

Мине бер ата қаз талаған ийе, қурқулық қойдорғаллар ыйы. Балаwызны эреткәч ата қаз эрәсеме төшкән ийе. Өшкөрделәр дә миңға күсәрттеләр, қара, менә қызым, ата қаз, дип.

Бөти тағып йөрисен. Бөтигә «тазалық бирсен, саулық бирсен» дип йазылған булсын.

Хайwанны ашқа кертермен, кешене гүргә кертермен дигән күз белән. Чәче озон булған кешеләр күзсендерә, диләр.

Абзар ийәләре йаратмый, симерми туарым, дип әйтәләр ийе. Хәзер қайа инде ул абзар ийәләре? Қачып беткәннәр.

Мәйетне йуwып салғач банкы қуйып ақча салырға кирәк, тиләр.

Хәситә, дип, миләш ағачлары тағып, бәбәйгә кийертеп, төрлө-төрлө нәстәләр тағып қуйарлар ийе.

Бүсерле балаға бүсер ташы чайқый-чайқый даwа биргәннәр.

Беренче күк күкрәгәч сикерәләр «Аwырлыққа – җиңгеллек», «Аwырлыққа – җиңгеллек» дип.

Әшһәде әннә, дип уқыйсын да:
Суwы сарықсын,
Үзе қалықсын, –

дип әйтә-әйтә қойындырасын баланы. Чутыр Нәгыймәсе әйтер ийе аларны.

Суға саласы,
Судан аласы.
Бүки баласы.

Қайсы бер кеше нық булсын дигән баласын, нық, дип қушқан.

Мин *(миң)* чықса морҗаға менеп қычқырғаннар, мин бетсен дип, мәңге бетсен, дип. Минтимер қушқаннар, нық булсын, дип.

Чутыр сүзе «қара» дигән сүз ул, нық була ул чутыр кеше».

*Сөйләүчеләр: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы),*
*Садыйкова Гайшә (1910 елгы). Куянавыл*

«Элек табипчылар бик күб ийе, чүмнәк *(чүлмәк)* салырлар ийе сылап-сылап.

Қурықса, қурқулық қойдоралар ийе балаwыз белә.

Арпа чықса күзгә Мәрзийә әбигә барадырыйық. Арпа белә санап-санап имнидер ийе. Башта туғызға хәтле саный да, туғызда тузып китсен, ди. Андрағысыннан җидегә хәтле саный да, җилгә очсон, ди. Бер, ике, өч, дүрт, биш, биштә бизеп китсен. Бер, ике, өч, өчтә очоп китсен. Бер, бердә берлексез булсын. Минем қулым түгел, Әйшә–Батима қулы, дип өшкөрөп-төкөрөп җибәрәдер ийе дә бетәдер ийе».

*Сөйләүче: Мөэминова Мәрьям (1936 елгы).*
*Мазарбашы (Алашайка)*

## Йолалар

«Безен әбийебез ипи пешереб китерде, ашлы-сулы булсын, дип. Қор’ән уқытқаллар әбиләр җийып. Йаңа өйдә йорт ийәсенә доға қылырға кирәк. Теге өйдәге нигездән балчығ алып, өшкөрөп, Ағачлар дәү барысы да, машина беләә йөртте, бәпчегем. Балчығын сала, бәхетле булсын бу нигез, дип.

Абзар ийәләренә ылыс қуйалар, хайван өстөнә хайван кертмәсләр ийе, чирли,дип, чир алып киләә, дип.

Сарық йонон теләде кемгә сатмаған, қул китә дип. Ақчасын җиргә қуйалар, куларты китмәсен дип. Әйберне алып киткәч, хәйwаны аwырый башласа, қулы қаты булды диләр. Кич беләән ақча тотмағыз, дип кенә торам.

Кич беләән себермиләр, борчу киләә. Қойаш байғач эш эшләргә йарамый. Җомға, шишәмбе көннәрне эшләргә йарамый.

Йул уңмый, берәрсе буш чиләк беләән очраса, үзең дә буш чиләк-көйәнтә беләән булғанда қарап қына йөрисе.

Йаңа йылдан соң иң башта ир кеше керсә йараталар, үзеңнеке кем керсә дә исәпкә алмыйсын».

*Сөйләүче: Кәүсәрия Галләмова (1933 елгы).*
*Яңавыл*

## Кием-салым, бизәнү әйберләре

«Элгәре «изү» дийерләр ийе, муйынға асып қуйып балалар алҗапқычы кебек, тәңкәләр, көмешләр тезеп йасаған, күлмәг өстеннән кийеп қуйарлар ийе қунаққа ашқа барғанда. Қалфақ кидем мин, әни алып кийертте, сәйләән тезгән ийе, җаулығ астыннан күрсәтеп қуйасың.

Көз көнө киндер итәрләр *(булдырырлар)* ийе. Андарығысыннан җегерләргә утырмаға җөрдөк инде, балам.

Хәситә, дип балаларға тағырлар ийе күз тимәскә, дип, артыш ағачлары теккән була аңғар. Артыш ағачын йандыралар да менә тушылай итеп йанына қуйып, борынына кертеп, төчкергән, дип. Ай балама күз тигән, күз тигәннең күзе китсен шунда, дип өшкөрәләр. Қайсысы күнчек беләән имни, изү йапмаларының тоташқан урыны беләән, пайдасы тигәндер инде, тимәсә, имнибез, дип әйтмәсләр ийе.

Ашаулыгын, шаршаwын, сөлгөсөн – барысын да киндердән теккәлләр. Чүпләм сөлгөләр даллыклы инде ул. Қандала қабыгы дирләр ийе, ансы тақта күтәреп, үзеннән бизәк чыгарып суққан, дигән сүз. Өститәк салып кийә торганнар ийе, өчәр итәк *(бәбәйтәк)* салып. Итәк тотқан күлмәкләрне үзем дә кидем әле. Җеб ойоқ бәйләр ийек, сүсне талқыр ыйық та.

Тезмә була торган ийе, ике кисәк була торган ийе, тәңкә тезеп менә торганнар ийе, чәчкә тага торганнар ийе, күт өстөнә хәтле төшөп тора торган ийе. Қулбаулары була торган ийе икешәр-өчәр қат қаптырмалы. Сабақлы чулпы, дийерләр ийе, бирнәгә салган кешеләр була шул сабақлы чулпыны.

Қул билгесенә *(вәгъдә бүләге)* бер җаулық, бер ашаулық, бер сөлге бирә. Қалынга бер сандық, бер читле шәл, бер қалын шәл, йақшы камзул. Җиңсез кәзәки, җә қама қуйарлар ыйы. Чапан сораган кешегә чапан салырлар ийе.

Шул ике қалфагымның берсесе жуқ, энҗелесе жуқ. Бөгәлҗәле алқаны алтынчыдан аладырыйық. Көзлектә, қызны бирергә уйласалар, қодалар төшә, бирнә кисәсең, күлмәк кисеп тегәсең бийем-бийатага. Күпмә сорый инде җегеттән ақчаны, қолақ сөйенчесенә бирәмә. Әwәл «wәл» дигән шәлләр булыр ийе бәк жақшы, үзе соро, ақ читле. Җәй көнө бөркәнә. Wәл өстөннән йәйсә қалын шәл, йә бубрик *(тукыма төре)* эшәл бөркәнә. Камфитле шәл, дийәр ийек, төрлө-төрлө төстә, йәшел була, аңгар шақмақлы ақ бизәк төшә. Пустау йанында торган – бубрик инде, ул менә болай бөтөркәсе булыр ийе, шуңа «бубрик» дигәлләр аны. Билифур йуқа, йақшы нәстә. Минем билифурым үз чәчәге үзенә төшкән ийе қақ төслөгә, қуйы чийә инде. Гөлҗаулықның *(кызыл шәльяулык)* мудысы бетте аның хәзер. Китәнне *(киндер тукыма)* үзен сугасың, туқмақлыйсың, агартасың, суга манасың да җәйәсең, суга манасың да җәйәсең. Кийәүгә барасы қызларга эш күп булган. Үрнәкләп йасаган бизәк, чиккән йанчық, анга моноң хәтле нилет *(лента)* тагылган. Тирәкләп намазлық чыгаралар. Ыргақ энә белән кертеп-чыгарып чигәләр, шул була инде тирәкләү.

Қаба төбенә утырабыз да үзәкне чөйәбез, орчоқны бөтөрөп-бөтөрөп җерлибез. Киндерне тарарга тәрәш тарагы, тәрәш қабасы була. Тәрәш тарагыннан буй сүсне тартып үзәк була, тимер шырттан тарттық – буй сүс. Тәрәштән тартыр ыйық, алдагысы – тәрәш

җебе, арттағысы – чүбек. Чүбеге белән мич ағартабыз, аппақ таш суwы йасап».

*Сөйләделәр: Газизова Мәүлизә, Бариева Фатыйха, Рахматуллина Маһибәдәр, Дәминова Сабира. Куянавыл*

«Муйынбаусыз йөргәнем йук, күркәм булып тора.

Минеке тәңкә генә йе, көмөш. Чулпы тағып җөрүчеләр дә бар. Үкчәсенә тийеп җөри чәче, очонда көмөш чулпы.

Шуғыш йылларда батинка урынына тоттоғ инде чабатаны. Чорнап қуйасың аны, йаман әйбәт, киндерәсе бар. Җон ойоқ, бәйләп қуйарлар ийе.

Күлмәкләрне тектерәдер ийек бөрмәле итеп, итәкләр салып, эшләбырлар *(тар балайтәк)* өстә була, аста итәк. Түгәрәк йақа йы элек, хәзер почмақлы йақа бит. Уймырлап, моннан түгәрәкләп тегәләр. Кечкенә йақа, дибез, йақаға тағы йақа утыртасын.

Қалын шәл – әдийал шикелле. Бакаwай шәл – шул суққан қалын шәл ул. Йефәк шәлләр бар ийе озон чуқлы. Қызмаға йаwып қуйған ийем түшәк өстөнә, тора-тора шунда эрегән. Кәшемир йаулықны киленгә бирдем».

*Сөйләүче: Ситдикова Гөлсылу (1925 елгы). Портянур*

«Әле тушы елларда ғына бабайым алқа кийертте, татар алқасы, қашсыз көмөш алқа, аппақ, киңгерәк, бөтөн алқа инде ул.

Киленнәр тәңкә тағалар ийе, зур буладырыйы. Икешәрне тағалар ийе бай қызлары. Йақты тәңкә чалтыр-чолтыр йөрер ийе. Кигән кеше қалфақ кигән, кимәгәне шул көйө йөргән.

Алйапқыч итәкләп тегеп пирде. Күлмәге моннан төймәле, қысқа қысалы, билле. Инеше (инече) алдында да бар, артында да бар, шулай итеп йуқадан эчлек қуйарлар ийе күлмәккә, йәнәсе тиз тузмый.

Идән киндерләре суғып қуйдым. Әwәле бит җитен чәчкәннәр, аны уралар, суға торғаннар ийе, талқы белән талқыйлар. Пачачны җерләwе җиңгел ул. Элек утырғаннар инде чыра җақтысында. Чүпләңгән сөлгөләр, киндерләр суққаллар».

Орлоқ чәчә торған ийек. Аның сүсеннән дә киндер суққаллар, идән киндерләре суққаллар».

*Сөйләүче: Галләмова Кәүсәрия (1933 елгы). Яңавыл*

«Күтәртмәле башмақ кийеп төшәр ийек, кош көнө чабата башмақ кийәрләр ийе, күфәйке, аннан чықты қуйан мамық шәл. Эрзин итек кийеп инештән су ташыр ыйық, пирме тулық сийыр, тез тигетен итек тәпийебездә (аягыбызда).

Күкрәкчә, дибез эчтән кийә торғанысын. Тәңкәләр тағадырыйық чәчкә, бөтөн тәңкә, диләр ийе. Әнекинен чулпысы бар ийе, ике толомға икене таққаннар аны, ақықлары қып-қызыл, җанып торадыр ыйы, чит-читләрендә wақ тәңкәләре дә буладыр ыйы, қашы челтәрнен уртасында була. Тәңкәне бау очона таққаллар, чәч баwы булыр ыйы, чылтыр-чалтыр суға баралар ийе.

Хәситәне қыйықлап кигәннәр, тәңкә тезгән, чат тәңкә генә, араға бер ахақлары да була, өстә – wағрақ тәңкә, аста – ирерәк, ин аста – бөтөннәр. Хәситәне тәңкәдер-нидер тезгәнне, күз тимәсеңгә балаларға да кийерткәлләр.

Изү күлмәктә була ул, нилетләрне, уқаларны түгәрәкләп тегеп чығалар, қайсы-берсе алына торған итеп тә эшли аны. Изүгә тагып, мийыңға бәйләп қуйалар. Бездә «күнчек» тип кесәне әйтәләр, күнчек кесә ул.

Йақалар хәзер қайтарып қуйа торған, ирләр йақасы басып тора, тирәк чығарған була. Күлмәкләрне инеш (инеч) қуйып теккәлләр, әби (бөрмәле) күлмәкләр дә кидек».

*Сөйләүче: Мөэминева Мәгъсүмә (1924 елгы).*
*Мазарбашы (Алашайка)*

# АСЫЛ СҮЗЛӘР ХАЛКЫМ ТЕЛЕНДӘ

*Миңнира Булатова*

*Һәр нигезнең, һәр авылның,*
*Һәр каланың үткәне бар...*
*Гыйбрәт алырлык мирасның*
*Калганы бар, киткәне бар...*

Җәйнең бер матур көнендә без – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, аспирантлары – Мари Эл Республикасының Бәрәңге районы татар авылларына комплекслы экспедициягә юл тоттык. Бурычыбыз – әлеге районның татар авылларында яшәүче милләттәшләребезнең көнкүрешен, җирле сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнеп, анализлау иде. Әйе, кайда гына таралмаган татар халкы.

Бу җирләрнең төп хуҗасы кем булганлыгына ишарәләп, байтак авыллар мари исемнәре белән аталган. Мәсәлән, Портянур (ягъни Басудагы йорт), Поле Кугунур (Дәү, зур басу) һ.б. Кайбер авылларның татарча икенче исемнәре дә бар. Марилар, татарлар килеп урнашкач, әкренләп башка якларга күчеп беткәннәр.

Алга куелган максатыбызны үтәп йөргәндә, онытылып китеп, бу якларның гүзәл яшеллеккә күмелгән басуларын, урманнарын, елгакүлләрен хәйран калып күзәттек. Табигать искиткеч матур! Әмма... шул гүзәллекне ямьләндерүче халкы гына аз! Ягъни буш өйләр күп, халкы кимегән, шәһәрләргә таралышкан.

Учаклары сүнү ягына барган бер-ике иске авылны санамаганда, йорт-каралтылар матур итеп төзелгән. Урамнан узып барганда ук, өйләрнең, капкаларның, тәрәзәләрнең бизәлеше безне

сокландырды. Ә йортның эченә керсәң инде, зур-зур бүлмәләр, алар пөхтә итеп җыештырылган, газ-сулар кертелгән.

Авыл кешеләре милләтебезгә хас мөлаемлыгы, тыйнаклыгы, кунакчыллыгы белән безне елмаеп каршы алдылар. Алар сугыш, ачлык елларында үткән балачак газапларын, кырыс язмышларын шигырь юлларына, җырларга салганнар. «Хәзерге wақытта элекке белән чағыштырғанда, таза булсақ, тыныч торсақ, безгә йәшәү бик рәхәт. Йөри торған йулыбызда қайғы қошо ғына килеп қунмасын, зәңгәр күгебезне қара төтөн қапламасын», – ди, мәсәлән, Мөэминова Мәрьям әби (Мазарбашы авылыннан). Күпне күргән, кыенлыклар кичергән бик тә җор телле, шаян да, йомшак күңелле дә булып чыкты әбиебез. Заман авыр, дип, ачлык, сугыш, дип төшенкелеккә бирелмәгән, авыл клубларында, җыен-сабантуйларында оста җырчы, биюче дә булган. Үзе язган шигырьләрен көйгә салып, авыл халкына җиткергән, ансыз бер чара да узмаган. Мәгълүматны безгә җиткергәндә, йөрәгендә уелып калган онытылмас яралары күз яшьләре булып тәгәрәделәр. Авыр булса да, күңелсезләнеп утырмаганнар, эшен дә эшләгәннәр, гармуннар белән җырлап биегәннәр дә, яланнарга «уйыңға да чыққаллар». Шул яшьлекләрендәге авырлык катыш шатлыклы, күңелле мизгелләрен исләренә төшереп көлешеп тә алдылар.

Һәр районның затлы кешеләрен онытмаучы, ата-бабалар тарихы, үз милләте, аның рухи үсеше, дип янып йөрүче каләм остасы, язучысы була. Бәрәңге поселогында яшәүче Габидуллина Гөлзифа шундыйлардан. Сатучы булып эшләсә дә, ул икенче һөнәргә дә ия. Әби-бабайлардан ишетеп күргән-белгәннәрен колак аша гына уздырмаган, дәфтәренә теркәгән, матбугатта бастыра барган. Әле хәзер дә үз районнарында чыга торган газетада һәм Татарстандагы «Безнең гәҗит»тә аның язмалары, атна саен диярлек, урын алып тора. Ышанулар, ырымнар, бәетләр, йолалар, рухи мәдәният, тормыш-көнкүреш турында хикәяләр дә яза, Бәрәңге районы тарихын да өйрәнә. Туган районынының тарихында гына калган «борынгы» һөнәрчелек турында ул безгә күп мәгълүмат бирде.

Аның сөйләвенчә, Бәрәңге төбәге тимерчеләре, кул эше осталары белән дан тоткан. Олыкыр авылында 1920 елларда бик матур ат арбалары, чаналар ясаганнар. Мунчала әзерләгәннәр, бау ишкәннәр. Яңавылда 1940 елдан «Труд» артеле эшләп килгән. Анда көрәкләр, мичкәләр ясаганнар. Авыл халкы чабата үргән. Ибрай күлендә ку-

рыс батырып, мунчала төшергәннәр. Сәгыйть заводында күмер яндырганнар, сумала, дегет куганнар. «Пуртаныр» артелендә скипидар, сумала куалар, мичкә-кисмәкләр ясыйлар, чабата үрәләр. Фронт өчен дары ясарга порошок әзерлиләр. Путчарада 1858 елны Сөләйман Маматов кәгазь фабрикасы төзетә, күп еллар дәвамында анда җитештерелгән кәгазь Казанга җибәрелеп тора. 1850–1859 елларда Максутов патша армиясе өчен ыштырлык (аяк чолгавына) материал эшләп чыгара торган фабрика тоткан. Бу эш белән Ситдыйк исемле кеше җитәкчелек иткән. Сабанурда тимер сукалар эшләгәннәр, балта осталары цехы булган. Киндер, җитен орлыгыннан май сыкканнар. Бәрәңгедә 1932 елдан кирпеч заводы эшли башлый. Иштыра авылында осталар сөяк тараклар, агачтан көрәкләр, йон эрләү станоклары эшләгәннәр. Тәгәрмәчләр, ат дугалары бөккәннәр. Куракинода 1928 елдан киез итек сугалар, йон тетәләр. Бондарь цехы эшли. Йон тетү машинасы төзиләр. 1942 елда анда фронт өчен җылы кием-салым тегү цехы ачыла. Полянур авылында 1905–1977 елларда җитен мае сыга торган завод эшләгән. Авылларда җил тегермәннәре булган. Уңган килен утсыз да учак кабыза, дигәндәй, авыл халкы үтә кыен шартларда да булганлык, сабырлык, максатчанлык үрнәкләре күрсәтеп яшәгән.

«Башын эшләткән кешегә хәзер авылда кәсепнең төрлесе бар – мал-туар асрау, каз-үрдәк үрчетү, балта-агач эше. Районыбыз авылларында кабер ташы, чардуган, теплица-корылмалар ясап бирүчеләр күбәеп китте», – дип сөйләде Габидуллина Гөлзифа.

Портянур авылындагы тормышка оптимистларча караган, әле дә янып-ялкынланып яшәгән өлкән яшьтәге Гөлсылу апа Ситдыйкованы да әйтеп үтмичә мөмкин түгел. Ул безнең керүебезне ашкынып көтеп утыра иде. Яше туксан белән барса да, йөрәгендә әле дә эш, яшәү дәрте кимемәгән. Гөлсылу апа 50 ел мәктәптә укытучы булып эшләгән. «Мин үземне өлкән йәшкә җитәм, дип уйламый идем. Хәзер исә төнләрен дә гомрем буйы эшләгән хезмәтләремне барлыйм, санап бетергесез тәрбийә чаралары хакында уйланып йатам», – ди ул. Портянурда туып-үскән Гөлсылу Габдрахман кызы җидееллык мәктәпне тәмамлап, 1939 елны Бәрәңге педучилищесына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлап, 1942 елдан бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә, укытуга багышлый. Мәктәп завучы, аннары директор вазифасын башкаручы Мөбәрәк Ситдыйков белән 60 ел бергә гомер кичереп, 9 бала тәрбияләп үстергәннәр. Күңеле һәм

эш-гамәлләре белән ул һаман да остаз икән әле. Авылдашларына берәр киңәш кирәк булса, Гөлсылу апа янына киләләр, һәм аның киңәшләре һәрчак дөрес юлга юнәлтә икән.

Гөлсылу апаның авыл тормышы, рухи мәдәнияте, төрле мажаралы хәлләр турында матур итеп безгә җиткерә алуын, бирелеп китеп, озак кына тыңлап утырдык. Әмма ул вакыт безгә аз тоелды, чөнки ул, рәхәтләндереп бер көлеп ала да, яшьләр темасын да, олыларныкын да читләтеп үтми. «Сөйлисем килә. Сезнениләр кызыксындыра? Шушы хәл турында да сөйлим әле», – дип, авылларының тарихын, тормыш-көнкүрешен, гаҗәеп вакыйгаларны кызыклы, фәһемле итеп ашкынып сөйләвен дәвам итә. Аның яшәү очкыны, дәрте безгә дә күчкәндәй булды, аннан чыккач, дәртләнеп, экспедициябезне дәвам иттек.

Үз авылларында туып-үскән, шунда картайган, хәтта 100 яшьне уздырып җибәргән әбиләр белән дә күрешеп, сөйләшә алдык. Иң олы әби-бабайлар телендә бу төбәкнең сөйләшү үрнәкләре яхшы сакланган. Акъәби, акбабайлар үз җирләренә хас булган йолаларны, гореф-гадәтләрне, авыллары тарихын, яшәешен безгә бәйнә-бәйнә сөйләгәндә, җирле сөйләш үзенчәлекләре дә ачылып китте. Шулар арасыннан минем кебек яшь диалектологның игътибарын җәлеп иткән кайбер тел күренешләрен атап үтү урынлы булыр.

Төп фонетик үзенчәлекләргә мисал итеп түбәндәгеләрне әйтеп узу мөһим. Бер төркем сүзләрнең ахырында, алмашлыклар һәм исемнәрнең иялек килеше кушымчаларында әдәби телдәге *ң* авазына тел очы *н* тартыгының тәңгәл килүе (*аннан сон* – аннан соң, *берсенен* – берсенең, *кешенен* – кешенең); сүз азагындагы *н* авазының кушымчадагы *л* авазына тулысынча охшашлануы (*кийемләр* – киемнәр, *хайваллар* – хайваннар, *баргаллар* – барганнар); *ш* авазы урынына *т* авазын куллану (*тушай* / *тушылай* – шулай, *тушы* – шушы); кайбер сүзләрдә *а* авазына *ә* сузык авазының тәңгәл килүе (*әчлек* – ачлык, *әч* – ач, *әчкеч* – ачкыч, *әчелде* – ачылды); *аннары* сүзендә *н* авазы урынына *д* авазын куллану *(андары)*; метатеза күренеше, ягъни авазларның яки иҗекләрнең урыннарын алмаштырып сөйләү (*андра* < *андары* – аннары) һ.б.

Ә грамматик аерымлыклардан -*мак*/-*мәк* + (*кирәк* сүзе) һәм -*мага*/-*мәгә* кушымчалы инфинитивларның актив кулланылуы (*ни эшләмәк кирәк, бармаға, куркытмаға килмәделәр, тегермән тартмаға баралар*), *да*/*дә* теркәгеченең *дағы(н)* / *дағысыннан да* /

*дәгесеннән дә* рәвешендә әйтелүе (*килгән дәген, күчкән дәгесеннән, түтәлдәгендәгесеннәндер*) һ.б.ларны күрсәтергә мөмкин.

Бәрәңге сөйләшенең лексик-семантик системасында да үзенчәлекле күренешләр бар:

Затларны белдерә торган сүзләр: *апай* – апа, *энекий*, *әтекий* – иренең эти-әнисенә киленнең эндәшүе, *бәпчегем* – иркәләп эндәшү, *әкәйләр* – мари халкы, *сыпы* – азан әйтүче, мулла ярдәмчесе. «Балам», дип олыга да, кечегә дә дәшү.

Тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр: *кәбәртке* – мич арасы, *пошаш* – киндер сүсе, *бүкән* – урындык, чалбар *балдағы* – чалбар балагы, *төнәген* – кичә, *төнәннән бирле* – кичәдән бирле, *қортлау* – котлау, *печтек кенә, печтеки генә* – кечкенә, *тәпи* – аяк, *чөгән атнасы* – өч атна уен уйнау атнасы, *киндер туқмақлау уйыны* – тактага сугып көй чыгару, *бақтым, бағу* – карадым, тәрбияләдем мәгънәсендә бу якларда еш кулланыла.

Терек һәм терек булмаган табигать: *пожарник* – кызыл таракан; *күкри бабай* – камка, чуар таракан; *кибәк* – кандала; *чақма йылан* – абзар иясе; *гөләп* – гөлҗимеш, *ләтчә қычытқан* – вак яфраклы кычыткан; *туйыра* – юан кыска агач, төптән юан булып чыга, ботаклары күп була, үсми ул.

Урта диалектның бәрәңге сөйләше татар әдәби теленә бик якын тора. Моның шулай булуын фәнни сәфәребездә язып алган сөйләү үрнәкләре тагын бер кат раслый.

### *Авыллар тарихы, тормыш-көнкүреш турында*

«Унсигезенче ғасырда Ғайфулла, Сөләйман, Әхматша исемле кешеләр христианлашудан қачып, урманға қачқаллар. Чиста йылға йанына урнашқаллар. Шулайтеп, Олықыр пачиныгы *(починок)* барлыққа килгән. Тушы аwыл инде. Бездә ике урам. Әле анда өч өй кечкенә урамда. Безнеке Советский урам, ул – Набережный. Сулық, платина бар тегендәрәк. Монда йегерме туқызлап өй бар. Басу биғ оло булған. Марыйчаға күчергәндә «Поле Кугунур». Кугу – дәү дигән сүз, нур – басу. Шуңа өстәгәлләр инде «поле» дигән сүзне дә. Марыйча Кугунур – «дәү басу» дигәнне аңлата. Мәктәп бар иде, беренче, икенче, өченчене уқыдым, аннан бетерделәр. Аннары Бәрәңгегә поселокқа йөрөп уқыдым. Мин белгәндә, менә тушы урамда 15 йорт бар ийе, әле өчәү генә қалде менә. Мин кечкенә

чағында пожар булған. Йөзгә йақын қаралты булған инде. Шул пожардан соң кешеләр күчеп киткәлләр инде. Ул wақытта мин кечкенә ийем, апайлар йөри торған ийе аулақ өйләргә, уйыллар, жырулар, йегетләр жыела. Бездә сабан туйы ике йыл инде булғаны йуқ, ақча булмағач. Элек буладырыйы, йаман күңелле буладырыйы, бөтөн халық жыйыладырыйы».

*Сөйләүчеләр: Фәйзрахманов Зиннур (1972 елгы), Шәйхиева Фәүзия (1942 елгы). Олыкыр*

«Үлгән бабайым әйтте. Ул бабайым Йаңаwылдан. Бер мулланы хәзер алып киләләр, ди, төрмәгә, Нурғали мулла дигәнне. «Мине алып китмәгез, зинһар өчөн. Хисаметдинов Борханетдин кешене мулла итеп қуйығыз», – дигән. Шул Борханетдин бабайым хезмәт иткән Варшавада. Шул әйткән. Безнен йаққа ике кеше килгән, дигән. Йаңаwылға Йаққол дигән кеше килеп утырған. Пурт'анырға Шаққол дигән кешеләр килеп утырғаллар. Монда йылға бар инде. Шул йылғаның ике йағына килеп утырғаллар, дип, бабайым сөйләде. Йылға Ировка дип атала. Купшерка дип тә йөриләр. Тее йақтан килә тағы бер йылға. Қайан килгәлләрдер мескелләр. Иван Гырозный килгәчме, қачқалларма, белмим.

Порт'анур – басудағы өй дигән сүз марыйча. Элек татарлар килеп утырғанчы, йәшәгәлләр, ди, утмуртлар. Татарлар килеп йәши башлағач, ул утмуртлар қүчеп киткәлләр. Түбән урамда йәшәгән урылларда йорт урыллары бар ийе».

*Сөйләүче: Ситдыйкова Гөлсылу (1925 елгы). Портянур*

«Нур – басу, Кугу – зур басу. Монда элек урман булған. Заречный, дип әйтәләр. Балық йаман тоталар. Ферма бар ийе, үгезләр фермасы. Мин шунда скутник булып эшләдем бик күп, сигез йыл кечкенә трактор белән.

Әмәлләп училищеға уқырға бардым. Башта плугар булып эшләдем, тузанны эчеп бағ инде! Элек қычытқан, чыпчық қузғалағы ашағаллар. Менә ич, тушының шикелле печән ич. Сап-сары була да. Элек уралар ийе шуны, апқайтып, әче ул тағын, ашап булмый иде аны, онға бутыйлар ийе. Черегән бәрәңгене жыйып қайтабыз да басудан бата-бата, шунын белән қушып пешерә идек кәтермәч.

Налоглар да җыйалар ийе ич әле. Ҡуйаннан *(авыл исеме)* төшә дә теге Ғыйзман дигән бер малай. Кәҗә бар ийе. Кәҗәңне апчығып китәбез, ди. Миңа әйтә. Ни, кәҗә ҡычҡырмасын, дип, аwызын ҡысып утырдым. Тегеләр киткенче. Ит сорый ич, май җыйалар силой кешедән. Если бирмисең икән, йә самаwырыңны апчығып китә, йә башҡаны. Шулай йәшереп ҡалдым кәҗәне, малай, теге узып киткенче утырдым».

*Сөйләүче: Әхмәдуллин Габделнур (1941 елгы). Олыкыр*

«Безен эти 1881нче йылғы ийе. Бу урыллар урман ийе, урман әрчеп, өй салдым, диде. Мин белгәндә ике йөзләп дом булған инде, дәү аwыл ийе, хәзер бетте, дисәң дә була. Бер туры урам ийе, әдерәк кечкенә урын җитмәгәнгә, бакча йағына салып чыҡҡан өйләр бар ийе. Бу урам Портчара дип атала, буйы белән олы йулға чыҡҡанчы. Элек тә бер урам ийе. Ике тегермән булған, бик зур аwыл ийе. Безен аwылдан атлар туҡтамас ийе. Марыйлар, урыслар тегермән тартмаға килерләр ийе. Арышны он итә торған тегермән. Солоны да йасарлар ийе. Җиде класска хәтле ышкул булды, андары сигезгә хәтле. Андары күрше аwылға, Бәрәңгегә дә 15 чакрым, шунда җийәү йөрөр ийек уҡырға. Атнасына бер ҡайтып. Ир-ат кистек суҡты (киез итек бастыру), хатын-ҡыз тегү текте, күлмәк тегәрләр ийе.

Су ҡазаны, дигән урыллар бар, йылға башыннан ағып төшкән су. Су тарта үзенә. Кеше батыб үлгәлләр бар монда. Әллә ҡайлардан, Ҡазаллардан су ҡойынмаҡ киләләр монда. Йылға бар безнен теге йаҡта, шунда сабантуй үткәрәләр. Бу сулы йылға түгел, анда ҡоро йылға, сусыз йылға. Элек «зәңгелдәк йылғасы» дийелгән. Андары ҡорый инде җәй көнө. Менә йаз көнө су аҡҡанда, су аға инде аҡҡанда».

*Сөйләүчеләр: Вәлиева Сабира (1921 елгы), Вәлиева Салиха (1924 елгы). Портчара*

«Ике йөз алтмышлап дом иде менә, шушы аwыл бетте. Хәзер бер йегерме бармы-йуҡмы.

Абый тимерче ийе, суғыштан бер айаҡсыз ҡайтты. Безен эти чабата йасыйдырыйы, базарға меңгереп сатадырыйы. Чабата башлы, үкчәле, баулы, бәйләп ҡуйа торған. Йәнәшәдәге күрше итек суға ийе. Колхозда рәдәwой булып эшләдем. Ун йылын фермада эшләдем, сарыҡ фермасы. Итен Бәрәңгегә сдавайтә идек.

Балалары булмағаннарны бағучы бар монда, Мазарбашыннан бер қатын килеп йөри, дүрт кешене баға. Атнасына өч килә. Мазарбашы бик зур ул, анда апайымның қызы да бар.

Бәйгене иртә белән җиде-сигезләрдә җыйалар, элек төллә җыйалар иде, элек кеше надан булған. Ә хәзер йақтырғач, атлар белән җыйалар. Пута суғыш, круг әйләнүләр. Хәзер бер җыру да белмим».

*Сөйләүче: Ибәтуллина Нурдидә (1927 елгы).*
*Портчара*

«Тушы аwылда туып үстем, берқайа да бармадым. Марыйлар торған монда элек. Шуңға марыйларны татарлар қуғаллар, бездән йырақ түгел бер генә чақрым. Шунда қуғаллар. Хәзер монда бер әкәй килгән дә, қайа барасың, дигәлләр. Иске аwылыма киләм, дигән әкәй. Монда торғач, аwылын Иске аwыл дип чығарғаллар моно, Таштойалны. Иске аwылым, дип марыйлар қушқан. Бу аwыл бик зур ыйы. Теге урамда ғына туқсан ни бар ийе. Чығыпчығып киттеләр читкә. Элек байлар булған инде монда. Байларны қуғаллар, шул сәбәпле таралышып беткәлләр.

Аwылыбыз белән чабата йасадық. Әниләр чабата сатарға китәр ийе. Сийенурға, моннан утыз чақрым. Коржово (*челтәр*) бәйлидерийек кручок белән.

Без анда әчлек күрмәдек, әч торған кешеләр дә булды. Әни белән урыс урағына чығадырыйық без. Урадырыйық, шунда тамағыбыз да туқ буладырыйы. Қычытқаллар, кузғалақлар турап ашқа. Ул wақытта таза булдық, печәлләр-ниләр (*үлән төнәтмәләре*) йасап эчеп йөрмәдек.

Безнең арйаққа Қуйанға (*авыл исеме*) киткән бик зур болон бар, шунда марыйлар ийе. Мәктәп бар ийе, сигез йыллық ийе. Балаларны хәзер машина белән алып китеп йөриләр уқырға, монда бер өчдүрт кенә бала буғай алар, балалар йуқ җүлләп».

*Сөйләүче: Галиева Мәрьям (1930 елгы).*
*Искеавыл (Таштоял)*

### ***Киндер орлыгының файдасы***

«Безнен әнеки сөлгөләр чиккән. Анын апасы идән киндерләре суғып бирде. Өйдә тора торған ийе суға торған нәрсәләре. Алар күлмәкне дә үзләре суққаллар ич, балам. Җитенне чәчеп, җитенне уралар, аны суғалар. Қул белән суға торғаннарыйы. Орлоғын алып қалалар, аннан сон шуны мичкә мунчаға йағып, мунчада қыздырып,

теге массаны, шуны талқы белән итәләрийе. Бөтөн қулларым қалмас ыйы салсақ. Туганнар өй салса, бөтөнесенә йөрибез, миңа да киләләр андары өй салғанда. Пошаш (*киндер сүсе*) кирәк ич. Пошаш йасарлар иде шуннан, балам. Туқмақ белән төйә-төйә шул массаны. Шуннан килеп чыққан шул күлмәққә дигән, нечкә итеп җирләнгән (*эрләнгән*). Киндер озон, өзөлми, сарықнықы шикелле мондой төйөрләре йуқ ич. Әйбәт итеп җирләгәннәр ич. Ут бармы әле анда. Чыра белән утырғаллар. Урақ урған wақытлар булмағанда, шуны эшләгәлләр инде алар. Үзләрен шулайтеп қарағаллар безнен әниләр. Әнекинен шулай күлмәге бар ийе.

Орлоқ чәчә торғаннар ийе. Җитен орлоғы, диләр аны. Киндер булса кирәк. Җитен орлоғы икенче – чәчә торған. Хәзер ул орлоқны никотин дип табалар. Аны йәм-йәшел көйө ашар ийек, басуда үсеп утырыр ийе, име. Киндер орлығын безнен басуда чәчмәделәр. Әкәйләрдә булыр ийе. Әнеки шуннан апқайтыр ийе. Йаман тәмле, шуннан кәтермәч пешererләр ийе. Шул орлоқны пешергәлләр, төйәләр, бәрәңге пәрәмәче шикелле итеп, қамырны дүртпочмақлап йасыйлар, бөгәләр. Монысы зур килеш қала. Тағын почмаққа қуйарлар ийы шуны. Шул булыр ийе кәтермәч. Төче қамырдан, чүпрәләр булмады ич. Киндер орлоғын шул қамырға күп итеп сылап қуйабыз. Балан бәлеше шикелле өстө әчек булыр ийы. Әммә тәмле булыр ийы. Май да саласы йуқ, майлы ич ул. Ул бик файдалы орлоқ. Бетте ул, әкәйләрдә үстерәләрийе. Алты-җиде йыл элек утырадыр ийы орлоқ. Хәзер йуқ ул, орлоғы йуқ. Марилар да ташлап бетерде инде аны».

*Сөйләүче: Галләмова Кәүсәрия (1934 елгы).*
*Яңавыл*

### ***Юкәне күлдә җебетеп, мунчала төшерү***

«Ибрай күле искиткеч матур урында, йүкә ағачлары запасы тупланған урында халық җәй фасылыннан уңышлы файдаланып қалырға ашыққан булған. Урманның байлығын йәшәү чығанағына әwерелдергән. Йүкә ағачын кисеп, қурысын (*кайырысын*) төшөреп, йылға, күлләргә салып, бик озақлап җебетелгән. Аннан мунчала алғаллар. Бу процессны күзәткәнем дә булды. Лайлалы мунчаланы қурыстан төшергәндә сасы искә чыдап булмый. Безнең әбинен сеңлесе Мәймүнә әбинен ире Хисмәтулла бабай ғомер буйы дийәрлек бу эш белән шөғылләнде. Баулар ишә, арқаннар ишә иде. Бәрәңге базарында сатып көн күрде.

Мунчаладан чыпта суққаллар. Хәттә қапчықлар да ул заманда мунчаладан суғылған булған. Йуыныրға да мунчала йасағаллар».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы),*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

## *Куллары эшләгән, күзләре курыкмаган*

«Чүркиләр кистек без шакмақлап тыракторга, аны җардық, кистек, чүмәкәй итеп өйөп қуйдық. Аны Нәғыймә исемле қатын ташыр ийе басуға тыракторға. Чүркине қул пысқысы белән ике кеше кисәдерейе, қайынма, усақма – әммесе була, нинди ағач чығаралар сийа. Без кисеп җардық. Тыракторға Нәгыймә апа қапчықлап күтәреп ташыды, төтөнө әллә қайларға чығарийе. Тыракторнын бензин сала торған җиренә салалар чүлкине. Шул утынны йандырып, басу суқаладылар.

Йаз көнө чәчергә сименә ташыдық. Кечкенә чана белән. Бездә ике йылға бар ийе, берсе – тирән, берсе сай йылға. Чабата тишелеп чығарыйы. Тағын кийеп қуйарыйық чабатаны, тәпи тунмасын, дип. Тушылайтеп торған қатыллар без, балам.

Безнен аwыл чабата йасады. Андары безнен бабай кистек (*киез итек*) тә сукты. Андары Учулыдан (*авыл исеме*) апқайттық соло. Йаз көнө арбалар белә бардық, булмағаннары күтәреп қайтты. Шул йарты кило, бер кило он бирәләрийе апқайтқанға. Шунын белән тордық. Урман да кистек без, андары басуларда урақ урдық, қул белә җитен йолықтық, урақ белән урдық без. Басуда камбайлар килмәде ич. Андары қалдық-постоқ җирләрне көрәк белән қазыдық. Фермада бер йылны сарық та бақтық, Қупайдан (авыл исеме) китергәлләр. Печәлләрне қул белән чабар ийек, чалғы белән колхозға да. Шундыйларны күргән 85 йәштәге қатын мин, балам».

*Сөйләүче: Габдрахманова Мәрзия (1928 елгы).*
*Куянавыл*

## *Авылдашлар, туганнар турында*

«Ғайнан Қормаш минен укытқан уқытучымны йаратқан. Данийә исемле уқытучымны, педушилище укытучысы. Ул «Данийәм, Данийәм» дийәр булған. Ғайнаннын этисенен этисенен бабасы Қуйан аwылында туған булған. Балалар берсе артыннан берсе үлеп торғаңға Қормас (*сулмас*) дип исем қушқаллар икән. Андары Қормашқа әйләндергәлләр. Шул Қормашнын оныкчасы инде бу

Ғайнан, балам. Данийә белән Ғайнан бергә педушилищедә уқығаллар. Андары Ғайнән Қуйан аwылында мәктәптә балалар уқытқан. Бөйек Ватан суғышында аны әсирлеккә алалар. 1942 йылдама, Муса Җәлил белән Ғайнан Қормашнын да башын өзәләр. Ул сөйгәне Данийәгә шиғырләр йазған. «Данийәмә» дигән шиғыре бар икәнен беләм. Ә Данийә йазған хатларны, лагерда тентүләгәндә, фашистлар йуқ итә икән, балам».

*Сөйләүче: Ситдыйкова Гөлсылу (1925 елгы).*
*Портянур*

## *Габдрахман бабай – кызыл партизан*

«Минен әтийем Закиров Ғаптрахман красный партизан булған. Чапаев дивизиясендә булып, Уржумға хәтле барып, шулай эшләп йөрегән. Чапаев дивизиясенен заместителе (Чапаев үлгәч тә) Мәскәүдән аңа хатлар йаза иде, минен әтийемә. Минен әтийем бик булдықлы булған. Анын қызы да армиәгә алынды – әтиемнен беренче қызы – минен апайым. Шул Чапаев дивизиясенен заместителе әтийемә хат йазадырыййы, балам. Монын нәселе булган партизан. Бөтен абыйлары партизан, кулакларнын кирәген биргәлләр».

*Сөйләүче: Ситдыйкова Гөлсылу (1925 елгы).*
*Портянур*

## *Кушаматлар*

«Бәрәңге районындағы қушаматлар: Кәтүкнекеләр, Мамықлар, Черки Зиннуры, Чутыр Мәннаны, Қозғон Ғабдулы, Ата қаз, Сайысқан, Туқран, Көртләк, Чыпчық, Қабач Зиннуры, Таракан Мансуры, Кибәк шайтан, Кендери, Саптый, Қабач, Қурчик, Мүкәй, Бақа, Қуқыр, Күкәлти, Қуқуқ, Кәмә, Кәйек, Чубрик, Чанчай Равиле, Нимәт Фәте, Даwыл, Сапый Мансуры, Мацка, Сөйәс, Дулый Мөдәрисе, Арыш Ғабдулы, Бәйез Хәйе, Күкми Сағулы, Әпис.

Бездә Ғабдуллалар барысы да Апуш, Хисмәт – Кисмәк, Ғайнетдин – Кәйет, Сафарқаи – Хан Сәпагы, Вилсур – Бичи, Фәйзулла – Тазый, Кишәнә Ғабдулы, Қылтыйнықылар, Кәбестә Галийе, Әчтерхан қызы, Бабай Илдусы, Тазый қызы, Кәҗә Гәлийәсе, Куқтый Сәмиғы, Мәрәпнекеләр, Чабақнықылар, Тәкеш Кәримулласы, Чатанықылар, Күсенекеләр, Мәченекеләр, Йалғанчылар, Кәчәйнекеләр, Әкәтнекеләр, Шадра, Чапай, Чабата, Ақаннықылар, Камайлар, Шуйақныкылар, Эчәге Мансуры, Рәпәт Мансуры, Келти

Рәисе, Китек Зиннуры, Төлкөләр, Бүреләр, Чәй малайы, Кәкәмин Ғабделхағы, Метек, учак, Пәтүләнекеләр, Мәкәлти. Менә шундый қызықлы қушаматлар Бәрәңге йағында».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

### *Чират күршедә (мәзәк)*

«Һәр төбәкнең Хужа Насретдин кебек тапкыр үз кешесе була ул. Безнең Бәрәңге йақларында да андыйлар йәшәде һәм йәши. Бәрәңгедән – Кәрим абый, Ғабделнур абый (қушаматы Чәйер), Йаңаwылдан Зиннур абый Хәбибрахманов, Қуйанаwылдан Зиннур абый (қушаматы Китек), Пуртанырдан Ренат Сөләйман улы Вәлиев, Илйас Шәйхетдинов, Фаяз Ғайнуллин. Шулардан ишеткән бер мәзәкне дә сөйлим әле.

Чират күршедә, дип атала ул. Көннәрдән бер көннө Ғабделнур абый чирләп китеп балнисаға (*больница*) менә. Табиптан эшен бетереп чығышына күршесе очрый:

– Ғабделнур, әллә син дә чирләп киттеңме? Қайчан үләсеңне әйтмәдеме духтыр, – дип қотыртқан сүзенә:

– Әй, күршекәйем, житәр инде, күп йәшәдем, қайчанга әзерләним, дип сораған идем, синең wақытың житмәгән әле, чиратта күршең тора, – дип күршесенең қотон алып, өйөнә йүнәлә».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

### *«Табипчы» Хәбибелжқамал*

«Монда, безнен аwылда, ызнайущий знахар булган. Безнен туғаныбыз, Мөбәрәкнен туғаны Хабибрахман қызы Хәбибелжқамал абыстай. Минем бабайым анын қаберен эзләп, зиратта анын қаберен табалмады. Чөнки суғыш wақытында Бәрәңгедә әптик салғаллар. Әптик салабыз, дип, қабер ташларын алып киткәлләр. Шуңга Хәбибелжқамал абыстайның қаберен белмәдек, билгеле түгел. Қабере йуқ.

Абыстай булған төшкөрүче (*төш юраучы*), төшөнә кергән. Иртә белән торошқа өй йанында умбиш ат тезелеп тора торған булған, ди. Дәwаланырға килгәлләр. Ул әйтә: «Ай, берсен төшөмдә күрдем. Бер атнадан үлә инде, ничек әйтим икән», – дип борчыла икән. Кешеләрне дәwалаған ул. Табипчы, диләр бездә аны, урычча ызна-

хар. Шул табипчынын қабере булмағач, Қазанға плитка йасатырға қуштым.

Андағы йортта йәшәгән. Сыпы азан әйтә, ул – мулланың йәрдәмчесе. Хатыны анын абыстай булып йөрдө. Кешеләргә ризық пешерде, бик оста пешекше ийе. Ул сыпы бездә туған булгач, икәү ийе. Берсе Нәҗәр дип атала, берсе – Хабибрахман. Хабибрахман дигәне минекенен баласы, Нәҗәр дигәне икенче туғаныбызнықы ийе. Ул Нәҗәр дигән бабайымнын қызын, Хәбибелҗамал абыстайны, килгән Қазан йағыннан бер мулла сорарға, эзләп. Шуны сорарға аwылға килгән. Аны алып киткән. Барып җитсә, тегендә ике хатыны бар, ди, мулланын. Ул мунчаға керергә дигәч, әзерләнгәч, үзенең читек-кәwешләрен кигән дә, мунчадан чығып чапқан. Ун километр урман анда, андра тағын урман. Шул урмаллардан бертуқтаусыз чапқан да чапқан. Мулла чапқан анын артыннан. Ул көндөз ағач астында йатқан, төнне чапқан йулдан. «Ничек қайттың Хәбибелҗамал абыстай?» – дип сорағаллар безнекеләр. Ул әйткән: «Миңа Аллаһы Тәгалә булышты. Һавадан миңа «Ләбәйкә, ләбәйкә, ләбәйкә» дип әйтте фәрештәләр», – дигән. «Мин хәзер, мин хәзер» дигән сүз икән ул. Хәбибелҗамал абыстай шулайтеп қайтып, бер җиргә кийәүгә бармаған, һаман кешеләрне дәwалаған. Шундый изге кеше булған. Алла бирса, шул изге кешегә, тақта қуйдырам».

*Сөйләүче: Ситдыйкова Гөлсылу (1925 елгы).*
*Портянур*

### *Ситдыйк бабай турында*

«Муса уғлы Мөхәммәтситдыйқнын биш балалы хатыны үлгән, минем әтекийемнен. Шул Искеаwылдан бер йыл буйы минен әнекийемә (йәш – 20 йәшлек қызға) килеп, аңға уже ниқахлашырға дип йөргән, йыл буйы килгән. Ул wақытта аwыл қапқалары йабық булған, ул зур булған, бер чанаға берүзе утырып, төлкө тамағы туны кийеп килә торған булған. Безнен тимерче йанындағы қапқаға килеп җиткәч, кесәсеннән бер уч wақ көмөш ақчалар чығарып ырғыта да, қапқаны әчеп кертә балалар. Менә шулай теге минен әнекийем – Төхватулла қызы Сабираны (Мазарбашыннан) эзләп, шуны өйләнергә хыйалланып йөргән бабай – Ситдыйқ бабай. Ул зур таргач (*сатучы*) Узуйского уезда. Ул анда бара торған булған. Шулайтеп, ул матур қызға өйләнергә булған, өйләнмәде инде, балам. Хәзер дәwам итеп сөйлим аны.

Төхватулла қызы Сабираны алырға йөри, ди, инде бу. Шул wақытта минен әнекийем йылый, ди. «Бай булса, мине урысқа да бирәсез икән», дип. Шул wақытта әйткән теге төшкөрүче (*төш күрүче*), табибчы Хәбибелжамал абыстай: «Сабира жылама, ирен үлеп, йыл йарымнан бала белән айырылып қайтасын», – дигән. Төш күргән ул, белгән. Шулай булған да. Бу барган да, тегендә биш бала утыра, ди. Қатыны үлгән. Бер баласы, йәше, йегет кеше әнекигә килгән дә: «Һай, син бик матур ич», – дип, борнын қысқан үги әнисенен, балам. Үги әнинен борнын қысқан өчөн минем әтекийем аны солдатқа жибәргән. Ул әле исән.

Йегерменче йылны чыққан тиф аwыруы. Бу бабай берүзе бер чанаға төлкө тамағы туны кийеп килә икән. Төлкө тамағы туны дигән сүз – ул төлкөнен бу төшө генә йомшақ була икән. Шундыйдан ғына теккән толопны. Ир быраchта (врачта) булған, рәдом булниса (*больница*)».

*Сөйләүче: Ситдыйкова Гөлсылу (1925 елгы). Портянур*

## ***Гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр, ырымнар***

## **Сабан туе**

«Бу аwылда бик зур буладырыйы сабантуй. Бер атнаға хәтле барадырыйы. Бәйге жыйыу ғына ике көн буладырыйы. Бәйге элек бик қысынқыйы ич. Урамны буйы белән йырлап килерләр ийе. Бәйгене ирләр жыйған, йәшләр инде. Атқа атланып ат белән жыйарларыйы, икенчеләре жырлар ийе, гармун белән жыйалар ийе. Қызларнын йаулығына жыйарларыйы, қулйаулығына. Без қағадырыйық. Тәрәзәләрне әчеп, тәрәзәләрне wатып бетерләр ийе, ат бороно белән бәреп. Тушының қадәр йаулық, шуны бирмәскә қачарыйық. Бәйгене жыйғаннан берәү жыйып ала. Әниләр «бәйге саwап була» дип бәйге биргәлләр, без қулйаулық. Безнен арйаққа Қуйанға (*авыл исеме*) киткән бик зур болон бар, шунда марыйлар ийе».

*Сөйләүче: Галиева Мәрьям (1930 елгы). Искеавыл (Тоштоял)*

## **Сабан туе дәвамы**

«Сабан туйы узғач, һәммә кеше чиратқа басып қунақ йасый, бөтөн кешене чақырып. Өч атнаға хәтле барыр ийы, чи-

ратлашып барып, күрше, туған – бөтөнесе. Шунда бер кеше исереп қайтмады. Бәлеш ашар ийық. Чиратлап, бер кеше қалмас ийе, барған кешене чақырасың ич, үзем барғач. Чиратлап йөрер ийек, қызық ийе. Сабантуйдан сон, сабан туйда ғына җитешеп булмый ич. Ул умбиш-өч атнаға хәтле барған, печәнгә төшкәнче. Қайwақытта печәннән қайтқач та қунақ булыр идек, җитешмәсәк, барыбер йасар ийек».

*Сөйләүче: Галләмова Кәүсәрия (1934 елгы).*
*Яңавыл*

## Кара җиләк атнасы

«Қараҗиләк өлгөргән wақыт – аwыл өчөн шатлықлы көннәр. Сабантуйдан соң туған-тумачаның йәнә бер очрашып алған wақыты. Тик бу боронғы заманда қалған инде. Урмансыз җирдә йәшәгән туғаннар, урманлы аwылға қара җиләк атнасына килә торған булғаллар. Җигүле атларға төйәлеп, алар килеп төшкән көннәрдә чиксез күңелле булған аwылда.

Безнен Йаңаwыл йақларында Ибрай күле дип аталған бик матур урын бар. Әйләнә-тирәсе қара җиләклек. Бар халық йабырылып шуннан җыйған ниғмәтләрне. Ул заманнарда варенйе қайнатқаннарын белмим, әммә ләкин киптергәлләр, қақ қойғаллар.

Қара җиләк атнасы бәйрәмнәре безнен көннәргә килеп җитмәгән. Кәүсәрия апа Ғалләмованың (Йаңавыл авылыннан) әнекисе сөйләwе буйынча, аларға да қыңғыраулы атлар белән Қуйанаwылдан туғаннары килеп, урмансыз йак, атна буйы җиләк киптереп, қақ қойып киткәннәр. Димәк, минең әбийем дөрөсөн сөйләгән».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

## Кияүгә чыгарга бирнә әзерләү

«Чаршаулар, қоршаулар. Элек бер өйдә мыштыр идек ич: йурған, мендәр – бөтөнесен бирделәр инде. Аны ат белән аппардық. Атта сандық ийе инде. Мин Миңзифа апайнын киткәне исемдә минем, әмә. Ул Мазарбашына гармунчы Гәрәйгә барды ич. Без анда бақча кетмәлләп йатабызмы инде. Шунда Миңзифа апай белән ул, карантасына утырып, артына сандықмы қуйып, менә матур итеп китте ул. Сандық белән төштөк инде, арт йаққа сандық қуйдық

та. Анысы урлап төшкәннән соң. Әнисе қайчан әзерләп бирә, шул wақытта алып қайталар инде аны. Йуқ wақытлар ул.

Симҗада әнекием барма, әтекийемме, қайын сеңлемме, аңа алйапқыч, әбигә күкрәк, бабайға чалмамы, чолғаумы инде – шундыйларны ғына бүләк итәләр ийе элек. Мин апайлардан шуны беләм, «килен бүләге» дип әйттеләр инде әнә ул биргәнне».

*Сөйләүчеләр: Һадиуллина Мәмдуха (1930 елгы), Гайнанова Фәридә (1935 елгы). Куянавыл*

**Сөннәтчеләр**

«Йазға таба һәр мөселманның изге бурычын үтәр – өч-биш йәшен тутырған ир баласын сөннәткә утыртыр wақытлар җитә. Иң беренче сөннәткә утырған ир – Ибраһим галәйһиссәлам йәшәгән чордан башлап, һәр мөселман өчөн фарыз ғамәл, қан сыйық чағында, қош-қорт йомырқа сала башлағанчы, йазғы ташулар ағар алдыннан, һәр ир баласы булған йортта дини йолаға әзерлек башлана. Бу йоланы башқаручы сөннәтче әби-бабайлар һәр төбәктә санаулы ғына ийы. Безнең районда Мазарбашы төбәгендә – Тайбә әби, Қаwый бабай Мифтахетдинов, Бәрәңгедә – Бәхтийәр бабай, Пуртаныр, Йаңаwыл, күрше Морқи татар авылларына Вәгыйза апа белән аның әтисе Шәйхетдин бабай игелек қылып йәшәделәр.

Туган йағым – Йаңаwыл – Пуртаныр төбәгендәге сөннәтчеләр – Шәйхетдин бабай белән аның қызы Вәғыйзә апа турында тулырақ сөйлим әле. Революциягә чақлы ук сөннәтче Шәйхетдин бабай «мулла» иткән, бездә шулай диләр инде.

1917 йылны туған Вәгыйзә апаға суғыш йылларында сөннәт пәкесен үз қулларына алырға туры килә. Аwыл халқын пошаманға салып, Шәйхетдин бабай урын өстөнә қала. Қызын чақырып:

– Қызым, көннәрем санаулы. Синең булғанлығыңны һәркем белә, йөрәгең таза. Һөнәремне өйрән, аwылда сөннәтче булырға тийеш, – ди.

Шунда урында ғына утырған хәлдә Вәгыйзә апаға өйрәтеп, бер баланы сөннәтли. Икенче балаға бу эшне қызы башқара. Алланың рәхмәте, бик уңышлы чыға. Шул көннән, 27 йәшеннән Вәгыйзә апа сөннәтче булып китә. Совет заманында йәшереп эшләргә туры килсә дә, безнең төбәктә бер генә сөннәтсез бала да қалмаған. Мәзәктәгечә: «Мич өстендә дә бала, мич астында да бала. Белсә, хатын ғына беләдер», – дигән, балалар күп туған заман. Бер генә дә уңышсыз килеп чыққан очрақ булмаған.

Вәгыйзә апаның даны йырақларға тарала, 1972 йылны азәрбайҗан кешесенен махсус шуның өчөн аны үз йақларына чақыруын да сөйләгән иде ул. Ул йақларда туй рәвешендә үткәрәләр икән бу чараны.

Вәгыйзә апа сөннәтләгән балаларнын исәп-хисабын да йуғалта. Күп ақча, қыйммәтле бүләкләр төйәп қайтып төшкән әбийебезне туған йағында да көтөп зарыққан булалар инде. Сабыр, йомшак қуллы, тәҗрибәле сөннәтче әбийебез әле 1983 йылдан соң да матди хәле начар булған ғаиләләрдә үз wазифасын бик уңышлы башқарап килде. 2003 йылны үлде ул. Мәрхүм әби-бабаларыбызның урыны җәннәттә булсын».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

## Йорт салу

«Сиксән бишенче йылны салдық өйне. Өйне салғанда, нигезен ойышырғач та, мулла апқайтасың да, андра шунда уқытасың. «Нигез ботқасы» дийәләр аны. Нигез ботқасы ашыйлар инде. Дөгөдән пешерәләр, май күб кирәг инде. Доғалар қуйадырыйық. Матчаға абыстайлар йазыб бирәдерейе дә, шунда баш-башларына қыстырабыз. Қәғәзгә йазыб бирәләр доға, шайталлар кермәсен өчөн. Матчаны менгергәндә шыпырт қына инде, сөйләшмисең дә, таwышланмыйсың да, әкрен генә, әйләндермисең дә. Тыныч булсын, дип. Өй салғанда күңелле булыр ийе, эшли алғанда, йәшерәк чақта. Өй йылы була. Өйләр йүешләнгән элек – йылы җитмәүлектән. Мичләрне хәзер сүтеп бетердек, газда ғына қулланабыз».

*Сөйләүче: Габдрахманов Саяр (1935 елгы).*
*Лажы*

## Өйгә нигез салу, армиягә озату

«Мулланы чақырып нигез салғанда қөрән уқыта торғаллар. Без үзебез җорт салғанда доғалар қыстырып, нигезгә қөрән уқытып өй салдық.

Уллар әрмийәгә киткәндә, башыннан әйләндереп бөтөн ипиләр белән, қайтып ризығы монда булсын, дип қалырлар ийе. Қайтқач шуның белән чәй эчтек бабайымныңын. Сақладык күгәртмичә, киптереп сыныгын. Җырулар күб ийе, йырлағаллардыр».

*Сөйләүче: Вәлиева Сабира (1921 елгы).*
*Портчара*

## Аулак өйләр, уеннар

«1930 йылларда Ғайнетдинова Мәрзия апаға туғыз-ун йәшләр чамасы wақыты. Апасы Нәсимә аулақ өйгә чақырулы. Ләкин әниләре, Нәсимәгә Мәрзияне ышандырып, үзе кич утырырға киткән. Инде нишләргә? Билгеле, қызчықны да үзе белән алырға туры килә. Зыйан йуқ, өйрәнә торыр, дип.

Менә алар аулақ өйгә барғаллар дей. Хуҗалар йорт-җирләрне қызларға ышандырып қалдырып, үзләре күрше аwылдағы бажаларына утырмаға киткән. Элек, игеннәр амбарға кергәч, дуғаларға қыңғыраулар тағып, күңел ачып алулар булған. Татар халқы элек-электән хәмерсез күңел ача белгән.

Аулақ өйгә килгән қызлар қайсы бәлеш йасый, қайсылары идән-сәке йуа, өй алды сайғақлары, болдор басқычлары қызлар қулы артыннан көлөп қала. Шуның өчөн дә хуҗалар аулақ өй уздырырға қызларға өйләрен теләп тапшыра торған булғаллардыр. Алар артыннан чисталық, пөхтәлек, йәшлек энергиясе қала торган булған бит...

Менә бәлеш пешеп чыға, аз ғына суытып алырға келәт киштәсенә қуйып торалар. Бәлешне бит утырмаға килгән қызлар ғына түгел, гармун тартып урам әйләнүче йегетләр дә йарата. Қайwақыт җитезрәк йегетләр табылса, ике-өч бәлешнең берсе урлана торған булған. Йегетләрнең берсе бәлеш урларға өйалдына кергәч, урамдағы йегетләр үзләренең дәртле тақмақлары белән қызларның иғтибарын урам тәрәзәләренә йүнәлткән. Теге «уғры» эссе бәлешне, тун эченә алып, қорсағына терәгән. Ләкин бәлеш пешергәч, қычқырып җибәргән икән. Анын қычқырган тавышына қызлар йөгөреп чығып, бәлешне қоткарып калғаллар.

Йегетләрсез нинди аулағөй инде ул, аулақ өй бәлешеннән аwыз итмәгән нинди йегет инде ул. Аулақ өй гөрли: қул эшләре эшләнә, җырлыйлар, төрлө уйыннарны искә төшөрәләр. Иң күңелле уйыннарның берсе болай уйнала: бер йегетне идәнгә тезләндерәләр дә, күзләрен бәйлиләр, ә бер қыз аның арқасына чабата белән суға. Йегет қызның исемен дөрөс итеп әйтергә тиеш. Әгәр дөрөс әйтсә, аларны тышқа йолдоз санарға чығаралар. Исемен әйтә алмыйсың икән, зарар йуқ, һөнәреңне күрсәтәсең. Шырпы салыш уйыннары да уйналған. Йөзөк салыш, шамақайлар булып кийенгәннәр. Җыр-бийү, уйын-көлкө, уйыннар белән төн уртасы

җитүе сизелми дә. Қызлар йегетләрне озата. Қызлар тузған өйне тәртипкә сала».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

«Төрәккә урманға менәләрийе, нарат урманына. Менә шунда баллы нарат қайырысын ашыйлар ийы да, җырлап-бийеп күңел ачалар ийы. Аны «төчөгән» дип йөрөгәлләр. Төчөгәнне чегән атнасы, дип куйғаллар. Чегән атнасы, дип сөйләгәлләр ийе, беләм. Нарат қайырысын ашыйлар, баллы була ди ул.

Аулак өйдә без қайчағында кәбәрткеләренә кереп қарап тора торғаныйық ич. Кәбәртке – мич арасын «кәбәртке» дибез бездә. Мич арасына кереп без балалар қарап торыр ийек шуларнын уйлағалларын.

Җырлап уйнарыйық, қашың қара қыйылған, буең зифа, қашыңнын бер почмағына Маратым (йәғни сөйгәнем) дип қуйылған. Кәнә мин Марат белән йөрим икән. Шундый уйыллар ийе инде, без урамда, әнә, йаз булса. болонда уйын ойыштырырыйық, безнен заманда шулай ийе».

*Сөйләүче: Гайнанова Фәридә (1935 елгы).*
*Куянавыл*

«Қыз wақытта без бик уйный торған ийек, аулагөйләр. Әниләр чабата сатарға китәр ийе. Сийенурға (*авыл исеме*), моннан утыз чақрым. Қайсыбызның әнисе шунда киткәченнән без аулақ өйләр йасыйдырыйық. Лампа ич ул wақытта. Утын җыйадырыйық, майлар, оллар җыйып, бәлешләр пешерәдерейек. Төрлө уйыллар уйныйдырыйық, өй кечкенә инде. Күз йомош уйныйдырыйық шул суқыр лампа белән, күзләрне бәйләп, аннан йәшләр килер ийе тәрәзә артыннан, аларны кертмидерийек ишектән. Төбөрдәтеп алаларийе. Коржово бәйлидерийек кручок белән.

Йаз көнө бик күңелле буладырыйы. Қар бетәр-бетмәстән, йылға қырыйында қар беткән җирдә уйыллар уйныйдырыйық. Аннан клубқа қайтадырыйық. Анда сәғат уникегә хәтле. Урта қазық булыр ыйы, тезелер ийек тә, җитәкләнеп болайттереп, икебез ике йаққа чаwып, тегендә тотарлар ийе безне. Круг, йаулық салыш уйныйдырыйық. Хатирә җырулары бар ийе. Анысын күз бәйләп уйныйдырыйық. Аннан сон берәү алдына мендәр салып болай утыра да, берәү қапланып қулны артқа қуйасың да, қулға суғалар.

Торасың кем суққанын белми, кем суқты, дип сорыйлар. Күрмисең ич инде. Қара қаршы тақмақ әйтешләр дә булды. Мәмдүхә исемле кеше бар ийе, ул мәрхүм инде, шунда ийе тақмақлар. Круглар уйнағанда әйтеп-әйтеп уйныйдырыйық. Йырулар да булырыйы».

*Сөйләүче: Галиева Мәрьям Газиз кызы (1930 елгы).*
*Искеавыл (Таштоял)*

## Чабаталы-чулпылы заманнар

«Ни хәтле хәсрәт, ғазап булса да, йәшлекне уйнап үткәрдек. Әчлек димәдек, уйнадық та, көлдөк тә. Кылубқа күтәртмәле башмақ кийеп төшәрийек. Кулға тотып, клубқа кергәндә резинкә кийеп керер ийек, чабатаны алыштырып. Күтәртмәле башмақ белән уйынға төшәрийек. Күтәртмәле башмақ – йүкәдән үрәләр дә, астына ағач қағаларыйы, су тимәсен, дип, йаз-көз кийәргә.

«Чабата башмақ» дийәр ийек, анысы йүкәдән үргән чабата башмақ, ағач қуйылмаған ғына. Фермада чабата белән эшләп, айақ су булырыйы.

Аннан сон хром итек чықты. Андары куфайкы була башлады. Куфайка белән уйынға төшәрийек. Андары чықты қуйан мамык шәл, қуйан мамығыннан бәйләнгән.

Сыйыр фермасында эшләүчеләргә, бөтөнебезгә 1966 йылда ғына 41 ле итек алып бирделәр, бертөрлөне. Зур итек ийе. «Монын белән қайа барасын?» дип көлөп қалалар ийе. Фермаға эшкә кергәндә 36 сыйыр ғыны ийе. Зур ағач чиләк белән инештән су ташыр ийек сыйырларға.

Муйын баwы, чулпы, тәңкә, көмөш тәңкә, бөтөн тәңкә таға ийек. Чәчқә чулпылар тақтық. Күлмәк йақасыннан инеш таққаллар тирләмәскә. Ыштан бөрмәле, баулы, озон балдақлы (*балаклы*) була ийе. Озон балдақлы ойоқ, тулы (*тула*) ойоқ – сукканнықы, җон носки кидек. Менә тушындый кийемләр, чабаталар кийәриек ул замалларда, әммә гармун аwазы да бар иде, гармун үкерә иде. Үзебезне үзебез йуатып тоттоқ».

*Сөйләүче: Хәйбрахманова Гөлсем (1925 елгы).*
*Мазарбашы*

## Туй өстәле һәм бәби чәе

«Туйға, дип, балан бәлеше, қабартма пешерәдерейек. Элек поднос белән зур итеп паштит пешерәләр ийе, бизәкле-бизәкле итеп,

чәчәкләр йасап. Зур түгәрәк ипи шикелле, ипидән дә зур ул. Йаман қабарып пешә, тушылай қалынлыкта була ул. Паштит – қабарған күмәч, өсләре чәчәкле, писоклы, күкәйдән. Йаман тәмле, қабартма шикелле генә түгел ул. Күкәйләр белән майлап аппарып, шуңға балмай белән, тегендә кисәләр дә, туйда ашыйлар иде. Паштитны әни кеше аппара парлаб, икәүне. Хәзер алай итү бетте.

Йуқа – қамырдан күзикмәк, майда күкәйгә генә басып пешерәләрийе. Йуқаны байтақ итеп аппаралар тәлинкә белән, йегерме бишме исәбе булған. Элек салатлар булмады ич. Туйда паштит белән бал-май, аш буладырыйы, аннары бәлеш, ит чығарып утырталар тәлинкә-тәлинкә. Башта бал-май белән ашыйсың паштитны, чәйе йуқ. Туйда шулай буладырыйы.

Бәбәй ашларында да тушылай уқ (*шундый ук*) булырыйы. Бәбәй тапқач, шул паштит белән, қашық белән балны алып, майны алып ашыйсың ғына, чәй эчермиләр. Андары алып килгән ақчаны саласын подносқа. Менә шулай бал-май ашаған өчөн қортлыйбыз (*котлыйбыз*). Теге йәш бәбәйне қотлап салабыз инде. Хәзер алай итү йуқ ул. Аннан сон бүләкләрне бирәдерейек. Аннан сон ашлар китерәләр ийе. Бәбәй чәйен, туғач, берәр айдан, әнийе тазарып киткәченнән инде узғаралар».

*Сөйләүче: Сәлахетдинова Рәшидә (1927 елгы).*
*Портянур*

**Тәбикмәкләр, коймаклар...**

«Көлтә урып, арышның башын уып ашарыйық. Қычытқан, қузғалақ, ақбаш ашлары пешерәдерейек. Зур болон бар ийы, арпа жыйарға шунда барырыйық. Орлоқ пәрәмәче пешерәләр ийе. Киндер орлоғо белән қамыр изеп қуйасың, басып қабартасың да, шуның тышын җәйәсен дә, шуның өстөнә шул орлоқно туғылап, қыздырып, төйөп йағасын инде қамырға, андра мичкә тығасын.Ул wақытта табалар йуғ ийе. Мичкә генә салырыйық, қоймақ, тәкмәк (*тәбикмәк*) пешерерийек, пәрәмәч пешерер ийек тә. Менә тушындай ризықлар ашыйдырыйық».

*Сөйләүче: Ибәтуллина Нурдидә (1927 елгы).*
*Портчара*

**Гөлләр**

«Мәрйәм анасы (*гөл*). Тәсбих тезгәлләр аның орлоғыннан. Җәйлекле қына, қышлықлы қына, йаран гөлө, фикус, қайын гөлө,

майтап гөлө һәм башка гөлләр үстергәлләр. Татарлар асылмалы, үрмәле гөлләрне «ир затыннан» дип үстермәгәлләр. Өскә үрмәләгәннәрне дә урысларның веногына охшатқаллар, үлем тели, дип үстермәгәлләр. Хәзер бегония утырта күпләр, йаран гөлө дә сирәг очрый башлады. Тамчы гөлгә дә көн бетте».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы). Бәрәңге авылы (район үзәге)*

## Яңгыр яусын өчен (*сынамыш*)

«Қоро йыллар былғанда, йамғыр йаусын өчөн чалғыларны суға тығалар. Ризықлар, йармалар җыйып қарға боткасы йасыйлар. Әбиләрбабайлар чабаталарны суға тыққаллар. Менә бер йылны қоролоқ булды да, Фәридә апайлар шул суға йазып салған ийе. Шуннан йамғыр йауды. Йазып салғанны, алып бәйләп, куйарға кирәк. Аны ағызып җибәрсәң, тағы күб итеп йамғыр йаwа, ди. Ағызып җибәрергә дә йарамый. Йазып суға салдым, дип йөрөйдерийе. Файдасы булған инде.

Қарға ботқасын балалар җыйып йөриләр ийе. Бөтөн кеше дә йармалар, күкәйләр җыйып алып, биреп чығарадырыйы. Шуны бер кеше пешереп бирәдер ийе дә, аны су буйында пешерәләр ийе. Үтеп китеп булмыйдырыйы. Тегеләр чиләк белән су күтәреп чығалар ийе дә, өскә җибәрәләр ийе. Бөтөн кеше чыланып бетеп қайтадырыйы. Менә шуннан сон ямғыр йаwып китәдерийе. Алланын рәхмәте булғандыр инде, бер ғаләмәте.

Бер төрлө ғөлдән, йамғыр йаwасы былса, тамчы бөртөкләре күренә, әме. Йамғыр буласы булса, шуннан чық бөртөкләре күренә. Үләннәрдә дә чық бөртөкләре была йамғыр йаwасы былмаса».

*Сөйләүче: Габдрахманова Дания (1935 елгы), Нуриева Майруза (1940 елгы). Лажы*

## Җен ияру

«Бисмиллаларымны уқыдым дый. Менә чат Мәүлиха апа шикелле «әү» ди. Үзе өйдә түгел, өйдә йозақ, ти. Менә моно хәзер бер апай сөйләде. Без кечкенә ийек, Ғадения апа йоқлый бардым дей. Мәүлиха апай чығып киткән, ди, ағу сибә, ди, име. Менә болайттереп басты, ди, тимер караватқа, бер ир кеше шикелле тәүмәлле, ди. Шунда, дый, шул хәтле қурықтым, ди, бөтөн бисмиллаларымны уқып, дий, йабыныб йаттым, дий. Ғаденийә апа үз өйендә тора. Алар бер тороп алдылар ич. Аннан йуққа чықты, дий. Теге Наилә апаға күренәдерейе буғай. Ағу сибә ди, ни сибә, ди. Аны җелләнгән

дип тә, ул «гел азаплыйлар» дип әйтәдерейе. Күршеләргә керерийе, әйтә утырырыйы «қалығыз, қалығыз, қалығыз» дип иттерәдерийе, қул белән күрсәтерейе. Уже ийәләнгәнме. Иске генә өйдә тордо да. Алла сақласын!»

*Сөйләүче: Хәбибрахманова Кәримә (1922 елгы). Куянавыл*

**Пәри туе**

«Бер әби сөйләгән иде моно:

– Ғомор буе ийәле (*җенле*) йорт күршесендә йәшәдем, ләкин аз ғына да қурқу хисе кичермәдем. Ул йортның хуҗасы Сәрийә апа кызы кийәүгә киткәч, йортта йалғыз ғына йоқламады, кеше дәште. Менә миңа да чират җитте. Кич утырдық, қул эшләре эшләнде, бер қат чәй эчеп алдық, ди. Йоқларға йатар алдыннан әби әйткән:

– Саҗидә, күрше, син қурықма, безнең қайтасы қунақлар бар. Тик алар төн уртасы җиткәч кенә қайталар. Ничек киләләр, шулай чығып китәләр. Тик син дәшмә, йоқлаған булып йат, йәме.

Сәғат ничәләр булғандыр, уйанып киттем, ди. Кинәт кенә рус қапқасы ике йаққа ачылып киткән, ишеғалдына пар ат җигелгән олау кереп туқтаған. Ишекләр үзләре ачылып киткән икән, һәм өч кеше өйгә узған. Ашағаллар, эчкәлләр, сөйләшкәлләр, тик сүзләре генә аңлашылмаған, ди. Бераз утырғаннан соң, қузғалған болар, тологларын кигәннәр, атларын җигеп, үзеннән-үзе ачылған қапқадан чығып киткәлләр. Буран да басылған. Әбидән аптырап сорагач, әбисе сөйләп биргән:

– Мин аларның йөрөшләренә ийәләнгән инде. Аwылыбыздан (*Мазарбашыннан*) килеп бу йортны сатып алғаннан бирле «қунақ»тан өзөлгән йуқ, бәбкәм. Қурықма, қызым, үзең дәшмәсәң қағылмый алар, үз йуллары белән йөри бирәләр, – дип, бу әби «Қөлһуаллалаһ»ын уқып, әйләнеп йатқан.

Иртән уйануға, өстәл җыйыштыру иде, ләкин ни хикмәт, өстәл өстө кичә ничек қалған, иртән дә берни қузғалмаған, әйтерсең лә төнө буйы «пәри туйы» булмаған....

Озақламый Сәрия әби «төп йортына» күчкән. Ике баласы белән қызы Рафийа торорға қайтқан. Берwақыт бу әби сораған.

– Рафия, бер сораwым бар иде. Сәрия әбигә иптәшкә кергәләгәнем булды, әле дә «қунақ»лары қайтамы? – дип сораган бу әби.

– Һии, мин аларны тиз бордырам, әни исән wақыттағы кебек, иркенләп «қунақ» була алмыйлар. Аты-йулы белән сүгенеп, утын

ағачы томыру белән чығып ычқыналар. Барыбер әрсезләр, ара-тирә борчойлар. Болары йарый әле, исеңдәме, моннан күп йыллар күрше Нәғыймә әбинең базы артында мари хатыны асылынып үлгән иде, менә шуның өрәге борчый соңғы wақытларда, дигән.

– Кит аннан, сөйлә әле, – дигән бу.

– Моносо өйгә кереп борчымый, әммә чормаға мич морҗасын йабарға менгәндә кәмит күрсәтеп қарый, йарый әле иске кийез итекне томыруға йуққа чыға. Беркөн балаларға да күренгән. Уйнарға чормаға менгәннәр. Түрдә матур ғына мари кийемендәге хатын қабаға атланып йон эрләп утыра икән, үзе йылмайа, берсеннән-берсе матур уйынчықлар күрсәтеп, балаларны үз йанына чақыра, ди. Шулwақыт урталарына үлгән әбиләре пәйда булған һәм мари хатыны йуққа чыққан. Ул урында қара мәче барлыққа килгән, ысылдап, балаларға ташланам, дигәндә, әбиләре мәчене тотоп алған, икесе дә йуққа чыққаллар. Балаларның шуннан соң чормаға йақын килгәне йук, дигән.

Бу хәлләргә күп йыллар узган инде. Әлеге йорт йанған. Урынында икенче хуҗалар йорт салған, ни хикмәт, аларның да бер тәрәзәсендә төннәрен ут йана. Аларның да «қунақ» көткәннәренә һич шигем йуқ, дип сүзен тамамлады Саҗидә әби».

*Сөйләүче: Габидуллина Гөлзифа (1954 елгы).*
*Бәрәңге авылы (район үзәге)*

## Күз тию

«Күз тийеү – йаман. Хайwанны ашқа кертермен, кешене гүргә кертермен дийелгән. Хайwан булырлық булмағач, суйалар да аш итәләр. Кешене ашап булмый – гүргә керә. Шуңға әйтелгән сүз. Хайwан аш була күз белән, күзгә қарап. Барған атны җығылдырткан итәрийе, күзе қаты. Барған атны «о-о-о, ат килә», дип әйтсәң, қаты итеп қарасаң, теге ат йығыла да үлә, ди. Менә, хәттә ат та йығылып үлә.

Мәймүнә барийе, хәзер дә булса йығып салыр ийе. Бер бала, әллә «Ғәлийә» диде, кәкерәйде дә китте, ди, болайтеп, бу әйткәнчә. Нишләтергә белмиче, өшкертеп-төкертеп тегене. Наилә апа әйтә, йаман матур сеңлем барийе, ди, име. Әллә кем қарап чығып китте, ди. Сразы үлгән. Чәче озон булған баланың. Чәче озон булғаллар күзсенә, магнитлы булғанға. Қайсыберсенең чәче бик озон була ич».

*Сөйләүче: Хәбибрахманова Кәримә (1922 елгы).*
*Куянавыл*

**«Истә қалған суғыш ғазаплары**

Қырық беренче йыл, йәмле бәйрәм киче,
Суғыш, дийеп хәбәр иттеләр.
Шул төннән үк барлық ир-атларны
Ил сақларға алып киттеләр.

Илебезнең зәңгәр күген
Қара төтөн қаплады.
Шаулап үскән иген басуларын
Дошман танклары таптады.

Өч абыйым ил сақларға китте,
Әтийем үлде, апам китте оқоп қазарға.
Ике бала әни белән қалды,
Көчөм житми аны йазарға.

Хатын-қызлар суқа тотто,
Тырмалады йаланайақ йөргән малайлар.
Калхуз сақлансын, дип, эшкә тотондолар
Ақ сақаллы қарт-қарт бабайлар.

Әниләр симинә ташыды,
Иңнәренә қапчық күтәреп.
Әчле-туқлы көйе салқын өйдә
Қөннәрне без йылап үткәрдек.

Әнийем қайтып керде, чабатасы қатқан,
Тишелғәлләр анын башлары.
Ап-ақ бәс қаплаған, күренмиләр
Әнийемнен қара қашлары.

Әнийем аш пешерде
Әрчемәгән бәрәңге турап.
Бераз арыш туғылап, тәмле итеп.
Күршеләр керде, бергә ашадық.

Йарлы булдық, барны бергә бүлдек,
Әммә ләкин тату йәшәдек.
Зиһен басып йылап уқыдылар
Ирләреннән, улларыннан килгән
Мондый хатларны:

– Озақ йазып булмый, без әлегә исән.
Суғыш һаман қотора,
Исән чақта күрешербез, сау булығыз! –
Дип йазыла иде хатлары.

Йылау-теләүләрдән башқа
Булмағандыр һичбер қунақлар.
Өстәлләрдә бары утырырлар
Черек бәрәңгедән пешкән коймақлар.

Қача-поса барып басуларға
Арыш башы уып ашадық.
Күрмәсәләр, қайтқач қыздырып ашарбыз, дип,
Алйапқычқа кесә йасадық.

Бәхетсезлек килде – бригадир күрде.
Кесәләрдән алты сабақ арыш башын
Җиргә алып ташлады.
Ник хурлықта йөрөйсез, – дип,
Җилкәбезгә суға башлады.

Бар ийе безнен күршедә
Тирмәнче дә, балықчы да
Ибрай исемле бабай.
Килеп керсәм урын бирер,
Әйтә иде: «Кил, утыр өстәл йанына,
Ойалма, аша давай!»
Қалын итеп ипи кисеп бирә иде.

Бабайыма қарый-қарый ашый идем,
Аwызымны тутырып.
Хәзер уйланам да, бабам искә төшә.
Аңа доға қылам утырып.

Йаңа арыштан он тартсалар,
Ыскылатқа чабабыз.
Берәр уч он бирә иде
Хафиз дигән бабабыз.

Онны кесәбезгә салып,
Өйләребезгә очабыз.
– Әни, тәмләп аш пешер, – дип,
Әниләрне қочабыз.

Әчлекләрдән, салқыллардан
Сақладылар безне әниләр.
Әчлекләрне күрми, суғышларны белми
Рәхәттә үссен нәниләр.

Қырық бишенче йыл, йақты май иртәсе.
Суғыш туқтаған, дип хәбәр таралды.

Суғыш беткән, сөенче, дип,
Йөгөрешәбез бала-чағалар.
Ирем қайтыр, улым қайтыр! – дип,
Зур апайлар арттан чабалар.

Суғыш батырлары дошман қочағыннан
Илебезне тартып алдылар.
Туған йақтан киткән бик күп ир-йегетләр
Туған илне сақлап урманнарда,
Далаларда, сазлықларда үлеп қалдылар.
Балам суғыштан қайтмады, дип,
Ғомре буйы әнийем көтте, йылады.
Аwырлықны җиңә, қайғыларға түзә –
Таш була икән ана йөрәге.

Йөрөй торған тыныч йулыбызға, дуслар!
Қайғы қошы килеп қунмасын.
Таза булсақ, тыныч торсақ, йәшәү бик рәхәт,
Суғыш, әчлек кенә булмасын.

Күңел һаман «йәшәргә» дип бара,
Берни күрмәгәндәй йөрәк йәшәрә.
Барыбызға да насыйп булса иде
Қайғы-хәсрәтсез йәшәргә.

Булмасыннар иде қан қойулар,
Булмасыннар иде суғышлар.
Йөрәк әрнемәсен, йөзләр сарғаймасын,
Тараймасын иде сулышлар.

Аwыр булды йазмыш, онытмағыз йалғыш.
Искә алығыз һәрчақ ул йылны.
Шундый ғазапларда үтте безнен
Гүзәл балачақнын биш йылы.

Йазмышлар нинди булса да,
Уза барыбыздан да.
Исәнлектә тағын очрашырға
Йазсын барыбызға да.

Бу йазмамны сезнен өчөн йаздым,
Миннән сезгә хәбәр барсын, дип.
Дөнйа хәлен белеп булмый, дуслар,
Истәлегем булып қалсын, дип».

*Сөйләүче: Мөэминова Мәрьям*
*(1936 елгы). Мазарбашы*

## ТАБЫН КҮРКЕ – ТУГАННАР

*Флера Баязитова*

Бәрәңге районы – татарларның күбрәк тупланып яшәве ягыннан аерым игътибарга лаек төбәк. Бәрәңге – үзе зур гына татар авылы. Тирә-күршедәге зур авыллар: Мазарбашы (Алашайка), Портянур, Куянавыл һ.б. элек-электән Казан белән дә, Татарстандагы татар авыллары белән дә тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр, тамырлары, нәсел җепләренең бергә килеп тоташуын онытмаганнар. Мәсәлән, Мазарбашы авылы картлары үзләренең борынгы бабаларының Алат юлы Күәм, Сулабаш авылларыннан күченеп килгән булуларын хәтерләрендә саклап, буыннан-буынга тапшырып килгәннәр.

Биредә яшәүче милләттәшләребез этнографик яктан да Казан арты авылларындагы татарларга якын. Мәсәлән, күбрәк Казан арты татарларына хас булган «җыен» бәйрәме биредәге татар авылларында да бик күңелле итеп уздырылган. Биредә өч җыен төркеме булган.

**Төчегән атнасы.** Анда Югары һәм Түбән Мазарбашы, Купай, Портчара, Куланур авыллары катнашкан.

**Арбалы җыены.** Анда Таштоял, Яңавыл (Ирнур), Портянур авыллары катнашкан. «Арбалы җыены» дигәндәге *арбалы* сүзе мари телендәге *арвыле* – бергәләп, бер төркем, күмәк дигән мәгънәне белдергән, дип аңлатыла.

**Сабан туе** – җәйге иң зур бәйрәм. Элек ул кар беткәч тә үткәрелә торган булган. Соңгы чорларда инде, җыен бәйрәмнәре дә онытылгач, сабан туе июнь аенда үткәрелә башлаган. Авыл буйлап, атларны матурлап бизәп, капка саен туктап, сабан туе бүләкләре җыеп йөрү биредә *бәйге җыю* дип атала. Элегрәк яшь киленнәр бүләге – кызыл башлы чүпләмле сөлге – иң зур дәрәҗәле бүләк

булган. Аны сабан туе мәйданына багана башына бәйләп куйганнар. Бала-чагалар, кулларына тастымалдан тегеп биргән букчаларын тотып, кызартылган йомырка җыеп йөргәннәр. Авыл гөр килеп торган.

Гаилә йолаларының иң зурысы – туй итү, өйләнүләр, барлык татар халкына хас булганча, яучы килү, димләү белән башланып китә торган булган. Килсәләр, кыз ягы, *җул билгесе* итеп, сөлге-ашъяулык, намазлык биреп җибәргән, ә кияү кияү ягы *җолаҗ сөенчесе* итеп, кызга шулай ук бүләк китергән. Кияү килү – үзе дә бер бәйрәм, балалар кияү бүләге көтеп торганнар. Кияү, чемоданга салып, кыз балаларга кечкенә көзге, *иллек* (иннек), *кершәлләр* (кершәннәр), малайларга пәке алып килгән.

Яхшы атлар җигеп, атларны матурлап бизәп, бөтен урамнарны әйләндереп, уң яктан китереп, киленне төшергәннәр. Киленнәр элек озын җиңле, бала итәкле күлмәкләрдән, изү, камзул яки кесәбикә киеп, бөркәнчек, шәл-яулыклар бәйләп, бием-биата (кайнана-кайната) янында оялып, әдәп саклап кына йөргәннәр.

Гомумән, бу төбәктә туган телгә дә, халык традицияләренә, гореф-гадәт, йолаларга да зур хөрмәт саклана. Без авылларда өлкән буын кешеләрен сөйләтеп, алар авызыннан бик күп истәлек-хатирәләр, борынгы йолалар, аш-сулар, бәйрәмнәр, им-томнар һ.б. темаларга караган мәгълүматларны диктофон хәтеренә яздырып кайттык. Биредә шул материалларның бер өлеше, бик зур рухи байлык буларак, халыкның үзенә кайтарып бирү максаты белән тәкъдим ителә.

## Өйләнешү, туй йолалары

***Җаучы, җаучы әби*** – кыз димләүче, егет белән кызның гаиләсе арасында арадашчылык итүче.

*– Җаучы әбиләр булған. Әйбәт җыз булса ғына димләгәлләр. Җыз әйбәт булмаса, күңгелсез була бит ул. Шулай җаучылап, димләп җаwыштырғаллар, табыштырғаллар әйбәт җызларны-җегетләрне.*

*– Җайсы җызларға өчәр тапҗыр җаучы җибәргәлләр. «Әни кемгә бирсә, шуңға барам», дип әйткәлләр җызлар.* (Бәрәңге)

Җаучы булып, җегет әнисе дә килгән:

*– Җаучы булып, җегет әнисе үзе дә килгән. Менә мин, малай әнисе, барып керәм. Ыштан балағын чығарам. Теге уйлый инде, бу тик торғанда ғына килмәгән, ыштан балағы чыҗҗан, ди, җыз әнисе сизә инде. Чәй җуйалар, чәй эчәбез. «Синдә җыз бар, миндә җегет*

*бар, қода-қодағый булышырға уйлап килдем, – ди. – Синең қызың бик әйбәт, улым да йахшы, уйлап бақмыйсыңмы?» – ди. Үзе бармаса, кешене қуша инде. Қыз инде қача, күренми җаучыға. Қыз әнисе әйтә: «Қыз ни әйтер, уйлашып бағарбыз», – ди. Тағы килә: «Җә, нәстә уйладығыз? Кыз ни әйтә?» Болар әйтә: «Без Аллаға тапшырабыз инде, қыз күнәргә уйлый», – ди.* (Портянур)

***Җабышып чығу*** – кызның, ата-анасы белән киңәшмичә, алар рөхсәтеннән башка, егет белән икесе генә килешеп кияүгә китүе.

– *Элгәре җаучыламыйча ғына җабышып та чыққаллар ич ул, менә төллә белән, йә кичтән ала да қайта уйыллыққа чыққан қызны.* (Купай)

***Қолақ сөйөнчесе*** – кыз ягыннан егет ягына бирелә торган вәгъдә бүләге.

– *«Қызығыз бездә» дип әйтергә килгән кешегә қолақ сөйөнчесе биргәлләр булса кирәк. Җә бер җаулық, җә қулҗаулық биргәлләр.* (Портянур)

***Қолақ тәңкәсе*** – кыз ягыннан колак сөенчесе алынганнан соң, егет ягыннан кызга бирелгән бүләк яки акча.

– *«Қолақ тәңкәсе күпме бирде?» – диләр. Ақчамы бирә, бүләкме бирә. Қортлап бүләк бирә бийеме.* (Мазарбашы)

***Мәһәр салу:***

– *Мәһәр салу элгәре булган ул. Қыз яғы нәстә сорый, шуны салалар мәһәргә. Қыз сорый читек-эрзиңкә, андары бер йақшы шәл, өчмә-дүртмә күлмәклек, сандық. Җарый, шуны салырбыз мәһәргә, ди.* (Куянавыл)

***Қул билгесе*** – кыз ягыннан яучыга бирелә торган вәгъдә бүләге.

– *Қыз әнисе бирә сөлге-ашаулық, туй билгесе була инде җегет җағына.*

– *Қул билгесенә җанчық, сөлге, чолғаулар бирәләр. Шуны дуғаға асалар да, ат башына бер җегет утыра. Урамны әйләнеп җөриләр җырлап.*

*Алай иттек, болай иттек,*
*Арпа қуштық бодайға.*
*Инде шөкер Ходайға,*
*Эшләр бара уңғайға.* (Портянур)

***Бирнә кисү*** – кияүгә китәсе кызның өенә аның иптәш кызларын чакырып, бирнә әйберләрен әзерләп кую.

*– Инде бирнә кисәсе бар, күлмәг-ыштан кисәсе бар, диләр. Қызлар җыйып, бирнә кистерәләр.* (Куянавыл)

***Ниқах*** – гарәп теленнән кергән сүз. Өйләнешүне, гаилә төзүне шәригатьчә, махсус дога укытып беркетү йоласы. Ул берничә өлештән гыйбарәт: өйләнүченең яучы җибәрүе, кыз ярәшү, ақлашу, кәләшнең әти-әнисе яки иң якын туганнары белән мәһәр турында сөйләшү, килешү, никах укыту (Коръәннең дүртенче сүрәсеннән аятьләр уку), егет белән кызның вазифалары турында үгет-нәсыйхәт сөйләү һәм туй мәҗлесен үткәрү.

*– Мулланың өйөнә барып, шыпырт қына ниқах уқытқаллар элгәре. Хәзер инде өйдә зурлап үткәрәләр.* (Олыкыр)

***Килен көтмәгә керү*** – килен төшәсе өйгә аны каршыларга керү.

*– Малайы қыз алып қайта, көтеп утыралар. Күршеләр кергәлләр килен көтмәгә. Ә теге қыз ойала ич. Күңгелле булған ул, эме.*

*– Йәш киленне көтәргә ун-унбиш қыз чақыралар ыйы. Йәш килен аларға алҗапкычлар бирәдерийе һәммәсенә дә.* (Бәрәңге)

***Киленне кийәү йортына китерү:***

*– Киленне бөтен урамнарны әйләндереп алып қайталар ыйы. Киленне уң җақтан төшерәләр.*

*– Пар ат җигә, қыңғырау таға, «килен төшерәбез» дип, киленне, чапан бөркәндереп, атқа утырталар.* (Мазарбашы)

***Килен төшү, аwызландыру*** – килен төшеп, кияү өенә кергәндә, бал-май каптырып каршы алу.

*– Килен төшкәндә урамға паштит алып чығабыз, бал-май.*

*– Иңгелек аwызландыралар малай белән киленне. Ипи өстөнә бал-май қуйып қаршы алабыз.*

*– Киленне алып қайтып өйгә керткәндә, басқычтан менгәндә бер мендәрне айақ астына салабыз, бал-майлы ипи қаптырабыз.*

*«Шушылай безнең өчөн йомошақ бул,*
*Тәмле-татлы телле бул,*
*Ашлы-сулы, икмәкле бул».*

***Килен күрмеш бирү*** – киленне беренче мәртәбә күргәндә нинди дә булса бүләк биреп күрешү.

*– Килен төшкәч, күрше-күбәләр керә килен күрергә. Алар килен күрмеш алып керәләр. Кем нәстә бирә, бүләк бирә, «килен күрмеш» дип, ойоқмы, сабынмы, исле маймы. Күрешәләр килен белән.* (Куянавыл)

**Атлар белән туй килү.** ***Туй*** – бөтен авыл халкы өчен зур бәйрәм. Элекке туйларда килен төшергәндә, килен каршыларга да авыл халкы бердәм булып чыккан. Туйларда атларны бизәүгә зур игътибар бирелгән. Алдан ук кияү егетләре арасыннан кучер, ат тотучылар билгеләп куелган. Атларны махсус туйлар өчен генә саклап тотыла торган затлы дирбияләр белән җиккәннәр.

*– Қырантаслар белән, атларны бизәп, туй килер ийе, қыңғыраулы атлар булыр ыйы. Туй килгәндә пар ат белән, йастық, мендәр, қызыл йурған алда.*

*– Қызны алып китәргә ике ат килә, берсендә қыз әйберсе була, берсендә кийәү белән қыз утыра.* (Олыкыр)

***Ат башы*** – туйда ат тотучы.

*– Ат башы итеп бер малайны қуйалар, кийәү белән қыз қырантасқа утырып қына қайталар.* (Яңавыл)

***Кода йөртү, кода төшерү*** – туй вакытында кодаларны хөрмәтләү, кунакка йөртү.

*– Қодаларны да атлар белән, қырантаслар белән йөртерләр ийе. Гармуннар уйнап, қаршы алырлар ыйы, қыз җағында да, җегет җағында да.*

*– Чақырышырлар ыйы берсен-берсе.* (Купай)

***Парлы қодалар:***

*– Парлы қодалар икешәр кич қунып китәләр.*

***Қазақ қода*** – туй кунагы булып килгән, өйләнмәгән, ялгыз егет яки ир.

*– Ике қазақ қода килә, дүрт пар парлы қода килә. Алар ике кич йоқладылар. Қазақ қода көнен генә китә. Ул қунып җатмый. Ул бер җегет, җә бер ир кеше була* (Искеавыл).

**Туйда бүләкләшү: кыз әйберсе, кийәү бүләге.** ***Инче*** – кыз кияүгә киткәндә әти-әниләре тарафыннан бирелә торган хайван яки кош-корт. Борынгы төрки телдә инчү сүзе мирас, бүлеп бирелә торган мал, өлеш мәгънәсендә кулланылган.

*– Қызы кияүгә китә икән, артыннан, мирас итеп, йә сарық, йә сыйыр илтеп бирәләр. «Инчесе белән килде», – дигәлләр.*

*– Менә бер хатынға бер үрдәк кенә бирделәр. Аны иренең анасы орышқан. «Инчегә бер сарық та бирмәделәр», – дип* (Портянур).

*– Кийәүгә киткән қыз артыннан әле хәлле кеше бозау биргән, қайсы кеше қаз биргән, йә кәҗә биргән. «Инчесе» диләр. Сарық, ан-*

*дары қаз, мамық кәжҗә – менә шуларны бирде минем әни тол хатын булса да. Қазым күп балалар чыгарды.* (Купай)

***Килен әйберләре, килен бүләкләре*** – кызның кияү өенә алып бару өчен әзерләгән әйберләре һәм бүләкләре.

*– Килен әйберләре күп булса күңгелле. Йастық-мендәрләре, йурғаллары, фәрдә-кашағалары, чаршаwы була, мендәрләрен қабартып қуйа.* (Олыкыр)

*– Намазлықлар, балтыр чолғаулары алып бардық без. Бийемгә инде сатин намазлық, тирәк чыгарып.*

*– Тирәк чығарып эшләгәлләр қызлар, кияүгә барырға әйбер әзерләгәлләр. Тирәк чығару – төрле җепләр белән бизәкләр чыгару (чигү).*

*– Кийәүгә тәпийен чолғарға чолғау әзерлә килгән, тәмәке җанчығы да булган. Мендәр җапқычлары, чынийақ җапқычлары да тирәк чығарып эшләгән.* (Бәрәңге)

*– Килен әйберләрен әйтәм менә. Әнекийенә – сөлгө, әтекийенә – сөлгө әзерләгән, андарығысыннан намазлықлар, тәһарәт чүпрәкләре, иренә күлмәк-ыштан.*

*– Бийем-бийатаға намазлық алып бара, күлмәк була, ыштан була, тастымал була килен бүләге. Қайын сеңелләренә дә бүләк була.* (Портянур)

*– Әбиләргә күкрәкчә биргәлләр килелләр, күкрәкчә кийеп җөргәлләр әбиләр. Қызлар үзләре теккәлләр күкрәкчәне.*

*– Бийатаға айақ чолгаwы йә түбәтәй биргәлләр.* (Куянавыл)

***Қыз әйберсен әзерләү:***

*– Мин менә үзем тийәк чығарам (чигү чигәм). Wақыты җиткәч, аwыр йыллар дип тормағаллар, қызлар кийәүгә киткән.*

*– Мин намазлық, сөлге, өстәл ашалығы әзерләп бирәдер ийем, әни инде идәнгә җәйеп, унике митердән йурған сырадыр ыйы. Бөтен кийәүгә киткән қызға әни белән икәү эшлидер ийек қыз әйберен. Әни қуйан мамығын җерләп торыр ыйы җеб итеп, мин шул җептән бер ойоқбаш бәйләп қуйар ыйым.* (Олыкыр)

*– Әни, балам, қул белән тегәдер ийе қызыл җурғалларны унике митердән. Шуны идәнгә җәйеп, бурлар белән сызып, төрле бизәкләр йасап тегәр ийе.* (Олыкыр)

*– Әни менә қызлар сайын уникешәр тастымал суғып бирде.*

*– Бишле, җиделе қылычлар белән суқтым. Ашаулық, сөлгеләрне әни дә, әнеки дә бик суқтылар. Кемнең қызы кийәүгә китә, бик суғарлар ыйы.* (Олыкыр)

***Ҡыз сандыгы*** – кызның кийәү йортына алып бара торган әйберләре тутырылган сандык.

*– Ҡыз әйберләрен, өй җыйыштыра торган әйберләрен, үзенең өс-баш кийемнәрен тутырып килгән сандыҡҡа. Җыраҡтан килеп, сандыҡ сатып йөрүчеләр булыр ыйы.*

*«Ҡызыңны бишеккә сал,*
*Сандыгыңа әйбереңе сал», –*

*дигәлләр әwәлгеләр.*

*– Ҡызымны сандыҡ белән бирдем әле мин. Ике мендәрен ҡабартып, сандыҡ өстенә ҡуйып алып китте, җургалларын ҡуйды сандыҡ өстенә.* (Бәрәңге)

***Бийем сандыгы*** – кайната булған кешенең әйберләре тутырып ҡуйылған сандыҡ.

*– Бийемнең дә сандыҡлары булды. Сандыҡҡа әйберләрен тутырып, чәчүргеч белән чәчләрен үреп, шул чәчүргечкә сандыҡ ачҡычын да, бөтен тәңкә дә тагып ҡуйарлар ыйы бийемнәр* (Кетнә).

***Өй кийендерү, өй ҡарамага керү*** – килен алып килгән әйберләр белән өй бизәү. Күршеләр өй күрергә киләләр.

*– «Килен нәстә апкилгән?» Өй ҡарамага керәләр күрше-күбәләр. «Матурмы, әйбәтме?» Өйне чат иттереп кийендереп куйгаллар.* (Бәрәңге)

*– Фәрдә-ҡашага җугыйы, сөлге элеп-элеп, килелләр өй җыйыштырадыр ыйы. Ҡызыл башлы сөлге элә киштәгә, түргә элеп ҡуйа. Намазлыҡ элә, чаршаwын ҡороп ҡуйа.*

*– Менә тушындый сандыҡ, ҡызның үз әйберсен тутырган. Сандыҡтан алып, өч митерле сөлге элә, башы ҡызыл, уртасы аҡ, буйы мамыҡ җебе, аны элә дәгесеннән ҡызыл башына чыра терәтеп ҡуйа.*

*– Өй җыйыштырмага шаршау, сөлгеләре күп булыр ыйы бай килелләрнең.* (Портянур)

*– Чүпләмә сөлгеләрне тәрәзә арасына элеп ҡуйгаллар. Матур булсынга. Элгәре җиһаз булмаган ич ул. Эстинәгә сөлге элдек. Мин үзем менә, ҡазаҡ ҡаҡтырып, йүлле ҡашагалар элдем.*

*– Шаршаулар ҡороп йатырлар ыйы бийем-бийаталы кешеләр.* (Олыкыр)

***Кийәү бүләге*** – кияүнең кыз өенә килгәч өләшү өчен алып килә торган бүләкләре.

*– Кийәү бүләге иттереп, жҫә матур шәл апкилгәлләр, жҫә матур күлмәкме алып килгәлләр. Кершәлләр, исле майлар булды. Минем дә кийәү бүләкләре алғаным булды.*

*– Кийәү бүләге алып килә кийәү балаларға өләшергә. Кершәлләр, иллекләрне чумаданға салып алып килә. Аны, кийәү киткәченнән, қыз өләшә инде бала-чағаларға.*

*– Без бала wахытта кийәү бүләгенә жҫөрөр ийек. Эрпет чикләwеге, перәллекләр, көзге-кершән бирерләр ийе.* (Бәрәңге)

***Кийәү килү, кийәүне қаршы алу.***

*– Кийәүне қызлар көтә. Шаршауларны эләләр, ике түшәк жҫәйәләр, аннан ары жҫастық салалар. Андары икесенә ике мендәр, жҫастық өстенә.*

***Итек басуwы сорау*** – кияүдән ишек бавы сорау.

*– Кийәү килеп керә, монда берәү ишекне бикләп тора, кийәүне кертмәскә.*

*«Ишек басуwы – йөз сум,*
*Минем аппай – мең сум», – ди.*

*– Йарар, мә сийа акча, әч ишегенне, – ди.*

*– Кийәүгә чәй әзерлиләр. Ике чынийақ чәй эчә дә, қызлар чығып китә, кийәү өйдә қала.* (Портянур)

***Кийәүләп йөрү*** – никахтан соң кияүнең кыз өенә барып, кунып, кунак булып йөрүе.

*– Элек қара-қаршы йөрүләр дә булған, ақ өйләр дә булған. Шул ақ өйдә жҫатқаллар. Шунда кийәү кич белән атқа атланып килгән, жҫоқлаған, қыз өйендә қунған. Тағын атына атланып қайтып киткән.* (Куянавыл)

*– Бер кийәү киләсе булған әбиләренә қунаққа Қупайға, қыз жҫанына кийәүләмәгә. Әбиләре, бер табақ ботқа пешереп, кийәү алдына қуйғаллар, чоқыр йасап, уртасына май салғаллар. «Кийәү, утыр, әйдә, кеше килгәнче ашап ал әле», – дип, өстәлгә табақ белән ботқаны китереп қуйған, ди, әби.*

*– Мин жҫарлы булғач та, әллә мине хайwан дип белдегезме, табақ белән ботқа ашап утырырға,– дигән дә кийәү, ботқаны қалдырып қайтқан да киткән. Қызны алмаға да килмәгән.* (Олыкыр)

*– Бер атна кийәүлимә, ике атна кийәүлимә, андары алып китә қызны* (Ирнур).

***Кийәү мунчасы, кийәү қоймағы*** – кыз ягында кияү килгәч ягып әзерләнә торган мунча; сый-хөрмәт.

*– Кийәү қадерлейе ич инде. Кийәү қоймағы, кийәү мунчасы буладырыйы. Бер кийәүдән сорағаллар: «Кийәү, мунчаға керәсенмә, қоймақ ашыйсынма?» – дигәлләр. Ул әйткән: «Мунчаға да керәм, қоймақ та ашыйм», – диган.*

*– Кийәү мунчасыннан чығышқа кийәү қоймағы булды.* (Купай)

***Кийәү мунчасына ақча салу, бүләк қалдыру:***

*– Кийәү мунчасына ақча салып чығалар ыйы кийәүләр, мунча жағучыны хөрмәтләп. Мунча тәрәзә төбенә жә ақча, жә бер бүләк салып қуйарлар ыйы. «Кийәү мунчасын без жағыйқ әле», – дип торалар ыйы күршеләр.*

*– Кийәү мунчасы қызның әнисе жағында булған ич ул* (Таштоял).

*– Кийәү мунчасы дигән булып, тәртипләп қуйалар. Акча салып чыққаллар тәрәзә төбенә мунча йағучыларға. Бер кеше йақса – бер кешегә, ике кеше йақса – ике кешегә.*

***Мунча жәймәсе, мунча сөлгесе, мунча киндере:***

*– Кийәү мунчасына мунча киндере, дип, мунча сөлгесе, мунча жәймәләре қуйғаллар. Мунча жәймәләрен мунча сөлгесенә жәйгәлләр. Сикертеп-сикертеп, тақта күтәреп, шақмақлап суғалар мунча киндерләрен.* (Олыкыр)

***Йәш киленгә су йулы күрсәтү:***

*– Йәш киленне алып китәләр су буйына. Мена тушыннан сиңа төшәргә, дип күрсәтәләр. Суны қызлар күтәрә, килен күтәрми. Килен қунақ қыз булып қына қайта.*

*– Килен башқа аwылдан булса, су йулы күрсәтәләр. Килен алйапқычлық биргән қайын сеңлесенә.* (Бәрәңге)

***Килен хезмәте:***

*– Килелләргә эш күп булды элгәре. Килен, килгән көннең иртәгесен иртүк торып, сыйырларны саwып, бозауларны арқаллап, су китереп, самаwыр қайнатыр ыйы. Шулай кийәү өйөнә килгәч тә самаwыр қайната мич арасында.* (Портянур)

***Килен чәйе, килен тәйекмәге, килен қоймағы:***

*– Чәй йасамаға утырталар киленне. Бийем белән күрешә. Бийем инде бүләк бирә, жаулықтанмы, күлмәктәнме. Әwәле шулай булған. «Килен қулыннан чәй тәмле», дип, чәй йасаталар.*

*– Тәйекмәк, қоймақ пешертәләр ийе. «Килен чәйенә керегез», дип, бийем күрше-күбәләрне чақырырыйы. Килен иртүк торып чәй қуйа.*

*– Шулай «килен тәйекмәге, килен қоймағы», дип мақтап, чәй эчәрләр ийе, бүләк алып кергән булыр ыйы үзенә күрә.*

*– Шулай чәйер утыны белән генә қоймақ, тәйекмәк пешереп алғаллар килелләр.* (Куянавыл)

*– Килен килгәченнән дәген иртә белән тәйекмәк-қоймақ изәләр дә киленгә пешертәләр. Күрше-күбәләр кереп аwыз иткән була килен қоймағын, килен тәйекмәген. «Бик уңған килен, бәхетле булыр», дип чығып китәләр андары, қоймақ-тәйекмәк белән чәй эчеп.* (Портянур)

***Бийем белән килен мөнәсәбәте:***

*– Бийемгә буйсынып тордом, «әнеки» дип әйтәбез бийемгә. Шул әнекийем, балам, җақшы кешийе. Ул баланы бақты. Әнекиләрне аларны бик зурлап торорға кирәк. Тора-бара үзең дә әнеки буласың, хәзерге йәшләр шуны белмиләр. Бийемнәр алар беркемгә дә матамый, булышалар.*

*– «Менә хәзерге өйләрдә бийем сыймас та морҗа сыймас», – диләр.* (Куянавыл)

***Бийемле-килелле тору*** – бийем һәм килен булып бергә яшәү.

*– Бийемле-килелле булып тордылар элгәреге wахытта. Икешәр-өчешәр килелле бийемнәр булыр ыйы. Сыйғаннар бер өйгә. Тәртипле булған халық.* (Олыкыр)

*– Әтеки белән әнеки ағөйдә генә торырлар ыйы. Безнең җәнәшәдә биш килен бар ыйы. Әтеки белән әнекине чәй эчмәгә генә чақырырлар ыйы. Әтеки белән әнеки йанына утырып чәй эчмәсләр ийе. Бер килен пешереп-пешереп торор ыйы, тегеләре хайwаллар қараған, йорт эшләрен эшләгән. Барысына да эш җиткән.*

*– Килен булып төшкәч, бийем-бийата йанына бөркәнеп утыра, җаулық бәйли, итәген қыстыра, битен күрсәтми.* (Портянур)

## Бәби тугач үткәрелә торган йолалар

***Бәбәй табу, бәбәйләү:***

*– Бийемле-килелле бәбәй табулар да булды.*

*– Бәбәйләдемә, ун көн тордома, ураққа чықтылар килелләр.* (Бәрәңге)

***Ир бала, қыз бала туу:***

*– Ир бала туса, әйтерләр ийе: «Айақ суқадан чықты», дип. Элек суқа белән, ат белән чәчкәлләр ич.*

*Ир бала булса – булган қатын,*
*Қыз бала булса – уңган қатын,*

*дип әйтерләр ийе* (Портчара).

***Бәбәйне мунчада йә кәбәрткәдә*** (мич арасында) ***тапқаллар:***

*– Әнеки әйтер ийе, йаққан жылы мунчада, қара мунчада таптым улымны, дийеп. Өйдә кеше күп булган ич әwәле. Жылы мунчасы булмаган ич әле күп кешенең. Андый кеше кәбәрткәдә табар ыйы, мич арасы жылы була, кеше күрми ич.* (Куянавыл)

*– Бәбәйне жылы мунчада таптық. Әбилек апчықтылар. Қайыллардан себерке жасадылар, ләүкәгә жәймә жәйделәр, шунда жылы су белән жуып, әз генә парландырдылар бәбәйне, тәгәрәтә-тәгәрәтә жудылар, марлыга сабын тидереп кенә қултыг асларын жудылар. Әбилек бәбәйне чапты, алдына қуйып* (Портянур).

***Әбилек, бәбәй әбисе, кендек әби:***

*– Даллықлы әбилекләр булды элгәре. Көммә, төммә, чақырасың, ул килә, сылый, бәбәйне таптыра.*

*– Әбилек ул бәбәйне дә, әнисен дә йуwындыра. Бәбәй әнисен йылы су белән йуwындыра.*

*– Бәбәйгә аwырта башласа, әбилекне алып қайтырлар ыйы. Шулай әбилек булды элгәре, бырачлар жугыйы. Әбилек, әнә, түшәмдәге калисуга* (божрага) *бау тагып қуйа да, бәбәй табучы шул бауга жабыша, көчәнә йатқан килеш. Ә әбилек «кеш-кеш» дип кенә сыйпап тора, балам, қуwадыр ыйы. Ә безне, балаларны, сәке астына қуwалар ыйы, аннан гына қарап йатадыр ыйық. Ул әбилек тайлый алмаган атларны да тайлатқан, шундый оста қуллы булган ул әбилек. Ул үзе пешерергә дә остайы, чәй дә әзерләр ийе.*

*– Бәбәй әбисен ололоқлап, йаман ололоқлап йөрткәлләр, аңга догалар қылгаллар. Йаман оста булдылар алар, әбилекләр. Бәбәйне мунчага апкерерләр ийе, бәбәйне йуwып, әйбәтләп төреп бирерләр ийе.* (Портянур)

*– Бала башы белән киләме, тәпийе белән киләме, шуны турылап тудырып қайтыр ыйы әбилек.*

*– Әбилекне мунчага чақыралар, ул бәбәйне жуwа. Өч мунча кермиче китмәс ийе ул.*

*– Әбилекне қунақ итеп, бер күлмәклек, бер сабын, бер жаулық бирәсең инде.* (Бәрәңге)

***Бәбәй аwызландыру:***

*– Баланы җуwып сала да, әзрәк исәйгәч, андары аwызландыра әбилек, аwызына, бисмилла әйтеп, бал-май тигезеп ала: «Бәхетле нарасый булсын», – ди.*

***Бәбәй мунчасы:***

*– Мунчаға йаңға себерке әзерләп қуйарлар ыйы, тәннәрен йомшақ себерке белән бисмилла әйтеп сыпырырлар ыйы.*

*Бу бәбәй таза булсын, бәхетле булсын,*
*Тигезлектә үссен, озын ғомерле булсын,*
*Әти-әнисенә миһербанлы булсын,*
*Илгә хезмәтче булсын,*
*Тәүфиқлы, иманлы булсын,*

*дип теләп чапқаллар кендек әбиләр бәбәйне мунчада. Йомошақ себерке белән парландырырлар ыйы.* (Бәрәңге)

*– Бәбәй мунчасын өч көн рәттән җағабыз. Мин үзем менә бәбәй җуучы, мине чақыралар бәбәй мунчасына бәбәй җуwарға.*

*– Җомшақ қайын себеркесен парландырып, җомошатып қуйам. Шул қайын себеркесенә бәбәйне салып әwәлим инде мин. Бәбәй шуны иснәп җата җомошақ себерке өстөндә.*

*– Қайын себеркеләре үзләренеке булмаса, өйөмнән булса да алып барам бәбәй мунчасына.*

*– Бәбәй мунчасына бәбәй җуwарға кергәндә болай итеп чорныйм чәч толымнарын да йаулық белән қысып қуйам, бәбәйгә чәч бөртекләрем төшмәсен дип.* (Куянавыл)

*– Өч мунчаға тийен әбилек керер ийе мунчаға бәбәйне йуwарға. Йомошақ себерке белән җылы ғына итеп парландырыр ыйы бәбәйне.*

*– Әбилек бәби тапқан киленне өч көнгә тикле мунчаға кертә, сылый. Әбилек эшли һәммәсен. Бәби тапқач, киленгә шулай хезмәт күрсәтәдер ийе әбилек булған кеше.* (Куянавыл)

*– Мин үзем бәбәй җуwып йөрим. Безнен әнеки әйтә торған ыйы: «Илем – күршем, алтын бишегем», – дип. Бөтен тирә-күршеләргә йөрим бәбәй җуарға. Җиренә җиткереп җусан бәбәйне, саwабы бик күп. Ләүкәгә салам баланы. Бер чоқорға – қамыр, бер чоқорға салып тоз алып керәм. Шул йомшақ қайын белән себеркегә салам баланы. Қултық асларына, бот араларына тозлы су тидерәм.* (Куянавыл)

***Баланың арқасын йуу, каты төкләрен (кәчтеркәләрен) чығару:***

*– Баланың күбесендә кәчтеркәләр була, менә қаты төкләр була инде арқасында. Иңгелек қамыр белән сылап, шул кәчтеркәләрен чығарам. Қоймақ қамыры шикелле йомшақ қына қамыр була инде ул. Андары шуны йомшақ губка белән, сабын белән йуwам. Сыйық қына марганцовкалы су белән қойондырам да төреп бирәм баланы.*

*Шушы бала ата-ана тигезлеге белән үссен,*
*Бәхетле, тәүфиқлы булсын,*
*Имән кебек таза булсын,*
*Кешеләргә шәфқәтле булсын,*
*Озон ғомерле булсын, –*

*дип, теләкләр телибез.*

*– Әнеки мунча йақтырадыр ыйы, әбине чақырып қуйа. Мунчада әби сылый, бәбәйнен кәчтеркәләрен чығара. Кәчтеркәләрен бер дә чығарғанығыз йуқмыни? Менә болай иттереп, сыртларын, җилкәләрен сылый. Ин қаты җирләрдә була ул кәчтеркә. Балға әз генә он туғлап җибәрәсен дә, марлыға саласын да шунын белән уwасын баланын қаты җирләрен. Бармағын белән уwасын шуннан менә шундый қаты төкләр чыға, хыт тартып ал.*

*– Бала җылый ул шул кәчтеркә чықмағанга. Кәчтеркәләр беткәченнән андары бик тынычлап җоқлый башлый бала. Бер атна чығарды шул кәчтеркәләрне бәбәй әбисе, шул бер атнада бетте, тәмләп җоқлый башлады.* (Куянавыл)

**Исем кушу. *Азан әйтеп исем қушу:***

*– Ике қолағына өреп, азан әйтеп исем қушабыз өченче мунчасында. Аны исемне сузарға йарамый. Алты-җиде көннән исем қушабыз. Бала ул исем сорап йылый, диләр. Озақ исем қушылмыйча торса, җен килеп исем қуша имеш.*

*– Қолағына азан әйтеп қушылса ғына исем дөрес була икән. Қыйблаға қаратып салып, алдан уң қолағына, андары сул қолағына әйтеп, исем қушқаллар.* (Бәрәңге)

***Миң чыққан кешенең исемен алмаштыру, исем қушу:***

*– Мин булса, имниләр, исемен алыштыралар. Минсылу, Минкә қуйалар. Менә Патыйма ыйы – Минсылу булып йөрде, Миңкә абый Ғаптрахман исемнейе, үлгәнче Миңкә булып йөрде. Бетте аларнын мине. Шул минне имләгәннән қалған исемнәр алар.*

*– Менә йаман әшәке мин чыққан булған. Моржадан қашық ташлағаллар, җә бал қашығы, җә аш қашығы. Миннебикә қушқаллар, Миңсылу қушқаллар. Қайсы бала исемен күтәрә алмыйча йылаған.*

*– Тушы оло малайнын тамақ астына таwық күкәйе хәтле бер нәрсә асылынды. Шуннан минем ишеткәнем бар ыйы. Әллә мин булды микән моңғар, дим. Элек морҗабызны мич башыннан җабадыр ыйық. Шул мич башына морҗа җаба торған җиргә бер қашық алып мендем дәген:*

*«Мирсәйет, бу қашық кемгә?»*
*«Минталипқа бу қашық», –*

*дип, өч тапқыр әйттем. Шуннан бетте.* (Олыкыр)

***Баланың қарын чәчен алу:***

*– Унҗиде көннән қарын чәчен алырлар ыйы. Әле аның көне дә бар ыйы. Карын чәче белән қороп төшкән кендекне сандыққа салып қуйарлар ыйы: «Озын ғомерле булсын», дип.* (Яңавыл)

***Баланың тырнағын кисү:***

*– Әбилекләр бәбәйнең беренче тырнағын кисәләр. Бәбәйнең бармағын онға тығып алалар. Менә тәлинкәдә он була инде, бармағын тыга, шулай итеп, онға төшерми ул тырнағын. Ул онно сәдәхә итеп биргәлләр әбилеккә.* (Олыкыр)

***Бәбәй ашы, бәбәй қортлату*** – бала туу хөрмәтенә уздырыла торган чәй мәҗлесе. Күршеләр һәм кунаклар үзләре дә «бәбәй ашы» күчтәнәчләре белән киләләр.

*– Биш-алтыны тапсалар да, бәбәй қортлаталар хәзер. Күмәч, бәлеш, күлмәк-ыштан китерәләр.*

*– Бәбәй ашына да паштит, төш пешереп киләләр ийе, бәлешләр, гөбәдийәләр дә булды, сары май, күкәй белән.*

*– Қызы бәбиләгәч, әни кеше бер паштит пешереп, бәбәйгә күлмәклек, бер җурған, бер мендәр тотып, моноң хәтле төйөнчек белән килгәлләр. Аннан сун инде бәбәй ашы итеп, күрше-күбәләрне җыйып чәй эчкәлләр. Қызнын әнисе китерә кийәү өйөнә бишеген-нийен. «Бәбәй ашына шул көнне килерсегез, әни дә килә шул көнне», – дип чақырғаллар.* (Портянур)

***Бишек, бишек тирбәтү:***

*– Киндердән бишек тегәсен, бишек эләсен, чыбылдық қорасын. Җыласа, бишеккә саласын.*

*– Әwәле бишектә үстеләр бәбәйләр. Бишек тирбәткәндә тақмақлап утыралар инде әбиләр:*

*Қызым, қызым, қыз кеше,*
*Қызыма килер йөз кеше.*
*Йөз кешенең арасыннан*
*Алып китәр бер кеше.*
*Сары-сары, сап-сары,*
*Сары күке баласы.*
*Сары булса да җарасы,*
*Қарасын, қайдан аласы.* (Портчара)

*– Йаратып бағып үстерделәр баланы. Ағач сиртмә булыр ыйы.*

*Аллаһу, аллаһу,*
*Кәҗәләрне тауға қу.*
*Кәҗә талны кимерсен,*
*Улым йоқлап симерсен.*
*Әлли итәр бу бала,*
*Бәлли итәр бу бала,*
*Әлли-бәлли итә торғач,*
*Йоқлап китәр бу бала.* (Купай)

***Бишекне артыш ағачына элү:***

*– Бишекне артыш ағачына, артыш тайағына элеп қуйғаллар. Җыласа, бишеккә салған. Қайдан апқайтқаллардыр инде ул артыш ағачын әтиләр.* (Олыкыр)

***Бишеккә изге йазулар салу*** (җен-пәри килмәскә):

*– Искечә, қәдимчә йазылған китапны мендәр астына салып җоқлатыр ыйык, шулай бәбәй бишегенә салыр ыйық «җен килмәскә». Бишек тирәсенә қайчы, пычақ қуйар ыйық.*

*– Бишеккә мендәр астына, җен-пәриләр килмәскә, доғалар салғаллар.*

*– Әлпине, Әбҗәтне, Айателкөрсине җазған җазуларны баланың мендәр астына салғаллар.* (Мазарбашы)

***Бишек, миләш сиртмә, чыбылдық:***

*– Ағач бишек ийе, миләш сиртмә эләрләр ийе. Чыбылдық йасарлар ыйы бишеккә бик матур иттереп.*

*– Миләш сиртмә қуйып, бишекне шул миләш сиртмәгә асып, бәбәй тирбәтәләр, сәкегә йақын эләләр. Бәбәй йыласа, бау қуйасын да тәпи белән тирбәтәсен.* (Купай)

***Сәке өстендәге бишек:***

*– Элек сәкейе ич инде. Сәке өстендә бишек сиртмә белән. Миләш агачыннан сиртмә, дип әйтәбез. Шунда тирбәтә торган ыйық.*

*– Мин үзем кечкенә булгаммын. Бәбәй җылап уйанса, бәбәйне бишегеннән алыр ыйым да үзем кереп утырыр ыйым бишеккә. Ул йаман әйбәт тирбәлә торган ыйы, бишек. Бишекнең төбенә таза киндер теккәлләр.* (Бәрәңге)

***Бәбәй арбасы:***

*– Бәбәй арбасын, чәчәкләп, фанирдан җасыйлар ыйы. Анын шаршаwы буладыр ыйы, чыбылдык, дип җороп җуйарлар ыйы чебелләр килмәскә.* (Олыкыр)

***Бәбәй арбасында баланы җырга алып йөрү:***

*– Бәбәй арбасы белән тартып барабыз баланы. Ул шунда сослон төбөндә торор ыйы, бәбәй арбасы. Җылый башласа, барасын җанына, җоҗлый ул бала җырда. Әбиле кеше булса, җалдырып китәдер ийек өйдә, дәүрәк балалары булса да җалдырам.*

*– Әwәле бишектә үстеләр бәбәйләр. Ураҗҗа, җырга барганда бәбәй арбасы булыр ыйы. Безнен әти бәбәй арбасын үзе йасый тоган ыйы. Бәбәй арбасына салып, бәбәйне җырга имезмәгә алып килә тогаллар ыйы, алып килә торган кешесе булса. Ә кешесе булмаса, үзе белән җырга алып китә бәбәйне.*

*– Килендәшләр булып та, бәбәйләрне басуга тартып җөрөр ийек, җабыҗ арбаларга салып, уттай ураҗ өстөндә. Мәмәйне чәйнәп, марлыга салып, имезлек йасар ыйыҗ. Аныҗ марлысы да булмады әле ул заманда.*

*– Бәбәй таптыма, ун көн тордыма, ураҗҗа чыҗтылар килелләр.* (Мазарбашы)

***Баланың кырыгы тулу:***

*– Җырыгы тулганчы, йалгыз җалдырырга йарамый, диләр ийе. Әле аныҗ баш астынамы, тәпи астынамы җайчы йә пычаҗ җуйып чыгып китәргә, дип әйтәләр ийе, бик ашыгыч чыгып китәргә туры килсә, «җен килмәскә».*

*– Менә бер җатын, җырыгы тулганчы, җалдырып чыҗҗан, туwар җарамага. Керсә, баласы ишек төбендә җата икән, җен алып китмәгән.* (Олыкыр)

***«Күз тимәскә» җуйыла торган әйберләр:***

*– Чын төймә, дип әйтерләр ийе, җалфаҗларына тегеп җуйырлар ыйы.*

*– Әзрәк башларына, баш түбәләренә өч кенә бөртек булса да тозлы сулар сибеп қуйабыз инде.*

*– Күз тимәскә, маңғайына қоромнар сөртөп қуйабыз инде.*

*– Миләш ағачы чыбығын әз генә итеп кисеп алып, қалфағына тегеп қуйабыз, беләгенә бәйләп қуйабыз.* (Куянавыл)

**Сөннәткә утырту.** – *Сөннәт бабай, Тәкә бабай сөннәткә утыртты. Шәйхетдин бабайны «Тәкә бабай» дип әйтерләр ийе. Ул үлгәченнән, сөннәткә аның қызы утыртты, Wәгыйзә утыртып йөрде. Ул сөннәтли торған қатын бик җөрәкле қатын ыйы.*

***Баланы кистерү, печтерү, сөннәтләү:***

*– Печтергән, кистергән, сөннәтләгән, дип әйтәдер ийек. Сөннәт балаға озон күлмәк кидертеп қуйарлар ийе, алар чаwып йөриләр ийе шул озон күлмәктән. Ағач череге сибәләр икән. Мин үзем әзерләп қуйдым ағач череген. «Сөннәт бабай килгән, бүген печәләр, кисәләр», дип шөйләшкәлләр».* (Мазарбашы)

*– Балаларны «печтерү» дип әйтәләр ийе, сөннәткә утырту инде, бабайлар җөрдө. Очон исеп ала да қайтара да қуйа печтерүче. Сәдәхәне ала да чыға да китә.* (Куянавыл)

*– Минә балаларны бальнискә алып барып печтерү булмады. Бер әди җөридер ийе шул эшкә, әби печте балаларны. Әп-әйбәт кенә тазардылар.*

*– Бүрәнә башыннан сары черекне аладырыйық та, бик әйбәтләп қыл иләктән илидер ийек. Ул бик әйбәт, йомшақ булып, сары ғына булып қала. Шуны сибәдер ийек. Бернинди дару эзләп йөрмәдек без аңға. Андары шул қутырлый башлағачын,майлыйсын да тағы шуны сибәсен.*

*– Тушы Мазарбашынын малайы бар ыйы, чат дүрт йәшендә печтердек шуны. Ике көнгә дә бармады, чабып җөри башлады, балам. Кистергәченнән, балаға үзебезнен йүпкәләрне кидертеп қуйдырайық, йә озон күлмәк, қыршылып йөрмәскә.*

*– Минә бер малайны дүртенче кыласка уқырға кергәч печтердек, икенчесен дә шулай йәнәшә печтердек.* (Мазарбашы)

***Мулла иту*** – сөннәткә утырту.

*– Баланы мулла итәрләр ийе дә, күрше-күбә күкәйләр буйап кертерләр ийе, малайны қортлап.* (Яңавыл)

**Аш-сулар**

***Табақлық, идән табақлығы:***

*– Элек идәнгә табын җәйеп аш итәләр ийе, идәнгә табақлық әзерлиләр ийе. Ул идән табақлығы бик иркен булыр ыйы, өйнең буй-ыннан-буйына.*

*– Кругум әйбер салалар утырырға.*

***Шақмақлы қызыл ашаулық җәйү:***

***Турба*** – калын итеп сугылган киндер тукыма.

*– Идәнгә башта турба җәйәләр. Турба ул қалын киндер җебен-нән була.*

***Көрпә, көрпәчә*** – корамалардан тегелгән, аска салып утыру өчен әзерләнгән әйбер.

*– Андары турба өстенә көрпәләр-көрпәчәләр җәйеп утыралар ыйы. Шулай көрпәчә тегәрләр ийе табақлық әйләнәсенә салырға. Бүкәлләргә дә көрпәчә салырлар ыйы.*

*– Шулай җәймә-ашаулықлар, қызыл ашаулықлар суғарлар ыйы табақлыққа җәйәргә.*

***Алтастымал*** – табында тезелеп утырган кешеләр алдына салу өчен әзерләнгән, озын итеп сугылган тастымал.

*– Кеше алдына салырға алтастымал суқтылар.*

***Ағартып қуйған сары самаwыр,*** *әкәли* (чыршы күркәсе) *салып самаwыр қайнату:*

*– Табақлықта ағартып қуйылған сап-сары самаwыр. Берәр чиләк су сыйа самаwырға. Дөнҗа күмерләр китәдер ийе. Әкәли дә җыйадыр ыйық шунда самаwыр қайнатырға дип.*

***Зур ағач табақ, тоқмачлы аш:***

*– Уртаға зур ағач табақ қуйып, ашны, тоқмачлы ашны табын рәтен белүче берәү салып-салып бирер ийе.* (Олыкыр)

**Туй ашлары.** ***Туй күчтәнәчләре. Ризык белән килү***:

*– Туйға қода-қодағыйлар йегетнеке дә ризық белән бара, қызнықы да ризық белән бара.*

***Қодағый күчтәнәчен кисү:***

*– Туйға барғанда қазы булса – қаз алып бара, қазы булмаса – ит алып бара, ике күмәч, җә җуқа алып бара. «Қодағый күчтәнәче» дип, андары кисәләр.* (Бәрәңге)

***Бал-май:***

*– Бал-майларны матур итеп қуйалар. Тәлинкә уртасына бал, қырыйларына атлан май турап қуйыла.*

*– Таш тәлинкә уртасына – бал, қырыйына май қуйырлар ыйы шулай.* (Портянур)

***Бал-май, төш, паштит:***

*– Туй булғанда иң алдан паштит белән бал-май чыға. Аның артыннан төш чыға. Өстәлдә әле бүтән нәстә булмый.*

***Бал-май, төшне қотлату:***

*– Баллар-майлар, паштитлар, төш ин алдан қуйыла да, шуңға қотлап ақча йә бүләк салалар ыйы. Ул ақчаны пуднусқа салып баралар да ул пуднусны чығарып бирәләр аш йағына.*

*– «Әйдә, аwыз итегез туй бал-майы, туй төшләреннән», – диб әйтәләр дә, әммә кеше шуларны қотлап, йә ақча, йә бүләк сала иде шунда, өстәлгә.* (Куянавыл)

*– Шулай өстәлдә бал-май була. Бөтен кеше қашықны қуйғачыннан, иң элек җегетнең әтисе белән әнисе бүләк сала. Шулай бөтен кеше қашықны қуйа, бөтен кеше, бал-майны қотлап, бүләк сала.*

*– Менә бер йаман қызық кеше бар ыйы Мазарбашында. Шулай алдан бал-май, паштит, төш чықты да аннан аш чықты. Менә бу әйтте дә салды ич: «Аллаға шөкер, инде моносына ақча кирәкми», – дип. Бөтөн кеше рәхәтләнеп көлөштек.* (Мазарбашы)

***Төш пешерү, төшне табынға бирү:***

*– Төшне пуднусқа салып, табақлыққа чығарып қуйалар, шуңға ақча салып аwыз итәләр. Аны, җыйып алып, сандыққа салып қуйалар, қунақлар килгәндә генә чәйгә қуйарлар ыйы.*

*– Төшне күкәйгә генә басып, wақ қына чумар шикелле итеп түгәрәкләтәләр дә шуны майда пешерәләр. Тоқмач қамыры күк җәйә дә пешерә. Қунаққа да пешерә, бәйрәмгә, туйға да.* (Бәрәңге)

– Т*өш пешереп, бер путнус төш қуйарлар ыйы. «Төшне қотлап, ақча саласы», дийәрләр ийе туйға килгән кешеләр. «Моно белеп ашағыз, бу – ақчалы әйбер», – дигән булырлар ыйы. Төшне күп пешерерләр ийе. Аны умарта балына туғылап, чәйгә салып эчәрләр ийе төшне.*

*– Төшкә кампасилар тезәләр, үрнәкләп-үрнәкләп.* (Портянур)

***Паштит*** – өстенә повидло яки җиләк-җимеш җәеп пешерелгән ачык бәлеш.

*– Туйға барғанда ике паштит, моноң бийеклеге. Паштитны, үрнәкләр йасап, қабартып пешерәләр, өстөнә павидла йағалар. Паштитны қызыл ашаулыққа төрөп алып баралар туйға. Қыз*

*энисе паштит алып килә. «Қодағыйның паштиты бик уңған», – диләр.* (Олыкыр)

***Йуқа / җуқа*** – йомырка сытып камыр басып, аны юка гына итеп җәеп, табада майда пешерелгән ашамлык.

*– Йуқа, дигәне күкәйдән генә була. Йуқаны бик йуқа итеп җәйәләр. Әчедән түгел ул, төчедән. Андары майға салып пешерәләр. Ул қабара, бик матур булып пешә, бик кадерле нәстәйе ул йуқа.* (Яңавыл)

*– Ун җеп йуқа, унике җеп йуқа, дип шөйләшерләр ийе. Бер җеп – ул ике йуқа була инде. Қызны биргәч, туйға барғанда унике җеп җуқа, дигәлләр. Унике җеб ул җегерме дүрт җуқа була инде. Күкәйгә генә онно туғылап, бик җуқа ғына итеп җәйеп пешерерләр ийе мич қаршысында.*

*– Әнеки минем пешекче булып йөрде. Туйларға гел йуқа пешерер ийе. Қазан астына йағып, қазан төбенә май салып, шуны қулы белән генә әйләндерер ийе. Ничек қулы пешмәгәндер аның. Ул, җеп йуқа пешердем, дип сөйләр ийе* (Искеавыл).

*– Җуқаны ун күкәйгә басасын. Бер күкәйдән бер пар чыға. Җәйәсен дә шуны майда пешереп аласын. Шуны бергә парлап қаплыйсын, ꞷатылмасқа иләккә салып барасын. Ꞷатылмасқа паштит өстенә қуйып бардық, қодағый булып барғанда.*

*– Җуқа җанына қура қағы да қуйалар матур итеп кисеп. Чәй җанына қуйа, бал-май ашарға җуқа қуйа.*

*– Җуқа ул бик қадерле аш булды элеке, туй ашы булды. Ару күкәйгә, майға ғына пешерәләр аны.*

*– Менә шундый қызықны сөйләрләр ийе. Бер кийәү әбиләренә кийәүләмәгә килгән. Җуқа пешереп қуйғаллар. Кийәү ашый да ашый икән. Әби әйткән: «Кийәү, җуқа ул, җуқа», – дигән. «Җуқа икәнен беләм мин. Шуңға күрә бөкләп ашыйм мин аны», – дип әйткән, ди, кийәү.* (Мазарбашы)

**Ипи пешерү. *Ипи башы қамыры қалдыру, ипи изү:***

*– Ипи башы қамыры қалдырабыз ич, он эченә тығып. Шул ипи башы қамырын суға изеп, он белән болғатып қуйабыз, кичтән шулай ипи изеп қуйабыз. Ул әчеп утыра иртәнгә хәтле.*

*– Чүпрә салу җуғ ыйы, чүпрә дә булмас ыйы. Күәс чиләге төбендә әз генә қамыр қалдырыр ыйық, ипи қамыры. Шул әче қамырны, җылы су белән җебетеп, тағын қамыр әчетер ийек. Туғылап қуйар ыйық он белән. Ул, әчегәч, чепер-чепер килеп утыра ич инде. Шуны он белән басып, тағын қабартыр ыйық.*

*– Ике кибет ипийенең эчен алып, җылы суга изеп, он белән тугылап қуйасын, тиз әчидерийе, тиз қабарып менәдер ийе.* (Куянавыл)

***Ипи басу, куас чиләге:***

*– Иртә белән тороп, тугылап-тугылап, өйдә җылынып торган онно салып, басасын инде ипине әйбәтләп. Бик қаты тыгызламыйча гына. Ул куас чиләге қабарып тула шушындый булып.*

***Ипи әwәләү:***

*– Куас чиләгендә ипи қамыры қабарып тулу белән, мичкә утын йагасың да, йастық салып, аның өстенә ару җәймәңне җәйеп, ипиләрне болай-болай кечкенә генә итеп әwәләп қуйабыз, ом белән әwәлибез. Ул менә шундый матур булып қабара, шул йастыққа җәйгән җәймә өстендә.* (Олыкыр)

***Мич төбе, мич пумаласы, ипи көрәге:***

*– Андары мич төбен мич пумаласы белән себереп, ипи көрәге белән мич төбенә салабыз. Он белән әwәләгән көйөнчә, ипи қып-қызыл булып қызарып қына, матур булып қына пешәр ийе.*

*– Мин, мендәрләргә ақ җәймә салып, шунда әwәләп сала торган ыйым. Мич йанып торганда қабарып менә торган ыйы. Андары мич төбен пумалалап, себереп, көрәк белән салыр ыйық ипине мич төбенә. Өй ипийен пешереп саласын өстәлгә, исләре чыгып тора. Ул ипи белән чәй эчмәле дә тәмле.* (Купай)

**Ипи камырыннан пешерелә торган ашамлыклар. *Ипи чумары*:**

*– Әче қамыр алып қалыр ыйық та ипи пешергәндә, чумар ашы пешерер ийек. Аны «ипи чумары» дип әйтәбез, борчақ та салабыз.* (Искеавыл)

***Ипи табикмәге, таба ипийе, таба икмәк:***

*– Шул ипи әwәләгән wахытта, ипи қамырын әз генә алып, майлаган табага салабыз, бармақ қалынлыгы гына иттереп. Ул шунда табада қабарып утыра. Қабарып менсә, аны мич қаршысында йалқында пешереп алабыз, ул тиз пешә. Сары май белән майлап та җибәрсәң, аннан да тәмле ризық җуқ дөнҗада. Хәзер дә бик қызыгам, түлке хәзер ипи пешерү дә җуқ, андарысын симийә дә җуқ.* (Куянавыл)

*– Мичкә йагып, ипи салырлар ыйы, тәбикмәк пешерерләр ийе, ипи тәбикмәге, дип. Аны әйбәтләп майларлар ыйы, зерә тәмне булыр ыйы ул. Ул ипи тәбикмәге пешкәч, тизрәк безне җыйып утыртып, чәй эчертер ийе әле әни: «Саwаплы ризық, әйдә, ашагыз», – дип.*

*– Таба икмәге пешерер ийе әни иңгелек. Ипи пешеп чыққанчы чәй эчегез әле, дип. Аны әйбәтләп майлап, тәмләп чәй эчәр ийек.* (Портянур)

*– Табипийе, дип, табикмәк, дип, табаға салып, мич қаршында пешереп алырлар ыйы. Аны майлап ашар ыйық.*

***Хәйер икмәге:***

*– Хәйер икмәге, дип, бер кечкенә ипи салып пешерәбез, аны абыстайға хәйер итеп бирәбез.* (Бәрәңге)

***Күмәч*** – ак оннан пешерелгән икмәк.

*– Туйға җегет җағыннан ике күмәч бара. Ике күмәч тә җуқа бара.*

*– Җуқаны күмәч өстөнә салалар. Икене бергә салалар да урталай бөклиләр, дәү пуднусқа қуйып, ашаулық белән төрә андан ары.*

*– Табында бер күмәчең артып қала икән, аны табаққа салып, өстен қаплап, идән астына төшөреп қуйалар.*

*– Күмәч салучы аwылда бер атақлы була.* (Мазарбашы)

***Тышлы тәйекмәк*** – төче камырны юка гына итеп җәеп пешереп алгач, өстенә солы оны яки манный ярмасы тугылган катык ягып, тагын бер кат мич каршында ялкында пешереп алалар.

*– Килен булып килгәч тә, тышлы тәйекмәк йасап пешердеп. Иртән иртүк торып, шулай тышлы тәйекмәк ашаттым.*

*– Мин тышын җәйдем, мичтә пешердем, әнеки эчен йасады, майлап утырды пешкән тышлы тәйекмәкне. Йаман тәмле булды. Тышлы тәйекмәккә қатық кирәк. Қатық ойоталар да, ул қатық булғач, бер көн торорға кирәк. Әз генә әчкелт тәм кергә. Шуңа май атлағачыннан, май туртасы салып җибәрәсен эченә. Андары шуңға соло оно, әзерәк кенә манный туғылыйбыз. Теге җәйгән күзикмәкне пешереп алабыз да шул әзерләп қуйған туғылаған қатықны өстөнә җәйәсен, әлеге сыйық қамырны. Ул йанып торған мич алдында пешә.*

*– Килен килгәч, иртәгесен ул шуны пешереп баға. Атланмайны эретеп майлыйлар. Шулай ич, Нурзада? Шул тышлы тәйекмәкне сағынабыз әле дә.* (Портянур)

*– Тышлы тәйекмәкне әле дә пешерәм мин. Төчө қамырны җәйәбез дә, күзикмәк күк итеп, табада пешереп алабыз.*

*– Шул күзикмәк өстөнә эчлек йағабыз. Эчлеккә кирәк була қатық. Қатыққа соло оно, әз генә манный қушып туғылыйбыз.*

*Шул сыйық эчлекне күзикмәк өстөнә йағабыз да тағын мич қаршында йалқында пешереп алабыз. Теге эчлек қызарып киткәч алабыз. Хәзер инде духовкада да пешереп була.* (Яңавыл)

***Күзикмәк:***

*– Күзикмәк ул гел күкәйдән генә булмый, аңға, күзикмәккә, қамырына әзерәк сөт қушабыз.* (Купай)

***Бийек бәлеш:***

*– Әwәле бийек бәлеш булыр ыйы ул. Қашық белән ашарлар ыйы.*

***Бәлеш барнағы*** – бәлешнең кисеп өләшенә торган өске капкачы.

*– «Бәлеш барнағын кисегез инде», – дийерләр ийе. Шулай табақлықта бәлешнең өске қапқачын кисәләр дә, бер өч барнақ илле итеп кисеп, кеше алдына қуйалар. Бәлешен дә уртаға қуйып, берәр-икешәр қашық салалар, май сибәләр.*

***Бәлеш ирнәwе*** – бәлешнең бөргән җире.

*– «Бәлеш ирнәwе», дип, өске бөргән җҗирен кисеп, бәлеш өстөнә тезеп чығарлар ыйы. Өләшәләр аны, бәлеш ирнәwен.*

*– Бәлеш ирнәwен алып қайтып, балаларға бирәдер ийек.*

***Бәлеш төбе:***

*– Бәлеш төбе – иң тәмле җҗире. «Бәлеш төбе – қызлар теле» дигәлләр. Кисеп өләшәләр, әз-әз генә итеп.*

***Бәлеш бөкесе*** – бәлешнең өске капкачында була, шуннан шулпа салып җибәрәләр.

*– Бәлеш бөкесен малайларға бирәләр. «Мә, балам, бөкесен ашасаң, бийүче буласың», – дийерләр ийе.*

***Қабақ бәлеше:***

*– Қабақ бәлеше – даллықлы бәлеш. Өстә бөкесе дә була. Әзерәк шулпа салып җҗибәрәләр, парланып пешсенгә.* (Олыкыр)

***Балан бәлеше:***

*– Баланны суға пешерәсен дә, шуңға арыш оно туғылыйбыз да төчетәбез. Балан бәлеше пешереп қуйам, исләре китеп ашыйлар.*

*– Баланны су белән пешерәсен дә, андары шуңға арыш оно туғылыйсын. Хәзер арыш оно да җуқ, куас оно туғылыйбыз. Менә шул балан бәлешен пешерәм, бик җҗараталар гурттан қайтучылар.* (Купай)

***Күкәй бәлеше:***

*– Күкәй бәлешенә унике күкәй уwалар, қорт җҗәйәләр төбөнә, ақ май җҗәйәләр. Дөгө белән күкәйне қатнаштырып салалар.*

*– Күкәй бәлеше дәү таба белән була. Күкәй бәлешен хәзер гөбәдийә диләр.* (Мазарбашы)

***Бөккән:***

*– Қабақ бөккәлләрен бик җараталар аш иткәндә. Чөгөндер бөккәлләре, кишер бөккәлләре дә пешерер ийек қыш буйынча. Сөт күп булған чағында эремчек бөккәлләре пешерер ийек.*

***Сумса*** – вак бөккән (пирожки).

*– Сумсаны бик оста пешерерләр ийе. Берәү әйткән: «Мин қырық сумса ашый алам», – дигән. Шул кешегә қушамат бирделәр, «қырық сумса», дип.* (Портянур)

***Белен:***

*– Беленгә қамырны сыйық қына итеп изеп қуйасын. Соло кибәген илисен, беренче қатында эреләре қала. Икенче қаты йармалы була. Менә шуны изәсен, ул кесәл шикелле була. Шуны андары туғылыйсын сыйық итеп. Җартышар күәс чиләге итеп әчетәләр беленне. Шуны андары табаны майлап җибәрәләр дә қызу күмер өстөндә пешерәләр. Әз генә қырыйлары күтәреләә башлағач та пешкән була ул. Тәлинкәгә қуйған wахытта дүрткә бөклисен. Шуны йә сөт белән, йә қаз ите шулпасы белән ашыйлар.*

*– Килен булып килгәч тә тиз генә белен пешермәгә қушқаллар чәйер утыны белән.* (Мазарбашы)

***Қазылық:***

*– Элек атны күп асырар ыйық. Килелләр қазылық тутырырлар ыйы ат итеннән.* (Куянавыл)

***Пичкә йағу:*** утын, әрем, салам һ.б.ны якканнар.

*– Пичкә җағып, қамыр ашлары пешерү ийе.*

*– Тәйекмәк-қоймақ. Пешерсәләр, «шыртлый торған утын алып кермә, қайын утыны алып кер», – дип әйтерләр ийе.*

*– Әремгә хәдәре җақтық пичкә. Мондый җуан әремнәр дә була ич инде. Шул әремнәрне, көлтә итеп бәйләп, тезеп-тезеп қуйарлар ыйы.*

*– Саламны хайwанға салабыз, хайwаннан қалғанын көлтә-көлтә итеп бәйләп қуйабыз. Иллешәр көлтә бәйлим мичкә йағарға. Салам көлтәне йағып җибәрәм, ут қаба, йана, төртеп җибәрәсен дә тағын икенчесе әзер тора. Чөгөндер бөккәлләре, кишер бөккәлләре пешерерләр ийе шул салам җаққан пичләрдә.* (Олыкыр)

***Мичтә шалқан пешерү:***

*– Мичкә чуйын белән қуйып, шалқан пешереп ашар ыйық. Әни безнең чуйынға тутырадыр ыйы да шалқанны өстенә табаны қаплап қуйар ыйы. Су салмыйдыр ыйы. Шунда парланып пешәдерийе, шуны ашыйдыр ыйық. Шул пешкән шалқанны тышқа чығарып суытадыр ыйық. Бик тәмле булыр ыйы ул, парланып пешкән шалқан, эркелдәп кенә пешәдер ийе, парланып. Инде мич йағарға туры килмәгәндә қазанда пешерәләр ийе. Нәстә бар, өстенә қаплый торғаллар ыйы, пары чықмасын, дип.* (Олыкыр)

## Авылларда мәгълүматлар бирүчеләр

***Бәрәңге:***

Габидуллина Гөлзифа (1954)
Гайфуллина Фәния
Гәрәева Әлфия
Саматова Нурания (1947)
Сафина Самавия
Сафуков Фоат Сафукович (1924)
Сафукова Оркыя Закировна (1930)
Шәрифҗанова Мәдхия (1925)

***Яңавыл (Ирнур):***

Галләмова Кәүсәрия
Лотфуллина Фәния

***Купай:***

Галимҗанова Мәрзия (1929)
Хәсәнова Гөлҗиһан (1931)

***Куянавыл:***

Газизова Дания (1940)
Мәүликова Рәмилә
Фәйзерахманова Гөлфия
Хәбибуллина Зәкәрия
Шәрәфетдинова Гөләүһәр
Шәрифҗанова Оркыя

***Мазарбашы (Алашайка):***

Әүхәдиева Фәгыйлә (1918)
Әхмәтханова Мәмдүхә
Габдерахманова Нәгыймә
Габдуллина Сәрия
Гайнетдинова Мәнфүсә
Гарипова Нәсимә
Закирҗанов Рәхимьян

Зәйнуллина Рәхимә
Нигъмәтҗанова Хәнифә
Нуруллина Зәкия
Сәгъдуллина Рәйсә
Тәминзәрова Мәрҗәнә
Фатыйхова Кәүсәрия
Шәрипова Кәүсәрия
Шиһапова Хәнифә

***Олыкыр:***

Вафин Зөлкәфир (1932)
Габдерахманова Зөлкәгъдә (1938)
Фәйзерахманова Рәхилә (1931)
Шәйхетдинова Кәфия (1937)

***Портчара:***

Йәмилова Хафиза (1927)
Йәмилова Фәүзия (1941)
Вәлиева Сабира (1924)
Вәлиева Салиха (1924)
Гайфуллина Зәкия (1925)
Гайфуллина Рафия (1966)
Фәхриева Нурдидә (1927)
Хафизова Бибидания (1926)

***Портянур:***

Габдуллина Фәрваз
Габдуллина Сара
Гайсина Мөкәррәмә
Каюмова Фидания
Мөхәммәтханова Мөкәррәмә
Мөхәммәтханова Нурзадә
Нәзирова Мөнирә
Шәйхетдинова Гөлсем
Ситдыйкова Гөлсылу
Әхмәдуллина Фәния

***Искеавыл (Таштоял):***

Хәмидуллина Шәргыя
Хәмидуллина Зинаида Леонидовна

# МИЛЛӘТНЕҢ КҮҢЕЛ САНДЫГЫ

*Алсу Низаметдинова*

*«Искеләрдән гыйбрәт ал, яңаларга нигез сал».*
Татар халык мәкале

Заман үзгәрә, кешеләр үзгәрә... Бүгенге көн иртәгә инде тарихка кереп калыр... Традиция сакланырмы, әллә онытылырмы?.. Киләчәк буын үз балаларына нәрсә тапшырыр?..

Бу сораулар бүген күпләрне борчый. Шуңа күрә дә әлеге тема, минемчә, һәрвакыт актуаль. Һәр кеше үз халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, телен белергә тиеш. Югыйсә, башка халыклар арасында ул милләт вәкиле буларак югалып калачак.

Бәрәңге районы татарлары марилар һәм урыслар белән тыгыз аралашып яши. Шулай да алар үз телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, гомумән, халык авыз иҗатын борын-борыннан бүгенгә кадәр саклап килә алган.

Бәрәңге районына оештырылган комплексны экспедиция вакытында элек-электән килгән ышанулар, төрле ияләр, җеннәр турында кызыклы гына хикәятләргә тап булдык. Өлкәннәр безнең сорауларыбызга бик иркенләп җаваплар бирделәр, кызыклы хәлләр сөйләделәр.

*– Сез йорт ияләренә ышанасызмы?*

*– Йорт ийәләре бар, бар, булырга тийеш, алар, йорт ийәсе дә булырга тийеш, абзар ийәсе дә булырга тийеш. Абзар ийәсенә әйтеп кереп китәдер ийек: «Балам, хайваннарымны сакла, хайваннарымны кара». Сыйырларны чиген саклаганда да, абзар ийәләре, булышыгыз инде, балам, дип. Бар алар, исән алар. Йортныкы да.*

*– Ә йортныкына нәрсә дип әйтәсез?*

*– Йортныкына инде менә догалар укыганда укыйбыз ич инде йатканда догалар. Йә, Рабби, Аллам, нигез хуҗасы Карашман батырның хушнут агачлы булсын. Хушнут агач ул шундый ире. Хушнут агачлы булсын, дисәң, тере ут, шуңа аңа да барып җитә. Шимбә көннәрдә, бигрәк тә, шул йорт хуҗаларына, йорт ийәләренә, дип әйтергә кирәк. Андары чыгып киткәндә, өйдән чыгып киткәндә, җорт ийәләре, сезгә ышанам, йортымны саклагыз, дип әйтеп чыгып китәргә кирәк икән.*

*Яңавылда яшәүче Гайсина Сания*
*Хәбибрахман кызыннан (1932 елгы)*
*А. Низаметдинова һәм Э. Каюмова язып алды*

*– Олыкырда атлар фермасы бар ийе. Шунда, ни, әйтәләр ийе инде, Кәримә апай нийе ийе инде безнең, Кәримә дигән хатын ат карыйдыр ийе. Шул безнен җиңгиләр белән без өч семья тордык, дип әйтәм ич. Шунда иртә белән торышка атларның бөтен йаллараын үреп куйалар ийе, ди, ат өсте тир генә буладыр ийе, ди. Шул менә, ийе, шуларны көләгәч, шул ниләр инде, нәрсәле, йорт... конюшня, ат абзары ийәләре, килеп, шул йаратмаган атларны шулай чаптырып, нитеп, йалларын үреп куйа торган булганнар. Шул апай сөйлидер ийе, Кәримә дигән апай сөйли, конюх булып эшләде ул сугыш вахытында. Йал, атның йалларын, чәчләрен үреп куйалар ийе, дип әйтә. Аннан сон атларнын... атның өсләре ап-пак күбек буладыр ийе, дип әйтә. Менә шуны ишеткәнем бар.*

*– Абзарга кергәндә нәрсә әйтергә кирәк? Тамак кырырга кирәкме?*

*– Аны шулай диләр менә, өйгә кайтып кергәндә дә... Эһем-эһем дип... Мунчага кергәндә дә, әйе, мунчага кергәндә обязательно. Абзарга керәсезме, сарайга керәсезме, өйгә керәсезме... Анда йорт ийәләре булырга может. Ул йорт ийәләре йаратмаган кешеләренә генә күренәләр икән, йаратмасалар йортта торган кешене.*

*– Ә шул йорт ияләрен ризалаштырыр өчен, берәр нәрсә эшләгәннәрме?*

*– Эшләгәннәр. Безнең әби шулай итә торган ийе, менә шушы Хафизә әби, ул болай итә торган ийе: әгәр берәр нәрсә берәр җирдә берәр нәрсә эшләнсә инде, әби күргәнчә түгел, икенче төрле итеп, шуларга нигезгә, менә идән астына төшәдер ие дә, нигезгә ботка пешерәдер ийе, шуларга ботка куйадыр ийе, нигездә, идән астында вокруг, чокыр кырыйына. Менә шулай итеп, алар-*

*ны, теге, майлар... нитергә кирәк ийе инде, кыстарга кирәк ийе. Аны сөйлидер ийе әби.*

*Олыкыр авылында туган Сәмигуллина*
*Зәмзәмия Гыйният кызыннан (1939 елгы)*
*Бәрәңге авылында А. Низаметдинова язып алды*

*– Минем әни әйтә торган ийе, нигә, атны караган ул. Әти читтәрәк эшләп йөргән. Ат карарга кергәч, тагарак башыннан бер кара әйбер төшеп тә китте, йугалды да, ди. Шунда, төшкән җирендә йугалды, ди. Абзар ийәсе булгандыр инде ул. Мәче шикелле, кара мәче шикелле ийе, ди, шуна төшеп йугалды, ди... Аннан әтинең бик әйткәне бар инде. Ул бит гармунчы булган, авыл җегете булган... Нидә, түбән йак... Түбән Мазарбашы бар әле безнең тегендә. Шул Түбән Мазарбашында кызлар белә йөргән. Шунда, элек ул йөрү бик сәйер ийе ич, ирле хатын шикелле, ирле-хатынлы шикелле кыз белә җегет... Мин андый нәрсәләрдән бик читтә тордым... Әти таң аткач кына кайта икән кызлар йанынннан... Кайтканда тимерче алачыгы бар ийе нидә, түбән йакта, тимерче эшли торган алачык бар ийе. Шунда Петя дигән бер кеше, дусы эшләгән. Шул Петя йанына, карале, ут бар ич тимерче алачыгында, дип... Таң алдыннан инде бу. Петя йанына кереп чыгыйм әле, нишләп йата икән бу дип керсәм, ишекне тоттым да, йозак икәнне күрдем дә, ди. Ишектә йозак – эчтә кемдер эшләп йата, ди. Йук ул, йук әйбер инде, җен булган инде. Ай, саташтым ич мин, өйгә кайтып китәргә кирәк әйбәтләп, дип, аннан йырак түгел, монда – тимерче алачыгы, монда – күпер. Күпергә килгән дә, күпернең ике тоткасы барыйы, күпергә килеп тә кердем, ди, башыннан, кыңгыраулы атлар килеп тә чыктылар, ди. Күп кыңгыраулы атлар, ди. Туй нindидер инде, марый туйымы, урыс туйымы. Чын кешеләр түгел, пәри туйы, пәри чыккан. Шуннан, ди, бик читенсенеп кенә, һай, бер дә шәп булмады ич бу минем төнем, дип әйттем дә, ди. Әни әйтә, төнне йөрмәссен, ди. Ул инде, күп йыллар үткәч инде сөйли иде. Шуннан басып тордым, тордым да, ди, йактырып та китте, тегеләр дә йугалды, бетте, ди, аннан. Менә шундый... мин үземнең күргәнем йук йугын, ну бар икәненә ышанам андый нәрсәләрнең, җеннәрнең. Кем белә, әллә бар, әллә юк инде, әллә бер ышану гына.*

*Мазарбашы авылында яшәүче*
*Һадиева Гәүһәрия ападан (1928 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

Күз тигәннән бу як татарлары халкы күптөрле өшкерү ысулларын белә: төрле догалар, Коръән аятьләре, сүрәләр, «чынаяк язу», таң суы алу һ.б. Әлеге өшкерү ысуллары ислам дине белән кергән. Аларны, гадәттә, олы яшьтәге әби-бабайлар башкарган. Хәзер дә гамәлдә бу еш кулланыла.

Мәсәлән, *таң суын алу* буенча төрле авылда төрле вариант табылды.

Ирнурда:

*– Чәршәмбе иртәсендә иртүк торып, бер чиләк суны, өстенә бер тимер куйып, тышка куйасың да, таң суы шунда төшә. Шул таң суы төшкәннән соң шуны алып, безнең күршебез бар ийе, бер галим әби, Нәгыймә апай, үлде инде, мәрхүм. Аңа да бик киләләр ийе... кертеп бирәдер ием дә банкага гына салып. Әби шуны өшкереп бирә дә, шуны, теге, суга саласың да, мунчага кергәченнән, ләгәнгә генә койынасың. Суың анда-монда төшмәсен, өшкерелгән су. Аннан соң салган вакытта да йә агач төбенә, былчырак җиренә салмыйсың инде айак астына. Менә шулар белән әбиләр безне дәвалап торганнар инде, духтырга да йөрмәгәнбез.*

*– Аның өчен суны каян алырга?*

*– Су аласың, колонкаданмы... Койаш чыккансы. Бу – койаш чыкканчы иртүк, кичтән салып куйасың. Суны бер агач, ни, төбенәме инде, койашлар, таңнар төшә торган җиргә. Эчкә түгел инде, лапас эченә. Шунда бер аркылы, бисмилланы әйтеп, тимерме, агачмы куйасың да шуны өшкертеп эчәсең. Авызыңа да кабасың, башларыңа да тидерәсең, койынасың да. Койынган суны түлке җиргә бисмиллалап салып куйасың.*

*Яңавылда яшәүче Гайсина Сания*
*Хәбибрахман кызыннан (1932 елгы)*
*А. Низаметдинова һәм Э. Каюмова язып алды*

Мазарбашы авылында *таң суын алу вакытына* карата башкачарак фикер ишетелде.

*– Безнең йола да инде, тийешле дә була – таң сулары алып өшкерүләр, таң сулары белән койындырулар, алар бар. Таң суы иртәңге... менә ул таң суын алалар чишмәдән азаннын «Аллаһу әкбар» дип, бер авазын ишетү белән. Менә шул азан әйткәндә, әгәр дә ишетми икән инде, азаннын вахытын белеп, чамалап, шу-*

*лай итеп алырга тийеш таң суын. Менә таң суы дип әйтәләр, таң ата башлагачыннан алырга дип, ә инде галимләр әйтәләр азанның бер авазын ишеткәч тә таң суын алырга дип. Таң суы белән койындыралар кешеләрне, андый гадәтләр бар. Алар элек-электән килгән тужы. Сунын өстенә каплап куйасын, чтобы шайтанлар аңа нитмәсен, шайтанлар кул тыкмасын, шайтанлар авыз тыкмасын. Өсте каплаулы булырга тийеш... Син аны алып менәсен дә, өстен каплап... тегендә алып төшеп болай, тастымал белән каплап менсән дә бик әйбәт. Төнгә калдырганда сунын өстен һәрвахытта да каплап калдырырга кирәк, эчә торган суларныкын да. Суны чишмәдән алырга. Ә инде менә хәзер краннар бар ич, әгәр дә чишмә күзе җуг икән, аннан алырга... зарурый нәрсә була икән, моннан алырга рөхсәт ителә. Бераз кранн*ы әчеп агызып торгызасын да шуннан аласын, рөхсәт ителә.

*Мазарбашы авылы мулласы Нигъмәтҗанов*
*Мөхтәр Мөхәммәтҗан улыннан (1938 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

Күз тиюдән чынаяк язып өшкерү (*«чынаяк язу»*) шулай ук бик популяр булган. Ул болай башкарылган: зәгъфранны суда җебетеп, язу карасы кебегрәк саргылт-кызыл сыекча ясыйлар, шуңа каләмне манып, чиста тәлинкәгә берәр сүрә язалар («Аятел көрси» һ.б.). Аннары әлеге язуны су белән чайкап, шул суны эчәләр.

Гадәттә, балаларга еш күз тия. Ата-ана күзе тисә, китмәс, ди мәкаль. Бәрәңге татарлары баланы өшкергәндә түбәндәге ырымнарны куллана.

*– Бала тугач, чәчне алмыйлар ийе. Ир балаларның чәченме, кыз балаларныңмы инде, шул чәчне җыйып куйалар ийе дә, бераз гына кисеп алып баланың, шул унсигезгә җиткәнче дип җыйып куйалар ийе шул чәчне, гомерле булсын, дип. Менә анысын точно беләм. Ә күз тимәсен өчен тагын менә монда җыйын матур нәстәләр йабыштыралар ийе, тегәләр ийе, миләш... миләш тегеп куйалар ийе. Аннан мускатный орех буладыр ийе әүвәл, нәрсә булгандыр инде ул, шуны кендек менә... эч авыртса, шул мускатный орех белән өшкөрәләр ийе. Өшкөрүче әбиләр бар ийе.*

*Олыкыр авылында туган Сәмигуллина*
*Зәмзәмия Гыйният кызыннан (1939 елгы)*
*Бәрәңге авылында А. Низаметдинова язып алды*

Халык миләш агачын гайре табигый көчкә ия дип ышанган. Ә аның бер кисәгеН яки башка әйберне, күз тимәскә дип, киемгә тегеп кую «каты күзле»ләрнең кешенең тышкы кыяфәтенә соклануын шул тегеп куелган әйбергә юнәлтә, дигән ышану булган һәм ул хәзер дә бар.

Күп кенә кеше, төрле сихердән, тормышындагы күңелсезлекләрдән ярдәм сорап, багучыларга, күрәзәчеләргә мөрәҗәгать итә. Әмма татар халык мәкальләренә килсәк, халыкның элек-электән андый «ярдәм итүчеләргә» карата тискәре мөнәсәбәте билгеле. Бу, әлбәттә, халык тәҗрибәсе белән аңлатыла: «Күрәзәгә ышанма, күргәнеңә ышан», «Димче диңгез кичерер, багучы өйдәняздырыр», «Багучыга барма, башыңа кайгы алма» һ.б. Ләкин шулай да багучы-күрәзәчеләргә ярдәм сорап бару бүгенге көндә дә еш күзәтелә.

Әлеге төбәктә календарь йолалар, гаилә йолалары һәм дини йолалар турында да мавыктыргыч итеп сөйлиләр.

***Календарь йолалар:*** бәйге җыю, сабан туе, арбалы җыен, чөгән атнасы, карга боткасы, каз өмәсе, нәүруз һ.б.

*Чөгән атнасы* дигән йола сирәк авылда очрый. Әмма безгә бик кечкенә генә Таштоял (Искеавыл) авылында әлеге йола турында сөйләделәр.

*– Буладыр ыйы сабан туйы. Аннан буладыр ыйы арбалы җыйын. Ә менә бу сабан туйы безнең элекке исем белә арбалы җыйын. Андары, андары буладыр ыйы йә синтәбер айында чөгән атнасы. Чөгән атнасы дип йөриләр ийе инде аны.*

*– Ул чөгән атнасында нишләгәннәр соң?*

*– Менә чөгән дип сөйләшәбез ич, ийие? Менә шуны йөриләр ийе инде чөгән атнасы дип. Көз көне була, ийе... Ураклар беткәч буладыр ийе инде ул, менә мин чат итеп сиңа хәзер вакытын...*

*– Аннан алдагысы арбалы җыйын була инде...*

*– Ийе, арбалы җыйын. Менә анысы инде сабан туйыннан соң буладыр ыйы, чәчүләр беткәч, ниткәч, эшләр җыйылгач, арбалы җыйын буладыр ыйы... Сабан туйы чәчүгә хәтле буладыр ыйы, йаз көне.*

*– Чөгән атнасыннан соң нәрсә булган?*

*– Чөгән атнасыннан сун андары йаңга йылга хәтле бернәрсә булмыйдыр ийе. Әле генә чыкты әле ул менә Уктәбер бәйрәмнәре, ниләр. Ул Сәбит бәйрәмнәре.*

*– Чөгән нәрсәне аңлата ул?*

*– Менә агач кайырысы белә агач үзәге арасында йүгеш су буламы? Менә шуны йөриләр инде чөгән дип. Менә шушы, әйе, чөгән атнасы менә шул заманда була икән ул. Менә шуңа күрә әйтеп йөриләр чөгән атнасы дип... Агачның менә кабыгы белә ни арасында булган йүгешне әйтәләр инде чөгән дип.*

*– Ул чөгән атнасы Таштоялда гына буладыр идеме, башка авыллар да катнашканмы?*

*– Катнашадыр ийы, менә Йаңгавыл, Портйанурларда аны бик зур итәләр ийе. Алар патамышты урманга йакын, кара җиләкләр, кура җиләкләр шуларда ийе инде, шунда барадыр ийык.*

*– Шушы өч авыл гына катнаша идеме?*

*– Без тушы өч авыл инде менә... Куйан авылы, Мазарбашы, без, Купай, Патчара – без бер силсәвит инде.*

*– Ә ничек итеп бәйрәм итәләр иде?*

*– Ничек итеп тиб инде, бер-берсенә кунакка йөрөшәләр инде, андары йәшләр, күбрәген йәшләр йөридер ийе инде, безнең шикелле картлар түгел. Бөтөн иренмәгән кеше катнашадыр ыйы.*

*– Аның сабан туеннан аермасы нәрсәдә булган соң?*

*– Ул бит инде бөтөн урожайларны, ниләрне, бөтен байлыкларны җийып алган ни була ич инде ул, атна.*

*– Көз көне ич инде.*

*– Ийе. Ул бик зур бәйрәм ийе, кешене канәгатьләндерә торган.*

*Таштоял (Искеавыл) авылында туган Шәрифьянов*
*Мөбарәк агадан (1929 елгы) М. Әхмәтҗанов,*
*Д. Рамазанова һәм А. Низаметдинова язып алды*

***Гаилә йолалары:*** кыз урлау, туй, бәби туе (бәби котлау), бәби мунчасы (өч мунча) һ.б.

Бәби мунчасы («*Өч мунча*») дигән йола болай үткән: яңа туган баланы әнисе белән бергә өч көн рәттән мунча керткәннәр, аларның бөтен тәннәрен балга тоз болгатылган масса белән ышкып юганнар.

***Дини йолалар:*** исем кушу, күмү йоласы; мәетнең өчесен, җидесен, кырыгын, илле берен, елын үткәрү; дәвер сөрү, Коръән укыту һ.б.

*Дәвер сөрү* йоласы турында безгә Мазарбашы авылы мулласы сөйләде. Ул болай уздырыла икән.

*– Андары җеназа вахытында дәвер сөрү Әбү Хәнифә мәзһәбендә бар. Ул дәвер сөрү бар инде менә Татарстанда да. Менә йәшләр ташлап бетерде аны. Җәлил хәзрәтләр дә дәвер сөрми башладылар.*

*Дәвер сөрү ул менә калган, укымый калган намазлар, тотылмаган уразалар өчен фидийә сәдәхәсе бирелә менә, эме. Шуларны ул вариска әйтеп калдырырга тийеш, үлгән кеше, шул менә минем фидийә сәдәхәсен бир, дип. Шул сәдәхәне, бик күпкә җыйыла ул. Например, 62 йәшендә ни үлә икән, ир кеше, 12 йәшен ташлыйлар, ул балигъ чагына. 50 йәшкә менә шуны, дәверне сөрү ул намазларны, бәлкем ул 50 көн калдырмагандыр, ну саклык өчен анысына да сөрү саваплы, дип йазылган инде. Безнен әбү хәнифә мәзһәбендә генә бар ул. Бүтән өч мәзһәбтә йук, шәфикыйдә, хәмбәлидә, мәликидә йук. Әбү Хәнифә безнен иң зур ни инде, галимебез. Шунда ул шул фидийә сәдәхәсен менә варис бер кешегә бирә. Ул кеше шул фидийә сәдәхәсен ала. Менә кара-каршы утыралар да, бер йыл эчендә калган намаз-уразаларнын фидийәсе өчөн шушы малны кабул итеп алдыңмы, дип, бер йарлыга бирә варис. Варис ур(ы)нына мулла утыра. Шул, кабул итеп алдым һәм кабул иттем дә һибә кылдым, – һибә кылдым – сиңа бүләк итеп бирәм, – дип, шул сәдәхәне шулай итеп йөртә. Ул, менә әйткән инде, ул микъдардагы сәдәхәләрне бирә алмаса, шул дәвер сөрөлә, дип әйтелгән. Ул китапларда да бар, әбү хәнифә мәзһәбендә бар. Ну хәзер әйтәләр инде укыткан вахытта да, йәшләр укыта инде, дәвер сөрмәскә кирәк, фәлән-төгән диләр. Ну әүвәлге йазганны минем ташласы килми, минем җизнәм дә мулла булып эшләде, ул да сөрдө. Һәм безнен тирәдә менә Куйан авылында да, монда да сөрәбез пока, мин ниткәченнән, аларны калдырмыйбыз.*

*– Ә шул дәвер сөрү малы күпме булырга тиеш?*

*– Мал ул исәпләнә элекке бодай белән. Бер килограмм бодай ул ничә тийен генә булган инде ул элек, шулай иттереп исәпләнгән. Хәзер инде бик күп суммаларга җыйыла. Ул 50 йылга күп тонналар, бик күп ниләр җыйыла. Шунын бирә(а)лмаса кешеләргә, дип сорау бирә Әбү Хәнифә. Бирә алган хәтлесен бирә. Аны да бирә(а)лмаса, бик әз генә – бер йыллыкны бирә. Бер йыллык сәдәхәне бирә. Например, бер йыллык сәдәхә меңгә җыйылды, ди. Ул, теге, 20 меңләргә, 30 меңләргә җыйылуы бар инде. Шул мең тәңкәне бирә дә, шул сәдәхәне теге йарлы кире бирә бу вариска. Мин дә кабул итеп алдым инде, хәзер, риза булып, мин сиңа кире бирәм бу сәдәхәне, ди. Менә, моңа калдыра, анын хәлен авыр икәнен белә. Менә шулай иттереп дәвер сөрү бар.*

*Мазарбашы авылы мулласы Нигъмәтҗанов*
*Мөхтәр Мөхәммәтҗан улыннан (1938 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

Татар мәкальләрендә, беренче карашка, дингә мөнәсәбәт тискәре дип аңлап була. Ләкин, чынлыкта, бу мөнәсәбәт дингә түгел, ә аны үз файдаларына кулланган яки, дин битлеге киеп, халыкны алдаган диндарларга белдерелгән. Мәсәлән: «Балчык (*балчык* – монда: кеше, беренче адәм балчыктан ясалган дигән дини легендадан *(Нәкый Исәнбәт)*) югары менде, дин түбән төште»; «Дине – Мөхәммәд дине, көне – эт көне»; «Имамның да имансызы була» һ.б. Канатлы сүзләрдә дин һәм мал каршылыгы да күзәтелә: «Дингә ышанган малсыз калган» һ.б.

Уеннардан *«Йөзек салыш», «Чокыр туп», «Кагыш туп», «Пута/каеш/кул сугыш», «Урта казык», «Әҗәт алыш», «Буяу сатыш»* (балалар уены), *«Мәкән-мәкән»* (балалар уены), *«Класс алыш», «Түгәрәк» уены/«Круг әйләнү»* кебекләре булган. Җырлардан – уен җырлары, озын көйләр, такмаклар, кыска җырлар. (Без язып алган кыска җырларның бер өлеше Ләйлә Мөхәмәтшина мәкаләсендә китерелә.)

Берничә шундый уенны карап үтик.

*– Балалар уйыны... «Буйау сатып алу» уйыны инде ул. Сатучы һәрбер балага исем кушып чыга инде, буйау исемнәре. Сатып алучы килә дә буйау сорый. Нинди буйауны әйтә – шул бала чыгып чаба. И ул аны тотарга тийеш. Тоткач... Ул аны тотып җыйып-җыйып бара да, аннан соң инде алар... Тагы шундыйы бар ийе анын менә, бөтөн кеше җыйылып бетә, хәзер йаңабаштан ведущий кирәк ич инде, шул ведущийны нитер өчөн, түгәрәккә басалар ийе дә балалар, арт йак белән киләдер ийе дә инде теге тотадыр ийе, командага, теге, бүлә инде ул аны. Шундыйлары бар инде. Ә «Мәкән-мәкән» уйыны. Бездә шулай дип аталадыр ийе инде ул. «Кача-кача» уйыны ул, икенче төрле әйткәндә. Ну монда тайак, гөрләүчедә тайак инде. И һәрбер кешене тапкач, ул әйтергә тийеш, например, «Мәкән-мәкән Наилә, мәкән-мәкән Илфат...» Ну теге качкан балалар, ул күрмәгәндә чыгып, «мәкән-мәкән Әлфийә», дип кычкыралар инде. Гөрләүчене басалар.*

*Портянур авылында туган Фәйзерахманова Әлфия*
*Мөхәлләм кызыннан (1965 елгы)*
*Яңавылда А. Низаметдинова язып алды*

Бәрәңге районындагы татар авылларында авыл тарихын белгән кеше бик аз. Шулай да без тагын бер кызыклы мәгълүматка тап булдык. Инде кешеләре бөтенләй әзәеп барган, күп йортлары бушаган Таштоял (Искеавыл) авылының тарихы турында болай сөйләделәр:

*– Бу авыл башланган менә шул безнең Бикчәнтәй бабайлардан. Бу авылда баштан булган марыйлар. Ул марыйлар алданрак җитешкәнләр, чим менә бу безнең бабайларга караганда, менә монда килеп урнашканлар. Алар тужы Финляндиядән күчкән кешеләр булганлар алар. Вот аларны марыйлар дип йөргәнләр инде. Андары аларга ийәреп, йаңгадан бер нация ийәргән, ширмис тигән, диләр. Вот менә шул марый белә ширимисийә, алар монда күчкәнләр Кәрилә-финнән. Менә тушы Волга буйы белә алар тушында төшкәнләр. Монда булган урман. Мин кечкенә чагында да беләм әле. Менә мин, бабайга ийәреп, Бәрәңгегә бара торган ыйык. Тушыннан туры йул йөридер ийе. Менә моннан йылгадан китеп менеп китәдер ийе Бәрәңгегә йул. Менә шул йулдан йөргән чагында бабай сөйләп-сөйләп бара торган ийе инде, мәрхүм, менә шулай, улым, менә монда шулай, дип, менә шунда...*

*– Марыйча Туштийал дип йөриләр инде аны, урысча Таштайал дип. Без җөрибез инде Искеавыл дип, татарлар.*

*– 37–38 нче йыллардан соң мәчет бетте инде ул. Менә шул 37–38 нче йылларга хәтле, ничәнче йылларда булгандыр инде, шунда бабайлар укыган чагында йөреп-йөреп төшә торган ыйым.*

*Безнең авылда гармунчылар данлыклы ийе инде элек. Безнең авыл вабшый данлыклы ийе инде бөтен йактан. Безнең авылда йәштән башлыйдыр ийе кеше, әнә шунда (зират ягына күрсәтә) кергәнчегә хәтле бөтен эшне эшләгән бик үнәрле авыл ийе бездә. Пылотник та бар ийе бездә, такта йаручылар да, кийезтек сугучылар да, кирпеч салучылар да. Бик үнәрле авыл ыйы безнең авыл... Тимерче дә барыйы, әммәсе дә үзебезнеке.Тегермән дә бар ыйы безен. Бөтөнөсен Куйанлар алып китте. Бергә кушылгач. Куйан белән кушылдык, куштылар да. Без әле ул чагында сызгыртып эшләгән кешеләр ийек әле. Менә шулай итеп, куйанлар безнең бөтөн нәрсәне ташыдылар. Безен авыл бик бай ийе, Куйанга караганда. Куйан бик хәйерче ийе ул элек. Менә аның тәрәзәсеннән болай итеп бөкөрәйеп карап китәсе бар ыйы. Безен авыл данлыклы авыл ыйы. Менә бөтөн нәрсәне безен, шулай итеп, ташып петерде Куйаннар.*

*– Менә монысын Зийарат урамы дип йөридер ийек. Әнә тегесен – Урта урам дип, әнә теге йактагысын – Габид урамы дип. Ул Габид нәрсәдән килеп чыккан? Менә монда, тушы авылда бер марый хатыны, әкәй дип йөрибез инде без, иймә, мужыт сез дә аңлый торгансыздыр әле әкәй диган исемне, шул бер байда эшләгән тушында эшләгән җирендә бала тапкан. Ул балага марый иссме*

*кушмаганлар инде, Габидулла, Габидт, тип исем биргәнләр. Менә шуннан киткән урам ул, Габид урамы. ...Авылның уртасында ансы Урта урам дип йөридер ийек инде... Өч урам ыйы. Дәү-дәү өч урам ыйы, әйтәм ич мин сиңа, 78 хазйайстыбы иде әле сугыштан соңгы йылларда гына. Силсәбит буйынча 368 хозйайстыбы бар ыйы.*

*– Менә Мостай арты дип йөрибез инде, ул болын...Анда сабан туйы була инде. Ул Мостай арты дип шуннан чыккан инде: иң беренче шул Мостай дигән кеше килеб утырган анда. Арт йагысында аның булган инде болон, шул чиста әчеклек булган инде. Ул чагында монда булган урман. Менә Бәрәңге белә ике ара безнең монда примерно 6–7 километр, имә, әнә шул йакта кыругом кара урман булган, урман аркылы чыгып йөргәнләр нигә, Бәрәңге дигән авылга. Ул чагында ул Бәрәңге районы булмаган инде, ул район булган шул 30 нчы йылларда, настайаший итеп район иткәнләр инде аны. Татар районы дип.*

*Таштоял (Искеавыл) авылында туган*
*Шәрифьянов Мөбарәк агадан (1929 елгы)*
*һәм Шәрифьянова Әминә ападан (1932 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

***Тышлы тәйкмәк:***

*– Тышлы тәйкмәк пешерәдер ийем мин бик элек, бик тәмле буладыр ийе ул. Аны, тышлы тәйкмәкне, аны соло оно белә дә болгаталарыйы. Катык ойоторга кирәг аңга. Төчө катык ойотоп, шуңга соло оно булмаганда инде мин манный белә бик пешерәдер ийем. Манный белә шунын эчен болгатып куйам да, күкәй сытып, күкәйгә тышын басасын. Аны болай-болай гына итеп, камырын йасап, шуны җәйәсен бик йука итеп, шуны... өстөнә теге катык белә болгаткан манныйнымы анда, солономы, шунысын тәйкмәкнең эченә җәйеп, шулай итеп, мичкә тыгып пешерәсен аны. Бик тәмле була. Шуны атланмай белә майлап ашасан, ин затлы ризык була инде бу безен халыкка... Бу тәйкмәк дигән нәрсә бик мәшәкатьле дә, мин аны бик пешерә торган ийем, балаларым да бик йаратып ашыйлар ийе инде.*

*Искеавылда (Таштоял) Шәрифьянова Әминә ападан (1932 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

*– Хәзер... Ике күкәй, 0,5 больше или меньше су, йарты, поллитр, 2–3 кашык аш кашыгы белән сыйык май – растительное масло, он, камыр җәйәсең, камыр итеп йасыйсын, аннан шуны түгәрәкләп-*

*түгәрәкләп, үзеңнен табаңнын размеры белән җәйәсен. Әни безнен шушы урындыкка мендәр куйадыр ийе, шуңга ике мөндәрне куйып, шуңа ашаулык җәйеп, шунда шуларны нитеп барадыр ийе, җәйеп-җәйеп барадыр ийе бер-берсе өстөнә, 30нымы, ни, вобщем, шул хәтле буладыр ийе. Шулай итеп, менә шушыннан күпме чыга инде, пол литр судан шуларны саласын. Хәзер эче, второе, начинка, дигән сүз инде бу. Тәйкмәкнен эченә 0,5 грамм, шушы 500 грамм кефир аласын, плюс бер чәй кашыгы сода, 0,5 чайный... чәй кашыгы белән лимонная кислота, бер чокор манный – болгатып куйасын. Шунда күпереп утыра. Хәзер, күпереп менә ул, айакка – зур савытка салып, нитәсен инде, зур айакка салып, шул күпереп менә дә, хәзер, в-третьих. Бу эчкә, тыш әзер булгач, кушасын сөт, теге, күпереп менгән нигә, второй, под цифрой двага. Хәзер сөт саласын, он саласын, әзрәк тоз саласын. Аннан болгатасын. Аннан соң – пешерү, аннан соң – майлау. Пешергәндә табаны майламыйсын, коро табага... коро табага шул лепешканы җәйәсен, тәйкмәкне җәйәсен дә бер кабатын пешереп аласын. Шул кубара башлый ул, кабара башлый ул болай итеп. Хәзер шуны әйләндерәсен дә шуңа хәзер менә бу өслөкне кашык белән җәйеп чыгасын. Тагын пешерәсен. Аннан сон, бу өстө катып киткәч, әйләндерәсен дә тагын пешереп аласын. Менә шул тышлы тәйкмәк була. Ашап туймаслык була... Йука итеп кенә җәйәсен. Теге, сөт белән, син теге массаны җебет... нитәсен ич, сыйыклыйсын, теге, болай, агып тора торган булсын. Җәйәсен, тигез итеп, теге камырга. Менә шулай итеп пешерәсен дә аннан сон майлыйсын ике йагын да. Камырын йука итәсен, теге, токмач шикелле, ну чүт кенә йука булса да йарый инде әз генә, чүт на миллиметр больше булса да йарый инде. Шулай итеп җәйсен.*

*Олыкыр авылында туган Сәмигуллина*
*Зәмзәмия Гыйният кызыннан (1939 елгы)*
*Бәрәңге авылында А. Низаметдинова язып алды*

Бәрәңге районы татарларының йола иҗаты бик бай. Аларның хәзер дә халык арасында кулланылышта булуы шатлыклы күренеш. Яңаны алдым дип, искене ташлама, дигән халык. Үз тарихын белмәгәннең киләчәге дә анык түгел. Шуңа күрә безнең әлеге хезмәтебез дә бу мирасны саклап калырга ярдәм итәр дип ышанабыз.

# ИҖАТ ЧИШМӘЛӘРЕ САЕКМАСЫН

*Айсылу Садыйкова*

Бәрәңге районы татарларының авыз иҗаты әле тиешенчә өйрәнелгән, дип әйтеп булмый. XX гасырда бирегә аерым фольклорчылар, галимнәр генә килгән. Мәсәлән, Котдус Хөснуллинның авылларда йөргәне билгеле, аны халык әле дә хәтерли.

Бәрәңге ягы урманнарга күмелеп утырса да, авыллары якты, нурлы, йортлары яңа, ачык төсләргә буялган. Халкы хезмәтчел. Бөтен җирдә гөлләр – бакчада, верандаларда, тәрәзә төпләрендә. Матурлык яраткан кешеләр хисчән, шигъри җанлы була күрәсең. Бу як кешеләре, бигрәк тә хатын-кызлар, шигырьләр яза. Безнең XIX гасырга кадәр язылган әдәби әсәрләребез нигездә шигъри әдәбият. Бу феноменны, әдәбиятчылар, психологлар «нюансовость мышления» дип аңлаталар. Татар халкына хас булган мондый шигъри фикерләү аның хәзерге иҗатында да күренә. Бәрәңге районында шигырьләр, бәетләр, мөнәҗәтләр күп язып алынды.

Портянур авылының мәдәният йортында без Вафина Мөнирәнең шигырьләр дәфтәре белән таныштык. Ул туган авылы, халыклар дуслыгы турында язган. Балаларына соклану, шатлану белән тулы язмалар бар. Күп юлларда Аллаһының биргәненә шөкер итеп яшәү, фәлсәфи фикерләр яңгырый:

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм?
Моңлана һәм уйлый белгәндә,
Өлешемә тигән көмешемне
Шулай тирән итеп сөйгәнгә.

Олыкыр авылында без Шәйхетдинова Кафия Сафа кызы белән озаклап сөйләштек. Аның үзе теккән, чиккән, бәйләгән кул эшләренә сокландык. Шигъри иҗаты күп темаларны эченә алган.

Ире белән тату яшәп, балалар үстергәннәр. Иҗатының төп темасы – сагыну, искә алу, үткәннәре һәм бүгенге тормыш-көнкүреше. Ире гармунчы булган. Кафия ханым аның өч тальян, бер рус гармунын кадерләп саклый. Дөньядан киткән ирен сагыну бу шигырьләрне бәет жанры әсәрләренә дә якынайта.

Үзәктә – шигырьләрне хисле иткән гармун образы. Гаиләнең көй-моң белән яшәп, матур гомер иткәнен символлаштыра, балалар, оныкларның шундый атмосферада үскәнен аңлата ул.

Шуны да әйтергә кирәк, сәнгатьчә фикерләү Кафия ханымга әнисе Маһитап ападан, әбисе Гөлзәйнәп әбидән күчкән. Ул аларның мөнәҗәтләр язылган дәфтәрләрен кадерле ядкяр итеп саклый. Үзенең дә әнисен сагынып язган шигырьләре мөнәҗәтләргә охшаш. Билгеле булганча, татар халык иҗатында «Ана һәм бала» дип аталган зур төркем мөнәҗәтләр бар. Кафия ханым әсәрләренә андый жанрларга хас традицион әҗәл сурәте, гомер узу, Ходайга сабырлык сорап мөрәҗәгать итү хас.

Әнкәй, нигә ташлап киттең,
Төшләремә керәсең.
Төшләремә керәсең дә,
Йөрәгемне теләсең.
Иртән торып, чыгып йөрим
Ямь-яшел аланнарга.
Ходай сабырлыклар бирсен
Әнисез калганнарга...

* * *

...Уйнады ул дүрт тальян гармун,
Каласыз ич миннән, дигәндер.
Миннән башка сезне кемнәр уйнар,
Йөрәгенә шулар тигәндер.
Дүрт гармуным дүрт оныгыма,
Уйнаганын син тыңларсың,
Оныкларым гармун уйнаганда,
Йөрәкләрең өзелеп, еларсың...
...Габделхагым, гармуныңны
Моңлы итеп уйнаттың.
Уйнаттың да, елаттың да,
Күңелемне юаттың.
Синнән калган гармуныңны
Күз нурлары кебек саклыйм.
Фоторәсемеңә карыйм да,
Күземне ала алмыйм.

Кулларыңа чәчкә тотып,
Төшләремә керәсең.
Төштә генә күреп сөйләшергә
Ходай кушкан күрәсең.
42 ел бергә яшәдек
Күзне күздән алмыйча.
Көн дә дога кылам сиңа,
Түзә алмыйм еламыйча.
Кадерләрен белмәгәнбез
Тормыш парлы чагында.
Үзәкләрем өзелеп китә,
Парлыларга карыйм да.
Дүрт гармунын алып уйнады ул,
Моңсу гына көйләрне сузды.
Әтиегез белән булган көннәрем
Узды бит ул, бигрәк тиз узды...

Кафия ханымның язган җырлары да бар. Шулай итеп, элек мөнәҗәтләр язган әбисенең, әнисенең иҗатын ул яңартып дәвам итә. Әбисеннән язып алган мөнәҗәтләре – «Бисмиллаһи эшләр башы», «Әҗәлнең вакыты җитәр», «Укытыгыз Коръән» («Ана васыяте») – өчесе дә традицион дини рухта.

Беренчесендә һәр эш Аллаһ исеме белән башланырга тиеш, зикер-тәсбих әйтергә, хәләл мал табарга, намаз укырга, гөнаһ кылмаска, иманны сакларга кирәк, андый кеше җәннәткә лаек булачак, диелә. Болар ислам динендәге кешегә тиешле гамәлләр.

Икенче әсәр фани дөнья, газраил килү, әҗәл җитү турындагы дини-фәлсәфи уй-фикерләрне үз эченә алган. Бу фикерләр борынгы төрки шагыйрьләрдә үк бар. Әдәби әсәрләрдә дә, халык әсәрләрендә дә караш бер төсле – дөнья фани, вакытлы. «Әҗәлнең вакыты җитәр» дип аталган мөнәҗәт тә шуны аңлата:

Куган дөньяң шулай калыр,
Тар ләхеткә илтеп салыр...
Әмма котылу юлы бар:
Ялварсагыз бер Аллага,
Алла үзе рәхим кылыр.

Мөнәҗәт (гарәпчә) – Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ярлыкауны сорау дигән мәгънәне аңлата бит. Аллаһы гына ярлыкый ала.

Өченче мөнәҗәт «Ана белән бала» дигән популяр әсәрләр төркеменә карый. Мөнәҗәттә ана балаларына теләкләрен әйтеп калдыра – үзенә атап Коръән укуларын үтенә.

Сөйлим әле, балаларым,
Сүзләремдә барлык моңнарым.
Вафат булсам, укытыгыз Коръән,
Тәрәзәдән кайтып тыңлармын.

Шуңа охшаган тагын бер мөнәҗәт Портчара авылында Сәгъдуллина Сәмәвия Йосыф кызыннан (1931 елда туган) язып алынды. Ул «Ана васыяте» дип атала:

Кабер эчләрендә мин ятырмын,
Балалардан дога көтәрмен...

Балалары һичшиксез бу васыятьне үтәрләр дип ышанасың.

Мондый әсәрләрне татарлар яшәгән барлык авылларда да без еш язып алабыз. Ислам динендә мең елдан артык яшәгән татар халкы кайда гына гомер итсә дә, бер үк уй-фикерләрне кичерә: Аллаһыга инану, җәннәт булачагына ышану.

Куянавылда без Мәфтуха Хәбибрахман кызыннан (1926 елгы) моңа хәтле очрамаган мөнәҗәт язып алдык.

Бисмиллаһир рахман иррахим.
Аллаһыма шөкер кылам,
Исәнлек биргәненә.
Аякларым йөргәненә,
Күзләрем күргәненә.
Аллаһыма шөкер кылам,
Биргән нигъмәтләренә,
Аятьләрне ятлар өчен
Зиһеннәр биргәненә.
Аллаһыма шөкер кылам,
Якты көн биргәненә.
Күктән яңгырлар яудырып,
Иген үстергәненә.
Аллаһыма шөкер кылам,
Караңгы төннәренә.
Намазларымны укырга
Ярдәмен биргәненә.
Аллаһыма шөкер кылам,
Ураза биргәненә.
Бәндәләрнең гөнаһларын
Ярлыкыйм, дигәненә.

Бу «Шөкерана» мөнәҗәте якты хисләр белән тулы, ул һәр булганына шөкер итеп язылган. Сөйләүче бигрәк тә Коръән аятьләрен укуына бик шатлана.

Бисмиллаһир-рахманир-рахим.
Мөнәҗәтләр укыйм әле,
Тыңласагыз күңгел салып,
Узган гомерләрне уйлап,
Утырам хәйранга калып.

Бу агачлар бөгелә микән,
Ботаклары кая икән?
Бу агачлар, минем кебек,
Сагынып саргая микән?

Бу агачлар яфракларын
Салкын җилләр коя микән?
Минем йөземнең нурларын
Сагынулар җуя микән?

Әй, туганнар, беләсезме,
Уза гомер, сизәсезме?
Бу гомерләр үткәннән соң
Ни буласын беләсезме?

Бу гомерләр үтеп китәр,
Әҗәл вакытлары җитәр,
Бу гомернең үтәрләре
Барыбер бер килеп җитәр.
Амин.

Бу якларда татар халкында бик борынгыдан килгән тагын бер традиция дәвам итә – бәетләр языла. Ирнур авылында яшәүче Галләмова Хәдичә Гыйбадулла кызыннан (1939 елда туган) 6 бәет язып алдык (18 яшьтә һәлак булган Сафин Илшат бәете, фаҗигале үлемгә дучар булган күршесе Шәйхетдинов Рафис бәете, энесе Фаил бәете, энесе Фарук бәете, Фәнис рухына бәет, Мөдәррис кызы Гүзәлия бәете). Иң аянычлысы, болар яшьли гомерләре киселгән кешеләр. Хәдичә ханым бәетләрне, тиешенчә, Аллаһ исеме белән башлый.

**Илшат бәете**

Бисмиллаһи, дип башладым
Бу бәетнең башларын.
Яман бәндәләр кулыннан
Башларымны башкардың.

Сишәмбе көн иртә белән
Булды бездә гаетләр.
Йөрәкләргә чыдый алмый
Чыга иде бәетләр.

Әнкәй, мине тапкачтын.
Сөенгәндер күңелең.
18 яшем тулганчы
Өзелде ич гомерем.

Шимбә көнне өйгә кайттым,
Кунак булырмын, диеп.
Кем уйлаган – шул ук көнне
Мәет булырмын диеп.

Өйдән чыгып киткән чакта
Карадым бер каерылып.
Әти, әни, энекәшем,
Калдыгыз ич аерылып.

Әни балам, кысмыймы ул
Аягыңдагы катаң?
Рәхәт яшәр чакларымда
Салкын гүрләрдә ятам.

Миннән калган киемнәрне,
Әти балам, киярсең.
«Бигрәк яшьләй гүргә керде
Газиз балам», – диярсең.

Өйдән чыгып киткән чакта,
Кайтам, дип белдем ич.
Корбан гаете көннәрендә
Каберләргә кердем ич.

Суларны чыккан вакытта
Аяк асты чи киртә.
Бер кеше дә үлми калмый –
Миңа килде бик иртә.

Дога кылып, ясин укытыгыз,
Минем васыятем шул булыр.
Миңа багышланган ясин белән
Каберем эчләренә нур тулыр.

Кабер эчләрендә яткан чакта
Әниемнән дога көтәрмен.
Догаларыгыз барса, шат булырмын,
Онытсагыз, ни хәл итәрмен.

Чабыштан кайткан атларның
Буялган дагалары.
Үлгәч, бигрәк кирәк икән
Әнинең догалары.

Язмыйк бүтән, җитәр инде.
Почталар китәр инде.
Әти, әни, мине сагынып
Гомерегез үтәр инде.

## Шәйхетдинов Рафис бәете

Бисмилла, дип башлыйм әле
Бәетемнең башларын.
Утыз тугыз яшьләремдә
Гүргә керде башларым.

Күрешә алмабыз инде,
Мәңгелеккә киттем ич.
Ярамаган эшләр эшләп,
Сезне ятим иттем ич.

Бигрәк тә авыр булды
Ходай җанымны алганда.
Ни хәлләр түзәрсез инде
Ләхетләргә салганда.

Йортымнан чыгып киткәндә
Карадым бер каерылып.
Рәзимәм, Рафиләм,
Калдыгыз ич аерылып.

Күршеләрем белән тату
Яшәдем җир йөзендә.
Үләрмен, дип уйламадым,
Белми калдым үзем дә.

Туганнарым, юксынмагыз,
Сабыр итегез инде.
Гомерләрем беткән икән,
Үлем артымнан килде.

Мәңгелек йортыма китәм,
Башка мине күрмәссез.
Бергә яшәгән вакытны
Искә алып сөйләрсез.

Апайларым, васыятем шул:
Миңа риза булыгыз.
Ир туганыгыз бер генә,
Дога кылып торыгыз.

«Әти балам, сиңа охшатып,
Кемнәргә карыйк икән.
Бик яшьли ятим калдык ич,
Кайларга барыйк икән».

Чиләкләрем тулып калды,
Шулай торсын, түкмәгез.
Сабый балам ятим калды,
Үгетләми сүкмәгез.

Апай, сине озатканда
Карап калдым күзеңә.
Ни хәлләр карый алдың
Минем җансыз йөземә.

«Әтием, син үлеп киттең,
Каберләрең тар микән?
Минем күк бәхетсез җаннар,
Тагын кемнәр бар икән?»

Мәңгелеккә китәм инде,
Юлга чыгып озатып калыгыз.
Шушы ап-ак кәфенлегем белән,
Фәрештәләр каршы алыгыз.
Амин.

## Энем Фаил бәете

Бисмилла, диеп башлыймын
Бәетемнең башларын.
Кырык ике яшем тулгач,
Гүргә керде башларым.
Килү булгач, китү була,
Килмәсәм китмәс идем,

Сезне шушы хәтле итеп
Бәхетсез итмәс идем.
Әни балам, җомга көнне
Яннарыма килерсең,
«Килдем, балам, дога кылам», –
Диеп хәбәр бирерсең.

Авыр чакта бик булышты
Миңа якын кешеләр.
Алланың рәхмәте яусын,
Барыгызга, күршеләр.
Нажиям, авыр булыр инде
Ялгыз гомер итүе.
Миңа да бик авыр булды
Сезне ташлап китүе.
Ләхетләргә салсагыз,
Караңгы булмасын гүр.
Ике улыңны үстереп,
Игелеген үзең күр.
Яңа салган өем калды,
Чәчәкләргә күмелеп.
Үзем ятам салкын гүрдә,
Балчыкларга күмелеп.
Ике улым, җәйләр җиткәч,
Яннарыма килерсез,
Үземне күрмәсәгез дә,
Каберемне күрерсез.
Ходай мине сездән аерса да,
Каерса да ике кулымны,
Ничек онытырмын икән
Ятим калган ике улымны.
Җан бирүем авыр булды,
Килмәдегез яныма.
Бигрәк иртә китеп бардым
Газизләрем янына.
Ләхетләргә кереп яткач,
Әти, бабай янымда.
«Иртә килдең, балам», – дигәч,
Авыр булды җаныма.
«Улым, көчең бик күп иде,
Ник бирештең үлемгә?»
Инде хәсрәт эчләрендә
Без ятабыз гомергә.
Елау елаугa китмәсен
Туктарга кирәк, балам.
Бераз гына сабырлар ит,
Яныңа үзем барам.
Китәм инде, якын кешеләрем,
Мине зурлап озатып калыгыз.
Сезнең янга мәңгелеккә киләм,
Фәрештәләр, каршы алыгыз.

## Мөдәррис кызы Гүзәлия бәете

Бисмилла, диеп башлыймын
Бәетемнең башларын.
Кырык ике яшем тулгач,
Гүргә керде башларым.

Әни балам, кысмыймы соң
Аягыңдагы катаң?
Ике балам ятим калды,
Мин салкын гүрдә ятам.

Кабат күрешә алмыйбыз,
Мәңгелеккә киттем ич.
Кирәкмәгән эшләр эшләп,
Сезне ятим иттем ич.

Тәрәзә төбендә гөлнең
Кызыл чәчәге юк ич.
Каршы алып озатырга
Инде әниегез юк ич.

Сәламәт бул инде, ирем,
Үрнәк булдың һәр эштә.
Ерак юлларга йөрисең,
Саклап йөрсен фәрештә.

Ләхетләргә салсагыз,
Караңгы булмасын гүр.
Ике улымны үстереп,
Игелеген үзең күр.

Җан биүе авыр булды,
Өзелде үзәкләрем.
Сабыр булыгыз, туганнар,
Сезгә шул теләкләрем.

Сау булыгыз, туганнарым,
Сау булыгыз, дус-ишләр.
Рәдинә апамны карагыз,
Миннән башка ул нишләр.

Әнкәемне бик яратып
Сагынып кайта идем.
Син тектергән күлмәк түгел,
Ак кәфенемне кидем.

Иртә белән торып чыксам,
Исә йомшак җилегез.
Җир астында юллар булса,
Бер күренер идегез.

Каберемә кереп яткач,
Әти килде яныма.

«Иртә килдең, кызым», – дигәч,
Авыр булды җаныма.

«Әни балам, үлеп киттең,
Җаның рәхәттә булсын.
Без исән-сау үсик инде,
Әтиебез исән булсын».

Барлык якын кешеләрем,
Мине озатып калыгыз.
Шушы ап-ак кәфенлегем белән,
Фәрештәләр, каршы алыгыз.

## Энем Фарук бәете

Егерме бишенче ноябрь
Була Ураза гаете.
Мин язамын, сез тыңлагыз
Бу Фарукның бәете.

Туган йортымнан киткәндә
Карадым бер каерылып.
Әни балам, күземә карап,
Калдың мәңге аерылып.

Аякларым һич тартмады,
Больнисларга менәргә.
Ходай шулай язган миңа
Яшьли гүргә керергә.

Төрле вакытым булгандыр,
Әлфинурым, гафу ит.
Үлем ачысы бик авыр,
Зинһар өчен, сабыр ит.

Ләхетләргә салсагыз,
Караңгы булмасын гүр.
Ике баламны үстереп,
Игелекләрен үзең күр.

Улларыбыз ятим калды,
Ничек түзәрсең инде.
Ходай синең гомереңне
Иртә өзмәсен инде.

Әни, авыр хезмәт белән,
Кулларыңны талдырма.
Ятимнәрем сиңа килсә,
Аш-суыңнан калдырма.

Кулъяулыгым юар идем,
Ишек алдында су юк.
Көн дә кайтып күрер идем,
Җир астында юллар юк.

Ай белән кояш бер генә,
Йолдызлары бик тә күп.
Бер сез генә түгел, балам,
Ятим калучылар күп.

Чиләкләрем тулып тора,
Тулы, диеп түкмәгез.
Ике улым ятим калды,
Үгетләми сүкмәгез.

Туганнарым, васыятем шул,
Риза-бәхил булыгыз.
Вакытыгыз бар чагында,
Миңа дога кылыгыз.

Китәм инде, балаларым,
Мәңгелеккә озатып калыгыз.
Шушы ап-ак кәфенлегем белән,
Фәрештәләр, каршы алыгыз.

## Фәнис бәете

Ни хәл итим язмыш сездән
Аерды шул бик иртә.

Җәй айлары бигрәк моңлы
Кайгы килгән кешегә.
Үләсемне алдан белдем,
Сулар йөздем төшемдә.

Төрле вакытым булгандыр,
Зөлфирәм, син гафу ит.
Үлем ачысы бик авыр,
Зинһар өчен сабыр ит.

Улларыбыз ятим калды,
Ничек түзәрсең инде?
Ходай синең гомереңне
Иртә өзмәсен инде.

Янымда беркем булмады
Җаннарым чыккан чакта.
Ничек түзәрсез, улларым,
Исегезгә төшкән чакта.

Язмыш мине сездән аерса да,
Каерса да ике кулымны,
Ничек итеп онытырмын инде
Ятим калган ике улымны.

Туганнарым белән тату
Яшәдем җир йөзендә.
Үләрмен, дип уйламадым,
Белми калдым үзем дә.

Мин үлгәчтен каберемә
Кунып сайрады тургай.
Казан больнисында ятып
Үләргә язган Ходай.

«Әти балам, үлеп киттең,
Каберләрең тар микән.
Безнең күк бәхетсез җаннар
Тагын кемнәр бар икән?»

Китәм инде, балаларым,
Мәңгелеккә озатып калыгыз.
Шушы ап-ак кәфенлегем белән,
Фәрештәләр, каршы алыгыз.

*Ирнур авылында Галләмова Хәдичә*
*Гыйбадулла кызыннан (1939 елгы)*
*А. Садыйкова белән Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Сәлим белән Мәрҗәнкәй бәете

Кызарып кояш чыкканда
Фабрикадан кайталар.
Агуланган Мәрҗәнкәйне
Больницага озаталар.
Агуланган Мәрҗәнкәйне
Салдылар койкаларга.
Ике доктор, бер сестра
Йөриләр тазартырга.
Беренче көн хәл белергә
Килде аның әнкәсе.
Докторлар җавап бирделәр,
Авыр аның хәлләре.
Икенче көн хәл белергә
Килде аның эткәсе.
Дуктырлар җавап бирделәр,
Мәрҗәнкәй үлгән, диеп.
Өченче көн хәл белергә
Килде аның сөйгәне.
Дуктырлар җавап бирделәр,
Мәрҗәнкәйне «амбарда» дип.
Амбарларга кердем исә,
Зур кара сандык ята.

Шул кара сандык эчендә
Үлгән Мәрҗәнкәй ята.
Ач күзеңне, ач күзеңне,
Ач күзеңне, сөйгәнем.
Әгәр ачмасаң күзеңне,
Һәлак итәм үземне.
Кайтты егет, кайтты егет,
Кайтты егет өенә.
Ялтырап яткан пычакны
Кадады йөрәгенә.
Кызарып кояш чыкканда
Фабрикадан кайталар.
Сәлим белән Мәрҗәнкәйне
Кабергә озаталар.

*Куянавылда Фатыйхова Рәмлә Мөэмин кызыннан (1950 елгы),*
*Мәүликеева Раймә Мөэмин кызыннан (1961 елгы)*
*һәм Хәмидуллина Раузалия Мөэмин кызыннан (1955 елгы)*
*А. Садыйкова белән Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Финзия бәете

1980 нче елда, 5 нче июньдә
Суларда чыкты яным.
Аллаһы Тәгалә белдергәндер,
Алдан ук бетте аңым.

Әнкәм, иртә торгачыннан
Төшем сиңга сөйләдем.
Суга баткач, чыгалмадым,
Беткән иде җегәрем.

Әнкәм, эткәм, еламагыз,
Үлемем судан булгандыр.
Үле гәүдәмне карар өчен,
Өй эченә халык тулгандыр.

Эткәм, күңелең йомшак
Синең, һаман елап йөремә.
Ятуларым читен булыр,
Сулар тулыр гүремә.

Үләсемне белгән кебек
Күңелем куркып йөрде.
Ундүрт яшемә җиткәчтен,
Саннарым гүргә керде.

Үле гәүдәмне күргәч, әнкәм,
Хәсрәтләрең арткандыр.
Аякларым ала алмадым,
Су анасы тарткандыр.

Су төбендә калдым ялгыз,
Иптәшләрем куркып чапты.
Белмиләр кемгә әйтергә,
Дөньялыкка килмәгәнбез
Яшәр өчен мәңгегә.

Үлмәктән калмак юк, диләр,
Дөресе шулай икән.
Әнкәм, сәдака бир, дога кылдыр,
Бүтәнне өмет итмәм.

Урамга чыгып керәм, дип,
Чыгып киттем ич өйдән.
Минем тәкъдиргә күрәме,
Сулар да булды тирән.

Гәүдәм табутка салдылар,
Бераз юллар алдылар.
Әнкәм, эткәм, туганнарым –
Бар да елап калдылар.

Минем мәңгелеккә өем,
Җәлил абыйлар карар яхшылап.
Аягым белән чыгып киттем,
Кайтардылар ич куллап.

Әнкәм, төрле вакыт булгандыр
Инде гафу итәрсез.
Аяк очымнан узганда
Дога кылып үтәрсез.

Бу язуымны язганча,
Әллә мин дә гаепле.
Кызгануыма чыдый алмый
Чыгардым бу бәетне.

Әллә яшьлегем беләнме,
Туймаган идем уйнап.
Дөньялыкта яшәп булмый,
Үзеңчә генә уйлап.

## Саимә бәете

Тәкъдиремә тиде үлем
Чөгендер басуында.
Кайткач су да эчеп бактым
Йөрәгем ярсуынга.

Бераздан соң куеп
Эчтем гөжелдәтеп чәемне.
Кайнар чәй дә баса алмады,
Авыруым җәелде.

Авыруым катыгамы,
Уйнады каннарым.
Әнкәм, төрле вакытым булды,
Ризалаша алмадым.

Дөнья кайгысы онытылды,
Ачалмадым күземне.
Дүрт балам ятим калды
Сакла, Илдус, үзеңне.

Туганнарым, елашырсыз,
Соңгы озатуыгыз.
Карчыкларга сәдака биреп,
Бергә дога кылыгыз.

Авыруым каты булды,
Белә алмады духтырлар.
Илдусыма калды инде
Кайгы-хәсрәт, уй-моңнар.

Чөгендер җиремне утадым,
Кызганмадым кулымны.
Кемнәр килеп тәрбияләр
Өч яшендәге улымны.

Илдус, ялгыз торалмассың,
Үз ягыңны карарсың.
Балаларымны кактырма,
Аларны үзең барларсың.

Балаларның бераздан соң
Өметләре өзелер.
Туганнарым, минем өчен
Сезнең үзәк өзелер.

Дөньялыкта яшәгәндә
Җитми безгә барсы да.
Туганнарым, онытмагыз
Тегe дөньяга барасын да.

Дару кулланмагыз,
Миннән гыйбрәт алыгыз.
Бергә тигез яшәгәндә,
Балаларны табыгыз.

Балаларны табыгыз да
Тигезлектә багыгыз.
Яшь вакытта барыбызның да
Шау-гөр килер чагыбыз.

Дөньялыкта яшәгәндә
Рәхәт күрмәдем бер дә.
Җиңгеллекләр булыр микән
Миңа караңгы гүрдә.

Фермачылар эштән төшәр,
Кыр казыдай тезелеп.
Минем әнкәм карап торыр,
Үзәкләре өзелеп.

## Алверт бәете

Газиз әнкәм, бик елама,
Үлемем судан булгандыр.
Минем дипломыма карап,
Күңелеңне юандыр.

Иптәшләремне коткардым,
Авыр булды анысы.
Үзем исән калалмадым,
Тоткандыр су анасы.

Су анасына үпкәләмим,
Мин дә Аллаһ баласы.
Бик артыгын җыламагыз,
Барыбыз шунда барасы.

Әткәм, әнкәм, туганнарым,
Сезгә булыр бик авыр.
Авырлыклар онытылырлар,
Ходаем бирсен сабыр.

Минем кинәт үлүемә
Аптырагандыр авыл.
Әткәм, сабыр итә күр,
Әнкәмә булыр авыр.

Мине судан алган чакта
Булмады ла билдән түбән.
Җанымда артык сулуым,
Сулаганда булмады әнкәм.

Шундый сөенеп бардым
Мин дипломымны алырга.
Иптәшләрем каушап калды,
Исән килеш алырга.

Минем соңгы ел укуым
Үкенечкә булгандыр.
Үле гәүдәм карар өчен
Өй эчләре тулгандыр.

Болай кинәт үлүнең дә
Хәсрәте бик авыр.
Урын өстендә ятсаң да
Багучыга бик авыр.
Авыр булса да, һәркемгә
Ходаем бирсен сабыр.

Алты ел буе укып
Йөрдем Йошкар-Ола түрендә.
Сөенеп өйгә кайтыр көндә
Дучар булдым үлемгә.

Алты ел укыган урыным –
Йошкар-Ола почмагы.
Мине гүргә илтеп салды
Су анасы кочагы.

Исемен әйтеп язалмадым,
Бәет чыгардым үзем.
Күрмәгәнгә күрсәтмә, Аллам,
Күргәнгә биргел түзем.

## Ясминә бәете

Бәрәңгедә 47 сарай янды.
Шул сарайда,
Ике үгез уртасында
Ясминә кереп янды.

Ясминә мәрхүмә көндезләрен
Ашкыныбырак йөрегән.
Ян ачысы белән янган,
Утка да кергән.

Ясминә мәрхүмә төннәрендә
Куркыныч төшләр күргән.
Шул ук кичен ут эчендә
Барлык әгъзасы эрегән.

«Сарай ишеге ябылды,
Тапмадым келәләрен.
Әнкәй, синең минем өчен
Үзәгең өзгәләнер.

Әнкәм, балаларым, мине күрүгә
Сезгә булыр бик авыр.
Авырлыклар онытылырлар,
Ходаем бирсен сабыр».

Карыйм әле йөзеңә,
Бәет әйтеп үзеңә.
Һичбер әмәл табып булмый
Ходай биргән үлемгә.

«Әнкәм, туганнарым,
Улым белән кызыма
Ярдәм итәрсез инде.
Исән чактагы авырлыкны
Гафу итәрсез инде.

Әнкәм, артыгын елама,
Өзеләдер бәгырең.
Сан сагышым ким булса да
Яныма булыр мәгълүм.

Кәримулла, син яшь әле,
Үз ягыңны карарсың.
Балаларымны кактырма,
Аларны үзең барларсың.

Безнең район зурайды
Исеме матур, Бәрәңге.
Бер дошман аркасында
Ут чорнады гәүдәмне.

Кардәшләрем, сезгә әйтәм,
Ут белән үч алмагыз.
Аның ачысы авыр,
Анысын үзегез аңлагыз.

Без үскәндә бергә булдык,
Җиде бала бер өйдә.
Барыгыз бергә җыйналганда
Авыр булыр әнигә».

## Илшат бәете

Җәйнең көне эссе, диеп
Якмыйбыз ич мичкә дә.
Ерткычлыкны эшләгән егет
Булмадымы Чечняда?

Илшат мәрхүм кайтмагандыр,
Сезнең кулдан үләргә?
Мондый ерткычлыкны эшләгәч,
Сез дә лаек үләргә.

Алай үчегез булса,
Үч алыгыз кул белән.
Әти-әнигә дә күңелле түгел,
Андый явыз ул белән.

Яшьләр, кызлар, сезгә әйтәм:
Кичләрен булсагыз иде аек.
Мондый күңелсезлекләр эшләп,
Йөрмәгез сез моңаеп.

Кулыма каләм алдым,
Мин берегезне дә белмим, күрмим.
Кызгануыма чыдый алмый,
Бу бәетне яздым мин.

Без үскәндә авыр булды,
Йөрдек оек, чабата киеп.
Мондый ерткычлыклар булгач,
Бар халык була боек.

Әллә булдыгыз аек,
Әллә башыгыз ярык.
Илшат мәрхүмне суйганчы,
Суегыз иде бер сарык.

Сарык суеп, уйнап-көлеп
Ашагыз иде шашлык.
Илшатны чүплеккә илтергә
Кайсыгыз булды башлык.

«Чыктык язга, карга, сыерчык килде,
Инде килер үрдәкләр.
Әткәм, энекәшем, сез киярсез,
Миннән калды күлмәкләр.

Зыярат буйлап узганда,
Дога кылып китегез.
Әллә азмыш, әллә язмыш
Минем үлем үкенеч».

Илшатны гәзиттә күргәч,
Бар халык та җылады.
Газап чиктерми калмагыз
Бу аждаһа оланны.

Телевизор карый-карый,
Без артыгын узындык.
Мондый күнелсезлек булгач,
Биткә килә кызыллык.

Әй, балалар, бераздан соң
Кирәк иде сабырлык.
Сез яманлар аркасында
Ата-анага авырлык.

Бәет язам утырып,
Дәфтәр битен тутырып.
Уйларга кирәк иде баштарак,
Инде булмый үкенеп.

Яз көнендә моңсу була,
Сайрарлар инде кошлар.
Газиз баламны үтерде
Бәрәңгедә ерткычлар.

«Әткәм, әнкәм, сезне күргәч,
Шул ук көнне минем гомерем өзелде.
Бу заманда ерткычлар күп,
Сакла, әткәм, үзеңне».

Мондый хәлләр булмас иде,
Балалар, булсагыз аек.
Әллә шөкерлекләр җитми,
Әллә китәбез баеп.

Күзнең матур көннәрендә
Кызырып пешә балан.
Бу хәсрәтне күргән аналарга
Сабырлык телим, балам.

Болай азыну ярамауны –
Аңладыгызмы моны.
Күп елларга барыр әле
Йөрәктә моның моңы.

*Портянур авылында Сабирьянова Нурания*
*Габдерәшит кызыннан (1930 елгы)*
*А. Садыйкова белән Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Тагын бер бәет бәхетсез мәхәббәткә багышланган, авыл тарихы белән бәйле. Аны безгә Куянавылда өч бертуган ханымнар – Фатыйхова Рәмлә, Мавликеева Раймә, Хәмидуллина Раузалия көе белән әйтеп күрсәттеләр.

Бу бәет борынгырак, ул «Фабрика җыры», «Егет белән кыз бәете», «Сәлим белән Мәрҗәнкәй бәете» дип төрлечә атап йөртелә икән. Бу авылда гасыр башындарак кумач фабрикасы, селте заводы, янмый торган кәгазь фабрикасы эшләп торган. Фаҗига шушы кәгазь фабрикасында булган дип сөйләп, көе белән әйтеп бирделәр.

Кызарып кояш чыкканда
Фабрикадан кайталар.
Агуланган Мәрҗәнкәйне
Больницага озаталар.

Кайбер сөйләүчеләр шигырьләр, бәетләр дә яза, мөнәҗәтләре дә бар. Портянур авылында Сабирьянова Нурания Габдерәшит кызыннан (1930 елда туган) 4 бәет язып алдык. Мондый әсәрләрне уку җиңел түгел. Алар кайгы-хәсрәт тулы иҗат. Шул ук вакытта бу әсәрләр милләтнең бер кешесе дөньядан китте, дип халыкка, гавамга белдерәләр. Икенчедән, мәрхүмнең йә мәрхүмәнең исемен авыл, хәтта халык тарихына язып калдыралар, фани дөньяда калганнарны юату да бар аларда. Бәетләр – бик әрнүле әсәрләр. Чыннан да, бер бәет ахырында бик дөрес әйтелә:

Күрмәгәнгә күрсәтмә, Аллам,
Күргәнгә биргел түзем.

## Әби бәете

Шушы кадәр чирләр белән өзелә ич бәгырьләрем,
Яшел зыярат эчләрендә тау булыр каберләрем.

Зыяратта бөтен агач яшел яфраклар ярыр.
Мин гомергә кайтмам инде, бу дөнья миннән калыр.

Каты кайгы-хәсрәтләрем, эчкә батты күзләрем.
Кайгы белән аралашты сезгә сөйләр сүзләрем.

Мин үлде дип, бик елама, балам, васыятьләрем.
Урал таулары кадәр ич минем хәсрәтләрем.

Басуларга чыгыйм дисәң, яшел башлы арыштыр.
Ходаем, Синнән телим ич, балам белән кавыштыр.

Алты-җиде еллар көттем, газиз балам кайта, дип,
Зыяратны үтеп китәр, әнием шунда ята, дип.

Газраилләр керер инде газиз җанымны алырга.
Сагынсам да, кайтмады ич үлгәч туфрак салырга.

Җиде еллар көттем, балам, җиде еллар үтте ич,
Кавышырбыз, дигәндә генә, Ходаем, мәхрүм булдым ич.

Сигез ай авырып ятып, бөтен саннарым катты.
Мине сагынмаган балам апасы янына кайтты.

Минем әҗәл-сырхауларны, Мәгъмүрә, балам, белмәдең.
Тетрәгән, шешле тәннәремне күзең белән күрмәдең.

Тар кабердә, салкын гүрдә ничек итеп ятармын?
Утсыз, кешесез йортларга дога көтеп кайтырмын.

Дога көтеп кайткан чакта мин кемнәргә керермен?
Үз йортларым бикле булгач, кая барырга да белмәмен.

Балам, мин үлгәч елама, кирәк булыр күзләрең.
Сагынсаң да күралмассың әнкәеңнең йөзләрен.

*Олыкыр авылында туган Сәмигуллина Зәмзәмия*
*Гыйният кызыннан (1939 елгы)*
*Бәрәңге авылында А. Низаметдинова язып алды*

## Ни булды, йөрәккәем?

Ни булды, йөрәккәем?
Әкрен генә сызып янасың.
Шул уйларым белән чорнап,
Мине газап дәрьясына саласың.

Нидер юксынасың, моңаясың,
Нидер эзләп син өзелеп сызлыйсың
Һәм кемгәдер, зарыгып эзләгәндәй,
Моңлы тавышың белән җырлыйсың.

Син бит андый түгел идең, йөрәк,
Син уенчык идең, шат идең,
Һаман көләч, һаман шаян идең,
Яшь балалар кебек саф идең.

Һаман уйный идең син елмаеп,
Таң кояшы төсле нурланып,
Мәңге шатлык җырын җырлый идең,
Күбәләктәй, гөлдә тулганып.
Нишләдең син, йөрәккәем,
Ник сызлыйсың, кемне эзлисең?

*Яңавылда Мәхмүтова Флүрә*
*Нургали кызыннан (1935 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

## Балаларым чыкмый истән минем

Әгузү билляхи минәшшәйтанир-ражим
бисмилляхир-рахманир-рахиим.
Балаларым бөтенесе читтә, берсе кабердә.

Сарман көе белән мин көйлимен,
Иртә торып мин чәчләремне тарыймын.

Урамнарга чыгып, мин карыймын,
Күренмәсме, дип газиз балаларым.

Һич туктамый яшь түгәдер ике күзем,
Сары яфрак кебек булды минем йөзем.

Сезнең белән бер авылда булсам үзем,
Хәсрәтемнең бик күбесе бетәр иде.

Кич булгачтын карыйм мин айларга,
Балаларым йөри микән, дип, кайларда?
Алар да карый микән шушы айларга?

Балаларым өчен өзелә үзәкләрем,
Кичен ятсам, йоклый алмыйм, тилмерәм мин.

Ничә хәсрәт уты яна минем эчтә.
Сердәшем юк, киңәшчем юк, ялгыз башым.

Бу башларым тагын ниләр күрер икән?
Ямансулап, җирсәп үтә бар вакытым.

Бәбкәсеннән аерылган казлар кебек,
Көнем-төнем ямансулап үтә минем.

Кайгы-хәсрәт күргәннәрнең бәгъре янар,
Кайгы-хәсрәт күрмәгәннәр уенга санар.

Моны яздым эчем пошкан вакытта уразада,
Ундүрте көнне 2008 нче елда.

*Яңавылда туган Мәхмүтова Флүрә*
*Нургали кызыннан (1935 елгы)*
*А. Низаметдинова язып алды*

Сабирьянова Нурания ападан мөнәҗәтләр дә язып алдык. Берсе «Ана һәм бала» төркеменә кергән «Ялгыз ана» яисә «Моңлы ана» дип аталган әсәр. Мондый эчтәлекле әсәрләр бик күп, башка районнарда, авылларда да язып алынган иде, күчеп йөри торган сюжет китапларга да кердгән («Мөнәҗәтләр». – Казан, 2000. – Б. 94–96). Мондый әсәрләрнең тәрбияви ягы бик көчле, ата-ана хакы татар халкында бик олы һәм мондый хәлләр бик сирәк очрый. Шулай ук аннан «Картлык нишләтә?» дигән мөнәҗәтне язып алдык. Картлыкның кире яклары – авырулар, хәлсезләнү – әсәрдә этаплап күзаллана. 60 яшьтән 90 яшькә бару әзрәк шаяру төсмерләре белән сөйләнә. Шулай да:

Бу картлыкның бер ягы ярый –
Бөтен кешегә бер тигез карый.

Талантлы кешедә төрле жанр әсәрләренә дә сәләт була. Нурания ханымнан язып алганнар арасында кыска җырлар да бар, алар шаян такмаклар белән аралаша:

Печән вакытын уздырып
Төштек хәзер уракка.
Ибраев сүз әйтми дип,
Санамагыз дуракка.

Бәрәңге районы шигырь, бәет чыгаручыларга бай, дидек. Куянавылда Һадиева Нурия Габдулла кызыннан (1953 елда туган, 30 ел балалар бакчасында эшләгән) әтисенә багышланган озын бәет язып алдык. Балаларына, оныкларына багышланган шигырьләре дә бар. 3 айлык оныгына да атап язган ул:

Көлә, диеп шатланабыз,
Елый, диеп борчылабыз.
Күз тимәскә сылукайга
Чуклы кием кидерәбез.

Нурия ханымның оныгы Рушанга багышлаган шигырьләре дә бар:

Түземсезлек белән көттем
Мин туган көнне.
Җыела барча туганнар,
Ай-һай, күңелле!
Туганнарым, беләсезме,
Сөенче барын.
Минем бит әтием килде
Бүләкләр алып.

Баланың шатлыгын әбисе бик матур тасвирлый.

Без язып алган әсәрләр бик күп, барысын да китереп булмый. Казанга кайткач, бер хат килеп төште. Аны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәүлидә Гомәрова җибәргән (Йошкар-Олада эшли). Ул Мазарбашы авылында яшәгән әнисе Гомәрова Мәнфүсә Рәхим кызының 3–4 юллыкларын безгә юллаган. Барысы 104 такмак. Бер төре аның, традицион рәвештә, кеше исемнәренә бәйләп язылган:

Исемнәре Фатыйма;
Очам, дидем, өч тибрәндем,
Бастылар канатыма.
Исемнәре Сабирә;
Суларга агарга уйлыйм,
Туктармын, дим сай җирдә.

Бу шигъри юллар мәхәббәт, аерылу, бәхет, язмыш кебек гомумкешелек темаларына багышланган. Алар татар шигъриятенә хас булган образ-сурәтләр – карурман, сандугач, алмагач, гөлләр, ак чәчәкләр...

Исле гөлләр күп утырттым,
Утыртмадым кынасын.
Күзләремне йома алмыйм,
Күз алдымда торасың.

Билгеле, язып алынган әсәрләрнең дә күбесе архивларда саклаunion, киләчәк буыннар алардан файдаланыр. Бу якның бәет, шигырьләрен аерым китап итеп тә чыгарырга мөмкин булыр иде. Бәрәңге якларында иҗат чишмәләре саекмас, без ишеткән, язып алган, укыган шигырь-бәетләр моның шулай икәнен раслый. Безгә игътибар күрсәткән, иҗат җимешләрен ишеттергән һәр кешегә тирән рәхмәтебез барып ирешсен.

Инде мөнәҗәтләрнең кайберләренә игътибар итик.

## Бисмиллаһи эшләр башы

Бисмиллаһи эшләр башы,
Бисмиллаһи күңгел кошы.
Бисмиллаһи иман нуры,
Әйтә күргел һаман аны.

Ал комганың, ал тәһарәт,
Эшләрең булыр мөбарәк.
Тәһарәт алып гамәл кылсаң,
Күрерсең сән күп хәсәнәт.

Укыгыл иртә намазың,
Алырсың сән күп савабын.
Үлеп каберләргә кергәч,
Күрмәссең сән гүр газабын.

Иртә торып таңга керсәң,
Шайтан вәсвәсә кылыр.
Шул вакытта гамәл кылсаң,
Фәрештәләр дога кылыр.

Әй, Ходаем, сакласана,
Шул шайтанның ширрләреннән*.
Зикер-тәсбих, тәһлилләрне
Чыгармаса күңгелләрдән.

Иман дигән шәриф нәрсә,
Саклаулары бигрәк авыр.
Кабахәт телле булсаң,
Шайтан иманыңны алыр.

Иманыңны яхшы сакла,
Нәҗес сүзләр белән ватма.
Нәҗес сүзләр белән ватып,
Үзеңне тәмугыга атма.

Карама хәрәм малларга,
Авыр килер бер якынга.
Хәләл аз булса да малың,
Шөкер кылсана барына.

Кыйла күргел гамәлләрен,
Уттан сакла бәндәләрең.
Фәрештәләр язып барыр,
Зикер әйткән каләмнәрен.

Әйтә күргел зикер, тәсбих,
Зикер иманның нурлары.
Зикер әйткән бәндәләргә,
Булачак җәннәт хурлары.

Үзең сәламәт чагында,
Кыйла күргел гамәлләрең.
Карыйлыкта кыйла алмассың,
Загыйфьләнер бәдәннәрең.

Намаздыр диннең терәге,
Намаздыр ахирәт бүләге.
Гамәл кылган бәндәләрнең,
Утта янмастыр сөяге.

Үлем-үлем, дип әйтәсез,
Үлем тора яныгызда.
Әҗәлнең вакыты җитсә,
Алып кала алмас малың да.

---

* Ширр – *гар.* усаллык, явызлык.

Үлем килер бер үк вакыт,
Котыла алмассың һичбер качып.
Үлә бәндә шул көннәрне,
Газраил алыр янын басып.

Уйла, бәндә, үләсеңне,
Кара җиргә керәсеңне.
Кара җир астына кергәч,
Ни җаваплар бирәсеңне.

Ни кадәрле куаласаң да,
Җитә алмассың бу дөньяга.
Куган дөнья шулай калыр,
Тар ләхеткә илтеп салыр.

Ни кадәрле җыйсаң малны,
Китәрсең барысын да куеп.
Авызыңнан яның чыккач,
Алырлар күлмәгең суеп.

Күлмәгең суеп алганда,
Башыңнан сулар койганда.
Илтеп ләхеткә куйганда,
Ни җаваплар бирербез анда.

Әҗәлнең вакыты җитәр,
Йөзеңнән нурларың китәр.
Шул вакытта шайтан мәльгун,
Баш очыңа килеп җитәр.

Карама хәрәм малларга,
Хисаплары авыр булыр.
Ялварсагыз бер Аллаһка,
Аллаһ үзе рәхим кылыр.

Әгәр булса сәнең малың,
Бирсәң Ходайның юлына.
Кыямәт көн булган чакта,
Һаман бирер уң кулыңа.

Сәдака бир ятимнәргә,
Икенче бир фәкыйрьләргә.
Өченче бир галимнәргә,
Ходайның сөйгән колына.

Сәдаканы бирә күңгел,
Үзенең сөйгән малыннан.
Кыямәт көн җәннәтләргә,
Юмартлар керәчәк алдан.

Сәдаканы бирә күңгел,
Сәдаканы бирергә кушкан.
Сәдакалы малың булса,
Кыямәт көн булыр дошман.

Зикер белән зиннәтләгез,
Шәриф булган авызларны.
Хорасатның юлын ярап,
Ала күргел азыкларны.

Азыгыңны ал юлларга,
Коралыңны ал кулларга.
Азыксыз юлга чыксаң,
Төшәрсең хәтәр юлларга.

Инанмыйсыз китапларга,
Калырсыз каты хисапларга.
Кылгыл гамәл, кылгыл тәүбә,
Газиз яныңны сакларга.

Сөйләмәгел, бәндә, гайбәт,
Гайбәт гамәлне ашыйдыр.
Үлеп каберләргә кергәч,
Шәриф тәннәрең сасыйдыр.

Җәннәтләрне бик мактыйсыз,
Коры булган телләр белән.
Изге гамәлләр кылмыйсыз,
Юанасыз сүзләр белән.

Йөрмә, бәндә, сән гафләттә,
Калырсың сән бер хәсрәткә.
Гафләт белән вафат булсаң,
Кермәссең сән һичбер җәннәткә.

Җәннәтләргә керәм дисәң,
Алгыл гамәл белән сатып.
Җәннәтләргә керә алмассың,
Һаман гафләтләрдә ятып.

Ходайның барлыгын тотсаң,
Рәсулнең фигылен кылсаң.
Аллаһ җәннәт насыйп итәр,
Һәрбер фаразларны кылсаң.

Бәндә уздыра гомерен,
Һаман гафләтләрдә ятып.
Каты булган газапларны,
Бәндә ала үзе сатып.

Тәмугыдин бик куркасыз,
Эчәсез шайтан шулпасын.
Үлеп каберләргә кергәч,
Сары суларын косарсыз.

Хәрәмгә салма малыңны,
Хәсрәткә салма башыңны.
Хәрәм белән шөгыльләнсәң,
Шайтан изәдер каныңны.

Хәрәм ашап вафат булсаң,
Тәмугыга башың китәр.
Хәрәм ашап, хәрәм эчсәң,
Иманыңның нуры китәр.

Лә иләһә Иллаллаһ –
Зикер тәсбихның баскычы.
Лә иләһә Иллаллаһ –
Сигез җәннәтнең ачкычы.

Лә иләһә Иллаллаһ
Даим әйткел һәм сән аны.
Лә иләһә Иллаллаһны
Күп әйткәннәрнең
Җәннәтләрдә булыр җаны.

## Әҗәлнең вакыты җитәр

Лә иләһә Иллаллаһның
Карамагыз азына.
Лә иләһә Иллаллаһ –
Мәңге бетмәс хәзинәдер.

Лә иләһә Иллаллаһ –
Гарши-көрси баскычыдыр.
Лә иләһә Иллаллаһ –
Сигез җәннәт ачкычыдыр.

Мәет әйтер: «Әй, кардәшләр,
Күлмәгемне салдырасыз.
Шәриф булган газиз тәнем,
Ялангачка калдырасыз».

Мәет әйтер: «Әй, кардәшләр,
Ачсагыз ла юрганнарым.
Китәмен бакый йортларга,
Күреп калсын туганнарым.

Пәрдә корыгыз өстемә,
Бүзләр ябыгыз йөземә.
Сөякләрем төзәткәчтен,
Тәһлил әйтегез үземә».

Мәетләрнең тәне тетрәр,
Юарга илтеп куйганда.
«Зинһар, йомшак тотсагыз ла,
Өстемә сулар куйганда.

Җеназамны күтәргәчтен,
Сабыр итеп барсагыз ла.
Ләхетләргә иңдергәндә,
Зикер әйтеп салсагыз ла.

Ләхетләрдә иңдергәндә,
Чишсәгез лә аякларым.
Ялгыз калам тар ләхеттә,
Нихәл бирим җавапларым.

Әй, кардәшләр, васыятем,
Ләхетемне киң уегыз.
Җеназамны күтәргәчтен,
Изге исемнән куегыз».

Хуш инде, хуш килдең,
Ни гамәлләр син китердең?
Куйдың, бәндә, дөньяны,
Үлмәс кебек булып йөрдең.

Мөнкир-Нәнкир җавап алыр,
Раббың кем сәнең, диярләр.
Икенчедәй җавапларда
Рәсүлең кем сәнең, диярләр.

Әгәр бирсәк безләр җавап,
Раббым бер Аллаһым, дәеп.
Хак пигамбәр Рәсүллулла,
Мөхәммәд өммәте, дәеп.

Хуш инде, бәндә, изгедер җавап,
Ходаем бирсен лә җәннәт.
Әгәр бирә алмасак җавап,
Эшләребез булыр харап.

Әй, Ходаем, бир нosрат,
Җавапларыбызны бирергә.
Җавапларыбызны бирә алмасак,
Белмәбез нә дияргә.

Әй, Ходаем, күрсәтсәнә,
Мәрхәмәтле карәмәтең.
Әй, Ходаем, насыйп иткел,
Рәсүллүлла шәфәгәтен.

Әйтә күргел салават шәриф,
Рәсүлулланың үзенә.
Кыямәт көне булганда,
Карарбыз аның йөзенә.

Кыямәтнең катысыннан,
Барча пигамбәрләр елар.
Шул вакытта Рәсүлулла,
Өммәтем, дип безне сорар.

Элек килгән пигамбәрләр
Өммәтләрен искә алмас.
Шул вакытта Рәсүлулла,
Өммәтем, дип телдән салмас.

Рәсүлулла сорар безне,
Өммәтемне ярлыка, дип.
Гөнаһлы өммәтләрем,
Тәмугыда калдырма, дип.

Ходавәндә, диләр анда,
Ярлыка бәнем өммәтемне.
Я хөббием, сәнең хакка
Багышладым җәннәтемне.

Фәрештәләр диләр анда,
Килдең Хода хозурына.
Гөнаһың күп, хәлең юк,
Тиешле син тәмугыга.

Иманлы булган бәндәне
Фәрештәләр каршы алыр.
Ходайның рәхмәте, дәеп,
Рәхәт җиргә алып барыр.

Кыямәт көн булган көнне,
Җәннәтләрне зиннәтләрләр,
Иманлы булган бәндәне,
Фәрештәләр хөрмәтләрләр.

Әй, Ходаем, рәхмәтең зур,
Дәфтәремне кылсаң уңга.
Гөнаһымны гафу итеп,
Китерсәнә изге юлга.

Гамәл дәфтәре булса уңнан,
Ходамның рәхмәте булыр.
Дәфтәребез булса сулдан,
Ходамның ләгънәте булыр.

Нәмаларны биргәннән соң,
Һәрбер бәндә үзе укыр.
Кыямәтнең булачагын
Һич белмәгән бәндә юктыр.

Нәмаларны укыгачтын,
Бәндәләр торырлар карап.
Дөньяда ни кылганын
Авызлары бирер җавап.

Нәмаларны укыгачтын,
Бәндәләрнең һушы китәр.
Гөнаһлы бәндәләргә
Зөбанилар килеп җитәр.

Кыямәтнең кызуындин,
Бәндәләрнең мие кайнар.
Ул вакытта фәрештәләр,
Иманлы бәндәне сайлар.

Кыямәтнең булачагын,
Сөйләде бит китаплар да.
Галимнәр әйтте бит сезгә,
Хурландыгыз ул чакларда.

Фәрештәләр нида кылыр,
Монда да каты кыямәт.
Дөньяда вакытларда,
Кемнәр кылгандыр хыянәт.

Мизаннарга, үлгәчтен,
Бәндәләрне озатырлар.
Бергеләре китәр җәннәткә,
Бергеләре китәр дузахка.

Гөнаһлы бәндәләрне,
Тәмугыга төшерерләр.
Сусадык, дип кычкыргачтын,
Сары сулар эчерерләр.

Кыямәтнең газаплары,
Кайнар тәмуг казаннары.
Тәмугыга китәрләр,
Бәндәләрнең яманнары.

Кыямәт көн булган чакта,
Тәмугларда аждаһалар.
Каты-каты сызгырырлар,
Әллә-ниләр яварлар.

Тәмугының чокырлары,
Казан кебек кайныйдыр.
Гөнаһлы бәндәләрне,
Еланнар да газаплыйдыр.

Иманлы бәндә булса ул,
Сират күперен кичеп китәр.
Сиратларны кичкәннән соң,
Рәхәт җиргә барып җитәр.

Әй, Ходаем, рәхмәтең зур,
Кылмасана безне газап.
Гөнаһымдин гафу итеп,
Тәмугыдин кылсаң азат.

Кыямәт көн шундый көн ул,
Һичбер кемнән ярдәм булмас.
Хәсән белән Хөсәенне
Раббым кылса үзе юлдаш.

Кыямәт көн, шундый көн ул,
Булмастыр анда юлдаш.
Һәм булмастыр анда ярдәм,
Һәм булмастыр анда иптәш.

Намазың буладыр юлдаш,
Тәсбихең буладыр кардәш.
Сәдакаларың булыр юлдаш,
Догаларың булыр кардәш.

Әүвәлге груһы кубар,
Башлары буладыр кисек.
Дөньяда вакытларда
Йөргәннәр хәрәм эчеп.

Икенче груһы кубар,
Куллары буладыр кисек.
Дөньяда вакытларда
Кылганнардыр хәрәм кәсеп.

Өченче груһы кубар,
Кара булгандыр йөзләре.
Дөньяда вакытларда
Гайбәт булгандыр сүзләре.

Дүртенче груһы кубар,
Йөрерләр тезләре белән.
Дөньяда вакытларда
Йөргәннәр шайтан сүзе белән.

Бишенче груһы кубар,
Муйнына елан чолганган.
Дөньяда вакытларда
Фарыз гамәлләр кылмаган.

Алтынчы груһы кубар,
Авызындин телен чәйнәп.
Дөньяда вакытларда
Сөйләгәндер каты гайбәт.

Җиденче груһы кубар,
Фәрезендин каннар агар.
Дөньяда вакытларда
Зина кылганнардыр алар.

Әүвәлге груһы кубар,
Башларына таҗ кигәннәр.
Дөньяда вакытларда
Изге гамәлләр кылганнар.

Икенче груһы кубар
Яшел хөлләләр кигәннәр.
Дөньяда вакытларда,
Хәләл нигъмәтләр кылганнар.

Өченче груһы кубар,
Нур булгандыр йөзләре.
Дөньяда вакытларда
Зикер булгандыр сүзләре.

Дүртенче груһы кубар,
Пыракларга менгәннәр.
Дөньяда вакытларда
Фарыз гамәлләр кылганнар.

Җаннар әйтер газиз тәнгә,
Бәхил булгыл, газиз тәнем.
Ни җаваплар бирермен бән,
Авырдыр ла бәнем хәлем.

Тәннәр әйтер, газиз җаным,
Китәсеңме, бәни куеп?
Кыямәт көн булмаенча,
Булмас, җаным, сәни күреп.

*Олыкыр авылында Шәйхетдинова Кафия*
*Әхмәтсафа кызының (1937 елгы)*
*Гөлзәйнәп әбисе дәфтәреннән*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Укытыгыз Коръән

Сөйлим әле, балаларым,
Сүзләремдә барлык моңнарым.
Вафат булсам, укытыгыз Коръән,
Тәрәзәдән кайтып тыңлармын.

Зинһар әйтәм, балам,
үзең укы Коръән,
Үтенечем сезгә шул булыр.
Әтиегез белән, миңа атап,
Коръән укысагыз,
Кабер эчебездә нур булыр.

Зинһар, әйтәм сезгә, балаларым,
Иң газизем сез бит, бәбкәем.
Атна киче җиткәч, яным кайтыр,
Ак күбәләк булып, бәбкәем.

Тар кабердә, кара гүр эчендә,
Сез балалардан дога көтәрбез.
Дога булса, без дә шат булырбыз,
Оныта калсагыз, ни хәл итәрбез.

Зинһар әйтәм, минем балаларым,
Бәхил булып миннән калыгыз.
Алып барып гүргә иңдергәч тә,
Тәһлил әйтеп туфрак салыгыз.

Юк, еламагыз, минем балаларым,
Аерылып миннән калганда.
Бер Ходаем тел ачкычы бирсен,
Мөнкир-Нәнкир җавап алганда.

Ялгызымнан дөнья эше өчен,
Җавап алыр өчен килерләр.
Чын иманым булса яннарымда,
Җәннәтләрдә урын бирерләр.

Зинһар, әйтәм сезгә, балаларым,
Уздырыгыз минем өчемне.
Сәдакалар биреп дога кылдыр,
Буш иттермә атна кичемне.

Җидемне дә, балам, үткәрә күр,
Кырыгымны аннан онытма.
Башка кеше өчен гыйбрәт булыр,
Каберемә баргаларга онытма.

Көннәр үтәр, елым җитәр,
Исегезгә алыгыз тагын да.
Догаларыгызны укыгыз, балам,
Сау-сәламәт булган чагында.

Моны яздым көндез җомга көнне,
Көндезге җил әкрен искәндә.
Йөрәкләрем әрни, күңел ярсый,
Үләселәр искә төшкәндә.

Ямьсез үлемнәрдән үзең сакла,
Хәерле үлемнәр бир, Ходаем.
Авызымнан яным чыккан чакта,
Үзем белән булсын иманым.

*Олыкыр авылында Шәйхетдинова Кафия*
*Әхмәтсафа кызыннан (1937 елгы)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Ана васыяте

Ниләр языйм сезгә, балаларым,
Күңелегездә мәңге калырлык.
Мин үлгәч тә, балаларым, мине
сагынып,
Әнкәем, дип искә алырлык.
Сөйлим әле сезгә, балаларым,
Сүзләрем түгел, моңнарым.
Мин үлгәч тә, укытыгыз Коръән,
Тәрәзәдән кайтып тыңлармын.
Зинһар өчен, мине онытмагыз,
Минем васыятем шул булыр.
Сез миңа Коръән укытсагыз,
Каберләрем өсләренә нур булыр.
Балаларым, мине онытмагыз,
Мин бит сезнең газиз анагыз.
Атна кичләрендә җаным кайтыр,
Булмас, кайтмас, диеп әйтмәгез.
Зинһар укытыгыз миңа Коръән,
Минем җаным кайтыр тыңларга.
Шушы сүзләремне калдырамын,
Онытмагыз, диеп сезләргә.
Кабер эчләрендә мин ятырмын,
Балалардан дога көтәрмен.
Дога барса, рәхәт ятырмын да,
Онытсалар, ни хәл итәрмен.
Сәдака бирегез минем өчен,
Мине яткырмагыз газапта.
Мин бит аннан кайтып сорый
алмыйм,
Мин бит тоткында, сез азатта.
Сур мугезләренә бер җыелгач,
Чыгып йөрүләр юк безгә.
Балаларым, ихлас белән әйтәм,
Уздырыгыз минем өчемне.
Белгәннәргә биреп укытыгыз,
Буш итмәгез атна кичемне.
Балаларым, тагын шуны әйтәм,
Уздырыгыз минем җидемне дә.
Коръән укытып, багышласагыз,
Тыныч булыр яткан җирем дә.
Балаларым, сезгә васыять әйтәм,
Бу бит минем актык сүзләрем.
Сез онытмый Коръән укытсагыз,
Якты булыр минем гүрләрем.
Укытыгыз, балаларым, Коръән,
Кырыгымда һәм дә елымда.
Сезнең өчен зур дәүләт булыр,
Оҗмах ачкычы ана кулында.
Еламагыз һәм дә яшь түкмәгез,
Миндән аерылып калганда.
Раббым Аллаһым тел ачкычы
бирсен,
Мөнкир-Нәнкир җавап алганда.
Якты дөньяларда яшәгәндә
Кайгы белән үтте ямем.
Җир астында калгач ялгыз
башым,
Нурлы иманым булсын юлдашым.
Кабер эчләренә күмеп киткәч,
Җавап алыр өчен килерләр.
Нурлы иманым булса яннарымда,
Җәннәтләрдә урын бирерләр.
Зинһар, әйтәм, барча мөэминнәр
Миннән риза булып калыгыз.
Алып барып гүрләремә куйгач,
Тәһлил әйтеп балчык салыгыз.
Юучылар, сезгә әйтәм шуны,
Бигрәк таман булсын суыгыз.
Чын күңелдән сездән үтенәмен,
Догалар әйтеп юыгыз.
Юучылар укып дога кылсын, диеп,
Язам, бармакларымны талдырам.
Мине сагынганда укырсыз, дип,
Васыятемне язып калдырам.

*Портчара авылында Сәгъдуллина*
*Самәвия Йосыф кызыннан (1931 елгы)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Ялгыз ана (Моңлы ана)

Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран?
Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач ак сөтемне бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баламнан катылык күрдем.
Бала анага бик татлы,
Барча тәннәрне пакьлый.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран
Ана күңелен бала тапмый.
Үләр хәлләремә җиткәч,
Хәлемне сорамый балам.
Бала бәгыре каты икән,
Бәхилләп үлми бит анаң.

Авырсам да ышанмадың,
Хәлемне һич сорамадың.
Авыр булса да хәлләрем,
Тузан чаклы кызганмадың.
Әй, бәбкәем, газиз балам,
Мин бит синең тапкан анаң.
Туган көнеңдә шатландым,
Хөрмәт итәр, диеп балам.
Әй, газиз бәгырем, парәм,
Ике күземдәге карам.
Мин үлеп гүрләргә кергәч,
Табылмас бит газиз анаң.
Хөрмәт күрәсегез килер,
Синең дә булыр газиз балаң!

## Картлык нишләтә?

Явыз бу картлык, шәфкать юк анда,
Кара җирләргә илтеп тә кертә.

Бу картлыкның да бер ягы ярый,
Бөтен кешене бер тигез карый.

Булсын ул бик бай, булсын ул түрә,
Фәкыйрь булса да бертигез күрә.

Алтмыштан узгач, картлык башлана,
Дөнья кирәкми, эш ташлана.

Җитмешкә кадәр барыбер эшли,
Бу картлыкка әле бирешми.

Җитмеш биштә эшләми башлый,
Авыр эшләрне бөтенләй ташлый.

Сиксәнгә җиткәч, эшләми башлый,
Барлык эшләрне кулыннан ташлый.

Ул чыга юлга өч аяк белән, әкрен генә бара да бара,
Алай да үзе байтак юл ала.

Сиксән бишкә җиткәч, бераз туктала,
Бераз ял иткәч, бераз юл ала.
Бара-бара да, юлдан адаша, югала.

Туксан яшенә җиткәч, таягын ташлый,
Караватыннан төшми дә башлый.

Ята да ята, торып бераз утыра,
Утыргач арый, яту ягын тизерәк карый.

Ашаганын түгәргә баралмый башлый,
Картлыкның соңгы чарасы, сиксән белән туксан арасы.

Тыныч булсын, якты булсын, гөрләп торсын илебез.
Кул күтәреп дога кылыйк, күтәрелсен динебез.

*Портянур авылында Сабирьянова*
*Нурания Габдерәшит кызыннан (1930 елда туган)*
*А. Садыйкова белән Л. Мөхәмәтшина язып алды*

## Әтиемә бәет

Соңгы юлга озатканда,
Әти балам, бик читен.
Бик күңелле яши идек,
Безне калдырып киттең.

Армиягә озатканда,
Балам, дип өзгәләндең,
Соңгы юлга киткәндә,
Улыңны күрә алмадың.

Авыруыңның башыннан,
Бигрәкләр дә кайгырдың.
Мәчет кебек йортларыңда
Әнине үзен генә калдырдың.

Даруның тартмалары,
Күп итеп эчеп баксаң да,
Тимәде файдалары.

Хәлләреңне бик белдек,
Шуңа күрә, көн саен
Яннарыңа йөгердек.

Кыш буйлары авырып,
Матур җәйләргә чыкканда,
Киттең безне калдырып.

Больнислардан көттек сине,
Исән кайтырсың, диеп.
Каршы алырга, дип чыктык,
Башларыбызны иеп.

Яннарыңа көн дә төштем,
Хәлләремне сөйләргә.

Инде хәзер калдың безгә,
Сагынып кына сөйләргә.

Хәлләреңне аңладык,
Сиңа дәва китерә торган,
Бер киңәш бирә алмадык.

Үләм, диеп үлмәдең,
Балаларым, дия-дия,
Бер рәхәт тә күрмәдең.

Өсләреңне салдырдым,
Манма суларга батканчы,
Ясалма сулыш алдырдым.

Эшләрдән син качмадың,
Үкереп-үкереп еласам да,
Күзләреңне ачмадың.

Больницларга баргач кына,
Килдең син аңнарыңа.
Тик шунысы үкенечле,
Бармадым яннарыңа.

Күзләреңне ачкач та син,
Сорадың Нураныңны.
Соңгы мәртәбә ябындың,
Аппарган юрганыңны.

Больницларга киткәчтен,
Керләреңне юды ул.
Тазарып кайткач кияр, дип,
Киптереп, үтүкләп куйды ул.

Матур иде өсләрең,
Тап-таза килеш китте ич
Авызыңда тешләрең.

Бар нәрсәң дә бар иде,
Артык кайгырып җибәрдең,
Торырлыгың бар иде.

Эшли алмас булдың син
Эшләгән эшләреңне.
Соңгы мәртәбә күрдем, дип,
Сөйләдең төшләреңне.

Килгән чакта аңыңа,
Торды кызың яныңда.
Кайда мин, дип сорадың,
Тазарырга юрадың.

Өсләреңә киертте
Уртанчы кызың күлмәк.
Тик насыйп булмады аны
Кияргә генә күбрәк.

«Олы кызым Нурдидәм,
Син сабырлы, син чыдам.
Шуңа күрә булдың син,
Килгәндә дә аңыма, үлгәндә дә
янымда».

Зиратлардан узган чакта,
Каберләрең күренә.
Йөрәкләрдән китмәс булып,
Калдың безнең күңелдә.

Зиратлардан узган чакта,
Кабереңә карамыйм.
Каберләреңә карасам,
Барыр юлым бара алмыйм.

Үлгән хәбәреңне алып,
Кайтты улың яныңа.
Тик хәлләреңне белде ул
Каберләрең янында.

«Хәлләремне сорамагыз,
Хәзер инде, кайтып булмый,
Балаларым, еламагыз.

Балаларым, барчагыз,
Әниегезне онытмагыз.
Миннән изге теләк шул,
Тигез рәхәт яшәгез.

Еллар үтәр, көзләр җитәр,
Кайтырсың, улым, син дә.
Тик мин хәзер кабердә,
Әниеңне син кадерлә».

*Куянаывлда Һадиева Нурания*
*Габдулла кызыннан (1953 елгы)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

# КҮҢЕЛДӘГЕ ҖЫРЛАР

*Ләйлә Мөхәмәтшина*

Халкыбызның рухи ядкярләрен туплау-барлау, киләчәк буыннарга тапшыру бүген аеруча мөһим, чөнки аларның күпчелеге заманча шартларда, көндәлек тормышта кулланылмый диярлек. Шунлыктан фольклор әсәрләренең кайбер төрләре, мәсәлән, тарихи җырлар, озын лирик җырлар, уен-бию җырлары онытыла бара. Ә менә дүрт юлдан торган кыска җырлар, лирик дүртьюллыклар әле дә еш яңгырый. Алар, гадәттә, авыл, урам көйләренә башкарыла, бер көйдән икенчесенә җиңел күчеп йөри; бер үк көйгә берничә дүртьюллыклар иҗат ителә, җырлана.

Күңелдә уянган катлаулы кичерешләрне, хис-тойгыларны башкалар белән бүлешергә, уртаклашырга да җыр ярдәм итә. Лирик җырларда һәркемнең күңелендә булган уйланулар, кичерешләр урын тапкан. Гадәттә, җырчы үзенә ошаган, уй-кичерешләренә якын, сәнгати яктан югары булган бер куплет сайлап җырлый һәм бу җыр кеше хисенең, кичерешләренең билгеле бер моментын гына чагылдыра. Ягъни лирик дүртьюллыкларда хис-кичерешләр дәвамлы, сюжетлы төс алмый.

Кыска җырлар татарлар яшәгән һәр авылда башкарыла. Үзенең кечкенә формасы, көенең гади һәм җиңел яңгырашы белән кыска җыр һәркемгә якын, таныш. Ул авыл урамында да, аулак өйдә, клубта да, бәйрәм-мәҗлесләрдә дә яңгырый. Аның ярдәмендә борчу-шатлыкны да, тирән кичерешләр һәм фәлсәфи уйлануларны да җиткерергә мөмкин.

Авылларда җыр иң популяр, киң таралган жанрларның берсе. Моның сәбәбе җыр жанрының үзенчәлекләре белән аңлатыла. Фольклорчы галим Ким Миңнуллин сүзләре белән әйткәндә, җырлар

кешенең аерылгысыз юлдашы буларак, теләсә кайсы вакытта, төрле урында башкарылып, аның күңеленә гаять якын торып, һәрвакыт юатып, тирән кайгы-хәсрәтен һәм кичерешләрен уртаклашалар[1].

Җырлар халыкның тормыш-көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән. Алар төрле бәйрәмнәрдә, йолалар, гореф-гадәтләр, күңел ачулар вакытында башкарыла. Кыска җырларга җитдилек тә, шаянлык та, драматизм да, лиризм да хас. Әлеге җырларның яшәү, таралу даирәләре киң, шунлыктан аларда сурәтләнгән темалар да күптөрле.

И. Надиров «Татар халык җырлары. Кыска җырлар» (Казан, 1976) дигән фәнни хезмәтендә кыска җырларны түбәндәге темаларга бүлә: тормыш-көнкүреш турында уйланулар, кайгы-хәсрәт, өмет, ышаныч җырлары; егетлек, уңганлык турындагы җырлар; читтә бәхет эзләүчеләр, зимагурлар, шахтерлар турындагы җырлар; рекрутлар, солдатлар, әсирләр арасында туган җырлар; туган җир һәм туган якны сагыну җырлары; хатын-кыз язмышына багышланган җырлар; дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары; кеше гомере, яшәү кадере турындагы җырлар; мәхәббәт җырлары; чәнечкеле-шаян җырлар; хат битләрендәге җырлар; иҗтимагый-лирик җырлар.

Мари Элга оештырылган экспедиция вакытында тупланган материаллардан чыгып фикер йөрткәндә, бу төбәктә язып алынган җырларны да төрле темаларга бүлеп карарга була. Алар да, нигездә, үзләренең табигате белән лирик характерда. Анда җырчының тирә-юньгә мөнәсәбәте, уй-тойгылары, хис-кичерешләре сурәтләнә. Мондый җырларда, кайгы-хәсрәт, сагыш мотивларын да, күңел ачу, җиңелчә шаяру авазларын да тоярга мөмкин.

Экспедиция материалларын анализлау биредә актив кулланылган җырларның, уеннарның төрен ачыкларга, әлеге төбәккә генә хас үзенчәлекле җырларны, шулай ук барлык татарлар яшәгән төбәкләрдә дә актив кулланыла торган популяр җырларны да ишетергә мөмкинлек бирде.

Әйтергә кирәк, милли җәүһәрләр күпчелек очракта өлкән яшьтәгеләр хәтерендә яхшырак сакланган.

Портянур авылыннан Хәлиуллина Фахирә (1921) безгә үзләре яшь вакытта җырлаган, яшь гомер, яшәү кадере тематикасына караган җырлар башкарды, үзләре уйнаган уеннар турында сөйләде.

---

[1] *Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 60.

Яшь гомерләр – бер вакыт,
Яшь гомердән туймагыз.
Вакыт җитми яшь гомернең
Чәчәкләрен коймагыз.

Яшь гомер ул шундый гаҗәп,
Бер корыгач чәчәк атмый.
Суга төшкән энҗе кебек,
Югалса, кире кайтмый.

Яшьлегем чәчәк атканда
Мин сине сөйгән идем.
Мондый күңелсез тормышка
Калдырмас, дигән идем.

Элек су буенда гөрләп торган яшьләр уеннарын да, аулак өйләр, каз өмәсе уеннарын да әби-бабайлар риваять итеп сөйлиләр. Яз көне карлар эреп, җир чыккач, яшьләр су буена уйнарга төшә торган булганнар. Анда төрле уеннар уйнаганнар.

*«Яшь вакытта урта казык, круг уены уйный торган идек.*

*Кар эри башлагач, күчкә төшер идек. Боз эри башлагач, боз китүне «күч китү» дип атыйлар. Боз киткәндә елга буена төшеп уеннар уйный идек. Каеш сугыш уеннарын. Тезелеп утыралар да, бер егетнең кулында каеш була, ул каеш белән ботка суга да и уртада урындык була, шуңа каешны илтеп куеп, үз урынына утырырга тиеш, өлгермәсә, каешны ала да аңа шалт итеп суга. Җәза бирәләр иде, өч тапкыр калса.*

*Шырпы салыш уйныйлар. «Кемдә шырпы, сикереп чык», – дип әйтәләр иде, тотып кала алсалар, тотып калалар иде.*

*Капкалы уеннарын уйнадык. Аны парлап уйныйлар. Җыр туктагач, кемнәр капка уртасында кала, шуларга җәза бирәләр иде, биергә, җырларга, шигырь сөйләргә.*

*Гөлбарый уенын уйный идек. Анда шундый такмак әйтелә иде:*

*Исемнәре, исемнәре,*
*Исемнәре Гөлбарый,*
*Ни уйнасаң, ни кылансаң,*
*Шуны эшләргә ярый.*

*Музыка туктагач, ул нинди хәлдә кала, ни кылана, шуны эшлисең инде».*

*Портянур авылында Хәлиуллина Фахирәдән (1921 елгы)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Кыска җырлар, гадәттә 4 юллыклардан торсалар да, Куянавылда яшәүче Шәрәфетдинова Мәрьям (Гөльяүһәр) һәм Шәрифьянова Оркыя 3–4 юллыклардан торган кыска җырларны моңлы итеп, борынгы көйгә башкардылар.

Мин яратам җырларга.
Борылып аккан сулар кебек,
Чумам, төрле уйларга.

Нигә тала beләгем,
Хәсрәтем дә юк шикелле,
Яна минем йөрәгем.

«Уф» дияргә ярамый,
Теләмәгән агачында,
Кошлар моңлы сайрамый.

Күке кычкыра өзеп,
Күке кычкырганда өзеп,
Ничек торырмын түзеп.

Теләкләр теләр идек,
Теләк теләп кавыштык, дип,
Гомергә сөйләр идек.

Китәм, димә, калдырма,
Мин таянган иңбашыңа
Ятларны таяндырма.

... Карап каерылгач та,
Рәхәт яшә, матур яшә,
Миннән аерылгач та..

Ага сулар болганып,
Аккан суда битем юам,
Ялгыз башым моңаеп.

Уйнашу да көлешү ...
Бер аерылгач булыр микән,
Сезнең белән күрешү.

... Гармун уйнаучыларны.
Үзем белән тиңдәш күрәм,
Күп уй уйлаучыларны.

Яшь вакытта уйнарга да,
Күкрәргә дә көч җитә,
Ләкин кадерен белү кирәк,
Яшь вакытлар тиз үтә.

Яшьлек бит ул интересный,
Бер китсә, кире кайтмый.
Суга төшкән энҗеләр күк,
Югала, кире кайтмый.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Акча сорыйсыз мәллә.
Ярларыгыз килмәгәнгә
Ямансылыйсыз мәллә.

Акча да сорамыйбыз ...
Ярларыбыз юк, дип әйтеп,
Сездән яр сорамыйбыз.

... Тургай, баласын җуйган бугай.
Баласын җуйган кош кебек,
Моңланып үләм бугай.

Ник талайкән беләгем?
Хәсрәтем дә юк шикелле,
Ник янайкән йөрәгем?

... Салдым да тартып алдым,
Нигә салдым кулларымны,
Дигән көннәргә калдым.

Так муеныңа гәрәбә,
Сагынсын да, саргайсын да,
Дигән Ходай Тәгалә.

Унны ды, тугызны да ...
Гөл чәчәгенә охшатам,
Дуслар барыгызны да.

*Куянавылда Шәрифьянова Оркыя (1937) һәм*
*Шәрәфетдинова Мәрьям (Гөльяүһәр) Хуҗа кызыннан (1930)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Хәзер дуслар, сирәк очрашабыз,
Ягез, бергә җырлап утырыйк.
Бергә җыелганда матур итеп,
Онытылмаслык итеп уздырыйк.

Бергә җыелганда матур итеп,
Бергә сөйләшүдән кем туя.
Һәр кешенең узган гомерендә
Онытылмаслык матур көне бар.

*Куянавылда Габдрахманова Дания*
*Кадыйр кызыннан (1939)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Биредә өлкән, 85–90 яшьтәгеләрдә элек уйнала торган уеннар, уздырылган арбалы җыен, җиләк атналары турында да бераз хатирәләр сакланган. Портянур авылыннан Габдуллин Галиулла Габдулла улы әлеге күренешләр турында яшь вакытта үзләре җырлаган җырларны исенә төшерде.

Сандугач бик моңлы сайрый,
Су буенда тирәктә.
Күз карашың бигрәк матур,
Ял бирә ич йөрәккә.

Бакчаларда алма пешә,
Кызарып алма төшә.
Алма кебек сөйгән ярым
Көн дә исемә төшә.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Чәчем сибелә җилләрдә.
Икәү бергә тормыш корыйк
Туып-үскән илләрдә.

Аклы күлмәгең бар икән,
Иңнәрең дә тар икән.
Агым суны туктатырлык
Мәхәббәтең бар икән.

Агым су ага башлый,
Дулкынын кага башлый.
Иртә торуларым белән
Йөрәгем яна башлый.

*«Без яшь чагында, егетләр-кызлар эштән кайткач, су буенда безнең борулар бар, шуның бер боруында җыелып, тальян белән күңелле итеп уен уйный идек.*

*Арбалы җыен. Җир кибә, арба тәгәри башлый, шул вакытта арбалы җыен була иде, ул бер өч көн була иде. Монда балалар да, егетләр-кызлар, олы ирләр дә була иде. Кеше күп була, почти сабантуй кадәр.*

*Аннары, сабанны чәчеп бетергәч, сабантуй була. Иң алда атларны-арбаларны тасмалар белән бизәп йөреп, бүләк җыялар иде бәйгегә.*

*Сабан туеннан соң җиләк атнасы була иде, кара җиләк атнасы, кура җиләк атнасы. Атларга төялеп, бар халык җырлап, уйнап урманга җиләккә баралар иде».*

*Портянур авылыннан Габдуллин*
*Галиулла Габдулла улыннан (1926)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Бәрәңге районында элек сабантуй бәйрәме бер атна алдан башланып, бер атна соң беткән. *«Сабантуйдан соң ике атна кичке уеннар була иде. Яшьләр, егетләр, кызлар җыелып уеннар уйныйлар иде. Кул белән кагыш туп; чокыр туп (ничә кеше уйный, барысы да үз алдына чокыр казыйлар да, тупны тәгәрәтәләр, кемнең чокырына төшә, шуңа җәза бирәләр, биетер идек тә, җырлатыр идек); алдырым-алдырым ата каз, бирмәм-бирмәм битә (ана) каз (беребезнең итәгенә беребез тотынабыз да, ата каз алмакчы була, ана каз бирми иде), урта казык, түгәрәк уеннары, шырпы салышлар уйныйлар, чыгып бииләр иде. Әпипә биюе бар иде. Бию вакытында круг әйләнеп «Гөлнәзирә», «Әпипә»не җырлап уйный идек, шундый такмаклар әйтәләр иде:*

*Әйдә, иркәм, кил әле,*
*Икәү әйләник әле.*
*Әйләнсәң, әйләнмәсәң дә,*
*Синең дустың мин әле.*

*Ай-ли, Хәтирә,*
*Хатлары сирәк килә.*
*Хатлары сирәк килсә дә,*
*Көтәргә туры килә».*

*Яңавылда Галләмова Хәдичә*
*Гыйбадулла кызыннан (1939),*
*Портянур авылында Сабирьянова Нурания*
*Габдерәшит кызыннан (1930)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Куянавылда кичке уеннар турында сөйләп кенә калмадылар, әлеге уеннарның күренешләрен уйнап та күрсәттеләр.

*«Без яшь вакытта кичке уеннар бар иде. Матур итеп кичке уенга төшә идек. «Шакатур» , «Шырпы салыш», «Каеш» уеннары, «Круг» уйный идек. Уен уйнаганда җырлар да җырлый идек:*

*... Матур итеп киенгән.*
*Чәчләрең озын билеңнән,*
*Чыгармаслар илеңнән.*

*Бас әле бер генә,*
*Ике бите гөл генә.*
*Син авылларда бер генә,*
*Сине сөймәс кем генә.*

*Кашың кара, буең зифа,*
*Сине сөймәс кем генә.*

*Әйтә ул теләкләрен ...*
*Син дә телә, мин дә телим,*
*Кавышу теләкләрен.*

*Бас әле, бер генә,*
*Ике бите гөл генә.*
*Син авылларда бер генә,*
*Сине сөймәс кем генә.*

*Кашың кара, буең зифа,*
*Аны сөймәс кем генә.*

*Шулай түгәрәкләнәсең дә, ике кеше уртага чыгып бии, йә егет сине тартып ала.*

*Кашың кара уелган,*
*Кашыңның бер почмагына*
*«Сөйгәнең» дип куелган.*

*Бас әле, бер генә,*
*Ике бите гөл генә.*
*Син авылларда бер генә,*
*Сине сөймәс кем генә.*

*Кашың кара, буең зифа,*
*Сине сөймәс кем генә.*

*Аннары «Шакатур» уены уйный идек.*

*Ай-ли шакатур,*
*Шакатурлары матур.*
*Үзе матур, үзеннән дә,*
*Сөйгән ярлары матур.*

*Шулай җырлагач, бер иптәш берәрсен алып чыга да, аннан яңадан икенчесе алга чыгып бара, бу уенны егетләр белән кызлар тезелеп басып уйныйлар иде».*

*Куянавылда Фатыйхова Рәмлә*
*Мөэмин кызы (1950), Хәмидуллина Раузалия (1955),*
*Мәүликиева Раймә Мөэмин кызыннан (1961)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

*«Бию алыш уйныйлар иде. Гармунда бию көе уйный, бер кыз чыга да егетне чакыра, егет чыга икән кызны чакыра, бер пар кереп китәр иде, икенчесе чыгар иде, яңадан шулай итеп уен дәвам итә иде. Уен барышында кара-каршы тезелешеп баскан егетләр һәм кызлар бер-берсенә багышлап җырлар җырлыйлар иде».*

Әлеге уеннар турында Мазарбашы авылында яшәүче Гомәров Шәрифулла Гомәр улы белән Гомәрова Мәмфүсә Рәхимҗан кызы мәгълүмат бирде. Алар үзләре яшь вакытта уйнаган уенарны исләренә төшерделәр:

*«Без яшь вакытта Пар Кәбир дигән уен бар иде.*

*Кулымдагы йөзегемнең,*
*Исемнәре Пар Кәбир.*
*Сөясеңме шул кешене (исеме белән әйтәсең),*
*Җырың белән әйт тә бир.*

*Мактап җырлыйсың килсә, мактап җырлыйсың.*

*Без икебез ике урамда идек, ул вакытта телефоннар юк иде, мин Шәрифуллага болай дип җырладым:*

*Сандугачның баласына*
*Гөл яфрагы ашатыйк.*
*Икебезнең арабызга*
*Телефоннар ясатыйк.*

*Ике кеше сөлге башын тота, әйләндереп торалар. Такмак әйтәләр:*

*Гөр-гөр баса күгәрчен.*
*Күгәрчен кебек егетеңне (исемен әйтеп)*
*Төшләреңдә күрәмсең, –*

*дип әйтә дә, син такмак әйтеп шул сөлгене атлыйсың.*

*Алдым чыбык, киттем чыгып,*
*Кердем өйләренә.*
*Өйләрендә киштә,*
*Киштәләрендә шәл,*
*Шәлләре чуклы,*
*Сөйләмәгез юкны, –*

*дип әйтәсең егетең булмаса, булса – тагын мактап әйтәсең».*

*Мазарбашы авылында Гомәров Шәрифулла Гомәр улы (1933),*
*Гомәрова Мәмфүсә Рәхимҗан кызыннан (1933)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Бәрәңге районында да элек аулак өйләр уздырыла торган булган.

*«Аулак өйләр бездә элек бик күңелле була иде. Бер җирдә аулак өй булса, төшеп китәр идек, һәй шуда аулак өй дип. Бөтен нәрсәне уйнарлар иде инде анда, пута сугыш та уйнарлар иде, яулык биреш*

*тә уйнарлар иде, аннан тышка чыгып та уйнарлар иде. Үзебезчә бик күңелле булган.*

*Җырлыйк әле, җырлыйк әле*
*Барыбыз бергә чакта.*
*Озакламый таралырбыз,*
*Төрлебез төрле якка, –*

*дип җырлый идек.*

*«Алырым ата казлар, бирермен ана казлар» уйный идек.*

*Бөтенебез тезелер идек тә, бер-беребез артына, алырмын ана каз, бирермен ата каз дип әйтә идек, шуннан бер «каз»ны егетләр суырып алыр иде дә, шулай-шулай итеп чүпләп, артка тезеп барырлар иде. Монысында җыр җырламаслар иде».*

*Мазарбашы авылында Сабирова*
*Сания Сабир кызыннан (1934)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

*«Без кечкенә булганда да йөри торган идек, элек каз йолкулар була иде. Анда чыгып китеп төрле уеннар уйнау бар иде.*

*«Күз йомыш уены» дияләр иде. Күзне бәйләп куясың да инде, әйләнеп, кешене тотып йөрисең. Башкалар сиңа кул чабаклап җырлап тора, син шуны килеп тотасың.*

*Артка кулны куеп, кулга сугып уйный торган уеннар бар иде. Ул кеше карамый, аннан «кем сукты?» – дип сорыйлар иде. Янәшәдә кешеләр тора, шунда кулына суккан кеше ниндидер исемне әйтә. Отса инде, ул кешене тышка алып чыгып китәләр иде. Кызлар малайларны алып чыгарлар иде, шул парлар инде чыга торганнар иде»,* – дип искә алды Лажы авылында Галләмова Сания Касыйм кызы.

*Лажы авылында Галләмова*
*Сания Касыйм кызыннан (1934)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Портянур авылыннан фольклор ансамбле җитәкчесе Закирова Гөлфия Зөфәр кызы, үзләренең авылларында элек уздырылган аулак өй, каз өмәсе кебек йолаларны өлкәннәрдән сорап, шуңа таянып, авыл мәдәният йортында оештырылган каз өмәсе, исем кушу кебек чаралар турында мәгълүмат бирде.

*«“Чишмә” исемле фольклор ансамблен җитәклим. 1998 елдан фольклор белән кызыксынам.*

*Җырлый-җырлый өмәләрдә күңел ачабыз. Каз өмәсе, орчык бәйрәме кебек уеннарны оештырабыз. Анда җырлап та алабыз, чигү дә чиккән булабыз.*

*Бездә туй йоласы түбәндәгечә: кызны сорарга киләләр дә, кызны сорап китәләр, шул көнгә никах дип билгеләнә. Кыз ягыннан да туганнар, егет ягыннан да өстәлне әзерләп кунак итәләр. Мулла никах укый башлый, ризалыкларын сорыйлар. И аннан соң бирнәгә нәрсә бирәсең, дип сорый, егет кызга, кыз егеткә бүләк бирә. Алтын әйбер бирәләр. Кайвакыт егет кызга яулык бирә дә, кыз егеткә түбәтәй бирә.*

*Бу минем әбиемнең бирнәсе. Әби үзе начар семья баласы булмаган, баерак гаиләдән булган. Исеме Әхмәтгалиева Мәрфуга иде. Әбидән калган озын ашъяулык, чүпләмле сөлге бар иде. Аны әби аны миңа биреп калдырды.*

*Элек каз өмәсе уздыра идек, анда җырлар җырлана иде.*

*Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли*
*Өмәләрдә күңел ачабыз.*
*Ай-хай, дусларым,*
*Дусларым, дус-ишләрем,*
*Сез дуслардан аерылсам,*
*Ялгыз башым нишләрмен.*

*Исем кушу йоласы бәйрәмен дә уздырдык. Мулла белән киңәшләшеп.*

*Анда өй хуҗасы, әни кеше, килен, бала, бишек куеп бишектә бер бәбәй, димче хатын, кодагый кеше, ир кеше уйнады. Өй әзерләнеп куелды, бишек, өстәл, эскәмия, караватчигелгән әйберләр белән.*

*Әлли бәлли бәү итәр,*
*Кәҗә көтүгә китәр.*
*Кәҗә көтүгә киткәндә,*
*Улым симереп йоклап китәр.*

*Шушы җырларны җырлап, бәбәйне тирбәтеп мулла килеп керде. Утырышып дога кылабыз. Дога кылганнан соң димче хатын килеп керә. Ул да матур, әйбәт сүзләрен тели дә, әйдә балалар, ди, мулла, сез әзерме, әзер булсагыз уйлаган эшебезне тәвәккәллик, дия. Без әзер, дигәч, баланы бишектән алып караватуртасына мендәр куясың, шул мендәргә баланы кыйблага каратып саласың да, мулла азан әйтә. Сорый балагызның исеме ни исемле була дип, аннан колакларына өрә, азан әйткәннән соң. Синең исемең шул була дип,*

*исемен өч тапкыр әйтә. Муллага садака бирәсең дә, әти-әни бирә, йорт хуҗасы бирә, кодагый кеше бирә. Аннан бөтен кешегә утырып дога кыла. Дога кылганнан соң, бал-маеңны куеп, төшләреңне пешереп, паштетларны куеп чәй эчертәсең. Чәй эчкәннән соң ул йортка, йорт-җир өчен дога укып ала. Шуның белән бәйрәм тәмамлана».*

*Портянур авылында Закирова Гөлфия Зөфәр кызыннан (1965)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Экспедиция вакытында язып алынган кыска җырлар, дүртьюллыклар арасында татарлар яши торган башка төбәкләрдә җырлана торган традицион әсәрләр дә очрады.

Китәм диден, китәм диден,
Китәм диден дә киттен.
Мине генә чәчәк атмый,
Торган гөлләр күк иттең.

Зөлхәбирә көлтә бирә
Арбадан кибәннәргә.
Сер бирмәбез, баш имәбез
«Без матур» дигәннәргә.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Нургали.
Бер күрешеп сөйләшергә,
Дигән көннәр булгалый.

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Гайнандыр.
Тәрәз ачып карап кала,
Әйтер сүзе калгандыр.

*Куянавылда Фатыйхова Рәмлә Мөэмин кызы (1950),*
*Хәмидуллина Раузалия (1955), Мәүләкиева*
*Раймә Мөэмин кызыннан (1961)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Тал төпләренә утырдым,
Тал төпләре салкынга.
Тал да коя яфырагын
Миннән чыккан ялкынга.

Алма бакчасында үзем,
Гөл бакчасында күзем.
Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем.

Сулар алам, су алганда,
Беләгем талмас әле.
Ике яшь йөрәк бер-берсен, бәгърем,
Аңламый калмас әле.

Алсу була, гөлсу була
Җәй көнендә таң ату.
Сагынуларым шулкадәрле,
Мөмкин түгел аңлату.

*Мазарбашы авылында Усманов*
*Нурияздан Усман улыннан (1928)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Әнә килә машиналар,
Төягәннәр буш яшник.
Мәңгегә табылмаслык булып,
Югала икән яшьлек.

Аллар бәйлимен беләгемә,
Гөлләр бәйләмәсәм дә.
Әнием каргыш каргый күрмә,
Теләк теләмәсәң дә.

Агып китте алъяулыгым,
Агыйделдә юганда.
Бер кайгылар булмый икән,
Аналардан туганда.

Сагынам сезне, көтәм сезне,
Көтәм сезне өзлексез.
Каз бәбкәсе бик күп була,
Ул да кала берлексез.

Урамына таш куялар,
Ташкент дигән каланың.
Йөзенә сары коела
Күпне күргән баланың.

Аргы якның арышы,
Бирге якка карышы.
Әллә ата-ана каргышы,
Әллә Ходай язмышы.

Арсам, утырып ял итәм мин
Зур имән төпләренә.
Әнием риза булырмы,
Имезгән сөтләренә.

Гармун каешлары баскан
Ап-ак беләкләреңне.
Кабереңнән казып алырмын
Асыл сөякләреңне.

*Мазарбашы авылында Гомәров Шәрифулла Гомәр улы (1933)*
*һәм Гомәрова Мәмфүсә Рәхимҗан кызыннан (1933)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Андый ерак араларга,
Кошлар да барып җитми.
Көлемсерәп караулары
Күз алларымнан китми.

*Мазарбашы авылында Нотфуллина*
*Гәүһәрия Нотфулла кызыннан (1931)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Мәҗлесләрдә кара-каршы башкарыла торган җырларга Бәрәңге районында мисаллар аз булды.

Каршы ява, каршы ява,
Каршы ява карыгыз.
Без килдек тә, кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз.

Каршы ява, каршы ява,
Каршы ява карыгыз.
Без кунактан курыкмыйбыз,
Чакырсагыз, барырбыз.

*Портянур авылында*
*Мөхәммәтханова Нурзадә Шәрифулла кызы (1966),*
*Ваһапова Наилә Мансур кызы (1967)*
*һәм Фәйзрахманова Әлфия Мөхәррәм кызыннан (1965)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Эх дусларым, җыр башлыймын,
Күтәреп җибәрегез.
Авыр сүзләр ишетсәгез,
Үткәреп җибәрегез.

Өй артындагы алмагачка,
Басып сайрый сандугач.
Ул канатын кагып сайрый,
Минем кебек ялгыз булгач.

*Олыкыр авылында Шәйхетдинова*
*Кафия Әхмәтсафа кызыннан (1937)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Бәрәңге районында сабантуй алдыннан милли киемнәрне киенеп, атларны бизәп, ат арбасына утырып, гармун уйнап, җырлар җырлап бер өйдән икенчесенә кереп сабантуйга бүләкләр җыялар. Биредә әлеге күренеш «бәйге җыю» дип атала. Без Ирнур авылында бәйге җыюда үзебез дә катнаштык. Бәйге җыйганда гармунга кушылып, күбесенчә, кыска җырлар, дүртьюллыклар җырлана:

Атлар иярләдеңме,
Тайлар йөгәнләдеңме.
Сабантуе җитә диеп,
Бүләк әзерләдеңме.

Атлар килә, атлар килә,
Атлар килә бәйгегә.
Эх яшь чагым, юләр чагым,
Каласың ич мәңгегә.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җыр күңелне ача ул.
Җырлау күңелне ача ул,
Кайгыларны баса ул.

Аргы очтан бирге очка
Очып килә йомычка.
Бармас идем шул очларга,
Сөйгән ярым шул очта.

Ал матурмы, гөл матурмы,
Кайсысын яратасың.
Аласың да серемне,
Ятларга таратасың.

Ак каен кисмәдем лә,
Кисеп суын эчмәдем.
Мине бәхетсез итмәгез,
Мин бәхетсез үсмәдем.

Ал да тукыма, тектер пәлтә,
Язлар җиткәч киярсең.
Сал суларга, бирмә ятка,
Үзе төште диярсең.

Күгәрчен күкәй салмасын,
Салса да чыгармасын.
Ризык читкә язса язсын,
Туфрак читкә язмасын.

Китәм дисең, китәм дисең,
Казанда туктарсыңмы?
Бергә булган вакытларны
Исеңдә тотарсыңмы.

Шулай да, башкарылган җырлар арасында без үзенчәлекле бер көйгә башкарыла торган лирик җырны тыңладык. Башкаручылар искәрткәнчә, әни-әтиләреннән, әби-бабаларыннан отып алынган бу җыр кунакларда, туй мәҗлесләрендә җырлана икән.

Мин телим очырашырга,
Ә син ник килдең дисең.
Дөнья эшләрен калдырып
Ник килеп йөрдең дисең.

Белсәң иде уйларымны,
Ашаудан да калганымны.
Әллә чынлап та, әллә чынлап та,
Сөю килдеме.

Зәңгәр күктә калка ай да,
Күктә йолдыз булганда.
Миңа рәхәт синең белән,
Бергә басып торганда.

Ала алмыйм күзем синнән,
Көнләшәм беренче җилдән.
Телим, бәгырем, чәчләреңнән,
Сыйпап сөяргә.

Чәчләреңнән сыйпый-сыйпый
Күзләреңә карадым.
Зәңгәр күктә балкып янган
Йолдызларны санадым.

Синең белән соңлап кына,
Кайтып киләм тыңлап кына
Яфрак тавышын, кошлар сагышын,
Җилләр искәндә.

*Яңавылда Хәбибрахманов Илфат Габделәхәт улының (1962)*
*гармунда уйнавына кушылып, Мөхәммәтханова Нурзадә*
*Шәрифулла кызы (1966), Ваһапова Наилә Мансур кызы (1967),*
*Фәйзрахманова Әлфия Мөхәррәм кызының (1965) җырлауларын*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Шунысы да игътибарны җәлеп итте, бер үк җыр текстларын өлкәннәр башкарганда озын көйгә, яшьрәк буын башкарганда кыска көйгә җырлый. Моңа мисал итеп «Военкомат» (егетләрне армиягә озату) җырын китерергә мөмкин:

Военкомат ишек алдын
Таптамам, дигән идем,
Яшьләй сөйгән ярларымны
Ташламам, дигән идем.

Военкомат ишек алдын
Таптарга туры килде.
Яшьләй сөйгән ярларымны
Ташларга туры килде.

Китмә, поезд, китмә, поезд,
Бөтен кеше утырсын –
Яшьләй сөйгән ярларыңны
Ничек итеп онытырсың.

*Куянавылда Фатыйхова Рәмлә Мөэмин кызы (1950 елгы),*
*Хәмидуллина Раузалия (1955 елгы) һәм*
*Мәүләкиева Раймә Мөэмин кызыннан (1961 елгы)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Әлеге армиягә озату җырларын үзе 1976–1978 елларда Ростов-Донда армия хезмәтендә булган Гайсин Шәрифҗан да җырлап күрсәтте.

Бәрәңге төбәгендә җырга-моңга бай халык яши, дидек. Портянур авылында Фәйзрахманова Гөлфия Габделфәт кызы *«гармунда уйнарга кечкенә вакытта, әти абыйны өйрәткәндә, әти үзе уйнаганда өйрәндем»,* – дип искә ала. Хромкада татар бию көен, мариларныкын да уйнады, тальян гармунында авыл көен, кыска көйне уйнап, җырлап бирде.

Яшьләр дә җырга битараф түгел. Мазарбашы авылыннан Казанда мәдәният-сәнгать академиясен тәмамлаган Ирек Әхмәдуллин (1981) озын көйгә, моңлы итеп берничә җыр җырлады.

**Әнкәйгә**

Якты кояш булып балкыйсың син,
Карамыйча күргән хәсрәткә.
Ул борчулар күпме әрнү салды,
Йодрык чаклы гына йөрәккә.

Балаларың, әнкәй, назларыңнан
Сөелсеннәр туган таң саен.
Ана бәхетен татып озак яшә,
Бала борчулары язмасын.

*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Куянавылдан Гайсин Илнур (1992) хәзерге вакытта егетләрне армиягә озатканда, бәйге җыйганда җырлый торган җырларны башкарды:

Арыслан айга сикерә,
Каршысында тал булса.
Кайгырма, егет, кайгырма,
Газиз башың сау булса.

Әллә кайдан күренеп тора
Магистраль ташлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Калды ич Куян яклары.

Солдатларга аш бирәләр
Калай тәлинкә белән.
«Смирно», диеп кычкыралар
Калын тавышлар белән.

Әй, дусларым, беләсезме,
Без бит Куян яклары.
Башларымның төрле уйлар
Уйлый торган чаклары.

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз.

Алма бакча, челтәр капка,
Ачыла ике якка.
Аккош балалары кебек,
Төрлебез төрле якта.

Җырлагыз, дуслар, җырлагыз,
Авызыгызны йоммагыз.
Бергә чакта җырлап калыйк,
Һаман бергә булмабыз.

Военкомат калсын иде
Комиссарлары белән.
Армиягә барсаң иде
Сөйгән ярларың белән.

Поезд килә, поезд килә
Төтенен калтыратып.
Солдат дустым кайтыр әле
Медален ялтыратып.

*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Портчара авылында Мөхәммәтов Зөлкәрам Зәйнулгарәп улы (1961) үзе армиягә киткән вакытта җырлаган җырларны башкарды:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм армияләргә.
Мин киткәчтен, кемнәр калыр,
Сезне тәрбияләргә.

Әйдә, дуслар, чыгыйк кырга,
Атыйк кыр үрдәкләрен.
Солдат мескен үзе җуа
Карайган күлмәкләрен.

Зөлхәбирә көлтә бирә
Уфадан килгәннәргә.
Сер бирмәгез, баш имәгез,
«Без матур» дигәннәргә.

Су өсләре кертләч-кертләч,
Кертләч бетә яз җиткәч.
Солдат кайтыр хезмәт иткәч,
Кызлар кайтмый бер киткәч.

*Портчара авылында*
*Мөхәммәтова Земфира Ибраһим кызыннан (1965) һәм*
*Мөхәммәтов Зөлкәрам Зәйнулгарәп улы (1961)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Җор телле апа шаян уен җырлары да башкарды.

Чәч тараган тарагымны
Кыстырып куйдым ярыкка.
Сине сагынган саен мин
Чыгып карыйм сарыкка.

*Портянур авылында Закирова Гөлфия Зөфәр кызыннан (1965)*
*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Җырларның тагын бер төре – хатларга язып җибәрелгән җырлар, ягъни хат җырлары. Алар Олыкыр авылында яшәүче Шәйхетдинова Кафиядә бар иде. 2000 елның 22 апрелендә Рамил вафат булгач, 23 апрельдә Майрауза ападан килгән хатта язылган булган.

Көмеш тәңкә, талир тәңкә
Әби патша акчасы,
Мине белгән, мине күргән,
Бәхил булсын барчасы.

Бу дөньяда һичбер калмас
Әдәмнәрнең гәүдәсе.
Калса калыр истәлеккә
Гәүдәсенең шәүләсе.

Кафия Әхмәтсафа кызында Дилбәр апасы хатында язып җибәрелгән җыр да сакланган.

Сандугачның балалары,
Сайрап йөри көн буе.
Яшә рәхәт, күрмә михнәт,
Бөтен гомерең буе.

Миннән теләкләр шул сиңа,
Башың михнәт күрмәсен.
Гомерең буе рәхәт яшә,
Йөзеңнән нур сүнмәсен.

Сез торган як кайсы якта,
Алмас идем күземне.
Очып барган кош аркылы,
Әйтеп җибәр сүзеңне.

*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Мазарбашы авылыннан Гомәрова Мәмфүсә Рәхимҗан кызы (1933) әтисе сугышта вакытта аның белән хатта язышкан җырларны исенә төшерде.

Ак самовар борыннарын
Боруы читен икән.
Әтием, балам, синнән башка
Торуы читен икән.

Аклы ситса күлмәгемнең
Итәге челтәр-челтәр.
Әтием, балам, хатлар җибәр,
Ике бит кәгазь җитәр.

Татарский җиз комган,
Урыс барып кул юган.
Кайтасы килгән көннәр күп,
Кайтармыйлар, чукынган.

*А. Садыйкова һәм Л. Мөхәмәтшина язып алды*

Җырларны яшь вакытта истәлек дәфтәрләренә язып та саклый идек, дип искә алалар. Кызганыч, аларның күбесе инде бүгенге көндә сакланмаган. Элек җырлар язып барган дәфтәрне без Олыкыр авылында гомер итүче Кафия Шәйхетдиновада күрдек. Әлеге дәфтәр 1951 елда язылган. Биредә төрле темаларга караган җыр текстлары, шул чор яшьләре яратып башкарган, алар яшәгән чорның популяр булган җыр текстлары тупланган. Истәлек дәфтәрендә урын алган берничә җыр тексты:

### Гөлзар

Бөдрә чәчле, кыйгач кашлы,
Күкрәгендә ал-гөл бар.
Ал-гөл төсле, алсу йөзле,
Бигрәк матур кыз Гөлзар.

Ил шикелле шат күңелле,
Аңа ят кайгы, моң-зар.
Ялкын йөрәк, алсу бигрәк,
Шатланып яши Гөлзар.

Ул һәр эшне үрнәк эшли,
Ул бар ярышта узар.
Булдыклы кыз, данлыклы кыз,
Бигрәк мактаулы Гөлзар.

### Озату

Чулпан калка, ай бата,
Тулпар шартлый иде еракта.
Абыем китте шул якка,
Атланып Акбүз атка.

Вакытың булган чагында,
Язып җибәр сәлам хат.
Исән йөреп, исән кайт,
Сау бул, абыем,җиңеп кайт.

Кара урманны чыкканда,
Солы сал атларыңа.
Хат алышу, ярты кавышу,
Тилмертмә хатларыңа.

Алма чәчәген өзеп ал,
Күкрәгеңә кадарсың.
Бик сагынган чакларыңда,
Күкрәгеңә кадарсың.

*Язылды: 1951 ел, 17 февраль*

### Уңыш көенә

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр сарымсак.
Без үзебез грамотный,
Хат язарга тотынсак.

Электрик үтүк белән,
Үтүклимен керләрне.
Китап, газет, журнал укып,
Үткәрәмен көннәрне.

Өч трактор, өч сабан,
Буразнасы ун табан.
Тракторың эшли һаман,
Шуңа бигрәк куанам.

Әйдә, җаным, клубка,
Концерт була, биерсең.
Әткәң, әнкәң сораса,
Концерт карадык, диярсең.

Актыр пәке саплары,
Күктер пәке саплары.
Сөйгән ярым язу белми,
Килми сәлам хатлары.

Су буйларында басмада,
Бәләклим керләремне.
Сине уйлап, ямансулап,
Үткәрәм көннәремне.

Бер ат җиктем бер сабан,
Буразнасы бер табан.
Үсеп җиттеләр бер заман,
Үскәчтен бигрәк яман.

Әйдә ямьле су буена,
Гармун уйныйм, биерсең.
Әткәң, әнкәң сораса,
Кыз карадым, диярсең.

Хәзер инде кара көннәр
Бик еракта калдылар.
Укый-яза белмәүчеләр
Грамотный булдылар.

## Сиңа

Кемнәр өчен матур тау башында,
Тәмле булып кызарып пешә бөрлегән.
Бөрлегәндәй алсу иреннәрең,
Кемне сагына, әйтче, бергенәм.

Кемнәр өчен алма бакчасында,
Сандугачлар матур итеп сайрый.
Сандугачтай синең йөрәгең,
Кемнәр өчен шулай кайгыра.

*Язылды: 1951 ел, 18 февраль*

## Карабай көе

Әй, апакайларым,
Әй, җиңгәкәйләрем.
Кышын клубта йөргәлә,
Эшләп үтәр җәйләрең.

Хатын-кызлар инде аңлы,
Якты көнне ул алды.
Котыртучы димче карчык,
Мәңгегә артта калды.

Бәрәңге районында яшәүче татарларның җырларын өйрәнгәннән соң, йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: биредә уен җырлары, бию такмаклары, үзенең махсус көе булмаган һәм төрле көйләргә башкарыла ала торган дүртьюллыклар киң таралган. Бу күренешне җырларның халык тормышына, аның уй-кичерешләренә үтә якын торуы белән аңлатырга мөмкин.

Җырларны дәфтәрләргә теркәп саклаучылар, сүзләрен күңелләрендә йөртүчеләр һәм уен коралларында уйнап башкаручыларның күп булуы, милли уеннарны, йола-бәйрәмнәрне дә югалтмыйча саклаулары куанычлы күренеш. Алар арасында төрле буын кешеләре булу, өлкәннәр белән бергә мондый төр иҗатка яшьләрнең дә тартылуы күңелне сөендерде. Димәк, Бәрәңге төбәгендә яшәүчеләр үз теленә, милли җәүһәрләренә кадер-хөрмәт белән карый, мөмкин булганча аларны сакларга тырыша.

Түбәндә Мазарбашы авылында яшәүче Һадиева Гәүһәрия апа (1928) язмаларыннан кыска җырларны тәкъдим итәбез.

Сандугачым, нигә болай
Сайрамыйча китәсең?
Тормыш безгә аерылырга
Кушкан, ни хәл итәсең?

Сандугачым, сайраганда
Канат кагасың икән;
Вакыт җиткәч, аерылуны
Сизми каласың икән.

Сандугачым, сыйрамыйсың,
Баскан талың сындымы?
Тормыш безгә аерылырга
Шулай карар кылдымы?

Сандугачның сайравына
Ямансулама, дустым,
Синең алларыңа басып,
Үзем сайрарга куштым.

Сандугачым, ник сайрыйсың,
Сайрама, дигән саен?
Күз алларымда торасың,
«Йә, Алла! » дигән саен.

Сандугачлар матур сайрый,
Моңлы сайрый урманда;
Мин бик бәхетле идем
Икәү бергә булганда.

Сандугачлар моңлы сайрый
Гөлләр чәчәк атканда;
Төнлә төшләремдә күрәм,
Югалтам таң атканда.

Сандугач сайраган була,
Тешен кайраган була;
Такыр басу ябалагы
Кызлар сайлаган була.

Әйдә, дустым, барасыңмы
Мин барган базарларга?
Жәлләмәдең, салып киттең
Кайнаган казаннарга.

Аерылдык, якын дустым,
Аерылдык бит инде,
Сабагыннан өзелеп төшкән
Гөл чәчәге шикелле.

Аерылабыз инде, дустым,
Аерылабыз, мин китәм.
(Аерылганнар сабыр итә,
Дип кенә сабыр итәм).
Бәлки әле бер күрешербез,
Дип кенә сабыр итәм.

Аерылабыз инде, дустым,
Аерылганчы бер күрим;
Син аерыл да рәхәт яшә,
Мин аерылыйм да үлим.

Аерылганда кулың бирдең
Син миңа салкын гына,
Салкын кулың йөрәгемдә
Тудырды ялкын гына.

Исемдә әле аерылганда
Кулларыңны биргәнең,
Мин сине мәңге онытмам,
Син дә онытма, дигәнең.

Бакчаларда гөлләр өчен
Аерым-аерым түтәлләр,
Без аерылдык, ләкин болай
Аерылмасын бүтәннәр.

Минем чәчем уңга сибелә,
Сулга да сибелерме?
Минем күңелем сине уйлап,
Белмим, бер сүрелерме.

Әйдә, иркәм, барасыңмы,
Мин барам кар суына,
Карлы-бозлы сулар эчәм
Йөрәгем ярсуына.

Йөрәгемнең януына
Эчәм бадъян майлары,
Бадъян майлары да басмый,
Яна торган айлары.

Зәңгәр күзем, бик яратам,
Бик сагынам мин сине,
Әз вакыт өчен танышып
Уйларга салдың мине.

Сандугачның, мескенкәйнең
Сайрамаган көне юк,
Сәлам әйтеп җибәрергә
Сандугачның теле юк.

Яшьлегемдә бер яр сөйдем,
Әле һаман үзәктә.
Чит җирләрдә ятып (үлеп) калды,
Табалмадым эзләп тә.

Кил, бәгърем, янымa утыр,
Лимон чәйләре эчерим,
Синнән алып, яшь күңелемне
Ничек ятка күчерим?

Өй эчендә мичләр яна,
Яна да күмерләнә.
Синең кебек якын дусны
Оныта алмам гомергә дә.

Әйдә, дустым, алып барыйм
Мәйданга, киендереп,
Бер башлагач, нигә ташлыйм,
Дошманнар сөендереп?

Чишмәләрдән су алганда
Тулмады чиләкләрем,
Агымсулар да туктаган,
Син дә шулай булма әле.

Синнән аерылганнан бирле
Гел боек күңелләрем,
Һаман шулай сине сагынып
Узармы гомерләрем?

Уза гомер гел моңланып,
Уза гомер, әз кала.
Әз калган гомерләрне дә
Кайгылар чолгап ала.

Башларымдагы эшләпәм –
Битләремә күләгә.
Төшләремә дә кермисең,
Сагынганга күрәме.

Матур җылы җәйләр җитте,
Исә җил талгын гына.
Төшләремдә бергә булам,
Уянсам ялгыз гына.

Бик сагынам сине, бәгырем,
Бик сагынам, белмисең,
Бик сагынган көннәремдә
Төшемә дә кермисең.

Бик сагынам сине, бәгырем,
Бик сагынам мин сине,
Әз вакыт өчен танышып,
Уйларга салдың мине.

Бакчаларда чәчәк ата
Роза гөлем, үз гөлем;
Алдавычлы мәхәббәткә
Ышанма, яшь күңелем.

Биек тауның башларында
Землямирлар җир бүлә;
Тигез мәхәббәт яшәми,
Йә аерыла, йә үлә.

Граммофон тәлинкәсе
Төрле көйгә әйләнсен,
Мәхәббәтең тигез булса гына
Чәчең бәйләнсен.

Алсу була, моңсу була
Җәй көнендә таң ату;
Сагынуларым шул кадәр,
Мөмкин түгел аңлату.

Синең апаңның мендәре –
Казның мамык йоннары,
Шул мендәрдә икәү бергә
Яткан идек элгәре.

Автомобиль кызу төшә
Кукмара үрләреннән;
Үлсәм дә, сине эзләрмен,
чыгалсам гүрләремнән.

Матур ки, бәгырем, матур ки,
Матур кияр чакларың.
Сайлап сөй, бәгырем, сайлап сөй,
Сайлап сөяр чакларың.

Йөзләреңә бик килешә,
Аеры булгач иягең,
Кай җирләреңдә бар икән
Мәхәббәтле сөягең.

Алмалар өзәр идем дә
Җепләргә тезәр идем,
Үз үзәгем кебек итеп
Аныкын да өзәр идем.

Аерылулар үкенечле,
Аерылулар бер көнлек;
Аерылгач, кавышуга
Булсын иде мөмкинлек.

Тальян гармунга җырларга
Безнең күкрәк киң әле.
Кайсы чәчәккә кунсак та
Өзәргә мөмкин әле.

Агыйделгә нигә төштем,
Нигә суларын эчтем,
Нигә туып, нигә үстем,
Дигән көннәргә төштем.

Агыйделгә суга төштем,
Гиздем суның салкынын.
Башым яшь булса да, күрәм
Ходаем кушканнннарны.

«Сандугач» белән «Асылъяр» –
Минем сөйгән көйләрем;
Бәгърем, сине оныта алмам,
Сагынып-сагынып сөйләрмен.

Кулымдагы балдагымның
Исеме Габдерахман;
Ике бит урталарына
Чәчелеп чәчәк аткан.

Ап-ак булып кырау төшкән
Кадерле гөлләремә.
Көн өстенә көн ялгана
Сагынган көннәремдә.

Сагынганда айга кара,
Мин дә айга карармын,
Күз нурларың айда калса,
Шунда эзләп табармын.

Сахраларга очасыңмы
Син назлы, күбәләгем?
Сине сөям, сине көтәм,
Син генә теләгәнем.

Тальян гармун тавышлары
Моңайта башларымны,
Исеңдә тот аерылганда
Түккән күз яшьләремне.

Бик күп авырлыклар күргән
Йөрәгем түзәр әле,
Күз яшьләрем дәрья булса,
Балыклар йөзәр әле.

Тулган айларга карыйм мин,
Ай түбәннән тәңкә күк;
Чит җирләрдә ялгыз яшим,
Аерылган бәпкә күк.

Яшь әле син, шат әле син,
Күкрәгең тулы чәчәк,
Гомер озаклыгы белән
Ул чәчәкләр шиңәчәк.

Чит-чит, дидем, читкә киттем,
Чит иде теләкләрем.
Хәзер яшим чит җирләрдә,
Өзелә үзәкләрем.

Сабыр ит, бәгърем, сабыр ит,
Сабыр төбе – саф алтын;
Мин үзем дә йөзләремне
Сабыр итми саргайттым.

Ак бәйлиләр, гөл бәйлиләр
Талган беләкләремә.
Сабыр итәргә кушалар,
Түзмим йөрәкләремә.

Автомобиль кызу бара
Үрләргә менгәндә дә;
Сине генә өзелеп сөйдем,
Диярмен үлгәндә дә.

Казаннардан алып кайттым
Асылмалы зур көзге;
Якты йолдызлар сүнгәнче
Уйлап ятам мин сезне.

Тимер юлдан поезд килә,
Артына вагон таккан.
Ул үзенә бер яр тапкан,
Неужели мин дә тапмам.

Алма бакчасына керсәм,
Кош кунган тирәгенә;
Ефәкләр булып уралдың
Минем яшь йөрәгемә.

Муен бавым муенымда
Алсу күбәләкләр белән,
Мин дә яшим бу дөньяда
Өзек өметләр белән.

Аллы-гөлле чәчәкләр
Бар резинка тупларда;
Аллы-гөлле гөлчәчәгем,
Янасың бит утларда.

Барган чакта карап бардым
Вагон тәрәзәсеннән;
Теләк кабул була икән
Чынлап теләгәченнән.

Шәһәрләргә барган чакта
Туктыйм станцияләрдә,
Синнән башканы сөя алмыйм,
Сөй, дип кыстасалар да.

Исәнлекләреңне белсәм,
Яныңа барыр идем,
Син бит минем өзелеп сөйгән
Бердәнбер ярым идең.

Әйтик әле, җырлыйк әле
Безнең авыл көенә;
Күләгәләрен күрсәм дә,
Күңелләрем сөенә.

Минем иркәм китеп барды
Минзәлә юлларыннан,
Теләгәннәрен сөйсен, дип
Җибәрдем кулларымнан.

Кулъяулыкларымны юдым
Шексина күлләрендә;
Хак Тәгалә ни кушкандыр
Алдагы көннәремдә.

Яшел башлы, яшел түшле,
Кайдан алдың бу кошны?
Тагилларда узды җәем,
Кайда үткәрермен кышны?

Әнә килә автомобиль,
Төягән маллар гына;
Без җете кызыллар түгел,
Тик алсу – аллар гына.

Тәрәзә төбемдә гөлләр,
Гөлфани гөлләр саный.
Сөбханалла, күз тимәсен,
Дип кенә карыйм, җаным.

Бик сагынам, өзелеп сагынам,
Сагынам син, гүзәлемне,
Бик сагынган көннәремдә
Белмимен түзәремне.

Аерылабыз, алма битем,
Аерылабыз, исән бул.
Бәхетләрең шулай булгач
Аерыласың икән ул.

Башларымда төрле уйлар,
Шат түгел күңелләрем,
Һаман шулай моңсуланып
Узармы гомерләрем?

Гармунчылар гармун ала
Гармунда ярышырга,
Гармунчылар моңлы була,
Ярамый танышырга.

Аклы күлмәкләр киямен,
Яратып кимәсәм дә;
Тар сулуларым киңәя,
Сагынып сөйләсәм дә.

Стенадагы сәгатем
